Татарстан язучылар берлегенең Чаллы бүлеге
Яр Чаллы шәһәре дәүләт педагогия университеты
Яр Чаллы шәһәренең Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе
Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”

# *“Шагыйрь һәм драматург, прозаик һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим исемендәге I региональ укулар”*

*(региональ укуларның материалларыннан электрон җыентык)*



**Яр Чаллы шәһәре,**
**3 нче май 2018 нче ел**

**Җаваплы редактор:** А.И.Гыйззатуллина

**Төзүчеләр:** А.И. Гыйззатуллина, Д.М. Гилманова

**Электрон ресурслар:** укуларда катнашучыларның фәнни-гамәли эшләре

“Шагыйрь һәм драматург, прозаик һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим исемендәге I региональ укулар”ның электрон җыентыгы, ТР, Яр Чаллы шәһәре, 3 нче май 2018 нче ел/ Яр Чаллы шәһәре Муниципаль бюждет гомуми белем бирү учреждениесе “41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”. 164 бит.

**Эчтәлек**

1. **Әмирова Л.Ф.** Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 41нче урта гомуми белем бирү мәктәбе Айдар Хәлимнең шигъриятенә анализ (Айну, яки тәнкыйди чигенү( 1971-1981)).
2. **Әхмәтгәрәева Г.И.** Яр Чаллы шәһәренең 25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе.“Мине яратмаска мөмкин – талант өчен. Мине яратырга мөмкин – талант өчен”.
3. **Багманова И. И.**,Яр Чаллы шәһәренең “30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе”.РИФАТ СӘЛАХ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТЕЛ - СҮРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ.
4. **Батдалова С. Ә.** Яр Чаллы шәһәре, 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе“Рәхмәт халкым, хак язмышым өчен. Үз телеңне бирдең иң элек”.
5. **Вагыйзова Г. Н.** Яр Чаллы шәһәренең МБГББУ “ 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” Айдар Хәлим иҗатында “канатлы сүзләр.
6. **Валиева Г. М.,** Яр Чаллы шәһәренең, 41нче урта гомуми белем бирү мәктәбе. АЙДАР ХӘЛИМ – ДРАМАТУРГ.
7. **Вәлиева З. Н.** Мөслим муниципаль районы Дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе “Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен “Түбән Табын мәктәп – интернаты”, Лилия Садриева лирикасының кеше күңеленә тәэсир итү көче.
8. **Гайнетдинова А. Р.** Яр Чаллы шәһәренең “49 нчы кадет мәктәбе” муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе, Күңелне кузгаткан моң.
9. **Галимуллина Г. М.** Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ.
10. **Гарипова Г.Ш. Яр Чаллы шәһәре** “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” , Биктырышлар бик кирәк. (Фәнни-методик эш. )
11. **Гәриева Г. В.** Яр Чаллы шәһәренең 49 нчы кадет мәктәбе, Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре**.**
12. **Гилмуллина Л.С.** Алабуга шәһәренең 6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Рәхмәт халкым, хак язмышым итеп Үз телеңне бирдең иң элек (Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы).
13. **Гыйззәтуллина К. М.** Яр Чаллы шәһәренең 45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы “Биктырыш” әсәренә кыскача анализ.
14. **Гыйльфанова Ф.М.,** Яр Чаллы шәһәре МАГББУ «Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат». Галимҗан Гыйльманов шигъриятенең тәрбияви әһәмияте.
15. **Закирҗанова Л. М.** Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет

гомуми белем бирү учреждениесе 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Айдар Хәлимнең

«Өч аяклы ат» повестендә Кәбир образы.

16. **Закирова Р.А., Муллагалиева Х.М**. Менделеев муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Гимназия №1”, 9нчы сыйныфта

“Бибинур” фильмы буенча үткәрелгән дәрес эшкәртмәсе.

17. **Зиннәтуллина А.С**. Яр Чаллы шәһәренең ДБГБУ “Н.Кайманов исмендәге кадет мәктәбе”

Экраннарда әдәбият дәресе.

18. **Ибатуллина Ф. Ә.,**Менделеевск шәһәренең 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Фәнил Гыйләҗев шигырьләрендә Тукай образы
19. **Каюмова Г.Р.** Яр Чаллы шәһәре 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Бүгенге көн татар киносының торышы.
20. **Корбанова А. И**, Яр Чаллы шәһәренең 52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кинолардан файдалану (А. Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәре буенча).
21. **Кутуева Р. М.** , Г.С.Боровиков исемендәге 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү

мәктәбе, Кино ул - тәрбия чарасы.

22. **Латыпова Э. Г.** Яр Чаллы шәһәре13 нче мәктәбе, “Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин иҗатында милләт язмышы”.
23. **Мавлеева Р.М.** Менделеев шәһәре, 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе

    Балалар өчен язылган шигъләренең үзенчәлекләре
24. **Мингалеева Р. Ә.** Чаллы шәһәре “51 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”,Кайнар йөрәкле әдип
25. **Минигареева А. М. ,** Яр Чаллы шәһәренең 18 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, А. Хәлимнең “Өч аяклы ат” повестенда яшь кешенең характеры формалашу.
26. **Миниешаехова Ф.Д.** Яр Чаллы шәһәре, 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе , Роберт Миңнуллинның татар балалар поэзиясенә алып килгән яңалыгы
27. **Минсадыкова Р.Ф.** Яр Чаллы шәһәре «33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», Дәресләрдә татар кино һәм спектакльләрен куллану буенча тәҗрибә.
28. **Мөхәмәтшина Г. М.,** Яр Чаллы шәһәре, 37 нче мәктәп, АйдарХәлим поэзиясе һәм прозасы.
29. **Нафикова А. Э.** ГБОУ «Нижнетабынская школа-интернат для детей с ОВЗ» РТ Муслюмовский район Д.Нижний Табын . “Рәхмәт халкым, хак язмышым итеп Үз телеңне бирдең иң элек” (Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы)
30. **Нурисламова Э. Ә.** Яр Чаллы шәһәренең М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясе, АЙДАР ХӘЛИМ ШИГЪРИЯТЕНДӘ АНА ОБРАЗЫ.
31. **Сабирова Г.Ш.,** Яр Чаллы шәһәре, «41 нче урта гомуми белем биру мәктәбе»,Әлфия Ситдыйкова иҗатында туган як темасы.
32. **Сабирянова Р.Н..** Әлмәт шәһәренең 12 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ ПОЭЗИЯСЕ ҺӘМ ПРОЗАСЫ.
33. **Салахова И. Х.** Яр Чаллы шәһәренең 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе,Биктырыш “Әлифба” укый
34. ( Айдар Хәлим һәм башка татар шагыйрьләренең иҗатында бүгенге көн чагылышы)
35. **Салихова** Г.А.Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе, «Татар дөньясы – операсыз һәм балетсыз яши алыр, ә киносыз яши алмаячак» (М.Гыйләҗев)
36. **Сафина Ф. С.** Яр Чаллы шәһәре МБГББУ “54 нче гимназия, Айдар Хәлимнең чәчмә әсәрләре (прозасы).
37. **Сәлимҗанова К.Г.,** Яр Чаллы шәһәренең “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАШКА ШАГЫЙРЬЛӘРНЕҢ ИҖАТЫНДА БҮГЕНГЕ КӨН ЧАГЫЛЫШЫ.
38. **Сәхәбиева А.Г.** Яр Чаллы шәһәренең 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Туган телебезне саклыйк!
39. **Смирнова Г.Р., Садыкова А.Н**. Менделеевск шәһәренең 1 нче гомуми белем бирү мәктәбе
    Татарстанда һәм Башкортстанда милли матбугат: “Ватаным Татарстан” һәм “Кызыл таң” гәзитләрендәге мәкаләләрне чагыштырма аспектта өйрәнү тәҗрибәсеннән.
40. **Ушакова Г. Г.**Яр Чаллы шәһәре 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Айдар Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. (А.Хәлим иҗаты турында башка язучыларның фикерләре)
41. **Хаертдинова Л. А**.Яр Чаллы шәһәре, “41 нче гомуми белем бирү мәктәбе”, Сирень Якупова иҗатында туган як мотивлары.
42. **Хаҗиева Р. Х.,** Яр Чаллы шәһәренең “30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе” Татар әдәбияты һәм кино сәнгате (Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте һәм фильмы мисалында)
43. **Хамаева Г.Ә., Рәхмәтуллина Ч.Х.,** Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбе,

Кино һәм Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәрен өйрәнүгә методик киңәшләр.

44. **Ханова А.И.**– Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбе, Вакытлы матбугат – рухи азык чыганагы (“Мәгариф” журналы тарихына күзәтү).
45. **Харисова Г. С.**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», А.Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. А.Хәлим иҗаты турында башка язучыларның фикерләре.
46. **Хуҗәхмәтова К. Н.** Яр Чаллы шәһәренең “Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 24нче гомуми урта белем бирү мәктәбе, Йолдызларга үрелеп яшә (Кадрия Наил кызы Хәлилова иҗаты буенча)
47. **Чанышова Р. К.** Яр Чаллы шәһәренең 53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Кино сәнгатенең укыту-тәрбия эшендәге роле.
48. **Шаева В. М.** Мөслим районы Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ “ӨЧ АЯКЛЫ АТ” ӘСӘРЕНДӘ МИЛЛӘТ ФАҖИГАСЕ.
49. **Шакирова Р. С.,** Яр Чаллы шәһәре, Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернаты,АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАЛАЛАР ТӘРБИЯСЕ.
50. **Шәйхуллина З.Н.** Мөслим районы Мари Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе”Шагыйрь Рифат Сәлах шигырьләрендә әхлак тәрбиясенең чагылышы.
51. **Шиһапова А.Р.**.Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “ 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”, АЙДАР ХӘЛИМ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРИ ЛЕКСИКАНЫҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ .
52. **Фатыйхова Ә. Ф.** Яр **чаллы шәһәре, “49 нчы кадет мәктәбе” муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе. Бүгенге көн яшь шагыйрьләр иҗаты**

**Әмирова Л. Ф.**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**41нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

**Айдар Хәлимнең шигъриятенә анализ**
**(Айну, яки тәнкыйди чигенү( 1971-1981)).**

Иҗатының бу этабында шагыйрь эпик әсәрләр – поэма һәм шигъри хикәят жанрында аеруча актив эшли. “Печән чапканда” (1971), “ Палестина” (1979), “Ул елда” (1980 -1981), “Стәрлебаш урманнарында”(1981), “Мөсаббиха әбигә хат” (1981), “Яралы бөртек” (1981-1983) һәм башка әсәрләрендә кеше язмышы милләт язмышы белән тәңгәл куела, язмышны заманга, заманны язмышка бәйләп, шәхестә шәхессезлек тәрбияләүнең антигуманистик проблемасы алгы планга чыгарыла. Заман ниндидер күктән төшә торган нәгъләтле язмыш түгел, заманны шәхес үзе тудыра:

Айныдым да, җирнең сазлыкларын
Яндырып, йөзләргә теләдем.
Яндырам дип, ешрак үзем яндым,
Шунда тынгы тапты йөрәгем...
Сау бул, идеал!
Үз алламны үзем
Аударды да төштем упкынга-
Каспий белә...
“Ярыймы соң, исәр?!”
Мине ярга бәргән дулкыннар...
Бугазымнан үлем кармаганда
Курыкмадым, ләкин чигендем.
Мин үземдә кешеләр йөрәген
Яшәртер көч барын
Шунда гына, сеңлем, сизендем!..

( Печән чапканда)

Ул тормыштан яңа эчтәлек, яңа эчтәлектән яңа ритмнар эзли.

1946.
Син- ятим урам.
Үзәккә үтеп сызгыра,
Сызгыра буран.
1946.
Инде төшенәм:
Боздан күгәргән тәрзәгә
Башак төшерәм.

(“Ул елда”)

Ул космик телескоптан карап бөртек эчендә дә галәми көрәш күрә. Бөртек эчендә - татар авылы. Бил бөгеп яшәүдән тыш, анда башны күтәреп яшәү дә бар икән. Поэманың

төп ритмик чарасы итеп тугыз иҗекле ике юллык сайлана. Гүя бөртек эчендәге яшел төкләр- хлорофилл гаскәрләре маршта үтә:

Нәрсә күрдем бөртек эчендә?
Төкләр кайный җиде төсендә!
Тетрәнеп ирексез ирекtә,
Җир-су кушыла интим берлектә!
Тыныч давыл, дөрес өермә-
Бөртекле бул, күкрәк киермә!
Анда байлык исәп-хисапсыз,
Анда халык- галим китапсыз.
Синдә, бөртек, атом таркала,
Көлеп үлә, елап ярала!
Яшел сәхра, чагу ашъяулык,
Синдә эшләмичә ашау юк.
Электрон-утлы кисәүләр
Тормыш ташый космик мичәүдә...

(“Яралы бөртек”)

“Стәрлебаш урманнарында” поэмасында сугыштан соңгы “кичә генә фашизмны җиңгән” авылда йорт тергезү өчен “палищщиктан качып” бүрәнәлек агач урлаучы үсмерләр сурәтләнә. Соңыннан “торгынлык чоры” дип аталачак җитмешенче-сиксәненче елларда “кадрлар тәрбияләү” һәм кешене үстергән булып “рухи үстерү” поеманың төп идеясен тәшкил итә. Билгеле, “урлашканда рифма эзләп” торып булмый. Әсәрнең технологик сурәтләү чарасы итеп ирекле шигырь – эчке рифмалар белән баетылган верлибр алына

Кит ары, калма аста, яуда үлгән әтиләр сыман,
Гөрселдәп ава агачлар!..
Кәүсәнең очы, чыбыркы сыман яшен шартлатып,
сылана җиргә,
Сабый яфраклар көче барынча,
Аз гына дерелди дә - агач җан бирә,
Үлә әле генә безнең белән
Киләчәккә очып барган
Яшел ябалдашлы Жанна д Арк һәм Спартаклар!..
Кичке шәфәкъка өстәлә корым,
Кояшның йокысыз кызарган күзенә кадала каен чыра!
Тәләкә Габдрахманы исә- түбәтәйле бурлак-
Аңа алтмыш биш, безнең дүртебезгә әле илле дә юк,
“Бәдавам көйли-көйли, үткер балтасы белән
Әле генә киләчәккә очып барган
Бу урман көрәшчеләренең канатларын туный,
Яшь агач- инде пеләш, ул чын бүрәнә,-
Абруйлы, юан, тәккәббер, иң мөһиме- шома һәм шыптагай,
Шулай
Балта ирегe астында бүрәнә яшәргә өйрәнә!..

(“Стәрлебаш урманнарында”)

Бу чорда шагыйрь үзенең киң билгеле лирик әсәрләрен тудыра. “Мәхәббәттән язмыш башлана”, “Туган йорт тупсасында”, “Әнәч авылы урманында”, Ай туа, туа иркенләп...” кебек тирән психологик, “Каз йолкыйлар кызлар”, “Шәл бәйлиләр кызлар”, “Урнаш”, “Кыярга төшкән малайлар турында баллада” кебек халыкчан, юморга бай шигырьләр Дим-Өязе елгалары бассейны, Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгында яшәгән татар-башкорт халыкларының рухи асылын, милли характерын ача. Кавказда язылган “Кул яссуы”(1979-1980) гөләндәменә авторның бу чордагы эзләнүләре җыелмасы итеп карап булыр иде. Аларда сурәтләү чаралары кырыслана төшә, буяуларның иң кирәк, иң

нечкәләре генә сайлап алына. Гомумән алганда, лирик каһарман гел сагына: гүя ул озак еллар туган ягыннан читтә яшәп чит илдән кайткан мөһаҗир-эмигрант, туган җирен беренче мәртәбә күрә һәм шуңа да “ туган җирендә туган җирен сагынып яши”. Илнең һәм халыкның ирексез, дәүләтсез булуын көчәйтү өчен ул шигырьләрендә “туган җирдә туган җирне сагынып яшәү” тенденциясен махсус көчәйтеп бирергә тырыша.

Ай. Кунакчыл, вай, кунакчыл
Безнең як.
Телендәге сүзе татлы,
Йөзе пакъ.
Алтын табадай ай кунгач
Талларга,
Аш күтәреп бара таллар
Таңнарга.
Шул чак Өязегә чык та,
Учак як.
Өянкеләр йөгреп килеп
Кочаклар...
(“Ай, кунакчыл...”)

Автор бик еш үз иҗатыннан канәгать булуын әйтә. Бу ниндидер позага басу, кыйналу түгел. Бу хакта ул йә мыек астыннан елмаеп, йә ачыргаланып яза. Әле иҗатының башында ук:

Үзем яшь, үзем пеләш, яңа чыга сакал-мыек,
Җырларым нәкъ каен суы- үзе зәңгәр, үзе сыек,

дип язса, җитмешенче елларда ул үзен кызгану белмичә камчылый:

Язганым күп, күбесе чүп, җансыз корама кылдан үтми,
Һәр шигырьдә үлеп тереләм, әмма көмешем төшеп бетми!
Төшеп бетми! Язганымда телимен мин тик бер нәрсә:
Иртән чәчкән кичкә шытсын, кыш булмасын ел әйләнә!..
(“Мендәрле кул чишмәсе”)

Сиксәненче еллар башына Айдар Хәлим баллы мактаулар торгынлыгына кереп баткан илнең һаман да “болай бара алмаячагына” тәмам инана һәм, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып драматургиядә, публицистикада һәм шигърияттә, үзе әйтмешли, “Горбачевлар тизрәк килсен өчен” ачыктан-ачык “диссидентлык” көрәшенә чыга. Үзе язганча, “тарихның кирәк кешесен һәрчак табуына” җаны-тәне белән ышанган әдип, шулай итеп, сиксәненче еллар башыннан үз иҗатының өченче этабына керә.

**Әхмәтгәрәева Г.И.**
**I кв. категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

## “Мине яратмаска мөмкин – талант өчен
## Мине яратырга мөмкин – талант өчен”

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын...
Габдулла Тукай

Бөек шагыйребез әнә шулай дигән. Халыкны сөйсәң, халыкның дөньясын яратсаң, хезмәтеңне, иҗатыңны халыкка багышласан, үзең дә халкың тарафыннан сөелерсең, халыкның мәхәббәтен казанырсың.

Һәрбер халыкның аерым бер мәхәббәт белән яраткан язучылары, драматурглары була. Иҗат кешесенә булган мондый зур ихтирам әлбәттә халыкның иң талантлы

улларына, кызларына  гына һәм, әйтергә кирәк, бик сирәгенә эләгә. Бүгенге көндә аларның иҗатын өйрәнүе актуаль дип таптык, шуңа күрә фәнни-эзләнү эшен татар халкының олы шәхесләреннән берсе – атаклы язучы А.Хәлимне алдык. Максатыбыз: Айдар Хәлимнең тормыш юлына, эшчәнлегенә күзәтү ясау, анализлау.

Эшебезнең максатыннан чыгып төп бурычлар билгеләнде:

1. Айдар Хәлимнең тормыш юлы белән танышырга;
2. Ижатын тирәнтен өйрәнергә һәм халыкка танытырга.

Хезмәттә анализлау методын кулландык. Теоретик база туплаганда газета-журналларда басылган мәкаләләргә, аның белән бергә эшләгән, яшәгән кешеләр белән аралашуга, архив материалларына таянып эш ителде. Интернет материалларына чагыштырмача анализ ясалды.

Бу эшнең фәнни яңалыгы шул: материалны әдәбият дәресләрендә, газеталар чыгарганда кулланырга мөмкин.

Айдар Хәлим татар шигърияте , татар прозасы, татар әдәби-эстетик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшләүче әдип. Шагыйр буларак аның беренче китабы 1969 елда Казанда “Беренче карлыгачлар» сериясендә  басылып чыга. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы,ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик,  лирик-публицстик шигырь цикллары белән, эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары “Беренчеләр”, “Ул елда” “Өмә”, “Печән чапканда”, “Набат белән Нәфисә турында хикәят”, белән билгеле. Шагыйрьнең поэтик әсәрләре “Йөрәк ташы”, “Милли шигырьләр”, “Тилергән сиреньнәр” җыентыкларында урын алган.

Пьесаларыннан “Җан – чишмә”, “Пәри туе” әсәрләреБашкорт дәүләт академия театрында уңыш казаналар, ә балалар өчен язган “Биктырыш” исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.

Айдар Хәлим проза өлкәсендә дә уңышка ирешә. Аның “Өч аяклы ат” повесте, “Казыктагы тальян” новелласы, “Татар вакыты” исемле романы бүгенге татар прозасының йөзек кашы.

А.Хәлим прозасы-  яшәешебезнең көзгесе, ваемсызлык йокысына талган милләттәшне уятырга теләү идеясе әдәби формада чагылыш таба. А.Хәлим безнең тормышыбызның аналитигы, татарның саф сыйфатларын яратып тасвирлаучы, милли рухның югалуына әрнеп язучы әдип.

“Казыктагы тальян” хикәясендә автор фаҗиганы персонажларның күңел дөньясындагы барган кичерешләр аша тасвирлый. Монда совет чорыныж ешелексез сщясщте,атарның үз битарафлыгы нәтиҗәсендә туган ктлаулы кичерешләрнең сурәтләнеше дщ, аларга авторның төгәл бәясе дә урын алган.

Чаллы тормышы турында язган “Хунвейбин” романын гына укып караса да, аның чынбарлыкны шулкадәр дөрес тасвирлый алуына таң каласың.

Бу роман-эпопеясендә Айдар Хәлим татар халкының язмышына кагылышлы сорауларны күтәрә, тел һәм гореф-гадәтләрнең милләтнең үзаңы белән бәйләнештә ачып бирә.Бер татарның бер гасырлык язмышы мисалында татар язмышын сурәтли.

Өч аяклы ат” әсәре аңа тагын да зуррак уңыш китерде. Бу әсәр буенча куелган әсәрне халык яратып кабул итте.

Ул соңгы елларда әдәби эшчәнлеген тагын да активлаштырды. Газета-журналларга мәкаләләр яза,  укучылар һәм укытучылар белән  белән очрашуларда актив катнаша,. “Җомга кичләре” оештыра. Бу кичәләрдә ул Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче яшь язучылар белән очрашулар, яңа чыккан китапларын презентацияләү, укучылар һәм укытучылар көче белән әзерләнгән концерт-кичәләр үткәрә. Аның ару –талу белмәс аны милләт өчен көн-төн ялсыз эшләргә әзер. Ул шундый олуг милләтпәрвар.

**Йомгаклау.**

Айдар Хәлим соңгы елларда әдәби эшчәнлеген тагын да активлаштырды. Газета-журналларга мәкаләләр яза,  укучылар һәм укытучылар белән  белән очрашуларда актив катнаша,. “Җомга кичләре” оештыра. Бу кичәләрдә ул Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче яшь язучылар белән очрашулар, яңа чыккан китапларын презентацияләү, укучылар һәм

укытучылар көче белән әзерләнгән концерт-кичәләр үткәрә. Аның ару –талу белмәс аны милләт өчен көн-төн ялсыз эшләргә әзер. Ул шундый олуг милләтпәрвар.

**Багманова И. И.,**
**югары квалификацион категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Яр Чаллы шәһәренең “30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

## РИФАТ СӘЛАХ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТЕЛ - СҮРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

### Кереш

Рифат Сәлах - алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләрнең берсе. Аның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар. Бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән яшь шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.

Шагыйрьнең бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, күңелне дулкынландыра, кыбырсыта. Алай гына да түгел, бер дулкын булып үзенә алып кереп китә. Шагыйрь төрле темаларны күтәрә. Бигрәк тә ул мәхәббәт лирикасында көчле. Табышлары да байтак. Шигырьләрнең халәти үлчәмнәре, хисси контрастлары төрле: бәхетле – бәхетсез, сагышлы – сөенеч катыш, җавапсыз – нәтиҗәле, моңсу – шатлыклы, , тирән – җиңелчә... Аларның Рифат Сәлах каләменнән агылганын тоеп була. Димәк, шагыйрьнең үз стиле бар дигән сүз.

Рифатның милли темага кагылышлы шигырьләрендә татар тарихы һәм аны барлау, бүгенге вазгыять һәм милләтнең киләчәге турында уйлану ачык тоемлана. Ул борчыла, үз халкын горур, көчле, ирекле итеп күрергә тели.

Шагыйрьнең шигырьләре тел-сүрәтләү чараларына бай. Мин эзләнү эшемдә Рифат Сәлах иҗатында очраган тропларның **(ассоциатив сурәтләү чаралары), стилистик фигураларның, лексик һәм фонетик чараларның кайбер төрләрен табарга һәм аларга салынган** фикерне ачыкларга тырышырмын.

**Эшнең максаты**: Рифат Сәлах шигырьләрендә тел –сурәтләү чараларын табып, анализлап, шигырьләрнең эчтәлеген , идеясен ачудагы әһәмиятен аңлатуга ирешү.

Әйтелгән максаттан чыгып, түбәндәге **бурычлар** куелды:

1. Әдәбият теориясе буенча тел-сурәтләү чараларын өйрәнү.
2. Рифат Сәлах шигырьләрен укып чыгу, тел - сурәтләү чараларын табу.
3. Шигырьләр тукымасындагы тел-сүрәтләү чараларының әһәмиятен аңлату.

Эзләнү эшем кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора. Төп өлештә Рифат Сәлахның кайбер шигырьләреннән мисаллар китерелде.

### Төп өлеш

### I. Рифат Сәлахның тормыш һәм иҗат юлы

Рифат Сәлах (тулы исеме Рифат Гали улы Сәлахов) 1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында эшче һәм укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылларында урта мәктәпне тәмамлый. Тел-әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлый. Беренче шигырен бишенче сыйныфта яза. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша. 2004-2009 елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында белем ала һәм шул елларда актив иҗат итә башлый. Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә чыныгу ала. 2007-2009 елларда әлеге берләшмәнең студентлар ягыннан җитәкчесе була. Студент чагында Казан дәүләт университетының татар студентлары газетасы «Тәрәзә»не чыгаруда катнаша. 2006-2009 елларда әлеге газетаның баш мөхәррире урынбасары булып эшли.

Татарстан Республикасы Яшьләр, спорт һәм туризм министрлыгының «Идел» яшьләр үзәге

оештырган «Иделем акчарлагы — 2005» конкурсында шигърият буенча беренче урынга, «Иделем акчарлагы — 2006»да «Гран-прига», Казан дәүләт университеты үткәргән Идел-Урал төбәге студентларының иҗат бәйгесе «Шигъри Сабантуй — 2006» — икенче, «Шигъри Сабантуй — 2008»дә беренче дәрәҗәдәге дипломга лаек була. Шигырьләре матбугатта даими басыла, «Безнең гәҗит», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә.
Азәрбайҗан шагыйрәсе Сона Вәлиеваның шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. 2016 елның апрелендә «Аразбары» исемле тәрҗемә китабы чыга.

"Акчарлак","Шәһри Казан","Дарелфөнүн" газеталарында, "Идел" журналында эшли. 2013-2014 Татарстан Язучылар берлегенең матбугат үзәге җитәкчесе. 2016 елдан Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 2008 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## II. Рифат Сәлах поэзиясе һәм аның әсәрләрендә тел-стиль үзенчәлекләре

### 2.1 Рифат Сәлах шигырьләрендә троплар (ассоциатив сурәтләү чаралары)

Тел сүрәтләү чараларының иң гади һәм иң киң таралган төрләреннән берсе – **чагыштыру.** Нинди дә булса күренешне аңа охшаш үзенчәлекләре булган икенче күренеш белән чагыштырып сыйфатлау-охшату – чагыштыру дип йөртелә. Чагыштырулар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төрле сурәтле төсмерләр өсти. Чагыштырулар борынгы чорларда ук киң кулланылган. Аларны татар халык иҗаты әсәрләреннән дә күп табарга була. Мәсәлән, "Авыздан чыккан сүз очкан кош кебек" (мәкаль)

Рифат Сәлах иҗатында алар бик күп. Мисалга түбәндәге юлларны китерә алабыз:

Алларымда
Истәлегең тора –
Соңгы ядкяр – тәүге китабың.
Сурәтеңне
Яңа бөреләнгән
Ак каеннар белән бутадым. *("Саташу")*

Дөньяда сүзләр генә җитмәс,
Әйтеп бирер өчен күңелдәген.
Төнге күктә йолдыз дигән идем –
Чыклы иртә икән иреннәрең. *("Тәүге адашу")*

Шагыйрь хисләрне сурәтләгәндә дә чагыштырулардан оста файдалана. Алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

Күз яшеңне яшермә син, яме,
Күренәсе инде күренгән.
Кочак-кочак кызыл гөлчәчәкләр
Ташып чыккан чагы күңелдән.
*("Гөлчәчәкләр")*

Карлыгачтай кыйгач синең кашың,
Ә күзләрең – көзге төннең үзе.
Сабырсыз дип гаеп такма, җаным,
Күңелкәем инде күпме түзде? *("Кыйгач кашым" шигыре)*

Сурәтләнә торган объектына туры китереп шагыйрь чагыштыруларның яңадан-яңаларын иҗат итә.

Баткан кояш яктысында
Чагыла гүя йөзең.
Бит очларың әйтерсең лә
Кызарып пешкән йөзем. *("Кызарып пешкән йөзем ")*
Син дә күңелем түрендә
Сары яфрак сыман.
Ничек котылырмын икән
Күзләр арасыннан. *("Көзгә элегия")*

Алдагы мисаллар Рифат Сәлах иҗатында чагыштыруларның шактый күп булуын раслый, алар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төзеклек, үтемлелек өсти.

Киң таралган поэтик тропларның тагын берсе – **сынландыру.** Сынландыру табигать күренешләрен, тере булмаган әйберләрне җанлы әйберләргә хас сыйфатлар белән сурәтләүдән гыйбарәт. Алар әдәби текстта сурәтләнә торган предметка җанлылык бирү өчен кулланыла. Рифат Сәлах шигъри әсәрләрендә сынландыруларга да мисаллар табып була:

Моңсу караш дисәм, алай түгел,
Төште микән аңа авыр уй?
- Хәлең ничек, дустым, нәрсә булды?
- Берни дә юк. Җаным авырый!...
(“Җаным авырый”)

*Чынында җан – авырмый. Автор аларны җанлы, тере итеп тасвирлый.*

Гармунда уйныйсың, эти,
Тирбәтеп күңел кылын.
Яныңда уйнап утыра,
Бу – улың, эти, улың. *(“Әти”)*

Гөнаһлар тәүбәгә китерә,
Ялгышлар төзәлер – үкенмә.
Сагынасыңдыр ул таңыңны,
Гомерең тиң булса бер көнгә. *(“Күбәләк”)*

Мисалга китерелгән сынландыруларда автор абстракт күренешләргә җан өрсә, түбәндәге юлларда табигатьнең матурлыгын сурәтләү өчен тропларның бу төренә мөрәҗәгать итә:

Айның бүген тулып көлгән чагы –
Тау эчендә тора эленеп. *(“Ай кызы”)*

Шулай итеп, авторның бай теле, чагыштыру, сынландыруларны оста куллануы – аның кабатланмас язу стилен формалаштыруга һәм мәхәббәт, табигать кебек олы төшенчәләрне ачуга китерә. Шагыйрьнең әсәрләре үзенең ритмы һәм аһәңе белән укучының җанын, рухын җәлеп итә, аларның камиллеге, гармония бөтенлеге һәм нәфислеге үзенә тарта.

Рифат Сәлах үзенең шигырьләрендә **оксюморроннарны** да мул куллана.

Кеше күңеле – мең кат челтәр генә,
Челтәрләрен кемнәр үргәндер?
Упкыннарга меңләп сукмаклар бар,
Аннан чыгу юлы бердәнбер!
(“Челтәр”)

Мин әзермен иртән кабынуга,
Мин әзермен кичен сүнүгә.
Сүнеп торуларым мөһиммени,
Кояш чыкса бүген күгемә?!
(“Кояш чыга”)

Шагыйрь үз иҗатында сурәтлелек тудыруда иң актив файдаланыла торган чараларның берсе **эпитетларны** файдалана. Алар күп төрле һәм сурәтлелек тудыруда катнашучы башка чаралар белән катнашып, аралашып киләләр:

Йокларга да кем яратмый аны?!
Иркә булып үстем бугай мин.
Күзләремдә гамь сүнсә дә, әни,
Таш йөрәкле кеше булалмыйм.
(“Син иртәгә иртә уят, әни!”)

Гомереңнең таныш кыйгач нуры
Күчкән, диләр, диңгез артына.
Идел нурсыз хәзер. Ялкау кояш

Идел аръягында яктыра. *(“Эңгер-меңгер”)*

## 2.2 Рифат Сәлах шигырьләрендә стилистик фигуралар

Рифат Сәлах иҗатында сөйләмнең сәнгатьлелек көчен арттыручы стилистик чараларның берсе – **кабатлаулар** зур урын алып тора. Кабатлау – әсәр эчендәге сүзләрнең кабатлануы ул. Кабатлауларның төп функциясе – эчтәлек һәм форма арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Шулай ук алар сүз ясый, алар эмоциональ бизәк була, алар мәгънәви басымны арттыра,

алар үзенчәлекле яңгырашны барлыкка китерә. Кабатлау алымына Р.Сәлах та мөрәҗәгать итә. Аның кабатлаулары туйдырмый, чөнки шагыйрь шигырьнең аһәңен көчәйтеп җибәрерлек яңадан-яңа төрләрен – гади кабатлау, анафора, эпифора, рәдиф, рефрен, кире кабатлау кебек төрләрен сайлый.

Рифат Сәлах иҗатында түбәндәге синтаксик берәмлекләрнең кабатланып килүен күзәтергә була: сүз, сүзтезмә, җөмлә. Гади кабатлаулар Р.Сәлах иҗатында шактый. Ул төрле сүз төркемнәре белән бирелә. Шагыйрь иҗатында исем, фигыль, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, хәтта ярдәмче фигыльле кабатлауларны да очратырга мөмкин:

Күзләреңнән якты нурлар киткән икән,
Чибәрлек тә бетә икән, сүнә икән, үтә икән.
(«Тормыш кагыйдәсе»)

Исем сүз төркеме белән бирелгән кабатлаулар:

Синең йөрәк – серле йөрәк,
Куе урман кебек.
Әмма никтер бер юл да юк –
Булмый гына кереп.
(«Синең йөрәк»)

Рәвеш сүз төркеме белән кабатлаулар да бар.

Канатларың җилпеп очсын әле
Офыкларның иң-иң түрендә,
Әллә нигә үз фәрештәм миңа
Якын да күк, якын түгел дә.
(«Дога»)

Алмашлык сүз төркеме белән бирелгән кабатлаулар:

Йөрәгемне үтәли күрмисең,
Күңелеңнән сизәсең генә.
Йөрәгемне күптән берәү борчый,
Ул син генә инде, син генә!
(«Берәүгә»)

Шагыйрь җөмләне тәмамлап, хәбәр функциясен башкаручы фигыльләрне кабатларга да ярата.

Кемлегеңне белмим,
Сурәтеңне күрмим, -
Бер илтер бормалы юлларым.
Тик сиңа юл урау,
Гүя син кыңгырау:
Күңелдә чыңладың, чыңладың.
(«Кемлегеңне белмим»)

Ә мин сине артык сөйдем бугай,
Артыграк сөйдем җанымнан.
Мәхәббәттән ярсып типкән йөрәк
Ул ярылган инде, ярылган!
(«Адашкан юлчы»)

Шагыйрь иҗатында **сүз кабатлаулары** да күзәтелә. Әлеге кабатлаулар логик басым алган сүзнең мәгънәсен тагын да ассызыклау өчен, җөмләнең теләсә кайсы урынында кабатланып килергә мөмкин:

Үзең ялкын,
Үзең салкын миңа –
Карашыңнан үзәк өзелә.
Үзең гашыйк иттең,
Үзең гашыйк иттең,
Үзең гашыйк иттең үзеңә.
(«Үзең гашыйк иттең»)

Кабатланып килгән **җөмләләр** дә шагыйрь иҗатында киң кулланылган. Алар шигырьнең сәнгатьлелеген арттыралар, интонацияне көчәйтүгә ярдәм итәләр.

...Күптән инде сине күргәнем юк,
Ялгыш SMS та язмыйсың.
Рөхсәт итче, төштә күрим сине,
Бик тә килә иркәм назлыйсым,
Бик тә килә иркәм назлыйсым!
(«Язлар сөю алып килә, диләр...»)

Р.Сәлах иҗатында **рәдифкә** дә мисаллар таптым. Рәдиф – рифмадан соң кабатланып килүче сүз яки сүзтезмә. Гадәттә, беренче строфа азагында кулланылган сүз яки сүзләр тезмәсе башка строфалар азагында да рифмалашкан сүздән соң бернинди үзгәрешсез кабатланып килә:

Син кил әле миңа,
Язларында
Туган якка кайткан кош сыман.
Кабаттан бер канатландыр мине –
Мин сагынам сине, юксынам.
Син кил әле миңа,
Яз аенда
Чәчәк аткан назлы гөл сыман.
Күзләремә синең күзләр кирәк,
Мин сагынам сине, юксынам.
(«Син кил әле...»)

Күргәнебезчә, Р.Сәлах поэтик кабатлауларны уңышлы куллана. Алар шигъри юлларның тәэсир көчен арттыра. Сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә. Сурәтләнә торган объектына туры китереп шагыйрь кабатлауларның яңадан-яңаларын иҗат итә.

Шагыйрь **рефрен** юллар кулланып күпмедер дәрәҗәдә шигырьләренең гомум рухын, моңын билгели. Мәсәлән,

Язмыш мәллә безне бәйләп куйган,
Китә алмыйм синнән һаман да.
Мин талпынам, синнән китәрмен дип,
Китәрмен дип әллә кайларга.
Язмыш безне бәйләп куйган бугай,
Якын бара алмыйм үзеңә.
Бөтен хисләремне бүләк итәм,
Бүләк итәм синең исемгә.
("Сөйгәнем")

Шулай итеп, авторның бай теле, аның кабатланмас язу стилен формалаштыруга һәм мәхәббәт, табигать кебек олы төшенчәләрне ачуга китерә. Шагыйрьнең әсәрләре үзенең ритмы һәм аһәңе белән укучының

җанын, рухын җәлеп итә, аларның камиллеге, гармония бөтенлеге һәм нәфислеге үзенә тарта.

**2.3 Рифат Сәлах шигырьләрендә лексик чаралар**

Шагыйрь теленең байлыгы да, андагы **синонимнарның** күп булуы белән билгеләнә.

Сагышларым ерак калды синнән,
Сөен-шатлан, һәрчак көлеп тор.

Оныттыра алсаң, җанымдагы
Бөтен борчуларны оныттыр.
(“Сагышларым ерак калды синнән”)
Син ягымлы... Рәхмәт! Гел шундый бул,
Якын дустым, җаным, матурым!...
Син ачасың мине иркәләргә
Тәрәзәдән төшкән таң нурын.
(“Таң нуры”)

**2.4 Рифат Сәлах шигырьләрендә фонетик чаралар**

Рифат Сәлах **анафораларга** да мөрәҗәгать итә. Алар шигырьләрдә, аеруча, күп очрый.

Ә бураннар инде тынып килә,
Ә бураннар китә кышлардан.
Якты күкләр юка тышлык белән
Хәтер дәфтәремне тышлаган.
(«Якты өмет»)

Мин күк тузаннан яралмадым,
Мин – җирнеке: кара балчыктан!
Яраларны тузан күмеп китәр,
Җир сукмагын үтеп талчыкмам.
Күккә чакырмагыз, менәлсәм дә
Мин ашыкмам анда, ашыкмам.
Галәм тузаныннан яралмадым –
Мин – җирнеке – кара балчыктан!
(«Мин җирнеке»)

**Йомгаклау**

Яшь, моңлы, романтик шагыйрь Рифат Сәлах әдәбиятка һәм күңелләргә үзәк өзгеч мәхәббәт сагышыннан торган иҗаты белән килеп керә. Аның саф, эчкерсез шигъри тәлгәшләрен укыгач, ничектер үзең дә караңгы вазгыятьне онытып, дөньяга, кешеләргә мәхәббәт белән карый башлыйсың.

Рифат Сәлах шигырьләрендә тел-сүрәтләү чараларын тикшергәннән соң, мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

-тел-сүрәтләү чаралары поэзиянең сәнгатьлелек дәрәҗәсен үстерәләр, шигырьләрне образлы итәләр. Коры сүз, коры фикер укучыларда бернинди хисләр дә уятмый, ә образлы чаралар шигъри строфаларны бизиләр,төсле буяуларга буйыйлар. Сүрәт чаралары ярдәмендә шагыйрь төп фикерне, әйтәсе сүзен уйдырып сала,тирән итеп әйтә, укучыны уйландыра, тетрәндерә һәм юата, борчый, көлдерә.

Чагыштырулар сурәтләгән предметны, хәрәкәтне, билгене, халәтне күз алдына җанлырак, тагын да калкурак һәм игътибарны үзенә тартып тора торган итеп китереп бастыра. Шагыйрь чагыштырулар аркылы тирә-юньгә, җәмгыятьтәге күренешләргә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Ул аларны ярата, тискәре мөнәсәбәттә тора, кызгана. Гомумән, чагыштырулар язучының стилен баета, образлы, җанлы картина тудыруга булышлык итә. Әсәрнең тел-сурәтләү чараларын өйрәнү аның темасын, проблемаларын, идеясен, пафосын, сюжетын аңларга, ачыкларга ярдәм итә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Рифат Сәлах шигъриятенең сәнгатьчә җитлегүе, эчтәлек һәм форма берлегенә, гармониясенә ирешүе, актуаль - тормышчан яңгыраулары, аларның сюжет һәм композицион бөтенлеге, барлык тел - сурәтләү чаралары байлыгын, поэтик активлыгын даими бер максатка буйсындыру белән тудырыла дип әйтә алабыз. Әлеге максатларга ирешүдә авторга, һичшиксез, ассоциатив сурәтләү алымнарын урынлы куллану да нигез булып торган. Аның шигырьләрендәге эпитетлар, метафоралар, чагыштырулар һ.б. шундый чаралар стилистик бизәккә генә кайтып калмыйча, тирән мәгънә саклаучы берәмлекләргә әверелеп киткәннәр.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әдәбият белеме сүзлеге. Редакторы Ахмадуллин. –Казан: Татар кит. нәшр, 1990
2. Хаков В. Х. Стилистика һәм сүз сәнгате. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 158 б.
3. Рифат Сәлах– Wikipedia материаллары.
4. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан: Мәгариф, 1994.
5. Сәлахов Р.Г. Күңел бөртекләре. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007.
6. Сәлахов Р.Г. Ташта үскән гөлләр. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012.
7. Сәлахов Р.Г.Яшел ай. –Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.
8. Хаков В.Х. Татар стилистикасына кереш. –Казан унив. нәшр, 1993.

**Батдалова С.Ә.**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Яр Чаллы шәһәре, 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

**“Рәхмәт халкым, хак язмышым өчен**
**Үз телеңне бирдең иң элек”**

**Кереш.**

Айдар Хәлим һәм татар милләте язмышы тыгыз үрелгән бер толым кебек. Тынгысызлыгы белән аерылып торган, үз позициясенә тугры калган шәхес ул. Мин Айдар Хәлим иҗатын бик яратып, кызыксынып укыйм. Аның иҗаты,тормышы белән даими танышып торам.Ул безгә татар теленең иксез-чиксез мөмкинлекләрен күрсәтеп: матурлык,табигать тәрбиясе,иман тәрбиясе бирә алды.Айдар Хәлим әсәрләре безне җитәкләп кылганны далаларга алып чыга, чикерткәләр симфониясен тыңларга, клын булып , тауларга алып менә, балык булып суларга алып төшә,кош булып, зәңгәр күкләрдән аваз сала...Әдип,гмер тавының түбәсеннән торып, мәңгелек Дала, мәңгелек Татар, мәңгелек Иман турында мәңгелек кыйссаларын яза.

**Максатым:** Айдар Хәлим иҗатын өйрәнү. Аның “Кыйбла” әсәрен, “Талант. Шәхес. Язмыш” җыентыгыннан иҗади сурәтләмәләр,әдәби бәхәсләр, әңгәмәләр,ачык хатлар һәм чыгышлардан кайбер язмалары. “Печән чапканда” исемле поэмалар җыентыгы, “Тилергән сирень” исемле җыентыктагы шигырьләре, балладалары “Өч аяклы ат” фильмы аша язучының иҗатын барлау иде.

**Бурычлар**:

-чорга иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни характеристика бирү
-татар әдәбиятының иҗтимагый тормыш,милли хәят белән тагын да якынаюы,милли азатлык,ирек,хөрлек идеяләре белән сугарылуын күрсәтү.
- Айдар Хәлимнең бу чордагы тормыш һәм иҗат юлын барлау.

Тарих битләре аны барлар әле

Тарих туктаусыз алга бара, ул һәрвакыт хәрәкәттә, диләр... Бик үк дөрес фикер түгелдер бу. Тарих та, күпмедер чор үткән саен, туктап тын аладыр, үзе хәрәкәт иткән вакытта кешелекнең нинди хәлләргә дучар булуына,гаделсезлекләр, рәхимсезлекләр мохитендә буталышып,бугазлашып мәш килүенә хәйран калып торадыр. Менә шул борылышларны җайлау өчен якты дөньяга берәү туа торгандыр. Тарих, Айдар Хәлим исемле җан иясенең дә барлыгын, белер әле.

Мин Айдар Хәлим дигән шәхес барлыгын күптән белә идем инде. Аның әсәрләре белән дә таныш мин. Айдар абыйны тугры сүзле, гадел, милли җанлы итеп күзаллыйм.

Айдар Хәлим – үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феномен күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмеш - белмәмешкә салынамы – анысы мөһим дә түгел, әмма Вакыт галиҗәнаплары бу шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә.

Әдәби даирәдә Айдар Хәлим исеме инде кырык еллап даими ишетелеп, аңга сеңеп килә. Айдар Хәлим – бу дөньялыкта Яшәү казыгын нык каккан әдип. Таныйк: соңгы 10-15 ел эчендә ул халыкара масштабтагы фигурага әйләнде. Аны һәр даирәдә шактый ук яхшы беләләр; гади укучылар да сәясәттәге эшмәкәрләр дә, хакимият – күзәтү вәкилләре дә, чит

илләрдә дә. Хикмәт нидә? Шагыйрьлеген, язучылыгын таныган хәлдә, миңа калса, ул иң әүвәл бүгенге көннең иң актив милләтпәрвәр публицисты. Ул әйтерсең МЧС ның бер җаваплы идарә пультында.Кайда хәвеф, кайда бәрелеш, кайда яра - Айдарның каләме шунда. Соңгы ун елда чыккан китапларын искә төшерик: “Книга печали, или Записки аборегина”, “Гомеремнең ун көне”, “Минем түгәрәк имәнем”. Кайберләре, үзебездә мөмкинлек табылмагач, чит илләрдә басылган, суд – мәхкәмә чикләрен үткән. Аннан да кыюрак, зирәгрәк, гайрәтлерәкләр бар икән – әйдә, андый әсәрләрне үзләре язып күрсәтсеннәр! Бу китапларның берсе генә дөнья күргән очракта да, тарихта урын дәгъва итәргә мөмкиндер ул.

Айдар Хәлим ике телдә – рус һәм татар телләрендә (теләгәндә саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь (Милли шигырьләр” китабын гына укып карагыз!) Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын –максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы – талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Театр дөньясы өчен пьесалары да яхшы мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте ул – проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә дип кенә беләм. Шулай да төп проза әсәрләре – “Өч аяклы ат”, “Татар вакыты”, “Казыктагы итальян “. Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы ,яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия, бүләкәргә лаеклы әсәрләр.

Айдар Хәлим – һәр зур талантка хас булганча, гаять катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Соңгы елларда Айдар Хәлим үз иҗатында тагын да ныграк үҗәтлек күрсәтеп, яңа үрләр яулады. Җәмәгатьчелек тә моны таныды, бәяләде.

Мин 8 нче сыйныф укучысы булсам да Айдар Хәлим иҗатын бик теләп,яратып укыйм. Аның “Кыйбла” әсәрен, “Талант. Шәхес. Язмыш” җыентыгыннан иҗади сурәтләмәләр,әдәби бәхәсләр, әңгәмәләр,ачык хатлар һәм чыгышлардан кайбер язмаларын укыдым. “Печән чапканда” исемле поэмалар җыентыгын, “Тилергән сирень” исемле җыентыктагы шигырьләрен, балладаларын укыдым. Ә менә “Колмак җыя кызлар” исемле җыентыктагы шигырьләрен һәм балладаларын әдәбият дәресендә укыдык. Укытучы белән берлектә анализладык

Быел без Айдар Хәлимнең үзе белән очраштык. Ул мәктәпкә килде. Ике дәрес үткәрде Айдар абый. Үзенең балачагы турында бик кызыклы һәм гыйбрәтле итеп сөйләде ул. Ятимлек ачысын бик яшьли татыган, ачлык – ялангачлыкны күп күргән, инде чәчләренә чал кергән олпат язучыны күреп йөрәк әрнеде. Күңелдә аны кызгану хисе уянды. “Балачак андый булырга тиеш түгел бит” дип аваз саласы килде. Үземнең бәхетлетормышыма мең кат шөкерана кылдым. Айдар абый бик күп шигырьләр укыды. Ул аларның һәрберсен яттан белә, сәнгатьле итеп укый. Киләчәктә тагын очрашырга сүз бирде ул безгә. Без аны 75 яшьлек юбелее белән котладык,аңа сәламәтлек, иҗади уңышлар теләдек.

Сиксәненче елларның уртасында сәяси мәйданда үзен башбирмәс көрәшче итеп танныткан Айдар Хәлимне күпләр аңлап бетермәделәр, милли хәрәкәттә катнашканда үз мәнфәгатьләрен алга куйган бәндәләр белән бутадылар, милләтләр арасындакаршылык китереп чыгаруда гаепләргә тырышучылар булды. Туган халкы өчен иң кискен минутларда аваз салган әдипнең тавышын өнәмәүчеләр дә җитәрлек иде. Шундый минутлар була: үзен татар әдибе дип санаган шәхескә эндәшмичә калырга һич ярамый. Шул чакларда сәяси мәйданда давыллы һәм гаугалыитеп хакыйкатьне игълан иткән әдипкә астыртын каршылык күрсәтеп,тынычлык саклаучы булып күренергә тырышучыларның гамәле артында үз мәнфәгатьләре ятканлыгы иртәме – соңмы милләкә фаш була, тарих һәрнәрсәне үз урынына куя. Чын әдипнең фидакарьлеге артында исә гаделлек хисе ята. Айдар Хәлим милләтчелеге нигезенә балачактан ук тәрбияләнгән хакыйкатькә омтылыш салынган. Шушы сыйфат аңа беркайчан да тынгылык бирми, совет чорында ук сәяси эзәрлекләнүләр аша узып чыныккан әдип әле бүген дә актив көрәш мәйданында, һәм аның көрәше милләтләргә каршы түгел,ә икейөзле сәясәткә каршы юнәлтелгән. ”Көнбагыш чәчкәсе” хикәясе аның менә шушы көрәшенең максаты, шуңа хәрәкәт бирүче

тойгы – хисләр турындагы гүзәл поэма,баллада булып тора..

Айдар Хәлим – үз дәрәҗәсен бик яхшы белеп иҗат итә торган әдип. "Үзем турында үзем" дигән язмасында мондый юллар бар: "Мин үзем турында татарның киләчәге булган һәм,һичшиксез, Тукай йолдызлыгыннан булган зур шагыйрьмен дип уйлыйм... Мин исән чагында "тарихта үземне булдыру" " түгел, анда милләтне булдыру өчен көрәштем һәм чамасыз кан һәм көч түктем. Милләт булсын! Бу – иң мөһиме. Милләт булса без дә булырбыз. Аллаһы боерса. Милләт булмый икән, без дә була алмыйбыз. Без ул чакта бер кемгә кирәкмибез". Айдар абый милләт тә, без дә яшәргә тиешбез әле бу дөньяда. Сез исән генә булыгыз!

Мин Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәрен берничә тапкыр укып чыктым. Бүгенге яшь буынга эле аңлашылып бетмәгән. Хәтта күз алдына да китерергә дә авыр булган бу вакыйгаларны кабат- кабат укыдым. Ирексездән күзләремә яшьләр килде. Тарих әнә инди чорлар кичергән Ачлык, ялангачлык, хәерчелек, сыйнфый көрәш, сугыш кешеләргә генә түгел, табигатькә дә күпме бәла-каза китергән. Язмыш җилләре никадәр кырыс булган

Бу әсәр миндә тирән хисләр уятты. Авырлыклар каршында баш имичә сыкранмыйча алга барырга,дөреслеккә омтылырга, хакыйкатьне ачарга кирәклеген төшендерде. Шушы повесть аша мәрхәмәтсез чр күз алдыма килеп басты.

Әсәрнең төп герое унике-унөч яшьләрендәге Кәбирнең аянычлы язмышы мине тетрәндерде. Трмышның иң кадерле, иң мөкатдәс бҗрасы дүрт шарттан тра. Шушы дүрт шартның берсе җитмәсә, бҗра өзелә һәм мәңге ялгана алмый. Ул шартлар:этиле булу, әниле булу,туганнарың булу, дусларың булу.Ни кызганыч Кәбир өчен бу шартларның барысы да булмый Әтисез яши ул. Әтисе сугышка киткәндә аңа ибары дүрт яшь була. Ай-һай әти югын юклый Кәбир бу рәхимсез тормышта.

Бер терәге булмаган, тормыш йөген берүзе тартучы анасының авыр сыкрануын күреп йөрәге әрни малайның. Анасының күз яшеннән дә газаплырак нәрсә булмый аңа дөньяда. Ә туганнарын язмыш җиле ил-көннән ераккарак алып китә. Бары Кәбирнең дусты Харис кенә янәшәдә кала.

Язучы Айдар Хәлим Совет власте төзелгән еллардагы сыйнфый көрәшнең асылын бик ста тасвирлый. Авылның мәдәни катламы Колымаларга сөрелгәннән соң , кичәге интелегентның сукбайлык белән алыштырылуын күрсәтә. Кешеләр язмышын хәл иткән бөке башлар тулаем бер социаль катламны барлыкка китерә. Бу кансыз катлам сыйнфый күрәалмаучылык белән коралланып шәхестән, нәселдән генә түгел, хәтта бу шәхес, бу нәсел асраган малдан,аттан да үч ала һәм аны да репрессияли. Повесть атка булган сирәк мәхәббәт тойгылары белән сугарылган.

Татар тормышында ат –гади бер йорт хайваны гына түгел. Ул –татар иренең нәкъ яртысы. Атның исеме дә бик матур –Бамбук. Сирәк урыннарда гына үсә торган бик чыдам агач исеме ул. Бәлки язучы атны тормыш сынауларына чыдам булганы өчен, түзгәне өчен дә сынмый торган агачка тиңләгәндер. Табигать тудырган бу җан иясенә кем генә сокланмас,гаҗәпләнмәс икән. Әнә Нәби агай белән ул сугышта Туган ил, туган җир өчен безнең азатлыгыбыз өчен дә көрәшкән икән бит Бамбук. Немецлар камалышында вакытта ул Нәби аганы үлемнән коткара. Хуҗасына атылган пуля ат иңенә тия. Ул исән кала. Сугыш кырларын кичеп яңадан туган якка әйләнеп кайта Бамбук. Нәби агай белән дә яңадан очраша.

Кәбир белән ат арасындагы мөнәсәбәт, ихласлык та мине сокландырды. Теле сөйләшә алмаса да атта адәм акылларын күрдем мин. Әллә ничә чакрым ераклыктагы авылдан туган җиренә кайта торган юлны таба бит ул. Ач, гарип өч аяклы Бамбукҗанның тормыш юлын тиңе булмаган батырлык дип уйлыйм мин. Минем ул атны күрәсем, аның башыннан,ялларыннан сыйпыйсым килә.Атның муенына пычак тидергән кешегә чиксез нәфрәт белән карыйм мин. Ходай биргән гомер азагына кадәр яшәргә хаклы иде бит Бамбук. Нигә кеше шулкадәр явыз? Нигә кеше шулкадәр мәкерле, кансыз икән? Ходай андый кешеләрне ничек җир йөзендә яшәтә икән?Бик зак вакытлар Кәбир белән Харисның киң ябалдашлы имән күләгәсенә кереп очлы ташлар ярдәмендә тырнак итләрен ерта-ерта Бамбук йөрәген күмү өчен кабер казуларын күңелем белән уйлап,йөрәгем аша кичердем.Ат

суела. Ир атсыз, канатсыз кала. Әйе,тормыш хәзер ялган юлдан кереп китәр һәм озак мантымас. Ир белән ат арасындагы өзеклек тиз генә ялганмас. Һәрхәлдә, егерменче гасырда ялгана алмас. Кәбир моны яхшы аңлый.

Ат белән булган вакыйгадан соң, Бөкебаш Санияне куркыта.Үзенең Саниягә карата булган ярату тойгыларын аклауда, үз теләгенә ирешүдә ул атны файдаланырга тырыша, әмма Сания сатылмый Ул иренә тугры кала.

Әсәр безгә ,ул елларның барлык ачысын:ачлык, ярлылык, ятимлекне әм бу афәт уртасында калган балалар тормышын күрергә ярдәм итте.

Язучы әйтергә теләгән фикерен үтемле итеп, халыкчан геройлар аша,аларныңавызы белән аларның хис-кичерешләре аша укучыларга җиткерә алды. Айдар Хәлимнең, һичшиксез, сирәк талантка ия булган прозаик икәнен дә белдек. Аның әсәрләрен кат-кат укыйсы килә. Мин бу язучының, безнең шәһәрдә яшәве белән горурланам. Ул инде олы яшьтә булса да һаман халык арасында; татар милләтен яклауда һәм саклауда хезмәт итә.Әле киләчәктә дә мин яраткан язучымның әдәбиятыбызга яңа чор, яңа геройлар алып килер, дигән ышаныч белән калам.

**Вагыйзова Г.Н.,**
**Яр Чаллы шәһәре**
**МБГББУ " 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## Айдар Хәлим иҗатында "канатлы сүзләр".

### I. Кереш

Айдар Хәлим... Табигать аңа нечкә тоемлау, тынгысыз йөрәк биргән. Балачагы югалтулы тирән кичерешләр, мәңге әрнүле язмыш алып килгән. Шундый ук нечкә бәгырьле, авыр язмышлы халкы, якты өметен, хикмәтле акылын сеңдереп, аны туры сүзле егет итеп тәрбияләп үстергән... Айдар Хәлим холык-фигыле, яшәү рәвеше, иҗат максаты һәм көрәш кыйбласы, эшчәнлек стихиясе - кыскасы, көндәлек адым-атламы, бөтен барлыгы белән чын мәгънәсендә ¬шагыйрь[7].

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли[9]**.** Язучы, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең иҗатын барлауда без дә өлеш кертергә тиеш дип уйлыйм.

Беренчедән, Айдар Хәлим җир һәм күкләр масштабында фикер йөртә[6]**.**

Икенчедән, ул үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феноменаль күренеш. Вакыт галиҗәнап¬лары бу Шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә...[7]
Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын - максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы - талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Пьесалар язуы да мәгълүм... төп иҗади хезмәте ул - проза әсәрләре...Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия-бүләкләргә лаеклы әсәрләр»[7]

Өченчедән,Айдар Хәлим ике телдә - рус һәм татар телләрендә (теләгәндә, саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл[7].

Фәнни-тикшеренү эшенең **максаты:**

1.Күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, күбрәк материал туплау һәм өйрәнү.

2. Айдар Хәлим иҗатында кулланган "канатлы сүзләрне" барлау.

**Бурычлары:**

1. Айдар Хәлим иҗаты турында материалларны туплау һәм куллану.
2. Айдар Хәлимнең әсәрләрен уку, тематикасын барлау, телен өйрәнү.

Бу тикшеренү эшенә әзерләнгәндә, Айдар Хәлимнең әсәрләрен, әдәбият тарихы һәм теориясенә караган китаплар, газета-журналлар, аның турында язылган истәлекләрне укыдым.

Мин сайлаган тема бик **актуаль** дип саныйм.Чөнки, беренчедән, ул тормышны, аның

үзгәрүчән сикәлтәле агышын нечкә сиземли, анда әледән-әле туып тора торган әхлакый, иҗтимагый проблемаларны, көнкүрештәге мөһим яңалыкларны оста тотып алып, аларны конкрет материал җирлегендә заманча яңгырашлы, сәнгатьчә тәэсирле-гыйбрәтле итеп сурәтли белә. Икенчедән, ул кешене дөрес яшәргә өйрәтә, аңа кыйбласын күрсәтә. Өченчедән, Айдар Хәлим милләтне саклап калырга, чын йөзен югалтмаска өнди.

## II. Төп өлеш

### 1. Айдар Хәлимнең тормыш юлына кыскача күзәтү

Айдар Хәлим 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә. Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959–1960елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмыкдалаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961–1964 елларда – Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә.

1968 елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлагач, А. Хәлим Татарстанның Түбән Камашәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында мөһәндис, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли. Түбән Камада яшьләрнең хакимият җитәкчелегенә буйсынмаган беренче «нәформаль» (формаль булмаган) иҗади-сәяси оешмасын – «Кама таңнары» исемле берләшмәне җанландырып җибәрә һәм шундагы эшчәнлеге өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, 1971 елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була.

1971–1975 елларда А. Хәлим Уфада «Совет Башкортстаны» газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып таныла. Аннары ул алты ел дәвамында Себер-Урал магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә өлкән мөһәндис вазифасында Түбән Варта – Курган – Әлмәт һәм Түбән Варта – Курган – Самар нефтьүткәргечләре салуда катнаша. 1981 елда аны Уфадагы Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983–1985 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала. 1985–1991 елларда Айдар Хәлим – язучы -профессионал, ә 1991 елдан 1996 елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугаи басма – «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган [10]. Айдар Хәлим 1976 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Язучылары берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты[9]. (2003)

### 2.Айдар Хәлим иҗатында “канатлы сүзләр”

Сөйләмнең матурлыгын, байлыгын тәэмин итүдә канатлы сүзләр зур роль уйный. Сөйләмдә “канатлы сүзләр” тезмәсе образлы тәгъбир мәгънәсендә һәм лексик термин

буларак кулланыла. Ул телебездә табигый яңгырый, сыйфатлы исем сүтезмә белән белдерелгән. Канатлы сүзләрнең чыганаклары күп төрле. Килеп чыгышлары ягыннан ике төркемгә бүләләр:

тел- мәдәниятебезнең үз җирлегендә барлыккак килгәннәр һәм башка телләрдән кергәннәр.

Канатлы сүзләр - әдәби әсәрнең теләсә нинди өзеге түгел, ә язучының әйтәсе килгән төп фикеренә хезмәт итә торган яңгырашлы өзеге. Фикерне төгәл аңлату өчен кайчак бер сүз дә җитә. Айдар Хәлим бу гыйбәрәләрдән аеруча оста файдаланган.

1. Прометей уты

Прометей – борынгы грек мифологиясендә кешеләрне аларның золымнарыннан коткаручы титан.

*Иген бөртеге - Прометей утыннан күпкә иртә ярлаган матдә. Таш гасырдан космик гасырга чыгу юлында мин кешегә ут, иген бөртеге һәм китаптан да күбрәк хезмәт иткән нәрсәне белмим.*\"Иген бөртеге"\

2. Агыла да болыт агыла.

*Агыла да болыт агыла. Кырык эшем кырылып ята. Язылмаган кырык әсәрем, ятим торна булып, йөрәктә чыңрый.*\"Гомеремнең ун көне"\

Хәсән Туфан шигыренең исеме. Язучыларның иҗатында бу тәгъбир еш кулланыла. Болыт- лирик геройның язмышына битараф, болыт өзлексез агыла- вакыт үтә, гомер уза. Болыт символ буларак кеше гомерен алыштырып килә.

3. Атадан калган хатам.

*Таң вакыты... Татар йоклый... Атадан калган хатам... Татарның "рәсми" тарихында бу фикерне соңгы җитмеш елда кемнәр әйтә алды сон?* \"Гомеремнең ун көне"\

Тәгъбир С.Рәмиевнең "Таң вакыты" шигыреннән. Илдә бөек кузгалышлар вакыты, ләкин татар хаман да йоклый. Лирик герой башка татарларны уйларга, үткәннәр һәм бүгенгене төпченергә сәләтле булуы белән аерылып тора. Ләкин ул да бары тик уйлана гына. Татарны йокыдан уяту гамәленә керешер иде, аталардан калган хаталары бар. "Хатам тирән, тамыры ерак", - ди лирик герой. Татар куркучан булып калган.

4. Печән базары.

*Гомумән алганда, тормышның алгы сызыгы, җан өчен көрәш, "Кызыл фикер белән кара фикер" көрәшкән сызык шушы "печән базары" мәйданыннан уза бит.*\"Озата килүче"\

Тәгъбир Г.Тукайның "Печән базары, яхут яңа Кисекбаш" поэмасы\1909, Г. Камалның "Безнең шәһәрнең серләре" комедиясе\1913 аркылы таралыш ала. Печән базары октябрь революциясенә кадәрге Казанда Киров һәм Татарстан урамнарының бергә тоташкан кварталларында урнашкан. Бу базарда сатучылар да, алучылар да күбрәк татарлар булган. Анда төрле карашлы кешеләр очрашкан. Еш кына тормышның төрле мәсьәләләре буенча бәхәсләр купкан, монда милләтнең эчке каршылыклары чагылган.

5. Туп- турыдан тут пошел

*Газета – беренче чиратта, "туп- турыдан тут пошел" дигәндәй, коры тәнкыйть түгел, ә уңай күренешләрдә тәрбияли торган трибуна.* \"Әгәр редактор булсам"\

Кешеләр, бер- берсе белән аралашу өчен, тел кануннары нигезендә сүзләрдән сөйләмнәр төзиләр. Сөйләшүче, чит телдәге әңгәмәдәшенә уен аңлату өчен, хәтта туган телдәге сүз-кагыйдәләрен дә хутка җибәрә.

...Элек булган хәл. Бер урыс кешесе татар авылыннан үтеп барганда, татар абзыеннан: "Күрше авылга ничек барырга?" – дип сораган ди. Шулчак татар абзые урыс кешесенә: "Туп- турыдан тут пошел"- дип җавап биргән, имеш. "Менә туп- туры юл, шуннан борылмыйча бар да бар, авылга барып чыгарсын", – дип әйтергә теләгән абзый. Тәгъбир фикерне ярлы тел белән аңлату мәгънәсендә кулланыла. Тапталмаган юлдан турыга яру мәгънәсендә дә йөри.

6. Чыктым аркылы күпер.

*Чит телдә язылган документның тәрҗемәсе "чыктым аркылы күпер" кебегрәк яңгырый.* \"Гомеремнең ун көне"\

Г.Тукай "Русчадан дөрес тәрҗемәләр" исемле памфлетында, сүзгә –сүз тәрҗемә

үрнәкләре биреп, үз чорындагы матбугатта еш очрый торган механистик, формаль тәрҗемәләрдән көлгән: “Русчадан: Я перешел через мост. Тәрҗемә: Мин чыктым аркылы күпер”.

Бу өзек –фраза, канатлы сүзгә әйләнеп, грамотасыз сөйләм, тәрҗемә үрнәге буларак кулланыла.

7. Соңгы могикан. Могиканнарның соңгысы.

*Сәйфи Кудаш...Искиткеч катлаулы, шаулы, фаҗигале егерменче гасырны тулысы белән үзенә алган шәхес. Татар дөньясының унтугызынчы гасырдан егерменчесенә күчеп, аның азагында китеп барган соңгы могиканы.* \"Гомеремнең ун көне"\

Тәгъбирнең чыганагы- Америка язучысы Фенимон Куперның “Могиканнарның соңгысы” романы\1826\. Романның атамасы күмәклек исеменә әйләнә. Бетеп баручы яхшы традициягә ихлас күңелдән бирелгән кешене характерлаганда, нинди дә булса юкка чыгучы иҗтимагый төркемнең, социаль күренешнең соңгы вәкиле турында шулай диләр.

## III. Йомгаклау.

Фәнни-тикшеренү эшемнең максаты күренекле шагыйрь һәм драматург, прозаик һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, күбрәк материал туплау һәм өйрәнү; милләт язмышы өчен көрәшүче язучыны безнең буынга һәрьяклап үрнәк итеп кую иде. Фәнни-тикшеренү эше барышында максатыма ирештем дип уйлыйм. Татар халкының горурлыгы Айдар Хәлим турында билгелекүләм материал тупланды, иҗатында кулланган тәгъбирләр билгеле бер системага салынды, язучының фикер сөреше, иҗатының гаять бай дәрәҗәсе күрсәтелде.

## IV. Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар


**1.** Гыйззәтуллин И. Канатлы сүзләр.-Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты. 2000. - 320 б.

**2.** Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М.Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: “Мәгариф”, 2006. - 319б.

**3.** Казлар көткәндә: Шигъри повесть.– Казан: «Мәгариф» нәшр., 2000.– 47 б.

**4.** Милли шигырьләр: Шигырьләр, балладалар.– Чаллы: «Хәерле иртә» нәшр., 2001.– 235 б.

**5.** Социалистик Татарстан, 1970, 8 март.( Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Саҗидә Сөләйманова)

**6.** Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.– 384 б.

*7.* «Татарстан» журналы, 2001, 11 нче сан, 2002, 1 нче сан.

**8.** Тилергән сиреньнәр: Шигырьләр.– Казан: «Рухият» нәшр., 2003.– 607 б.

**9.** http://tt.adabiyat.wikia.com/wiki/Айдар_Хәлим

**10.** https://tt.wikipedia.org/wiki/



**Валиева Г. М.,**
**татар теле укытучысы**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**41нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## АЙДАР ХӘЛИМ – ДРАМАТУРГ

Айдар Хәлимнең сәхнә әсәрләре күп тугел. Аның нибары ике оригиналь пьесасы һәм “Биктырыш” поэмасының курчак театры өчен язылган инсөенировкасы бар.

Беренче “Ишек ач, Чишмә кайтты” пьесасы 1981 елда язузыларның Рига янындагы Дубулты иҗат йортында языла, 1983 ел Башкорт Академия драма театрында режиссер Лек Вәлиев тарафыннан “Җанчишмә” исеме астында сәхнәгә чыгарыла.

“Җанчишмә”спектакле белән автор, аның уйлавынча, үзенең яна типтагы сәхнә әсәрләре – драматургия системасын булдыру һәм аларны гамәлгә кую – сценография конституциясен тудыра башлый.

Әсәр драматурглар секциясендә тикшерелүдән башлап бик зур каршылыкларга очрый... Беренчедән, автор сәхнәгә яңа тема алып килсә, икенчедән, яңа тема сценографиядә яңа чаралар табуны шарт итеп куя. Театрдан читтә һәм театрның үзендә булган кайбер дошман көчләр репетицияләрне өзү учен идән асты көрәше алып баралар. Театрдагы киеренкелек пьесаны уйныячак сосставка да күчә. Премьера җитәрәк кенә, спектакльнең рәссамы Галия Имашева оркестр чокырына егылып төшеп, бик каты имгәнә. Нэтиҗәдә премьера декорациясез, арткы пәрдә белән генә чыга.

Әмма күтәрелгән теманың бик тә актуальлеге, актерларның яратып уйнавы нәтиҗәсендә премьера зур уңыш белән үтә.

Әсәрнең үзәгендә башкорт сәхнәсендә бөтен кискелеге белән беренче тапкыр кеше белән тирә-як мохит арасында яралган ясалма конфликт тора. Дуңгыз фермасына суны колхоз җитәкчелеге "акча түгеп бораулаңган" артезиан коесыннан түгел, ә бөтенләй бушка төшерә: моның өчен авыл каршындагы таудан шарлап агып яткан, бөтен тирә-якка даны таралган чишмәне күмдерә, суын тимер резервуарга куып кертә һәм торбалар буйлап фермага китерә. Чишмә классик фәлсәфәнең чагылыш теориясендә ("теория отражения") субъект ролен үти: шәһәрдән бөтенләйгә авылга кайтучы белән авылдан бөтенләйгә шәһәргә китүче арасындагы идеологик бәхәс партиянең дистә еллар буе "авылны шәһәргә якынайту" идеясен чәлпәрәмә китерә. Дуңгыз фермасына "суы шәһәрдәге кебек торба буйлап кына төшерелгән чишмә"не халык хәтереннән юк итү исәбенә башкарыла. Кешедә кешене, шәхесне үтерү- авылда авыл табигатен корыту аша бара. "Кешене үтереп йөрергә һич кенә дә кирәкми, ди пьесаның бер каһарманы Сәлимҗан. – Аның чишмәсен генә күмдерергә кирәк. Аннан кеше үзеннән-үзе үләчәк". Бу "үлемсез" процесс белән Йоклаган Кеше җитәкчелек итә. Йоклаган кеше көне-төне авыл буйлап йөри. Беркем белән дә сөйләшми, бары тик елмая һәм кул чаба. "Силсәүит исәбенә яши".

Спектакль башкорт матбугатында Г. Әпсәләмованың һәм башкаларның тәнкыйтенә эләгә һәм партиягә каршы чыгуда гаепләнә. Уфа буйлап Йоклаган Кеше образы аша партия җитәкчелеге сурәтләнә икән, дигән имеш-мимешләр таратыла. Шулай булуына карамастан, Уфа, Башкортстан тамашачысының ул сезондагы иң яраткан спектакленә әверелә. Аны кат-кат карау өчен халык авыллардан, шәһәрләрдән агыла. Спектакльләргә билет сату яшерен рәвештә тыела. "Халык йөрми" дигән сылтау белән спектакль бер сезонда нибары унсигез тапкыр чыгарылганнан соң сәхнәдән алына.

1985 елның 30 маенда Мәскәүдә РСФСР Язучылар берлегенең драматургия һәм театраль тәнкыйть буенча советында С.В. Михалков җитәкчелегендә башкорт драматургиясе турында зур сөйләшү үткәрелә. Сөйләшүдә Уфадан бер төркем драматурглар, шул исәптән Айдар Хәлим дә катнаша. Бу көннәрдә даматург Владимир Малягин тарафыннан "Вечная вода" исеме астында тәрҗемә ителгән "Ишек ач, Чишмә кайтты!" пьесасы, РСФСР Мәдәният министрлыгы тарафыннан күбәйтелә һәм ил театрларына куелуга тәкъдим ителгән була. Пьеса белән урыс телендә танышкан Мәскәү драматурглары аңа югары бәя бирәләр. Үзенең кереш сүзендә ,мәсәлән, С.В.Михалков әсәрне бик җылы итеп телгә ала. "Мостай Кәримнең күп кенә пьесаларына һәм Айдар Хәлимнең "Җанчишмә" пьесасына хас булган шигъри караш миңа бик ошый, - ди драматург С.Злотников. "Җанчишмә" – бик тә яхшы пьеса. Монда төгәл һәм акыллы нәрсәләр күп , хәер, миңа монда бераз күпсүзлелек бар кебек күренсә дә. Мин пьесаны бераз кыскарткан булыр идем. Ул бик эчкерсез, пьеса тере су кебек мәңгелек мирасны саклау турында җан әрнеше белән язылган. Монда пафос бар, әмма ул вакыт-вакыт күпсүзлелек аркасында риторикага күчә..."

"Мине "Җанчишмә" пьесасы бик тә куандырды. Бер яктан ул кеше җанында моңлы кәеф тудырган баллада булса, икенче яктан, кызыклы образлары, батыр көрәшче сыйфатында хәрәкәткә кертелгән һәм кеше персонажлары белән бергә хәрәкәт иткән чишмәсе дә булган каты төшле романтик-реалистик пьеса, - ди урыс драматургиясенең аксакалы А. С. Симуков. – Ул үзендә Башкортстан табигатен чагылдыра. Монда кызыклы образлар байтак, мәсәлән, табигатькә коры исәп аша гына килгән колхоз рәисе образы. Ул бик мәгънәле һәм ышандырырлык образ. Арбатовның вафат булган хатынының васыяте

буенча халык судьясы белән очрашу күренешендә күзләргә яшь бәреп чыга. Монда драманың нигезе пластикада икәнлеге тагын бер тапкыр ышанасың. Театр – пластика бәйрәме ул. Моны аңлап эшләгән драматурглар оталар. “Оптимистическая трагедия”нең безнең репертуардан төшмәве шуның белән аңлатыла да. Ул- пластик бәйрәме.

“Җанчишмә”дә тере, хәрәкәттә булган чишмәнең тавышын ишетәсең. Пьесаның башка персонажлары да моны аңлый. Әмма чишмә безгә турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә барысы да җимерелә, чөнки болай иткәндә автор ирешергә теләгән туры элемтә бозыла. Чөнки чишмә гадәттән тыш төгәл мохиткә урнаштырылган”.

Минемчә, “Җанчишмә” пьесасы бүгенге көндә дә актуаль булган проблеманы күтәрә – экологик проблема.

Авторның “Бакыр  туй” исемле икенче пьесасы 1985 елның көзендә Дим буендагы Канбәк авылында язылa һәм беренчесенә караганда да кискенрәк каршылыкларга очрый. 1988 елда “Дружба народов” журналында “Язык мой- друг мой...” дигән мәкаләсе басылып чыккач, Башкортстанда бик зур шау-шу куптарып, авторның исеме “дошман” исемлегенә кертелгәннән соң, пьесаның сәхнәгә чыгу юлы тәмам ябыла – драматурглар секциясенең уңай фикерен алган һәм бу вакыйгаларга кадәр Башкорт Академия театры тарафыннан кабул ителгән әсәрне Башкортстан главлиты (“цензурасы”) куюдан тыя. Автор СССР Главлитына шикаять белән мөрәҗәгать итә һәм аның үтенече канәгатьләндерелә: Үзәк Главлит Башкортстан Мәдәният министрыгына “Бакый туй” пьесасын кичектергесез рәвештә сәхнәгә чыгару бурычын йөкли.

Репетицияләр Башкортстанда кайбер көчләрнең татарга каршы аеруча котыра башлаган көннәренә туры килә. Мондый авыр чорда пьесаны сәхнәләштерү бурычын башкорт халкының чын интернационалист улы – Рәсәйнең һәм Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла Гыйләҗев үз өстенә ала һәм үз бурычын намус белән үти. Әмма кара көчләр пьесада уйныячак актерлар арасында коткы тарата, куркыта, кайбер актерлар моңа бирелеп,  уйнаудан баш тарта.

Спектакльнең “Пәри туе” исеме астында чыккан премьерасы 1989 елның февралендә була һәм тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

Әгәр автор беренче пьесасында кешенең үзен тудырган анасы – табигатьне җимерү аша үзендә шәхесне җимерү микроструктурасын күрсәтсә, икенче маҗаралы трагикомедия дип аталган “Бакыр туй” пьесасында исә Башкортстан, Рәсәй сәхнәсендә генә түгел, дөнья сәхнәсендә дә өйрәнелмәгән тема – феминизм, “хатын-кызларның ир-ат белән тигезлеге” дигән битлек артына яшеренеп, бер җенесне икенче җенескә буйсындырып тезләндерү, яңадан матриархатка кайтып, җенесләр арасындагы гармония тигезлеген бозу исәбенә “типтереп яшәү” темасы күтәрелә. Өч игезәк кыз – ирдәүкәләр Зилә, Дилә, Вилә аталары төзеп биргән “кәттиҗгә” өч ир-егетне урлап алып килеп, аларны үзләренә өйләндерү һәм тезләндерү экспериментын үткәрәләр. Алар өчен хатын-кыз матурлыгы һәм әхлакый идеал юк: барлык җир шары – галәмәт зур уйнаш йорты. Авылдан качып киткән бу татар кызлары галәми элемтә аша уйнаш итәләр. Әсәрдә бүгенге көннең кадагына суккан проблема – ир-егеттәге катыншалык , хатын-кыздагы ирдәүкәлек ачы сатира алымы белән, әле моннан егерме елга якын элек дип әйтергә мөмкин, утка тотыла.

Пьеса заман сәхнәсенең иң югары технологиясе – лазер, неон һәм галәми элемтә чараларына исәпләп язылган.

Әлбәттә, премьерада аларның берсе дә була алмый.

Шулай да темасы белән гадәти булмаган тамаша җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Әмма Мәскәү сүзен “екмас” өчен генә куелган спектакльне Башкортстан җитәкчелекге ашыга-ашыга “әхлаксызлык”та гаепли һәм , “Җанчишмә” кебек үк,  радиога да яздыртмый, телевидениегә дә төшертми торып, нибары ун тапкыр куелганнан соң. Сәхнәдән алып та ташлыйлар.

Драматургиядә үз системасын тудыру хыялы белән ашкынган яшь драматург пьеса язудан туктый.

**Вәлиева З. Н.**

**1 нче квалификацион категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен**
**Түбән Табын мәктәп – интернаты”**

**Лилия Садриева лирикасының кеше күңеленә тәэсир итү көче**

Мөслим ягы – җырлы, шигырьле як. Туган ягымның юл буенда яткан ташларыннан да салкын томсалык түгел, йөрәкләрне җылытырлык сагышлы, моңсу, серле яктылык сирпелеп тора сыман. Шулайдыр, гадәти төбәк түгел шул безнең яклар. Татар шигъриятенең, җырының иң бөек үрнәкләрен тудырган гаҗәеп талантлар биргән як ул Мөслим төбәге. Ык буенда үскән таллары суга иелеп нидер сөйлиләр, пышылдашалар, нәзберек җил дулкыннарны уйнатып ала, офыкка таба сак кына үрелгән оялчан зирек яфракларыннан сихри моңнар тарала. Мөслим өстендә илаһи моң, серле балкыш, җаннарны иләсләндерерлек көйләр агыла. Күңелең шуларны тотып алырга һәм шигырь юлларына салырга өлгерсен!

Лилия Садриева – Ык буе шагыйрәсе. Аны Мөслимдә олысы-кечесе танып белә. Һәрвакыт кешеләр белән, халык алдында. Аның шигырьләре район һәм республика күләмендә чыга торган матбугат битләрендә басыла. Алай гына да түгел, ул үз шигырьләрен үзәккә үтәрлек итеп сәхнәләрдән сөйли. Күңеле - гамь, җаны кешеләрне, туган ягын, гомумән, тормышны ярату белән тулы. Һәр вакыйга-күренеш уңаеннан, һәр форсатта аның үзенә хас әйтер сүзе бар – ул шигырь белән сөйләшә. Шигырь аның барлык күзәнәкләрендә.

Һәр кеше, минемчә, үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, милли традицияләрен, мәдәниятен, тарихын, күренекле кешеләрен яхшы белергә тиеш. Без, укытучылар, белү генә түгел балалар күңеленә дә салырга тиеш.

“ Лилия Садриева лирикасының кеше күңеленә тәэсир итү көче” - дип исемләнгән фәнни-эзләнү эшемә мин түбәндәге **максатларны** куям:

1. Туган якны, аның табигатен, балалык елларын сагыну хисенең шагыйрә иҗатында чагылышын табу.
2. Шигырьнең кеше күңеленә үтеп керүе һәм тәэсир итү көче.
3. Туган җиргә, ата-анага мәхәббәт, туган төбәккә бәйле күренекле кешеләргә хөрмәт һәм горурлану хисләре тәрбияләү.

**Эшемнең төп бурычлары:**

- республикабызга танылган якташыбызның иҗатын һәм шуңа китергән юлын укучы күңеленә сеңдерү;
- шул шәхес иҗаты үрнәгендә туган илгә, туган якка, туган авылга мәхәббәт хисләре тәрбияләү;
- шигъърият сөючеләрне яшьлек елларына алып кайту.

**Көтелгән белем нәтиҗәләре:**

- якташларыбыз турында мәгълүмат алу;
- эшчәнлекләрен анализлый белү;
- әңгәмә-дискуссияләрдә катнашу һәм үз фикереңне әйтү;
- үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

Бу эшнең **фәнни яңалыгы**:

- материалны тәрбия сәгатьләрендә, сыйныфтан тыш чараларда, әдәби кичәләрдә, стена газеталары чыгарганда куллану мөмкинлеге;
- фәнни эш өчен әзерләнгән презентация укытучылар өчен зур ярдәмлек булып тора.

**Төп өлеш.**

Лилия Садриева Мөслимебезнең иң сихри почмагында урнашкан Дусай авылында

дөньяга килгән дә, туган ягының серле урманнарында адашып, чишмәләренең суын эчеп, данлы Дусай бакчасының алма чәчәкләре исеннән исереп, сылу каеннарыннан күңеленә аклык, пакълек сеңдереп үскән зат. Ул матурлыкка үзе генә сокланып калмый, ә барлык шигърият сөючеләрне дә туган ягына алып кайта, һәртөрле җиләк-җимешкә бай урманнарына алып чыга, сандугач сайрауларын тыңлата, балачак сукмакларыннан йөртә, саф сулы чишмә суларыннан авыз иттерә. Йөздән артык шигыре, дистәгә якын җыры һәм багышлаулары тупланган "Өр-яңа яз", "Күңелләр чәчәк тели" дип исемләнгән китаплары тулаем туган якка мәхәббәт белән сугарылган, аңа мәдхия булып яңгыраган шигырьләре һәм җырлары белән үзенең Дусаена, Мөслимебезнең гүзәл табигатенә, ак каенлы урманнарына, тулпарлар чапкан киң болыннарына сәяхәт кылдырды, күңел сандыгының байлыгы белән таныштыра.

"Иң беренче күзгә чалынганы-аның нечкә лиризм белән сугарылган пәрвәрлеге. Ватанпәрвәрлеге. Мөслимпәрвәрлеге. Дусайпәрвәрлеге. Ыкпәрвәрлеге. Табигатьпәрвәрлеге. Ул барысын да ихлас ярата, барысы өчен дә ихлас борчыла, барысы белән дә ихлас горурлана. Хәтта Дусайның исәр Мирзагаяны да, каеннары, чишмәләре, урманнары, болыннары белән бер рәткә басып, күңелдә уелып калырлык шигъри тамгага әверелә" - дип бәя биргән иде шагыйрь Әхмәт Дусайлы.[1] Пәрвәр сүзенә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә эшкә, берәр нәрсәгә, шөгыльгә чын күңелдән бирелгән, инанган, ышанып мөкиббән киткән дигән аңлатма бирелгән.[6] Димәк, шагыйрә үз ватанына, туган ягы, авылына, Дусаена, Ыгына, аның табигатенә чын күңеленнән бирелгән кеше икән! Шушы зур мәгънәгә ия булган бәяләмәне мин шагыйрә иҗатында табарга теләдем һәм кулыма шагыйрәнең "Күңелләр чәчәк тели" китабын алдым.

Кайчандыр шаулаган-гөрләгән
Бар йортлар йокыга талганнар.
Туган нигезләрен изге күреп,
Карт-корылар торып калганнар.[7]

«Нигезләрне изге итеп» шигырен укыгач минем туган, үскән, балалык чорым узган Тугашым исемә килде. Чыннан да, без үскәндә шаулап тора иде бит Югары оч. Безнең гаиләдә 6 бала, Гатия апа һәм Мулланур абыйларда тыйнак, үзләренең тотышларыннан ук зыялылыклары күренеп торган Фәйрүзә, Гөлүсә апалар, апаларыннан качып кына шуклыкланып ала торган Фикус үсте. Сабирҗан абый белән Рабига апалар гаиләсендә 3 бала, Фәния апа белән Шәйхулла абыйларда 5 бала, гомерләрен балалар укытуга багышлаган Нәгыймә апа һәм Мирзаян абыйларда 3 бала, Мулланур абый һәм Тәзкирә апаларда 4 бала, Нуриәхмәт абый белән Мәүлидә апаларда 6 бала үсте. Мәктәптән кайтып ике сәгать вакыт узуга шушы балаларның барысы да авыл башындагы болында булырлар иде дә, аларның тавышлары ярты авылны гөрләтеп торыр иде. Кышкы көннәрдә өй тирәсендәге эшләр эшләнгәннән соң чаңгы-чана шуу вакыты була иде. Өлкән яшьтәге балалар чаңгы тагып болынны урарлар иде. Үзләре артыннан кечкенәләрне дә ияртерләр һәм бик артка калдырмыйча, ләкин бик иркенәйтмичә дә, көтә-көтә кайтырлар иде. Ә ат чанасы белән таудан «Кем утыра, кем утырмый»,- дип шуганда, әлбәттә, инде чананы тауга кире алып менү, чанадан тиз генә торып өлгерә алмаган, кечкенәләргә туры килә иде .

Тик уен турында беләсез:
Шатланып җырлыйсыз, көләсез.
Ак күбәләк кебек очынып,
Ашкынып мәктәпкә киләсез. («Балалар») [7]

Чыннан да безнең гамьсез балалык вакытыбыз булган икән бит ул!

Ә яшьләр нигәдер ашыгып,
Ашкынып шәһәргә агыла.
Каланың бизәкле тормышы,
Шау-шуы ошаган аларга. («Нигезләрне изге итеп») [7]

Шау-шуы ошагандырмы, юкмы, ләкин ул балалар тормышта үз урыннарын таптылар. Фаил абый Азнакай шәһәрендә танылган балалар врачы, Наил абый нефтьче, Фәйрүзә һәм Гөлүсә апалар мактаулы укытучылар, Ринат абый Әлмәттә нефтьче, Әлфинур Бөгелмәдә

шәфкать туташы, Зөлфия, Илсөя, Гүзәлияләр укытучы һәм башкалар барысы да тормышта югалып калмаган, башкалар көнләшерлек итеп тормыш корган, хезмәтләрендә макталып эшлиләр һәм күпләре инде лаеклы ялга чыкканнар һәм шагыйрәбез әйткәнчә, туган авылларын, урман- болыннарын, авылга терәлеп торган Ыкта су коенуларын искә алып сагыну хисләре кичерәләр.

Сагынырсыз әле, саргаерсыз
Җаныгызга сеңгән якларны.
Искә алып күп еларсыз әле
Туган якта калган картларны.
Тау башында калган каберләрнең
Ишәйгәнен әле күрерсез.
Сагынуга түзә алмаенча,
Бер кайтып килерсез, килерсез. («Нигезләрне изге итеп») [7]
Еракларга синнән китсәләр дә,
Балаларың кайта сагынып.
Туган көннән алып һәрбер бала
Яши туган җиргә табынып. («Изге җирем минем») [7]

Әйе, бер кайтабыз авылга. Кайту юлының язын-көзен пычрак булуы, кышын кар көртләрен уза алмыйча интегүләргә дә карамыйча авылга кайтасы килә, урамнарыннан узасы килә.

Юллары да үтеп кералмаслык,
Сазлык баскан иде югыйсә,
Кайтыла шул сагынып балачакны,
Яшьлегемә кайтам, юл төшсә.(«Сагыну»)[7]

Авылда төпләнеп калган Рөстәмнәр, Җәүдәтләр, Таһир абыйлар, Илсурлар үз эшләрен башлап терлекчелек белән шөгыльләнәләр, каз-үрдәк асрыйлар, кибетләр ачып сату итәләр. Алар хезмәтенә бәя рәвешендә юлларга асфальт җәелде. Гомер көзләренә кергән Насих абый, Мулланур абый, Сабирҗан абыйларны тәрбияләү, тормышларына күз-колак булу да алар җилкәсендә.

Лилия Ясировнаның «Кайгы төсе» шигыре минем күңелемне аеруча кузгатты, чөнки мин гомеренең чәчәккә бөреләнгән генә чорында кызымны, шушы көннәрдә генә әтиемне югалттым.

Мин кайгының төсен белми идем,
Әткәемнең өстендә икән.
Әткәемнең кабере өстендәге
Кызыл балчык төсендә икән. («Кайгы төсе») [7]
Сукыр әби күзлегедәй
Тынып калган өй тәрәзәләре.
Авылда кеше барлыгын белдереп,
Үлән чүпләп йөри кәҗәләре. («Нигезләрне изге итеп») [7]

Хәзер минем дә туган өй тәрәзәләре «ятимлек төсе алыр, сукыр әби күзлегедәй тынып калыр» микәнни?

Туган авылым болынында вак-вак күлләр күп. Язын-җәен кичләр бакалар җырына күмелә. Шагыйрәнең «Бака туе» шигыре мине шул туйга алып кайткандай була.

Гөр килешеп туй итәләр,
Күлгә хуҗа бакалар.
Оркестрын, хорын кушып,
Серле көй тараталар. («Бака туе») [7]

Шагыйрәнең сыерчык бураннары да нәкъ минем авылымда булган бураннарга охшаган. Алар безнең урамнарга сыймыйлар, гел туктамас кебекләр, язларны тиз генә китермәс төслеләр.

Гел тынмас төсле бураннар,
Бар җиһан ап-ак карда.

Күңелләрне җылытырлык
Әле дә язлар бар алда. («Сыерчык бураннары») [7]
Туган ягыгызда сезнең
Калын урманнар бармы?
Горур имәннәр үсәме,
Җиләк-җимешкә баймы? («Туган авылым») [7]

Бар, Лилия, калын урманнар да, шифа чишмәләре дә, каеннар, таллар, җиләк-җимешле әрәмәләр, җир җиләкле аланнар да бар! Мин дә синең кебек туган авылым, Ыгым, матур табигатем, данлы, тырыш авылдашларым булуы белән бәхетле!

Авылымнан җыенып чыгып киттем,
Каеннарым озата бардылар.
«Кабат безгә әйләнеп кайт!» - диеп,
Күңелемә шатлык салдылар.
Каеннарым озата калдылар. («Каеннарым шавы») [7]

Лилия Ясирровнаның бөтен барлыгы, эчке дөньясы туган ягын шашып ярату, бүгенге тормышның матурлыгына дан җырлау һәм шул ук вакытта кайбер тискәре күренешләргә борчылу кебек халәттән тора. Шагыйрьнең хисләре үзенчә, ул үзенчә фикер йөртә, үзенчә хөкем чыгара. Аның шигырьләре үзенекен итә: уйландыра, канат куя, борчуга сала. Шигырьләрендәге лирик герой-олпат акыллы нәфис татар кызы. Ул ана да, киңәшче дә, хөкем чыгаручы да, шул ук вакытта туган якның изгелеген искәртеп торучы бер илаһи зат та.

Шагыйрә иҗатына якташ язучыларыбыз да битараф калмады.

« Шигырьнең тәэсир  көчен автор эчке рифма белән дә арттыра.  Укучы, үзе дә сизмәстән, лирик геройның уй - теләкләренә кушылып китә» - дип яза Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, үзебезнең районыбыз язучысы Мөҗәһит Әхмәтҗанов. [3]

«Лилиянең шигырьләрен мин бик җентекләп укыдым. Укыдым, укыдым – укып туялмадым. Яхшы кассетаны кат - кат әйләндергән кебек, кабат - кабат укыдым» - диде Әхмәт Дусайлы. [1]

«Шагыйрь кеше өчен иң мөһиме-укучыны үз артыңнан ияртү, аны хыял иленә алып керә алу. Ә моның өчен үзенчәлекле, талантлы каләм иясе булу кирәк. Л. Садриеваның иҗаты башка хатын-кыз шагыйрьләрнекеннән үзгә. Сәбәбе: аның халыкчан тел белән беркемне дә кабатламыйча иҗат итүендәдер»- дип үз фикерләрен әйтте Ләйлә Ялалова.

“Мин генә түгел, бик күпләр Лилиянең балачак сукмакларыннан йөреп, аны иҗатка рухландырган төбәкнең гүзәллегенә соклану хисе кичергәндер”- дип язды редакциядә эшләүче Ә.Ногманова. [3]

Мин лирик геройның гади шигырь укучыларга тәэсир итү көчен дә тикшердем.

«Шигырьләр минем күңел кылларын тибрәтте. Мин әти-әниемнең балачагына кызыгам. Әбием яшәгән Колын авылына кайтасым, бакча артындагы чишмәгә төшәсем, Борынчык болынына бөрлегән җыярга барасым килде» - диде 28 яшьлек Ландыш.

«Мин Дөм каенда җәен кызыл бөрлегән, кура җиләге, көзен гөмбә җыйган вакытларымны искә төшердем» - диде 33 яшьлек Рушания.

«Велосипед белән Шифа чишмәсенә баруым, андагы түгәрәк күлгә сокланып карап торуларым минем хәзер дә исемдә» - диде 43 яшьлек Гүзәлия.

«« Очратырмын димә урамнарда
Сабакташны, иске танышны»- дип дөрес язган Лилия. Урамда уйнап йөрүче балалар да юк. Сугыш чорында да эшләп торган балалар бакчасы да эшләми хәзер»- дип зарланып куйды 84 яшьлек Насих бабай «Рәнҗеттек бугай» шигырен укып күрсәткәч.

## Йомгаклау

Лилия Яссировна төрле дәрәҗәдәге укучылар аңлый алырлык итеп фәлсәфи фикер йөртә. Шуның белән кеше күңеленә үтеп керә. Анда үзе теләгән хисне кузгатырлык орлык та салып куя.

Мин гүзәл Мөслимебездә яши һәм иҗат итә торган шагыйрәбез иҗатына гашыйк. Мин генә түгел, күпләр, бик күпләр Лилиянең балачак сукмакларыннан йөреп, ул эчкән саф

чишмә сулары белән сусауларын басып, аны иҗатка рухландырган төбәкнең гүзәллегенә соклану бәхете кичергәндер. Язучының шигырьләрен тәкъдим итеп бик күпләрдә шушы хисне тудыра алсам, алар чын туган җирен яратучы, хөрмәт итүче шәхесләр булырлар иде.

Фәнни-эзләнү эшем барышында мин үз алдыма куйган максат һәм бурычларга ирештем дип уйлыйм.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: башкарылган эшем, тупланган материалларның башкалар өчен да файдалы булуын теләр идем.

**Эзләнү чыганаклары**

1. “Авыл утлары” газетасы, Гомерләр язлардан башлана – мәкалә, 2002 нче ел. – 13 апрель.

2. “Авыл утлары” газетасы, Шагыйрә – бар!– мәкалә, 2002 нче ел, декабрь.

3. “Авыл утлары” газетасы, Шигърият аланында – мәкалә, 2002 нче ел.

4. Әхмәтҗанов М. Рекомендация (Шагыйрә Лилия Садриевага Татарстан Язучылар берлегенә керү өчен), 2003 нче ел, 26 март.

5. Әхмәтҗанов М. Якташ әдипләребез. Мөслим, 2002 нче ел.

6. Садриева Л. Өр-яңа яз.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2002 нче ел.

7. Садриева Л. Күңелләр чәчәк тели.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2012 нче ел. (27, 29, 82, 95, 96, 102, 103)

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан. «Матбугат йорты» нәшрияты. 2005. - 437 бит.

**Гайнетдинова А.Р.**
**Югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**“49 нчы кадет мәктәбе” муниципаль**
**гомуми белем бирү учреждениесе**

## Күңелне кузгаткан моң

I. Кереш.

Кеше җирдә ни өчен яши? Үзенең кыска гына вакыты эчендә ул барысына өлгерергә, барын да танырга, белергә, үзе дә эшләп карарга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне җиңеп чыгарга тырыша. Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәсәпсез” дип халык юкка гына әйтмәгән. Һәр кеше үзенең якташ язучыларын  белергә тиеш дип уйлыйм . Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган йортының, үз халкының кадерен беләчәк.

Татар әдәбиятына шагыйрь буларак килеп кереп, проза мәйданына «күчкән» талант ияләре аз түгел. Гадәттә, болар язган чәчмә әсәрләр хис–кичерешләргә бай булулары, лиризмы белән, ассоциатив сурәт тудыру мөмкинлекләренең зурлыгы ягыннан аерылып тора.

Мин дә бу эзләнү эшемдә татар әдәбиятының мактанычы, горурлыгы булган язучыларның  берсе Айдар Хәлим иҗатын яктыртырга булдым.

Хезмәтемнең төп максаты – Айдар Хәлимгә  Шагыйрь, прозаик  һәм Олы шәхес буларак бәя бирү, аның иҗатына күзәтү ясау.

Төп максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

-әдипнең тормыш юлын кыскача бәян итү;

-аның хикәяләренә күзәтү ясау;

Хезмәтем кереш өлешеннән, төп өлештән, йомгаклау һәм әдәбият исемлегеннән тора. Кереш өлешендә эзләнүнең гамәли әһәмияте, максаты бурычлары күрсәтелә. Төп өлештә, Айдар Хәлимнең эшчәнлеге, эзләнүчән, талантлы язучы  булуы яктыртыла. Йомгаклауда эзләнү нәтиҗәләре тәртипкә салына. Әдәбият исемлегендә файдаланылган чыгынаклар күрсәтелә.

II.Төп өлеш.

1.1 Сүземне күренекле сәясәтче, шагыйрь, драматург, бик тә талантлы публицист,

иң уңай мәгънәсендә милләтче, Татар Милли Мәҗлесе җитәкчесе Айдар Хәлимнең тәрҗемәи хәленә күз салудан башлыйм .

Айдар Хәлим... Табигать аңа нечкә тоемлау, тынгысыз йөрәк биргән. Балачагы югалтулы тирән кичерешләр, мәңге әрнүле язмыш алып килгән.

Ул 1942 нче елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Кәркәлетамак авылында укытучы Нәҗметдин абый гаиләсендә төпчек бала булып дөньяга килә. Заманына туры китереп, педагог әти улына Борис дигән исем куштыра, һәм өч көннән фронтка китеп бара. Сугыш бетәргә 4 ай калгач, ул Словакиянең Татар тауларында барган көчле бәрелешләрнең берсендә һәлак була.

Колхоз авылында тормыш бервакытта да җиңел булмаган. 1947-1948 еллар җәендә кечкенә Айдар ялланып көтү көткән абыйларына булыша. Малай башлангыч белемне туган авылында, җидееллык белемне Олы Кәркәледә ала. Урта мәктәпне район үзәге Кыргыз-Миякәдә тәмамлый.

1964 елда Айдар Хәлим Казан дәүләт университетының журналистика факультетына, зур конкурс үтеп укырга керә. Казанда яшәвенең беренче көннәреннән алып ул газета-журналлар, Татарстан радиосы белән хезмәттәшлек итә башлый. Рәшит Әхмәтҗанов әдәби даирәгә алып керә, язучылар белән таныштыра.

1966 елда “Казан утлары” журналының сентябрь санында А.Хәлимнең шигырьләре Мостай Кәрим сүз башы белән басыла һәм яшь шагыйрь зур әдәбиятка юл ала. 1967 елда Казан утлары” журналының сентябрь санында

аның “Колмак җыя кызлар” һәм ”Тальян” дигән шигырьләре беренче тапкыр Айдар Хәлим тәхәлләүсе астында басылып чыга.

Театр һәм фото белән мавыгу шулкадәр көчле була ки, бер мәлне аның алдына “Кем булырга?” дигән сорау килеп баса. Шигърият җиңә.

Айдар Хәлим Казанда шагыйрь буларак туса, Уфада шагыйрь һәм шәхес буларак чәчәк атса, Чаллыда ул публицистик һәм чәчмә әсәрләр остасы буларак киң танылды.

Каләмдәше Рәдиф Гаташча әйтсәк, “тынгысыз җанлы, күпьяклы талант, гаҗәеп уңган шагыйрь”.

Шигъряттә А.Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары ( “Беренчеләр”, “Ул елда”, “Өмә”, “Печән чапканда”, ”Яралы бөркет”, “Эксперимент-86”) белән билгеләнә.

Тормышның бик авыр һәм киеренке бер минутында кыйналып һәм тапталып, рәхимсез рәвештә эзәрлекләнеп, төшенкелеккә бирелергә тиешле бер чакта үзенең көндәлегенә әдип менә бу юлларны язып куя” “Әле бит минем дөньяны үземдә булган тел һәм үзем кичергән кичереш белән нәфис әдәбият – прозада ачасым бар. Минем бит әле “Айдар Хәлим прозасы”н тудырасым бар!..” . [7, б. 132-133]

Айдар Хәлим прозасы – яшәешебезнең көзгесе, милли сурәтебезнең гарип формаларга керүен татарның үзенә күрсәтү, ваемсызлык йокысына талган милләттәшне уяту идеясенең нечкә сәнгать алымнарына төренеп, әдәби формада чагылыш табуы. Айдар Хәлим – безнең тормышның аналитигы, андагы кара күренешләрнең тамырын эзләүче һәм табучы, татарның саф сыйфатларына мөкиббән киткән гашыйгы, милли рухның югалуына әрнүче һәм чаң сугучы фидакарь әдип. [8, б. 132-133]

Айдар Хәлим прозасының нигезендә тирән моң ята. Татарга гына хас булган, бары тик татар җаны гына аңлый, шуны гына тетрәтә торган тирән моң.

Бирелә сүзне бары тик әдәбиятның бик тә серле хасиятләренә ия булган хикәя жанры турында гына алып барырбыз. Әлеге жанрның серле куәте шунда: теләсә кайсы иҗатчы укучыны үзе артыннан ияртерлек һәм уйландырырлык тылсымга ия булган хикәя иҗат итә алмый. Айдар Хәлим -үзенең каләме белән хикәяне хәрәкәтләндерүче эчке яшерен көчләрне оста тойган, жанрның хасиятенә төшенгән бәхетле язучы. Бик тә лирик исемле “Кылганнар чәчәк атканда”, “Трофей ашъяулык”, “Җырлар вакыт”, “Берлинга хат”, яңгырашы белән үк сискәндереп җибәрә торган “Казыктагы тальян””Кара кышта” публицистик аһәң белән өретелгән “Эңгер”, “Авылдаш” , сатирик пафос белән кушылган

фаҗигане сурәтләүче “Сандугач белән Карлыгач” –әдип каләменнән соңгы елларда чыккан хикәяләрнең тулы булмаган исемлеге шулардан гыйбарәт.

Айдар Хәлим - хикәя кысаларында образның киң эчке дөньясын, аның калыбында барган үзгәрешләрне, ул үзгәрешләрнең сәбәбен сыйдыра алган, үткән гасырның утызынчы елларыннан башлап бүгенге көнгәчә татар җаны нидән сыкрануын сурәтләгән каләм иясе. Бу җәһәттән аның “Казыктагы тальян” хикәясе игътибарны җәлеп итә. Хикәядә әдип чор вакыйгаларына бәяне уналты яшьлек үсмер малай күңелендәге кичерешләр аша бирә. Вакыт-вакыт авторның аналитик каләме кайбер публицистик гомумиләштерүләр ясап куйгаласа да(бу әдип прозасына хас сыйфат), хикәядә нигездә аның персонажы Бәгърем хисе, аның күңелендә барган эзләнүләр, лирик чигенешләр ясый -ясый, үзалдына куйган катлаулы сорауларга җавап табарга омтылышлары урын алган.

Айдар Хәлимнең “Казыктагы тальян” хикәясе субъектив образ, ягъни хикәяләүче исеменнән бәян ителә. Эпик әсәрдә хикәяләүче – автор белән якынаерга да, нейтраль яки үз позициясен ачык белдерүче булырга да мөмкин. Әсәрнең хикәяләүчесе – үз позициясен, мөнәсәбәтен ачык белдерүче зат. Аның үз героен Бәгъремне тасвирлавы, егетнең уй-фикерләрендә, хис-кичерешләрендә калкып чыккан каршылыкларга битараф калмавы күзгә ташлана. Бәгърем –егетлек, ирлек, булдыклылык, эзлеклелек кебек татарда мактала торган сыйфатлар иясе.

А.Хәлим – символлар теле белән эш итә белгән нечкә тоемлы язучы. Ә бу тел бары тик талант ияләренә генә буйсына һәм аларга гына үзенең серләрен ача. [2, б.120] Ясалма образлардан автор символларга мөрәҗәгать итә. Бәгърем образы символ булып килә. Туры мәгънәсендә егет исеме сөю хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе символ була. Егетнең әнисе Тәнзилә үлгәндә “улыма Бәгърем исеме кушыгыз” ди. Әйе, яраткан кешегә без төрле матур сүзләр белән эндәшәбез. Мәсәлән, бәгырь кисәгем, бәгырем кисәге, сөеклем, җаным һ.б. Әсәрдә мондый өзек бирелә: *“Аңлагансыздыр: Бәгърем исемле ул. Бәгърем исемле бегърем, димәк. Аңлагансыздыр: аның исемендә үк нииндидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде. Уйлап кына карагыз: Бәгърем кадәр бегъремне яратмаска, инкяр итәргә, аеруча ташлап китәргә мөмкинме? Мөмкин түгел. Шуңа күрә дә Бәгърем бит ул. Син Бәгъремгә: “Мин сине яратмыйм, Бәгърем” – дип әйтеп кенә кара!..”* [5, б. 124]

Шулай итеп, хикәядә Бәгърем образы, характеры үзәктә тора. Бәгъремнең характер буларак тулы итеп тудырылуы егеттәге акыл һәм хис көрәшенең, аның кечкенә чактан ук бергә уйнап үскән дусты Разиясын югалту һ.б. ышандырырлык итеп укучыга җиткерергә булыша.

Бу хикәясендә автор фаҗиганы персонажларның күңел дөньясында барган кичерешләр аша тасвирлый. Монда совет чорының кешелексез сәясәте һәм татарның үз битарафлыгы нәтиҗәсендә туган катлаулы кичерешләрнең сурәтләнеше дә, аларга авторның төгәл бәясе дә урын тапкан.

Сүзне без моң дип башлаган идек. Моң... Бу сүзне тәрҗемә итеп булмый диләр. Айдар абыйның “Өч аяклы ат”ын, лирик хикәяләрен дөнья телләренә тәрҗемә итеп таратыр идем. Татар моңы булып яңгырасын иде алар башка милләт вәкилләренең күңелләләрендә.

Йомгаклау.

Хезмәтемне йомгаклаганда, шуны искәртеп үтәсем килә: чыннан да Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек. Утрау... Ачылмаган утрау... Беренче карашка артык җитди тоелмаган тормыш ваклыкларын да энҗедәй балкып торырлык, тирән мәгънәле сәнгать һәм тормыш күренешенә әйләндерә белә.

А.Хәлим хикәяләренең повесть дип атарга мөмкин булганнарының байтагында төп геройлар – сабыйлар яисә сабыйлыктан яшүсмерлеккә чыгып килүчеләр.Тормышка сабый күзләре белән карау, күренешләрнеяшүсмерлеккә хөкем аша үлчәү, шуларның күңел бизмәннәренә салып, бәхет-хәсрәт, гаделлек-имансызлык, матурлык-сыйфатсызлык, миһербансызлык-юньсезлек кебек күренешләрне бәяләү, шуларны күрә-күрә, бу тигезсез һәм мәрхәмәтсез тормышта үз урыныңны табарга тырышу – менә Айдар Хәлим

әсәрләрендә еш очрый торган мотивларның кайберләре...

Гомумән алганда, А.Хәлим иҗаты үзенең масштабы белән гаять якты, чекрәеп янган йолдызлар белән бизәлгән күк гөмбәзен хәтерләтә.

Сүзне без моң дип башлаган идек. Моң... Бу сүзне тәрҗемә итеп булмый диләр. Айдар абыйның "Өч аяклы ат"ын, лирик хикәяләрен дөнья телләренә тәрҗемә итеп таратыр идем. Татар моңы булып яңгырасын иде алар башка милләт вәкилләренең күңелләләрендә.

Әдәбият исемлеге.


1. Әдипләребез. Библиографик белешмә. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2009, 564 б.

2. Бәйрәмова Ф. Ак һәм кара көрәше.// Казан утлары. – 2001. - № 12. – 119-128

3. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. - Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004, 247 б.

4.Сверигин Р. "Кыйблага кайту". Казан утлары.-2017.-№1, 164 б.

Фәтхерахманов Р. Йөрәкнең җеназасы.// Казан утлары. – 2003. - № 11. – 132-138 б.

5. Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002, 383 б.

6.Хәлим А. " Милли шигырьләр". Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2001.

7. Хәлим А. "Кыйбла". Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2005.

8. Фәтхерахманов Р. Йөрәкнең җеназасы.// Казан утлары. – 2003. - № 11. – 132-138 б.



**Галимуллина Г. М.,**

**Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты**


## АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Татар әдәбиятында заман шаукымына иярмәгән, кыйбласына тугрылык саклаган, әсәрләреннән зыялылык өртелеп торган әдипләр төркеме бар. Халык язмышы, милләт язмышын иң югары кыйммәт дип таныган мондый әдипләр арасында Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) лаеклы урын алып тора.

Айдар Хәлим 1942 елның 1нче гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туа. А.Хәлим тормышны төрле яктан күргән, төрле өлкәләрдә эшчәнлек күрсәткән тәҗрибәле шәхес. Аның азатлыкка омтылу, каршылыкларны җиңеп чыгу, кыйбласына тугрылык саклау кебек сыйфатлары Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешендә эшли башлагач ук ачык чагыла башлый.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. 2003 нче елда әдип Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты булуга ирешә. Әйтергә кирәк, иҗатының үзенчәлекләре, идея-эстетик кыйммәте, бүгенге әдәбиятта тоткан урыны А.Хәлимнең үзе тарафыннан да тикшерелә. Мәсәлән, балалар шигъриятендә "Орчык-малай Биктырыш" поэмасының ролен өйрәнгән хезмәте шундыйлардан санала ала [4]. Әдипнең балалар өчен язылган хикәяләре үсмерлек чорына кереп баручы балаларны изгелек һәм яхшылык, милли хәтер, җан сафлыгы кебек төшенчәләр белән кызыклы, шул ук вакытта уйланырга этәрә торган формада таныштыра. Татар җанын, татар рухын тоеп яши һәм эшли торган балалар тәрбиләүче мондый әсәрләрне фәнни өйрәнү – бүгенге чорда актуаль проблема булып тора.

А.Хәлим иҗаты әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан игътибарсыз калмый, аның тормыш юлы һәм иҗаты олпат галимнәр, язучылар тарафыннан өйрәнелә. Мәсәлән, аның иҗатына югары бәя бирүчеләрдән, "милләт каһарманы" дәрәҗәсенә күтәрүчеләрдән Ф.Бәйрәмова, М.Әхмәтҗановны атарга була. Әдип иҗаты шулай ук Р.Рахмани һәм Р.Сверигин кебек әдәбият галимнәре тарафыннан төрле аспектларда өйрәнелә.

Фәнни-тикшеренү эшенең максаты – Айдар Хәлимнең балалар әдәбиятында тоткан урынын һәм "Тал баласы Талхаветдин", "Казанбаш", "Кыяр караклары" әсәрләрен идея-

эстетик аспектта анализлау.

Максатка ярашлы рәвештә, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1) А.Хәлимнең балалар әдәбиятында тоткан урынын билгеләү;

2) А. Хәлимнең әсәрләрендә әхлакый проблемаларның бирелеше һәм чишелешен күрсәтү;

3) А. Хәлимнең әсәрләрендә фәлсәфи проблемалар бирелешен ачыклау.

Тикшеренү объекты итеп А.Хәлимнең "Тал баласы Талхаветдин", "Казанбаш", "Кыяр караклары" әсәрләре алынды.

Тикшеренү предметы – әсәрләрдә күтәрелгән әхлакый һәм фәлсәфи проблемалар.

Кулланылган тикшерү методлары: тасвирлама, психологик, чагыштырма.

Эшебезнең гамәли әһәмияте анда тәкъдим ителгән материалның филология факультеты студентлары тарафыннан семинар дәресләргә, конференцияләрдә чыгыш ясарга хәзерләнгәндә кулланылу мөмкинлеге белән билгеләнә.

**1. "Тал баласы Талхаветдин" әсәрендә әхлакый һәм фәлсәфи катлам**

Әсәр тартмалы композициягә корылган. 19 хикәя бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп тулы бербөтенгә оеша. Әсәрнең һәр бүлеге татар милләтенең, татар халкының тарихын, үсеш чорын тасвирлый. Аның структурасы түбәндәгедән гыйбәрәт:

- "Болыттан туган тал баласы" хикәясе кешелекнең барлыкка килүен тасвирлый;
- "Таллар шатлыгы" – башка милләтләр белән бер рәттән татар милләтенең формалашуын күрсәтә;
- "Төн һәм көн" – әйләнә-тирәбездәге һәр нәрсәне бар иткән, мәңгелек мәрхәмәт, изгелек һәм рәхмәт иясе – Аллаһы Тәгалә;
- "Һавалар нигә зәңгәр?" – татар халкы кичергән авырлыклар аларга аерым хәтер бүләк итеп, аларны беркайда да адашмас һәм беркайчан да бер-берсен ташламас нәселгә әверелдергән;
- "Арбадагы сәяхәт" – сабырлык һәм күп көч куеп кына нәтиҗәгә ирешеп булу турында;
- "Кем акча югалтты" – татар халкы дин тыелган заманаларда яшәсә дә, үз диненнән баш тартмый. Безнең изге китабыбыз "Коръән Кәрим"ебез бар;
- "Йөзү остасы" – яхшы гамәлләр кылу өчен тирән акыл, тырыш кул белән теләк кенә кирәк;
- "Диңгез ярында сөйләшү" – татар милләте кыйналып җиңәргә өйрәнә;
- "Уенчык кибетендә" – бәхетле булу өчен кыйбатлы уенчыклар да, таш диварлар да кирәкми, бары тик Ватаның, туган йортың, якыннарың янында булу кирәк;
- "Беренче намаз" – бар нәрсәне барлыкка китергән өчен без Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтебезне намаз аша җиткерәбез;
- "Кискән саен үсә торган тал-металл" – "без мәңге үлемсез. Без – тал-татарлар! Без киселгән җирдән генә түгел, сагынудан җиргә тамган күз яшеннән дә үсәбез!";
- "Үзәгеңне сакла балам!" – сабырсыз, ялкау булсаң эшнең нәтиҗәсе аянычлы була;
- "Боз сөңгесе, Күргән һәм Күрмәгән" – "иртә торсаң ит пешә, соңга калсаң бит пешә";
- "Кайсы тәмлерәк?" – һәр кәвемнең, һәр кешенең яраткан ризыгы була. Татарларның төп ризыклары – бәрәңге һәм икмәк;
- "Күрше хакы" – безнең якыннарыбыз, дусларыбыз нинди генә милләт вәкилләре булмасын без аларга яхшылык кына эшләргә тиеш;
- "Авыл бетмәячәк!..." – авылларның яшәешендә татар милләтенең киләчәге;
- "Булмаганны чүпли" – кешеләрнең булганнары һәм булмаганнары да бар;
- "Туган тел" китабы" – татар милләтенең горурланырдай бөек шәхесләре, туган телләре – татар телебез бар;
- "Шифаханәдә" – безнең үз кануннары булган саф, пакь динебез бар;

Әсәрнең төп герое тал баласы Талхаветдин символ дәрәҗәсенә җиткерелеп, милләтнең киләчәге кебек мәгънәви эчтәлекне үзенә беркетә.

Бу әсәрендә А.Хәлимнең милли концепциясе үзенчәлекле итеп ике катламда бирелгән:

1) Һәр хикәядә Талхаветдиннең төрле сыйфатлары ачыла бара, шулар аша язучы татар милләтендә күрергә теләгән сыйфатларны барлый:намуслы, бердәм, юмарт, батыр,

эшлекле, көчле, тырыш, сабыр, түзем, игътибарлы, нечкә күңелле, оялчан, бәхетле, гөнаһсыз, акыллы, иманлы;  Һәр хикәядә автор милли идеянең мәгүнәви эчтәлеген ача: тарих, намус, Аллаһы Тәгалә, тырышлык, хәтер, авыл, Коръән Кәрим, милләт, акыл, иман, ватан, туган тел, туган җир, туган йорт, хезмәт, ата-ана;

Әлеге әсәрнең кызыклы ягы тагын шунда, автор балаларга фикерне әйтеп бетерми, балада сорау туу мөмкинлеге, уйлану өчен җирлек калдыра.

## 2. "Казанбаш" поэмасының иде-эстетик кыйммәте

Поэма бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп тулы бербөтенгә оешкан 8 бүлектән гыйбәрәт. Әсәрнең һәр бүлеге татар милләте, татар халкының тарихын барлауга һәм шуңа бәйле горурлык хисләре белән януга корылган.

Аның структурасы түбәндәгедән гыйбәрәт:

I бүлектә поэма герое балаларны кызыксындырып үз балачагына сәяхәткә чакыра, дуслары Камил һәм Вәкил белән таныштыра. Төп герой "кишер карагы" кушаматына ия булган биш яшьлек, гаиләдә төпчек бала. Малайлар бик тату яшиләр, аларны бер хәсрәт берләштерә:

"Бер кашыктан ашап үскән әхири-дусларыбыз,
Әтиләр сугышта үлеп, югалткач хушларыбыз,
Газиз әнкәйләребез канаты асларында
(Алар безгә бирә иде кабасы ашларын да!)
Без ике ятим гаилә, бүлешеп ярты-ярым,
Яшибез бер оя булып – ястыклар гына аерым" [5, б.4].

II бүлектә А. Хәлим игътибарын туган якның матурлыгына, хозурлыгына юнәлтә:

"Кырылган инешең буйлап озатып килә таулар,
Гүя таулар үзәннәрне җитәкләп барган баулар.
Уралтавыбыз бай ташка – чакматаш, якутташка,
Айташ, майташ, гәрәбәташ, беләүташ, тактаташка"
"Менә урманга да җиттек. Саумы, әй, серле урман!
Үзең түшәк, үзең мендәр, үзең үк йомшак юрган!" [5, б.8]

III бүлектә исә А. Хәлим тарихка мөрәҗәгать итә.

"Монда карттәйләр ук юнган, тире иләп, теккән садак,
Яндырып күмер, эретеп тимер, ясаган дага, кадак;
Көтүләр көтеп, җәйләүдә мал чалып, ит каклаган,
Сәнәк саплап, кием баплап, дошманнан ил саклаган;
Монда карт инәйләребез күренми илгә артык,
Гөбердәтеп сыер сауган, оеткан төче катык;
Каймак язып, май таскыган, кайнаткан ачы корыт,
Ак гөбедә кымыз пешкән таңнардан иртә торып..." [5, б.10].

IV, V бүлекләрдә урман үзенең бар матурлыгы белән сурәтләнә. Урман – ниндидер бер сихри көчкә ия. Аның һәр агачыннан, һәр яфрагыннан җан өркеп тора. Табигатьнең, туган якның матурлыгына сокланып, яшел үләндә тәгәрәгәндә кинәт кенә балаларны "нифте базы"на ташлаучы Казанбашлар барлыкка килә.

Ләкин "кишер карагы" моңа юл куймый, ул бөтен авыл халкын бу "гыйфритләргә" каршы көрәшкә чыгара:

"Артка боролып карасам – күтәрелгән бар авыл:
Кемдә уклау, бәләк, җәмкә, кисәүагач, сыргавыл,
Кемдә чалгы, кемдә көрәк, тырма, йә шунда сәнәк,
Тотып колган, чыккан юлга – коралланганнар һәлак!" [5, б.22].

Әлеге сюжет VI-VII бүлекләрне тәшкил итә.

VIII бүлектә исә автор чынбарлыкка кайта. Киләчәктә "күктә янсын якты кояш, җирдә – илһам утлары, нифте даулап, бомба ташлап, үтмәсен самолетлар" [5, б.26] дигән теләк белән әкиятен тәмамлый.

Гомумән алганда, поэманың сюжет-композицион яктан төзелеше үзенчәлекле: әкият

эчендә әкият рәвешендә язылган.

I әкиятнең нигезенә Казанбашлар турындагы риваять салынган. Имеш, Ишембай якларыннан башларына казан кигән кешеләр килеп, балаларны тотып алалар, җир мае базларына салалар да, каннарын сыгалар икән.

Моның нигезендә II әкият барлыкка килә. Ул Вәкил белән Камилнең лирик геройны алдавыннан башланып китә. Беркатлы авыл баласы, үзенең туган нигезе, милләттәшләре өчен борчылып, бөтен авыл халкын шул “бала ашаучылар”га каршы күтәрә. Ләкин дөреслек ачылгач та, лирик “мин” борчылмый, киресенчә, анда горурлык хисе уяна, чөнки ул үз милләтенең киләчәге өчен көрәшердәй шәхес булып үсә.

Әлеге поэмада автор сугышка, тарихка бала күзлегеннән бәя бирә. Чөнки татар халкының үсеш дәверендә басып алулар, сугышлар күп булган, ләкин татар халкы каршы тора алырдай зур һәм көчле милләт. “Казанбаш” поэмасының төп герое да милләтебезнең киләчәге өчен көрәшергә өнди:

“Әйдәгез, тотып тастымал, аңарга каршы барыйк,
Егып үзен, бәйләп күзен, безнең коега салыйк!” [5, б.24].

Ул сугыш фаҗигасен татыган, ләкин шул ук вакытта бала булып кала алган герой. Балаларга хас барлык сыйфатларда: шаян, тәвәкәл, самими, хыялый, киң күңелле, кызыксынучан, игътибарлы, куркак һәм шул ук вакытта батыр, беркатлы, авылҗанлы, тырыш, шул ук вакытта акыллы, баһадир, милләтенең, нәселенең үткәнен белүче көчле һәм горур образ.

Элеге сыйфатлар лирик “мин”не символ дәрәҗәсенә күтәрә һәм милләтнең киләчәге дигән мәгънәви эчтәлекне үз эченә ала. Автор лирик герой аша балаларда нинди хис тәрбияләргә икәнен ачып бирә. Ул милләтнең киләчәген татар халкының тарихын белгән, ана телен хөрмәт итүче, халкыбызнең традицияләрен саклап килүче – татар авылларының киләчәге өчен көрәшә алучы, үзенең татар милләтенең бер вәкиле булуы белән горурланучы шәхесләрдә күрә.

“Казанбаш” поэмасында татар халкының бөек шагыйре, Г.Тукай традицияләрен тоемларга була. Әсәрнең сюжет-композициясе, образлар бирелеше, идея-тематикасы Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасына охшаш.

Тарихи яссылыкта карасак әлеге әсәрдә А. Хәлимнең азатлык һәм табигать белән кеше бердәмлеген яклап чыгуы ачык күренә. “Казанбаш” образын ике яклап ача:

- беренчедән ул “Казанбашларны” немец сугышчылары белән чагыштыра: “Әтиләребез, нәкъ шул казан сыман “каска” кигән немец-фашистларына каршы сугышта һәлак булганга, күрәсең, бу “Казан-баш”лар безнең күз алдыбызга басканчы дошманнар рәвешендә киләләр иде” [5, б.2].

- икенчедән “Казанбаш”лар образы ярдәмендә А. Хәлим чорның рухи фаҗигасе – кеше белән табигать гармониясенең җуелуы турында сөйли:

“Шәпкорсаклар, капкорсаклар – корсакларында боргыч.
Шуннан нифте атыла ди җир астыннан суыргач.
Табигатьне җен ясый, ди, шакшы нифте базлары –
Дегет эчеп карая, ди, ап-ак авыл казлары!...” [5, б.16].

Поэманың тагын бер үзенчәлеген әйтеп үтәргә кирәк:

“Мин бүген дә сабыйларны казан башлардан саклап,
Утырам Мендәрле Күлда тау яклап – урман яклап.” [5, б.26]

– дигән строфалар төп герой һәм автор арасында параллель уздырырга мөмкинчелек бирә. Чөнки А. Хәлим татар милләте, ана телебез – татар теле өчен янып-көюче шәхес.

Шул рәвешле, “Казанбаш” поэмасында балачак, табигать, авыл матурлыгына фаҗигале милләт язмышы каршы куела. Дуслык, тугърылык, бердәмлек, горурлык, мәхәббәт, тынычлык кебек кыйммәтләр поэманың үзәгенә ята.

**3. “Кыяр караклары” әсәрендә әдәп-әхлак мәсьәләләре**

Айдар Хәлимнең күп кенә әсәрләрендә бала образы мөһим роль башкара. “Кыяр караклары” әсәре үсмерлек чорына кереп баручы балаларны милли хәтер, җан сафлыгы, гаделлек кебек төшенчәләр белән кызыклы, уен формасында таныштыра.

Әсәрнең төп геройлары, Шәрифҗан картның сугыш турындагы маҗараларын тыңлап үскән “кыяр караклары”, кыяр басуына һөҗүм итү планын коралар:

“Менә әле дә кыярлар янына кермәс борын
Безне танымасын, диеп буйыйбыз биткә корым.
Без Һинд Чингачгук сыман, башларга тасма бәйләп,
Ук-җәяләребездән аркага йөкләп корал,
Һәркайсыбыз кыяр өчен үләргә әзер тора” [6, б.5].

Шәрифҗан карт исә Мисыр мәкаме белән изге гамәл – намаз уку белән мавыгып киткән арада малайлар тавыш-тынсыз капшаштырып, кыярларны уятып изү аша күлмәкләренең эченә озаталар, юллары уңса күлмәк эченә утыз биш кыяр сыя.

Шәрифҗан карт әлеге гамәлләре өчен малайларны ачуланмый, чөнки аларны әлеге адымга барырга шушы чор вакыйглары мәҗбүр итә, алар бит ачлык чоры балалары: “Изү ачык. Бил буыла. Ул, бусаң да буш була.”. Алай гына да түгел балаларны яраткан агалары моңа үзе өйрәтә.

Шәрифҗан карт, әлеге әсәрдә гомумкешелек сыйфатларына ия булган татар карты буларак бирелә:

“Яхшы кеше ул, әлбәтта. Ачык җирдә җил кумас.
Йомшак күңелле. Безне һич эш өстендә борчымас.
Гади түгел безнең бабай. Брусилов әрмәсендә
Ул ярманнан яра ала Сандомир тирәсендә” [6, б.9].

Әлеге вакыйгалар әсәрне ике төп өлешкә бүлергә ярдәм итә:

I – уен өлеше: әлеге өлешкә “чингачгук” малайларының балачагы, кыяр басуын басып алу операциясен әзерләүләре керсә, II – чынбарлык өлешендә Шәрифҗан картның сугыш чоры сурәтләнә.

Айдар Хәлим балачакны “ярый-ярамый йозагы” дип атый, бары тик балачакта кеше дөньяның тәмен татып, ләззәтләнеп, керсез хыялларда яши:

“Әй, бала чак! Эзләр салып, ләззәтле газап белән
Ярый-ярамый йозагын ачасың кадак белән.
Көнен-төнен ак хыялда чикләрнең чиген узып,
Чабасың хәтер атларда – шунда табасың кызык ” [6, б.10].

Балаларның уенын сурәтләү өчен кулланылган сугыш лексикасы (“сайладык позиция”, “кайтты разведка”, “зур походка җыенган гаскәр сыман”, “командир”, “шуышабыз пластунча”, “патрон” һ.б.) безгә балалар һәм Шәрифҗан карт арасында параллель уздырырга ярдәм итә. Балаларга – кыяр кадерле булса, Шәрифҗан картка сугыш вакытында – туган җире кадерле була. Туган ягының саф һавасын, туфрактан бөркелгән кайнар дымын, хәтта әрем тәмен дә сагына ул:

“Саумы, әй, кыяр туган!...
Сөекле хуш исләреңне кем генә иснәп туйган!
Пешенгән туфрак. Яшел җил. Үтә рәт араларын
Кайнар дым. Яшь кыяр тәме... әллә нәрсәләр тагын!.. ” [6, б.8].

Сугышта Шәрифҗан ага һәм башка солдатлар туган ягы өчен үз гомерләрен, көч һәм сәламәтлекләрен җәлләмәгән кебек үк малайлар да “һөҗүм” вакытында “кыяр өчен үләргә әзер тора”.

Әлеге ике өлешне берләштерүче булып туган як табигате, аның матурлыгы билгеләнә. Баш очында кояш та җырлый, чыпчыклар оча пырлап, хәтта гади кыярны да автор “су белән кояш бәбәе” дип атый.

Айдар Хәлимнең балалар иҗатына хас бер үзенчәлеге әлеге әсәрендә дә чагылыш таба. Милләтпәрвар язучы буларак ул әлеге әсәрендә көлкеле һәм мавыктыргыч сюжет сызыгына киң, тирән мәгънә сала.

“Дәүләтең бай да – малың юк, акчаң да юк.

Шуклыктан урлыйсың кыяр – яшелчә бакчаң да юк” [6, б.10] юллары авторның сәясәткә, милләтенә булган мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. А. Хәлимнең нинди генә әсәрен алып карасак та алар татар рухы белән өртелгән булулары, иманлы буын тәрбияләүдә

гаҗәеп зур потенциалы белән, милли концепция салынуы аерылып торалар.

**Йомгак**

Әдәбиятыбызда тәнкыйтьчеләр тарафыннан да, галимнәр тарафыннан да аз өйрәнелгән өлкәләр, иҗатлары җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән каләм ияләре бар. Айдар Хәлим – шундыйларның берсе. Дөрес, фикердәшләре-каләмдәшләре аның иҗатына гомуми бәя бирәләр, кыю фикерле һәм сынмас рухлы булуы тәнкыйтьчеләр тарафыннан да ассызыкланып кителә. Әмма әдипнең иҗат лабораториясе тәфсилләп тикшерелмәгән, әсәрләренә төпле анализ әлегәчә ясалмаган. Бигрәк тә әдипнең балалар әдәбияты өлкәсендәге иҗатында ак таплар күплеге күзгә ташлана.

Әлеге фәнни-тикшеренү эше кысаларында без Айдар Хәлимнең балалар өчен язылган әсәрләренең идея-тематик эчтәлеген әхлакый һәм фәлсәфи яктан өйрәнүне максат итеп куеп, әдипнең хәтта балалар өчен язган әсәрләренең дә күп катламлы, төрле дәрәҗәдә әзерлекле укучыга юнәлгән булуы, хәтта, әйтер идек, интеллектуаль проза дәрәҗәсендә торуын ачыкладык. Ул балаларны олылар белән тиң күреп, алар белән олылар телендә сөйләшә. Аларда эш сөючәнлек, Ватанга мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләүне төп максат итеп куя. Аның әсәрләре мәктәп яшендәге балаларга аталып язылып, фәлсәфи тирәнлеге белән олыларны да таң калдырырлык әсәрләр буларак бәяләнә ала. Әмма игътибарны икенче юнәлешкә дә бирәсе килә. Соңгы елларда Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә нигезләнеп язылган яңа дәреслекләр дөнья күрде, әмма аларда Айдар Хәлимнең “Орчык-малай Биктырыш” әкият-поэмасы да, “Тал баласы Талхаветдин” хикәяләр җыентыгы да урын алмаган. Шәхсән, безнең уйлавыбызча, аның бөтен әсәрләредә моңа лаек. Әлбәттә, рус телле балаларга татар рухын аңлавы да, әсәрләрне укуы да катлаулы булыр иде, әмма татар мәктәпләре өчен язылган дәреслекләрдә Айдар Хәлимнең әлеге әсәрләре урын алырга лаек.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Даутов, Р.Н. Әдипләребез: биобиблиграфик белешмәлек: 2 томда: 2 том / Р. Н. Даутов, Р. Н. Рахмани. / – Казан: Татар. кит. нәшр, 2009. – Б. 564 – 568.
2. Заһидуллина, Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Зәкирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. / – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.
3. Хәлим, А. Тал баласы Талхаветдин: балалар өчен нәни хикәяләр /А. Хәлим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 48 б.
4. Хәлим, А. Татар балалар шигърияте һәм “Орчык-малай Биктырыш” (бүгенге балалар шигъриятенә фәлсәфи күзәтү) / А. Хәлим. – Чаллы: ҖЧҖ Диамант, 2010. – 268 б.
5. Хәлим, А. Казанбаш: төсле нәфис чыгрылыш /А. Хәлим. – Казан: «Идел-пресс», 2014. – 29 б.
6. Хәлимов А.Н. Кыяр караклары. – Казан: «Раннур» нәшрияты., 2002. – 14 б.
7. Бәйрәмова, Ф. Ак һәм кара көрәше / Ф. Бәйрамова // Казан утлары. – 2001. – № 12. – Б. 119 – 128.
8. Сверигин Р. Кыйблага кайту. – URL: http://kazanutlary.ru/?p=22716



**Гарипова Г.Ш.**
**Татарстан Республикасы**
**“Аерым предметлар**
**тирәнтен өйрәнелә торган**
**34нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**муниципаль автономияле гомуми**
**белем бирү учреждениесе**


## Биктырышлар бик кирәк.
## (Фәнни-методик эш. )

Язучы, шагыйрь, публицист
Айдар Хәлимнең барча
кылган гамәлләре, бөтен гомере -

миллəт язмышы , миллəтнең киләчәге
хакындагы уйлар белән үрелгән .

Разил Вәлиев.

I.Кереш.

Күпгасырлык тарихы булган татар әдәбиятының, шигъриятнең төп уйлану һәм хислану даирәсе –ил, халык язмышы.Һәр татар әдибе кеше язмышына гаять зур игътибар бирә, язылган һәм язылмаган кануннар хакында фикер йөртә, бүгенге көн күзлегенән чыгып бәя бирә, үз-үзе белән бәхәскә керә, нәтиҗә ясый. Язучының тулы бер иҗатын күздән кичерсәң, аңа шәхес, җәмгиять,ватан турында тирән фәлсәфә салынганын аңлыйсың. Чыннан да, шәхес һәм җәмгыять бер-берсенә мең төрле җепләр белән бәйләнгән. Өлгергән шәхес үз халкының, үз социаль төркеменең яшәешен, күргәннәрен йөрәге белән кичерә, шушы хисләр белән янып яши .

Җәмгыятьтәге кешеләрнең үз идеалы була, монсыз яшәү мөмкин түгел. Бу хакыйкать.

Безнең бабаларыбыз социаль гаделлек, дуслык –туганлык кебек төшенчәләргә табынып яшәгән. Ә милли азатлык идеясе? Тарихыбыз, ата-бабаларыбыз рухы белән бәйләп тоткан, телебезне бүгенге көнгәчә исән-имин китереп җиткергән дәүләтчелегебезне әзме –күпме булса да саклап калган идея түгелме ул? Бүгенге көндә һәр миллəтпәрвәрнең хыялы- һәр милләткә тигез хокуклар тудырылган бай, матур Татарстанда яшәү. Моңа ничек ирешергә? Югары әхлак, телең, халкың, тарихың белән горурлану –ата-бабаларыбыз саклап калган, аларның яшәү рәвеше булган иң бөек кыйммәтләр, иң изге мирастыр. Белемлелегең белән син татар кешесенең дәрәҗәсен күтәрергә, ә хезмәт сөючәнлек, тырышлык, чисталык, намуслык татарның һәр яшь буынында тәрбияләнергә тиеш. Шундый кеше генә үз милләтенең язмышына битараф булмаячак.

II. Төп өлеш .

Минем идеаллрым –халык, милләт белән бәйле хыялларым –Г.Тукай, Г.Исхакый,Дәрдемәнд, Х.Туфан, Т.Миңнуллин, Ф.Бәйрамова, Айдар Хәлим кебек милләтпәрвәрләрнең иҗади мирасында тупланган фикерләр белән бәйле.

Язучы, шагыйрь, публицист Айдар Хәлимнең “ Орчык- малай Биктырыш”китабындагы шигырьләр укучыга күңеленә бик хуш килә. Айдар Хәлим һәм “орчык –малай” Биктырыш.Язучының бу китабы озак вакытлар читтә калды.Татар китап нәшриятында, уку-укыту өлкәсендә бөтенләй күрсәтмичә, бәясез кала килде, әдәби –педагогик мирастан читтә торды.

Ниһәять, соң булса да уң булсын дигәгдәй, милли татар баласы –“Орчык-малай” Биктырышның әдәби образы дөнья күрде. Язучы үзен һәм күпләрне борчыган күп сорауларга җавап эзли кебек . Бүгенге тормышыбыз ни хәлдә? Алга китешебез нинди ? Ялгышаларыбыз бармы, нинди ? Татар милләтенә хас иманлылык, миһербанлылык, ярдәмчеллек тырышлык, хезмәт сөю белемлелек сыйфатлары тәрбияләү әдипнең һәр шигыренә салынган.

Биктырыш...Исеменнән күренгәнчә “бик” һәм “тырыш”. Йогышлы сөйкемле исем. Кечкенәләр аны чынлап та бик яратты. “Миңа дистәләгән ата –аналарның: “Сабыебыз сезнең “Биктырыш”ыгызны һәр көн кич укып чыкмый торып, күзен дә йоммый. Китап, укый-укый мунчалага әйләнде”,-дигәннәрен күп тапкырлар ишетергә туры килде”,- дип яза язучы. А.Хәлимнең шигырьләре - халыкның милли характерын, иманлы холкын, үзәген ныгыта торган серле оеткы ул . Сабыйда бишектән үк ихтыяр көче, түземлелек, батырлык сыйфатлары тәрбияләү - аның иң изге бурычларыннан берсе. Әдипнең иҗаты шуның белән бәяле, ул иң кыйммәтле асылташларга тиң.

Нинди соң ул Биктырыш? Билгеле, бик тырыш һәм эшчән. Әле укырга да кермәгән малай эшләмичә тора алмый: чебиләр ашата,көтүдән маллар каршы ала, әти-әнисе эштән кайтуга самавыр куя, катык оета, тагын –тагын әллә ниләр эшли. Чын-чынлап татар малае була да куя инде. Биктырышның юл башында торган атасы һәм бабасы - бөек Тукай. Туры Тукай .Тукаебыз да милләт балаларында тырышлык, тугрылык белем тәрбияләргә омтыла бит. “Эш беткәч, уйнарга ярый “балладасы –шуның ачык мисалы.

Әмма онытмыйк: бала һәрвакыт бала булып кала.  Балачакның милләте –бер генә – ул ихласлык, шаянлык, наянлыкка бәйле Биктырыш та иптәшләре белән уйнарга вакыт таба,” сүз уйнатып”, көйләп шигырьләр чыгара. Шундый милли сыйфатлары белән Биктырыш- әдипнең үзенең прототибы, дип фикер йөртүчеләр белән килешәм мин, чөнки һәрьяклап алар охшашлар.

Биктырышның милли характер үзенчәлеге турында турында уйланып, шагыйрь, җәмәгать эшелеклесе Р.Вәлиев китапның 2008 елда  “Мәгариф” нәшриятендә чыккан яңа басмасына язылган” Балачакны сагыну” мәкаләсендә болай яза: “ А. Хлимнең Биктырыш дигән бәянендә исеме җисеменә туры килгән малай турында сүз бара. Әйе,күңелемә бик тә хуш килде, ошады ул шук та, шаян да, зирәк тә һәм тырыш та малай!  Шул яшендә үк ул кешелек өчен иң кыйммәтле,иң кирәкле сыйфатларны әкрен –әкрен күңеленә –халкына сеңдерә бара. Тырышлык,  чисталык,  пөхтәлекнең татардагы иң гүзәл сыйфатлар булып саклану –сакланмавы киләчәктә  шушы бүгенге” Биктырыш”лардан тора . Бу бәянне укыгач,  мин бик тә сокландым, чөнки ул ике тамчы су кебек,  А.Хәлимнең үзенә, аның бала чагына охшаган.” Шуңа күрә ул әдәбиятыбызда иң кадерле мираз булып санала.

Татарны татар иткән күп кенә гүзәл сыйфатлар бар.  Белемле булу- тагын бер күркәм сыйфат. Әнә ул –татар ишек алды малае, чебиләрне ашаткан , катыгын оеткан, болдырда самаварын куйган да, инде Алладан төшкән хәләл китабын укый:

Йозагың юк, бигең юк ,
Дошманыңнан дусың күп,
Утта янмас атлы син,
Һәр халыкка якын син,
Шуның белән хаклы син,
Әй, Әлифба,  Әлифба!...

Әйе,  баланың кулында китап –хәләл ризык күк ,хәләл китап,  аны тартып алырга,  я читкә куярга беркемнең дә хакы юк . Орчык кадәр малай –Биктырыш, нибары 7 яшендә булуга карамастан, китапның ямен- тәмен белеп, туган телнең урынын аңлап өлгергән илаһи җан иясе.  Китаптан башка белем юк, белемнән башка алга барып булмый шул. Милләтне бары тик табигатьтән килгән милли сыйфатлар:  диндарлык укымышлылык тырышлык кына саклап килгән.

Шушы 3 сыйфат татар балаларын әхлакый тәрбияләүнең нигезен тәшкил иткән . Әдипләребез шушы сыйфатларны тәрбияти торган әсәрләр язган. Мәсәлән:

Ай күрдем аман белән,
Авызым тулды иман берлән!
Шушы айларда вафат булсам,
Үткәр, ходаем иман берлән !...

дигән халкыбыз изге Айны күрү белән ,күзләрен йомып укыган догасында. Әйе, иман ялварылган бу теләкне күк йөзендә яңа ай урагы күренү белән, олылар гына түгел, балалар да кабатлаган. Иман тәрбиясе шуннан башлана.

Дин, иман, намаз ...Хәтеребездә Кол Гәлинең XIII гасырда язылган “Кыйссаи Йосыф”ында агаларының кайтып, аталарына Йосыфны бүре ашавы турындагы хәбәрне җиткерер алдыннан, болай ди :

Йәгъкүб ястү намазыны укый иде,
Угълannары егълап өйгә якын килде,
Колагына егълаулары ишетелде ,
Ул ,ашыгып каршыларга чыгар имди...

Бөек Тукаебыз ,дингә багышлап ,60 ка якын шигырь язган .

Күренекле язучы, милләтпәрвәр Фәйрүзә Бәйрамова ,язучы М. Гафуриның “Адәм белән Иблис “шигыре хакында болай яза: “Адәм вә Иблиснең сюжеты һәркемгә ачык : ул Аллаһ алдында  кылынган гөнаһ һәм аның өчен Аллаһ алдында тотылган җавап” .”Җан шифасы – иман”, -диеп юкка гына әйтмиләр бит .Моны һәр зат сабый чагыннан ук күңеленә сеңдерергә тиеш.Бары шул чакта гына җәмгыять иманлы кануннар нигезендә яши ала.

Шулай итеп ,шагыйрь сабыйларга җир йөзендә иман – Аллаһ ,гадел пәйгамбәрләребек ,изгелек, явызлык, төшенчәсе барлыкка килүен аңлата.

“ Биктырыш “ әсәренең герое милли характер – холык чыганагы буларак,татар балалар шигъриятенә яңалык алып килде . Тырышлык, эш сөю сыйфатлары бүгенге татар балалары тормышында ничегрәк саклана? Биктырыш үзе исәнме, дуслары иминме ? Авырмыйлармы? Нинди авырулар белән авырыйлар?Биктырыш аларга кирәкме? Әллә аларга бүтәннәр аяк чалалар? Тырышлык ,югыйсә ,татарның исән калу чарасы да бит! Язучы бу сыйфатларны һәр укучының күңеленә керерлек итеп яза.

III. Йомгаклау .

Без зур үзгәрешләр чорында яшибез. Коммунистик идеаллар юкка чыгып, яңалары барлыкка килә алмаган заман. Яшәү көче биреп торган озын гомерле идеаллар югалды. Яшь буынга тиешле тәрбия юк. Гаделлек –гаделсезлек белән дөреслек- ялган белән, намуслык –намуссызлык белән ,юмартлык –саранлык белән,тигезлек- тигезсезлек белән алышынды хәзер.

Урлашу, алдашу, үтерү гәдәти күренешкә әйләнде .Тир түкми генә (намусны артка ташлап )байлык җыю төп кәсепкә әверелде. Буыннан буынга күчеп килгәч намуслылык ,шәфкатьлелек, олысын – кечесен хөрмәт итү авыр чакта кешегә ярдәм итү, сүзеңдә тору кебек әхлакый хәзинәләр юкка чыга бара. Бер сүз белән әйткәндә “ата-улны,ана- кызны” белми торган заманга җиттек .Әдәплеләр һәм намуслылар булдыксызлар рәтендә йөри. Бик кызганыч!

Мин моңа тыныч кына карый алмыйм. Бу тормышның ясалма булуын,гаделсезлекне күреп күңел әрни... Әхлап кануннары югала барган җәмгыятьнең тамырына бернинди сугышларсыз балта чабарга мөмкин икәнен тормыш үзе искәртә бүген. Кая китте соң бабаларыбыздан калган әхлагыбыз ? Намус ? Гаделлек ? Биктырышлар, кайда соң сез?!! Бу сүзләр хәзер күпләрне борчый торган җан авазына әйләнде.

Җәмгыятебез гадел, яшәешебез чәчәк атсын өчен ,без барыбыз да тискәре күренешләргә каршы көрәшергә тиешбез.Шулай да Биктырышлар,Фәүзия Бәйрамовалар,Айдар Хәлим кебек асылташларыбыз күбрәк булсын иде.Алар безгә бик кирәк.

Чыгышымны йомгаклар өчен ,Айдар Хәлимгә багышлап, укучым язган шигырьне китерәм:

**Татарның бөек улы.**

Ходай аңа өеп биргән:
Камил акыл,күпьяклы талант.
Орчык-малай-Биктырышны
Укыйбыз кабат-кабат.
(Әдәбият күгендә ул,
иң изге,рухи кыйммәт).

Хезмәтләре ил алдында ,
Күпкырлы иҗатында.
Тормыш гаме, милләт зары-
Айдар Хәлим җанында .

Уйчан гына, сабыр гына,
Тирән фикерле булган.
“Гаделсезлек”!-шушы каһәр
Йөрәккә кан булып уелган.

Әхлак, иман кирәк диеп,
Бик белеп чаң суга ул
Тукай кебек туры да ул
Такташ кебек моңлы ул.

Әрнүле дә, әрсез дә ул,
Таш яра һәрбер сүзе.

Горур да ул, самими дә,
Олпат шәхес –шул узе!
Күпне күрде әдип башы-
Сынмады, сыгылмады.
Алтынга саз ябышмый шул-
Күпләрне таң калдырды.

**Гәриева Г. В.**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**49 нчы кадет мәктәбе”**

## Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре.

### I. Кереш

Татар әдәбиятының горурлыгы булган каләм ияләре арасында Айдар Хәлим лаеклы урын тота. Ул татар шигърияте, татар прозасы, татар драматургиясе, татар публицистикасы һәм татар тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли.

Айдар Хәлимнең иҗаты күпкырлы һәм мул уңдырышлы. Беренче әсәрләреннән үк сиземләнгән язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Кайсы чор турында һәм нинди генә темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш – гамәлләрен гуманистик идея - эстетик карашлар югарылыгыннан торып анализларга тырыша. Аларны чынбарлыктагы милли, тарихи – иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.

Танылган әдип иҗатын һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә аңлый һәм бәя бирә, шуңа күрә аның иҗаты безнең фикерләвебездә дә кызыклы булыр дип саныйбыз. Иҗади эшемне башкарганда түбәндәге максатларны куйдым:

1.Айдар Хәлим турындагы белемнәремне киңәйтү;

2.Укылган әдәби әсәрне аңлау, бәяләү, анализлау;

Мин эшемдә күңелемә тирән кереп урнашкан һәм яраткан әсәрем булган “Өч аяклы ат” повестенә тукталдым. Бу әсәр турында сүз башлаганчы, Айдар Хәлимнең нинди тормыш юлы узуы белән таныштым.

Айдар Хәлим 1942 нче елның 1 нче гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Гаиләдә дүрт бала. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак була. Әнисе дә бу якты дөньяны бик иртә калдырып китә. Айдар Хәлим дүрт яшендә балалар йортына урнаштырыла. [1].

Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959-1960 нчы елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961-1964 нче елларда – Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә. Айдар Хәлим ишегалды җыештыручы һәм “Спартак” комбинаты балалар бакчасында каравылчы хезмәтләрен башкарып, көндезге бүлектә укып, 1968 нче елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлый. Аннары, Татарстанның Түбән Кама шәһәренә килеп, нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында инженер, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли.

1971–1975 нче елларда Айдар Хәлим Уфада “Совет Башкортстаны” газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып танылa [1].1981 нче елда аны Уфадагы Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия

драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983–1985 нче елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала.

1991нче елдан 1996 нчы елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугат басма – «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли [1].Бүген ЯрЧаллыда яши, иҗат итә.

**II. Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре турында.**

**1**.«Өч аяклы ат» фильмының «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, йөздән артык әсәр арасында җиңеп, унлыкка керүе билгеле булды. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч китерде. Аның дөньяга танылу көнен татар киносы туу көне буларак билгеләп куйдылар. Аның режиссеры безгә күп кенә татар фильмнары аша таныш ханым Нурания Җамали. Без аның «Китәм димә!», «Яланаяклы кыз» һәм башка фильмнарын бик яратып зәңгәр экраннар аша күзәткән идек. Хәзер дөньяга аның балаларга, яшь- җилкенчәккә, өлкәннәргә - һәркемнең күңеленә хуш килә торган «Өч аяклы ат» фильмы дөнья күрде. Айдар Хәлим дулкынланып һәм ышанмыйчарак "Өч аяклы ат буенча фильм төшерелү турындагы хәбәрне кабул итә: "Дөрес, фильмның булачак режиссеры Нурания Җамали моннан биш-алты ел элек үк: "Өч аяклы ат" буенча фильм төшерәсем килә",-дип йөри башлаган иде. Бу миңа фантастика кебек кенә тоелды. Әмма татарның Нурания ханым кебек җәмгыяви двигательләре булган хәлдә хыял чынбарлыкка әверелә дә куя икән. Их, барыбыз да шулай бирелеп эшләсәк!.. Инде Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән халкыбызга бу фильмны күрү бәхетенә ирешергә язсын. Ул барыбызга уртак сызлану куанычы китерсен. Мин мондый мәшһүр фестивальдә катнаша алуыбызга бик тә куанам һәм дулкынланам. 300 фильм арасыннан барлыгы, ялгышмасам-27, шулар исәбеннән безнең фильны да сайлап алганнар»,-дип яза ул. [3].

Әсәрнең исеме - «Өч аяклы ат». Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый - өч аяклы: менә - менә егылам дип тора. Бер эшкә яраксыз Галләметдин ишеләр власть белән идарә иткәндә шулай булмый нишләсен! Ул үзе дә болай ди бит: «Катымын! Каты булачакмын! Мин- влач! Дәүләтнең алтын баганасы. Мин бар, димәк, човет влачы бар, мин юк – човет влачы да юк!»

Хәзерге яшьләрдә битарафлык, күңел бушлыгы, гамьсезлек, ваемсызлык хөкем сөргән заманда бу әсәрнең дөньяга тууы күңелләргә сары май булып ятты. Алайса, телевизор экраннарында күрсәтелә торган мәгънәсез тапшырулар, үтереш-суеш, көчләү-талауны күрсәткән кинолар безне тәмам бозып бетерде. Мәгънәле, һәркемнең күңел кылларын тибрәтә торган шушындый әсәрләр күбрәк булсын иде диясем килә минем. «Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган. Вакыйгалар үткәннәрне

искә төшерү белән үрелеп бара. Анда сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә. Әсәрдә авылның тормыш – көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тулы картина булып безнең күз алдыбызга килеп баса. Әсәр табигатьнең үзе кебек: караңгы төне дә, кояшлы көне дә бар. Әйе, яшәү җиңел булмаячак. Әмма яшәргә, тырышырга кирәк. Сугыш дигән олы афәт тудырган ул елларны.

Айдар Хәлимнең әлеге әсәрендә ил, халык язмышының аеруча катлаулы һәм фаҗигале дәвере–крестьяннарны көчләп күмәкләштерүгә мөнәсәбәте дә чагылыш тапкан. Бу чорда акыллы һәм таза тормышлы игенчеләрнең үрнәк хуҗалыкларын туздырып, аларның хәләл көч белән тупланган мал – мөлкәтләрен ирексездән тартып алып, ил икътисадына һәм аның абруена, рухи байлыгына иксез – чиксез зыян китерелә. Сугыштан соңгы елларда авыл халкы җәбер – җәфаны, интегүләрне байтак күргән шул. Хезмәт көненә берни бирмиләр диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфалыйлар! Еллар буе берни бирмиләр, еллар буе барын халыктан гына сорыйлар. Кесәңнән бер башак табылса, бер ел төрмә, ике башак табылса, ике ел төрмә каралган. Ә бер кесә ашлык белән тотылсаң, башыңны ун елга төрмәгә тыгалар. Ә шушы чорда ат хәтле атны сафтан чыгарсаң, бу колхозны сафтан чыгару

дигән сүз. Димәк, башың гомерең буе төрмәдә чериячәк.

Сугыш арты еллары бик авыр чор. Әтисез калган ятимнәргә тагын да авыр. Үз көннәрен үзләре күрергә өйрәнеп, авырлыкларны җиңә - җиңә яшәгән чак. Бөтен тормыш авырлыгы хатын – кыз һәм балалар җилкәсендә. Ирләр юк дәрәҗәсендә. Кечкенә малай Кәбир һәм аның әнисе Сания апа шул чор корбаннары. Колхоз бик авырлык белән генә сөйрәлә. Техника юк, барлык авыр эшкә атлар җигелә. Әле аның анысы да санаулы гына. Күп атлар сугышка җибәрелеп, шунда башларын салганнар. Лобогрейкага, сукага һәм башка колхоз эшләренә җигү өчен Кәреш авылында нибары ике ат исәпләнә. Ашарга да такы-токы гына. Җизнәсе һәм апасы Зөлхиҗәләрдән хат килеп төшкәч, алар янына барырга булалар. Бер-ике капчык бәрәңге, азрак он, атланмай алып китәрсез дигәннәр бит… Алар тормышындагы кара көннәр шушы төннән башлана да инде.

Әсәрдә сугыштан соңгы татар авылында, тормышлары бик авыр булуга карамастан, халыкның бер – берсенә ярдәмләшеп, бер – берсен якларга әзер булып яшәве сурәтләнә. Кәбир исемле 12 яшьлек малай әнисе Сания апа белән, колхозның Бамбук исемле байталын җигеп, 50 чакрым ераклыктагы совхозда яшәүче туганнарына кунакка баралар. Ләкин атны бүре яралый һәм алар Бамбукны калдырып кайталар. Сания апаны гаепләп ябып куялар. Шушы бәладән әнисен йолып калу өчен, Кәбир яралы атны авылга алып кайта. Аңа юлда бик күп яхшы кешеләр очрый, ярдәм итәләр, кундырып чыгаралар, атның ярасын бәйлиләр. Участковый Сәйфуллин белән бригадир Галләмгә Кәбирне беркем дә сатмый. Авылдагы гади кешеләр, колхозчылар, тол хатыннар Сания апаның кайгысын уртаклашалар, ат бәясен эшләп түләргә әзерләр. Ләкин Сания апа ул ярдәмне кабул итми, чөнки тол хатыннар үзләре бик авыр хәлдә.

Авыл халкының бер-берсенә мөнәсәбәте – әсәрдә иң якты урыннар. Татар халкы гомергә ярдәмчел һәм шәфкатьле булган, башка милләт вәкилләрен хөрмәт иткән, алар белән дус, тату яшәгән. Әсәрдә без моны Кәбир – Степан, Муса – Андрей мөнәсәбәтләрендә ачык күрәбез. Ә авыл халкының хокуксызлыгы, көче җитмәслек салым -заданиеләргә килгәндә, аларның күбесе әле 70 нче елларга кадәр үз көчендә кала.

**2. Төп образларның бирелеше.**

Әсәрдән эчке бер җылылык бөркелеп тора. Әсәрнең төп герое - Кәбир исемле үсмер малай. Аңа әле 12 яшь кенә. Ләкин инде ул тормышта күп авырлыклар күргән. Әтисе сугышта һәлак була. Әнисе – Сания апа 3 баланы берүзе үстерә. Олы абыйсы бик авырлык белән авылдан китә. Икенче абыйсын, елата- елата, ФЗУга озаталар. Шулай итеп, Кәбир әнисенең төп ярдәмчесе булып кала. Ул әнисен өзелеп ярата, аны кайгырта. Кәбир – зирәк, тәвәккәл, уңган малай. Ул үзенең ихласлыгы һәм авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухлы үсмер булып безнең күңелләрне яулый. Нинди генә кыенлыклар, кимсетелү- җәберләүләр, михнәт – газаплар күрергә туры килми аларга ?! Әнисен хаксызга мыскыл иткән колхоз бригадирының ямьсез гамәлләренә ул түзеп тора алмый. Явызлык, намуссызлык, шәфкатьсезлек хакимлек итмәскә тиеш! Алар тиешле җәзаларын алырга тиешләр!

Колхоз бригадиры Галләметдин, лейтенант Шәрифуллин ишеләр үз вазифаларыннан файдаланып, хезмәт ияләренә кол итеп карап, аларны төрлечә мәсхәрәләргә һәм кешелек сыйфатларын санга сукмаска тырышалар. Гуманлылык күзлегеннән караганда, Санияне гомер буе шул колхозда тир түккән фронтовик хатыны булуын исәпкә алып, кичерергә тиешләр иде кебек. Ләкин юк. Яшьли үк Саниягә кызыгып, аның мәхәббәтен кире какканы өчен, үч алу тойгысы уяна Галләметдиндә. Алар икейөзле, әхлаксыз, эчкече, имансыз бәндәләр.

Галләметдиннәргә ил, халык, вөҗдан кебек олы мәгънәгә ия булган сүзләр бары абстракт төшенчәләр генә. Бары байлык, муллык һәм рәхәтлек китергән төшенчәләр генә алар тарафыннан хөрмәт ителә, кадерләнә. Бер эшкә яраксыз хөрәсәннәрнең колхоз малын эчеп ятулары гына җитмәгән, әле алар фронтовик хатыны Санияэнең алтын – көмешләрен урлап чыгудан да тартынып тормыйлар. Участковыйның ялган яла ягуы, нигезсез дәлилләр китерүе күңелдә андый кешеләргә карата җирәнү хисләре тудыра. Лейтенант Шәфигуллин фронтовик хатынына түбәндәге уйдырма гаепләр табып, нахак

бәла яга « Үзегезнең раскулачивать ителгән ат нәселеннән икәнен белеп зыянлаттыгызмы? Җизнәгезгә сугымга калдырдыгызмы? Җизнәгезнең абзарына бернинди дә бүре төшмәгән. Совет властеның борынгы дошманы аның аягын махсус сындырган. Соң булса да уң булсын, дип, киткән малын кире кайтарырга уйлаган. Бик беләсегез килсә, ул аны суеп та ашаган. Бу сезнең алдан уйлап эшләгән җинаятегез. Менә җизнәгезнең атны суеп, базарга чыгарып сатуы турында жалоба». Шулай да Галәметдин кебек мәкерле, астыртын, хәйләле, кешелексез бәндәләр халык әхлагының күркәм сыйфатларын гәүдәләндергән намуслы яшәүче хезмәт ияләре алдында көчсез.

Кәбирнең күңелендә әлеге хаксыз рәнҗетүләр, мыскыллауларга карата көчле протест уяна. Аның җаны ярсый, бәргәләнә. Галәметдин кебек властьтан файдаланып, итәк астыннан эш йөртүчеләрнең мыскылы карарларын нигезсез, законсыз дип саный. Аның әнисенә тагылган нахак гаепләүләргә җаны җәрәхәтләнә, күңеле сыкрана. «Үсеп кенә җитим, кирәкләрен бирермен мин аларның»,- дип күңеленә салып куя. Шулай да ул җебеп-сыгылып төшми, үзендә алга таба барырга тагы да зуррак көч туплый бара. Тормыш рәхимсезлеге белән көрәшергә үзендә бетмәс- төкәнмәс көч таба. Әнисен Сания апаны бары бер генә нәрсә коткара ала – Бамбукны алып кайтып, аның исән икәнлеген раслау. Бәрелеп- сугылып, төрле кыенлыкларга очрап, сазлыкларда бата – бата, чегәннәргә юлыгып, аның эзенә төшәргә теләгән бригадир һәм участковыйлардан яшеренеп, ул исән-имин килеш, атны үз авылларына - Кәрешкә алып кайтып җиткерә. Аны ана мәхәббәте, җитезлеге, уңганлыгы бу бәладән чын егетләрчә чыгарга мөмкинлек бирә. Ананың балага, баланың анага карата булган мәхәббәте таш – кыяларны да җимерергә, явызлыкларны җиңәргә сәләтле шул!

Ул ат җанлы. Андыйлар турында «хайван җене кагылган» дип әйтәләр. Бамбук малай өчен бик якын җан иясе. Атны суйганда өзәләнеп кычкырулары әле дә колагымда яңгырый. Дусты белән ат йөрәген кадерләп күмүләрен генә искә төшерик… Ике дус җирне тырмый – тырмый кабер казый. Бамбук каберенә киләчәктә һәйкәл кую, ай һәм йолдыз сурәте төшерү уйларында. Әйе, Кәбир нечкә күңелле. Аның атка булган мөнәсәбәте дә сокландыргыч. Атны иң олы ярату белән ярата белә шул ул.

Ул, әнисен төрмәдән коткару өчен, бер аягына баса алмаган Бамбукны 50 чакрым озын һәм авыр юлга алып чыга һәм атны авылга алып кайтып җиткерә.

Кәбир атларны, табигатьне ярата, бөтен барлыгы белән матурлыкка омтыла. Аның күңелендә явызлык юк. Әле бик яшь булса да, Кәбир әнисе өчен, Бамбук өчен, үзләренең тормышлары өчен җаваплылык тоя.

Әсәрдә гомергә күңелдә кала торган образларның берсе – Бамбук. Кәбир образын аннан башка карап булмый. “Ир канаты – ат” дигән борынгылар. Бамбук – искиткеч акыллы, зирәк хайван. Аның да язмышы – Кәбир, Сания апа, Степан дәдәйләрнеке кебек аянычлы. Бамбук сугышта булган. Ул хуҗасы Нәби абыйны үлемнән коткара, ләкин үзе авыр яралана. Яралары төзәлгәч, аны тылга җибәрәләр. Һәм бу акыллы хайван көне-төне авыр хезмәттә. Ачлы-туклы яши. Сәми бабай, Кәбир кебек мәрхәмәтле кешеләрнең мәхәббәте яшәтә аны. Ул да – шул чорда

хөкем сөргән гаделсезлек корбаны. Кәбирнең кулак дип читкә сөрелгән бабалары асраган затлы ат нәселеннән булган өчен суялар аны. Бөкебаш хәтта хайваннан да үч ала.

Әсәрдәге олы, якты образларның берсе – Сания апа, Кәбирнең әнисе. Ул таза тормышлы, укымышлы гаиләдән. Ләкин аның нәселен Бөкебашлар туздырган, читкә сөргән, талаган. Сания апа–тормыш юлында бик көчле, нык ихтыярлы. Үлгән иренең рухына, балаларына тугрыклы. Ана кеше бердәнбер юанычы - малае Кәбиргә зур өметләр баглап, сабырлыгын җыеп, бөтен көчен эшкә бирә. Сания апа ниләр генә күрми, нинди авырлыкларга гына түзми! Аның чыдамлыгына, түземлегенә сокланмау мөмкин түгел. Сугышта батырларча үлеп калган иренә булган мәхәббәтне олы бер хис итеп саклый. Мәхәббәтенә хыянәт итүне ул уйлап та карый алмый. Күпме газап - михнәтләр чиксә чигәр, башкайлары төрмәләргә керсә керер, ләкин ул намусына тап төшермәс!

Көнне төнгә ялгап эшләсә дә, колхозны җигелеп тартса да, аның кадере юк. Чөнки

ул–бик булдыклы, чиста, саф күңелле хатын. Депутат Саҗидә, Ябалак Галләм ишеләр үзләреннән өстен кешеләрне күрә алмыйлар. Ләкин аның нык

таянычы – Кәбире бар. Әнисенә кул сузган Ябалак Галләмнең артына тибеп чыгарырлык көч таба ул үзендә. Кәбир әнисен беркайчан да ташламаячак. Яхшылык һәрвакыт яманлыкны җиңә. Шуңа да игътибарыбызны юнәлтик: Кәбир куйган максатына ирешә беләә, үҗәтләнеп тормышка ябыша. Нинди авырлыклар аша үтә ул, ә күңелендә явызлык юк, үзен һәм әнисен кыерсытучыларга үпкә-рәнҗү бар, ә явызлык юк. Иң кыен чакларда да ул кеше булып кала белә, үзе булып кала белә.

**3. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше, тел-сурәт чаралары.**

Әсәрнең сюжеты артык катлаулы түгел, ләкин мавыктыргыч, кызыклы һәм үзенчәлекле. Төп вакыйга Кәбирнең атны авылга алып кайтуы, шуның эчендә булган кичерәкләре: чегәннәр белән очрашу; Степан дәдәйләрдә куну; Нәби абыйның Кәбирне коткаруы; Сәйфуллин белән Бөкебашның сөйләшкәнен тыңлау. Болар белән Кәбир исенә төшергән хәл-вакыйгалар аралаша, бер-берсен тулыландыра. Вакыйга арты вакыйга килә, һәрберсе белән Кәбиргә яңа сынау килә. Шуңа күрә әсәрне аерыла алмыйча укыйсың.

Әсәр искиткеч матур тел белән язылган. Ул – җырлы һәм догалы тел.

Нәби абый намаз ахрында мондый теләкләр теле: "Хәтәр сугышларда башлары югалган ватандашларым, барлык тере һәм тере булмаган рухлар ихтыярына кабул ит, илаһым. Үз табигатең һәм чит табигатьләр иминлеге хакына! Балаларым, балаларымның балалары хакына ошбу Кәбир атлы ятим сабыйны, рыясыз ат җаны – Бамбук кардәшемне сугышларда исән-аман саклап калдырган канатым итеп, барлык сырхаулардан азат итеп, күктән очырт, җирдән йөгерт, илаһым! Ошбу ир-ат җанын кош-корт күзеннән, кешебашлы козгыннар кулыннан сакла, илаһым! [3]"

Әсәр төрле сурәтләү чараларына бик бай. "Бамбукҗан [3]",– дип эндәшә Кәбир атына. "Йомры тоягым, тырнак колагым минем!.. Карлыгач ботым!.. Күгәрчен төшем!.. Ялбыр ялым, нечкә бөерем, "И җаныем! И сабыркаем! [2]"," – дип иркәли.

Әсәрдә көтелмәгән чагыштырулар, эпитетлар күп: "...пәке белән уелгандай тигез таулар тезмәсе. "Офыкта күкәй сарысы кебек таң саргаеп килә ". "Ике яктан да үзәнен күпер сыман итеп таллар биләгән Сабыр... агып ята. "...кургашын сыман авырайган күз кабаклары..., ... катык кебек төссезләнеп, оеп барган күзләр... "Ай исә ак салган тана күзе кебек тоныкланып калды [2]".

"Сабыр буе таллары сыман сыгылмалы гәүдә" "Зәңгәр күзле, җитен сары чәчле, өтер кебек җыйнак матур борынлы Нәстүк [3]".

Кабатлаулар, риторик эндәшләр дә әсәрнең тәэсир көчен арттыралар: "Туган як җиле! Күләгәләр, шәүләләр һәм колактагы сихри зеңләү! Сагыну һәм наз, анаң елмаюы һәм яшел үлән! [3]"."Мәңгегә атасыз, әлегә хәтта анасыз, күкрәкләрендә үр җилләре кураен уйнатып, кеше биргән күлмәк-ыштанда, кеше биргән кәвешләрдә, сугышларны үтеп исән калган, явызлар пычагы астыннан очраклы гына котылган атны урман төпкелләреннән йөрәге сыман күтәреп алып чыгып килгән малай – кемең булыр ул синең, туган ил? Кем өчендер бик тә кадерсез, туфрактан яралган, кояшта карайган, җилдә җилләнгән, кырда көрәйгән, илдә иләнгән, төптән, бик тирәннән күтәрелгән бу тере тамыр, тормышның зирәк һәм хисле бер күзәнәге – кемең булыр ул синең, туган ил? [3]."

Әсәрнең теле башыннан алып ахырына кадәр әнә шулай бизәкле.

Әйе, Айдар Хәлим туган телнең барлык бизәкләрен нечкә сиземләп яза. Аның бу әсәре безне, ягъни укучыларны кайта-кайта уйландыра, яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, иман белән яшәргә өйрәтә.

**III. Йомгаклау**. "Өч аяклы ат" әсәренең укучыга тәэсире.Әсәрнең төп мәгънәсе-идеясе Айдар Хәлим болай дип яза: "Менә шул хакта мин әле генә әйтә биреп куйдым бит инде. "Өч аяклы ат" – татар халкы язмышы. Сезнең татар халкындагы "ир-ат" дигән гыйбарә-төшенчәгә игътибар иткәнегез булгандыр. Шунысы кызык, аны башка бер генә төрки халыкта да очратканым булмады минем. "Ир-ат". Ул урысча бөтенләй ябешми кебек: "мужчина-конь"? [4]. " Ә менә татарда ул кандагы ак һәм кызыл тәнчекләр кебек

бербөтенне тәшкил итә. Сабый чакта татар угылы ат сыртында, Сабантуйда. Басуда җир сөргәндә – сабан сукасы артында. Яуда – ат өстендә. Ашары да, яшәре дә, үлеме дә шул ат сыртында»-ди ул[4].

Совет власте, көчләп оештырылган "күмәк колхоз" тормышы татар ир-атын көчләп икегә аерды. Ул атны – иткә, ирне үзе өстерәп урман кисәргә озатты. Ир белән Ат мәңгелеккә аерылды. Алар әле дә булса кушыла алмады. Без, Русия халыклары, бигрәк тә татар халкы, шушы бозылган гармонияне яңадан төзәтә алмау аркасында бүгенге фаҗигане кичерәбез. Кыргый капитализм татар атын татар авылына кайтару белән шөгыльләнәсе урында ипподромнар өчен гарәп чабышкыларын кайтарту белән генә чикләнде. Ат кадерен белеп үсмәгән ир машина кадерен дә белә алмый. Шуңа күрә ул бер мәгънәсез "встречный полоса"га чыгып", елына кырык меңлек корбан бирә. Ир кадерен күрмәгән хатын-кыз ир-атны олылый алмый. Шушы дисгармонияне тигезләми торып, милләт бәхетсез булачак. Менә шуны тирән аңлаган башкорт туганнарыбыз сабыйларда курай һәм ат культы тәрбияли, ә без сикеренгәләп җырлау белән чикләнәбез. Совет хакимияте тәрбияләгән сыйнфый күрәлмаучылык кешеләрне генә түгел, аларның малларын да репрессиягә тарттырды. Бу хәл Галәметдиннәр, Санияләр нәселен генә түгел, аларның малларының нәселләре, бу очракта бурлы Бия – Бамбуктан да сыйнфый дошман ясый һәм аны "общий котел" хакына суйдыра... Ләкин Кәбир киләчәккә өметен өзми, ул атының йөрәген Түгәрәк имән төбенә күмә һәм, таң нурларына чумып, төрмәдән кайткан әнисен каршылый...

Әсәрнең ахыры үкенечле бетә. Дөрес, Галләметдин җәза ала алуын. Атны суйдырган өчен, авыл халкы, абзарда тезләндереп, аңа тизәк ашата. Санияне дә өенә кайтаралар, әнисен дә Галләметдин ише адәмнәрдән якларга сүз бирәләр. Тик…Тик менә Кәбир генә Бамбуксыз кала…

Фильмны тамаша кылганда йөрәк телгәләнә, күзгә яшьләр килә. Геройларның тиешсезгә рәнҗетелгән урыннарында ярсуларым, ачуым кабарулар тынны кыса, бугазымнан буа. Кәбирнең җан ачысы белән өзгәләнгән, ачыргаланган минутларында бөтен тәнемә кырмыскалар йөгергәндәй була, кайгы-хәсрәт ялкынында янам.

Шушындый фильмнарны дөньяга тудырган Нурания Җамалига рәхмәтем чиксез минем. Киләчәктә дә армый - талмый милләтебезгә хезмәт итсен. Сезнең татар халкына эшләгән игелекләрегез дәвамлы булып, милләтебезне дан - шөһрәткә күмсен!

Әсәр бик гыйбрәтле, безгә бик көчле тәэсир итә. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, образлар уйландыра; Кәбир, Сания апа, Бамбук язмышы өчен чын күңелдән борчыласың, кайгырасың. Кәбир белән Сания апа арасындагы мөнәсәбәтләр соклandыра. Кәбир гел яхшылыкка омтылып, яхшылыкка ышанып яши. Шуңа күрә дөнья аңа яхшылык белән җавап бирә. Әсәр авырлыкларга бирешмәскә өйрәтә. Повестьны укып чыккач, шундый нәтиҗәгә киләсең: дөньяда яхшы кешеләр күбрәк һәм авыр вакытта алар ярдәм итәргә әзер икән.

Өметеңне өзмичә, бәхеткә омтылып, кешелекле булып, янәшәңдәге кешеләргә йөрәк җылыңны биреп яшәсәң, бу дөньяда авырлыкларны җиңеп-җиңеләйтеп, тирә-ягыбызны сафландырып була дип уйлыйбыз.

**Кулланылган әдәбият**


1. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
2. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 6. – 52-101б.
3. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 7. – 88-129 б.
4. Шагыйрь, әдип, милләт хадиме. // Казан утлары. – 2002. – №1. – 82-83 б.
5. Хәлим Айдар.Кылга күзен ачкан әдип.// Мәйдан-2012.-№3.-102-111 б.



**Гыйззәтуллина К. М.**
**"Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"**

**" Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы "Биктырыш" әсәренә кыскача анализ"**

Айдар Хәлим - зур ихтыяри көчкә ия булган трибун шагыйрь, тирән аналитик язучы, кабатланмас фикерләр әйтүче фәлсәфәче, социаль тигезлек, кеше хокукы өчен җанын-тәнен биргән көрәшче, залларны үзенә каратып тоткан иҗтимагый җәмәгать эшлеклесе. Еш кына аның исеме «беренче» дигән сыйфат белән рәттән йөри. Һәм ул моңа лаеклы да. Бер караганда, аның тормыш һәм иҗат юлы – үзе тоташ батырлыктан гына торган моңлы бер җыр. Шуңа күрә, аның иҗаты бүгенгесе көндә бик актуаль.

Айдар Хәлим турында каләмдәшләре.Мондый шигырьләрнең бары тик хезмәтнең , мәхәббәтнең кадерен белгән кеше йөрәгендә генә яралуы мөмкин. Борис Хәлимовның шигырьләре шигырь сөючеләргә, димәк матурлык сөючеләргә, ләззәтле минутлар китерер, дип ышанаМостай КӘРИМ. ...Аның биографиясе шактый бай. Ул язу характеры белән аерыла. Аның шигырьләре давыллы, өермәле, вулкан дияр идем мин...Кайсы вакыт барысы да бергә бутала, шигъри юллар, детальләр, образлар сүз өермәсе эчендә югала. Бәлки, бу вакытлы хәлдер, үтәр!

Сибгат ХӘКИМ. Айдар Хәлим җир һәм күкләр масштабында фикер йөртә. Аларда фикерләүгә караганда киземләү көчлерәк.

Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА. Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары гамәлдәге профессионал булып була икән ул? Айдар Хәлим ике телдә - рус һәм татар телләрендә (теләгәндә саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь... Айдар Хәлим- олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп, кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия.

Рифат СВЕРИГИН. ... Айдар Хәлим - үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят- яшәвебездә феноменаль күренеш.

Равил Фәйзуллин. Кереш

Шагыйрь, оратор, язучы, ялкынлы публицист, 1968 елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлаучы. Болар барысы да күренекле шәхес – Айдар Хәлим турында. Татарстан Республикасының

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатларның берсе Айдар Хәлим – хәзерге заман татар язучыларының иң күренеклеләреннән. Мөгаен, ул үзен сынап карамаган бер генә жанр да калмагандыр. Хәер, театр һәм кино сценарийлары язмаган ул. Анысы да Татарстаныбызда әлегә кадәр кино тармагының аякка басып китә алмавы нәтиҗәсендә.

Айдар Хәлим. Айдар исеме – дәрәҗәле, билгеле, маңгаенда ай йөртүче, дип тәрҗемә ителә. Күргәнебезчә, исеме җисеменә туры килгән. Алтмыштан артык китап авторы. 2005 елда Мәккәгә хаҗ сәфәре кылган, 2011 елда татарлар чакыруы буенча Америка Кушма Штатларында булган, өч бала атасы, Чаллы шәһәрендә яшәүче күренекле прозаик, шагыйрь драматург һәм публицист булып танылган Айдар Хәлим турында язасым килде. Ни өчендер бу әдипнең язганнарын, гомумән, аның үтә дә киң кырлы иҗатын күңелемә ихластан аваздаш һәм якын дип кабул итәм. Нинди жанрда язуына карамастан, аның әсәрләрендә сурәтләнгән вакыйгаларга катнашкан геройларның хәл-әхвәлләре, кичергән мажаралары җанга якын хәтирәләремне искә төшерә, күңелне сызландыра, шуларны яңартып, элеккеге, кайчандыр янәшәмдә йөреп тә, бүген инде истәлекләре генә калган яшьлек дусларым, иптәшләрем белән кавыштыргандай итә.

Инде байтак вакытлардан ышанган карашым буенча, А.Хәлимнең иҗат стилендәге әһәмиятле үзенчәлек һәм билгеләрнең берсе итеп аның әдәби деталь һәм миниатюр бизәкләр белән оста эш итү сәләтен курсәтәсем килә. Чыннан да бу аның новелла- хикәяләрендә һәм “Татар вакыты” дип аталган әсәрендә бик ачык расланган.

Язучы — татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби тәнкыйтенең иң күренекле һәм үзенчәлекле вәкилләреннән берсе. Шагыйрь буларак аның беренче әсәрләре татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. А. Хәлим — драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм остасы. Туксанынчы елларда А. Хәлим проза өлкәсендә дә зур иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат», «Казыктагы итальян» повестьлары, «Кыйбла», «Берлинга хат», «Авылдаш», «Җырларга вакыт» һәм башка күпсанлы хикәяләре һәм бигрәк

тә «Татар вакыты» исемле кечкенә романы әдәби тәнкыйтьтә бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге итеп бәяләнә.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эстетик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган. Төп өлеше.

Үзенең бала чагын сагынып, татлы хисләргә бирелмәгән кеше сирәктер. Ә инде шагыйрьләргә язучыларга килсәк, алар инде- гомерлек сабыйлар. Кайсы гына әдипнең иҗатын алсак анда һичшиксез, балалар өчен язган әсәрләр тапмый калмыйсын. Тукай белән Пушкинда да, Толстой белән Галимҗан Ибраһимовта да, Такташ белән Маяковскийда да бар андый иҗат үрнәкләре. Гомумән, язучы- шагыйрьләрнең иҗат колачын билгеләгәндә, аның балалар әдәбиятына керткән өлешен истә тотарга кирәк.Чөнки үз баласы, үз милләтенең баласы турында уйламаган, кайгыртмаган әдип нәселенең һәм милләтенең киләчәгенә битарафтыр дип уйлыйсы кала.

Язучы, шагыйрь һәм публицист А.Хәлимнең бөтен эшләгән эше, бөтен гомере милләт язмышы, милләтнең киләчәге хакындагы уй- хыяллар белән үрелеп бара. А.Хәлимнең балалар өчен әсәрләр иҗат итүе миңа баштарак гаҗәп бер хәл булып тоелды. Чыннан да президентлар, ил башлыклары белән катлаулы бәхәсләр алып барган әдипнең кинәт кенә сабый балага әйләнеп, алты - җиде яшьлек малай хакында поэма иҗат итүе бер караганда шаккатырлык нәрсә ул.

А.Хәлимнең “Биктырыш” китабында исеме җисеменә туры килгән малай турында сүз бара. Шул яшендә үк ул кеше өчен иң кыйммәтле, иң кирәкле сыйфатларны әкрен-әкрен күңеленә, холкына сеңдерә бара. Ул әти-әнисендәге, әби-бабасындагы, укытучыларындагы иң күркәм гадәтләрне күреп үсә, шулай итеп, бәлки үзе дә сизмичәдер, халкының затлы-зыялы шәхесе булырга әзерләнә. Ә тырышлык, уңганлык, чисталык-пөхтәлек татар халкындагы иң гүзәл сыйфатлар булып саклану- сакланмавы киләчәктә шушы бүгенге “Биктырыш” лардан торуы барыбызга да мәгълум. Бу “Биктырыш китабын укыгач, мин әсәр өчен дә, аның авторы өчен дә куанып куйдым. Чөнки, бу малай ике тамчы су кебек А.Хәлимнең үзенә, дөресерәге аның бала чагына охшаган.

” Биктырыш” дигән соңгы китабының кереш өлешендә А.Хәлим болай дип яза:

“Әдәби тәнкыйтебез булмагач, “Биктырыш” китабы тиешле бәясен алмагач, эш башындагылар аны күрмәгәч, я күрергә теләмәгәч, үз хезмәтемнең барлык дөнья әдәбиятында тоткан урынын билгеләү хокукы бардыр бит?! Үз әсәреңне, аның белән бергә замандаш әсәрләрне шәрехләп язуда, минемчә, ихтыяҗ бар иде. Һәм ул ихтыяҗ зурдан иде”, ди язучы.

Китапның кереш өлешендә мондый юллар да бар: “Сизенәм, язмам басылып чыккан хәлдә, бу балалар шигърияте дип аталган кырмыска оясына таяк тыгып бутауга тиң булачак. Мин моңардан курыкмыйм” ди.

“Биктырыш” дигән китап 1968 елда язылып, Уфада башкорт, Мәскәүдә бернечә тапкыр урыс телендә басылып танылу ала. 40 елга якын китап Татарстанда читләштерелеп торыла. Бары 1996 елда гына, үз хисабына, Казанда бастырып чыгара. Ул аның ун ел гомерен ала.

Укучыга бу әсәр тиешле азык китерде, дип уйлыйм. Тәнкыйть кешенең җанына тимичә, ачык булырга тиеш. Балаларга нәрсә бирәбез – белү зарур. Без – Тукайлы халык. Аның эшен дәвам итәргә тиешбез.

Мин татар балалар әдәбиятында, дөресрәге, шигъриятендә, билгеле булып та, гамәлдә бигүк билгеле булмаган, әмма таш катламнары астында яшәвен дәвам иткән бер бик тә милли татар балабыз – Биктырыш, аның рухи сыны турында уйланам. Рухи сын, рухи рәвеш ул безнеңчә “образ” дигән төшенчәгә туры киләдер кебек. Биктырыш, баксаң,

ул җыелма образ, ике сүздән тора икән: “Бик” һәм “Тырыш”. Бик + Тырыш. Менә сиңа мә!..

Бик тырыш булгач- эшләмичә бер минут та торалмый, димәк. Остазыбыз Ризаэддин Фәхреддин бердә юкка гына “Кошлар-канатлары белән очканда , кешелер тырышлыклары белән очалар”,- димәгән икән шул.

Эшләмәгән кеше яшәми. Безнең Биктырышның хәләл уены, хәләл эш кебек, җитди, саллы, хәләл эше хәләл уены кебек мавыктыргыч. Шулай була ала микән? Була ала һәм булырга тиеш тә икән шул. Югыйсә әхлак бозыла. Кешелек таркала, нәсел-нәсәп юкка чыга. Әдәбият, ни дисәң дә, әдәбият инде - үзе хыялый да, үзе үк чын да бит ул. Ул җир өстеннән йөрми, оча. Бераз гына булса да оча. Тик шунысы, кеше баласы гына түгел, хәтта бер генә хыял да Ватансыз яратылмый. Димәк, кемдер кайдадыр яшәргә тиеш. Ярату һәм яратылу өчен Ватан кирәк. Ватанны ярату өчен ватанчыл йөрәк кирәк.

Бәс, шулай булгач, атап әйткәндә:

Кайда яши ут-малай,<br>
Җитез, йөгерек, телгә бай,<br>
Буй гынасы биш карыш,<br>
Ә исеме – Биктырыш?

Чынлап та, кайда яши? Автор раславынча, аның туган иле - Идел- Урал киңлекләрендә җәйрәп яткан һәм бер дәүләт булырга тиеш булган Татарстан-Башкортстан дәүләтләре. Гомер иткән җире - татар авылы. Ә менә әсәр герое булып туган – бар булган, язылган җире - Түбән Кама төзелеше икән. Бу- гомумән әйтелә.

Авторның раславынча әсәрнең беренче бүлекләре Түбән Кама гомумторагының үзе яшәгән бүлмәсендә ¬¬– эштән кайтып, идәнгә җәелгән келәмдә уйнаган кызын күргәч фонтан булып бәреп чыккан. Соңыннан, 1989 елда Мәскәүнең үзәк “Детгиз” нәшриятында, 1996 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан басмаларында автор бу хакта менә нәрсә яза: “Төзелеш, чыннан да, бөек иде. Күз күреме җитмәс мәйданда эш кайный. Бульдозерлар үкерешә, казаннарда кайнаган сумаладан кара төтен баганалары күтәрелә, җир ергаланып беткән, яңа цехларның челтәр-челтәр эстакадалары үсә. Мин төзелеп яткан суыту җайланмасы – градирняда салмак хәрәкәтләр белән такта өзекләре кагам. Кагам, кагам һәм кинәт бу кагу ритмында ниндидер мәгънә, ниндидер сүзләр ишетәм... Үзем сугам. Үзем пышылдыйм:

-- Кайда яши Биктырыш... кем әле син, Биктырыш?

Бу – Биктырыш турындагы шигырьләрнең иң беренче юллары иде...”

Йомгаклау.

Язучы – татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби тәнкыйтенең иң күренекле һәм үзенчәлекле вәкилләреннән берсе. Чөнки, ул ике телдә дә, рус һәм татар телләрендә бертигез итеп яза ала. А.Хәлим – драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм остасы. Пьесаларыннан «Җанчишмә» , «Пәри туе» әсәрләре заманында Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш казаналар, ә балалар өчен язган «Биктырыш» исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.

Шулай да А.Хәлимнең исемен таныткан әсәрләре – туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книга печали, или Записки аборигена»), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» , «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!». «Яңа «Сагыш китабы», яки Минзәлә Гаагадан еракмы?», «Боза-боза паспортны, арттырабыз башкортны...» дигән китапларында язучы башкорт шовинизмына әчке лаборатор анализ бирә. Язучының «Җиңелмәс ул чечен» китабы документаль материаллар нигезендә каһарман чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен хәрби техниканың иң соңгы казанышлары белән коралланган «явызлык империясе»нең миллионлы армиясенә каршы бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи һәм хәзерге фаҗигале

язмышына юнәлтелә.

Әдипнең XX гасырның ахыргы – XXI гасырның беренче елларында иҗат ителгән күпсанлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселәре, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Имәнем» , халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш», «Боза-боза паспортны...» кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Публицистика өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен А.Хәлим 2003 елда Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый, Бөгелмә җәмәгатьчелегенең мәгариф буенча Һ.Атласи исемендәге әдәби бүләгенә лаек була.

А.Хәлим – 1992 елдан татар халкының Милли Мәҗлесе депутаты, 1997–2001 елларда Мәҗлеснең рәисе вазифаларын башкара. 1992, 1997, 2002, 2007 елларда җыелган I, II, III, IV Бөтендөнья татар конгрессында делегат булып катнаша. А.Хәлим – 1976 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Айдар Хәлим Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премия¬сенә «Өч аяклы ат», «Кыйб¬ла», «Казыктагы тальян», «Татар вакыты» романы һәм -«Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» хикәяләре (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел), «Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2002 ел) китаплары өчен тәкъдим ителә.

Нәтиҗә.

А.Хәлим – әдәби тәнкыйть өлкәсендә иң актив эшләүче каләм осталарының берсе. Аның аерым әдәби әсәрләргә яки язучылар иҗатына багышлап язылган мәкаләләре көчле аналитик фикер куәсенә, әдәби күренешне тарихи яссылыкта заман проблемалары белән тыгыз бәйләп аңлату осталыгына ия булуы турында сөйлиләр. «Казан утлары» журналында «Заман герое» темасына оештырылган дискуссия уңае белән басылган һәм бөтен татар әдәбиятын күздән кичереп, үзенең үтә тәнкыйди принципиаль фикерләрен турыдан-туры бәян иткән «Сез беләмсез кая барганны?» исемле зур мәкаләсе әдәби җәмәгатьчелектә көчле резонанс уятты һәм фикри бәхәсләргә сәбәп була. Айдар Хәлимгә багышланган эшемне Айдар Хәлимгә багышлап язылган шигырем белән бетерәсем килә.

Башкортстан илекнең
Кәркәле авылында.
Айдар исемле бала туган
Куңелебездә калырга.

Укытучы гаиләсендә Айдар
Асыл зат булып туган.
Тырыш бала кечкенәдән
Белем алырга омтылган.

Сугыш чорында туган бала
Ятимлекне татыган.
Авыр тормышта үссә дә
Язучы булып танылган.

Яшь чагыннан халкына
Хезмәт итәргә алынган.
Гәҗит – журнал чыгаруда.
Җитәкче булып торган.

“Аргамак” журналын халык
Бик яратып укыды.
Халкын яраткан язучы
Журнал чыгаруны оештырды.

Аның язган китаплары
Тарихыбызга тоташкан.
Халкын зурлау теләге
Тырышкач, тормышка ашкан.

Татар – башкорт кешесе
Айдар белән горурлана.
Укучы балалар мәктәптә
Иҗатыннан нур ала.

Чаллабызда әдипләр күп
Факил, Бәшәр һәм Хәлим.
Иҗат эшегездә Айдар,
Сезгә уңышлар телим!

Әдәбият

1. Биктырыш: Шигъри бәян. Казан. "Мәгариф" нәшрияты. – 2008ел. 4-9 б
2. Айдар Хәлим. "Мәйдан" журналы. - 2012- №3.- 8-102 б.
3. "Кыйблага кайту". "Казан Утлары". – 2017- №1.- 164-170 б

**Гилмуллина Л.С.**
**Ікв.категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**"Татарстан Республикасы**
**Алабуга шәһәренең**
**6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе"**

**Рәхмәт халкым, хак язмышым итеп**
**Үз телеңне бирдең иң элек** (Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы)

Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган каләм ияләре арасында Айдар Хәлим лаеклы урын тота. Айдар Хәлимнең иҗаты күп кырлы һәм мул уңдырышлы. Беренче әсәрләреннән үк сиземләнгән язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Кайсы чор турында һәм нинди генә темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш – гамәлләрен гуманистик идея- эстетик карашлар югарылыгыннан торып анализларга тырыша. Аларны чынбарлыктагы милли, тарихи – иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.Ул татар шигърияте, татар прозасы, татар драматургиясе, татар публицистикасы, һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укыган елларында ул яшь шагыйрь буларак таныла. Җәмәгатьчелек игътибарын яулаган шигырьләре беренче тапкыр 1964 нче елда «Татарстан яшьләре» газетасында басылып чыга. 1966 нчы елда Башкортстанның халык шагыйре М.Кәримнең сүз башы белән «Казан утлары» журналында дөнья күргән шигырьләре татар әдәбиятына үзенчәлекле шагыйрь килүен раслый. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 нчы елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга.

Шигъриятта Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 нче елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган. Хәлимовның

шигырьләре җир сулышы белән сугарылганнар. Мондый шигырьләр хезмәтнең, мәхәббәтнең, тормышның кадерен белгән кеше йөрәгендә генә туарга мөмкин.

Шулай да А.Хәлимнең исемен таныткан әсәрләре – туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книга печали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997). «Яңа «Сагыш китабы», яки Минзәлә Гаагадан еракмы?», «Боза-боза паспортны, арттырабыз башкортны...» (2002) дигән китапларында язучы башкорт шовинизмына әчке лаборатор анализ бирә. Язучының «Җиңелмәс ул чечен» китабы документаль материаллар нигезендә каһарман чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен хәрби техниканың иң соңгы казанышлары белән коралланган «явызлык империясе»нең миллионлы армиясенә каршы бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи һәм хәзерге фаҗигале язмышына юнәлтелә.

Әдипнең XX гасырның ахыргы – XXI гасырның беренче елларында иҗат ителгән күпсанлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Иманем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш», «Боза-боза паспортны...» кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Публицистика өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен А.Хәлим 2003 нче елда Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый, Бөгелмә җәмәгатьчелегенең мәгариф буенча Һ.Атласи исемендәге әдәби бүләгенә (1995) лаек була.

Туксанынчы елларда А.Хәлим сәнгатьле проза өлкәсендә дә зур иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992), «Казыктагы итальян» (1999) повестьлары, «Кыйбла», «Берлинга хат», «Авылдаш», «Җырлар вакыт» һәм башка күпсанлы хикәяләре һәм бигрәк тә «Татар вакыты» исемле кечкенә романы (1998) әдәби тәнкыйтьтә бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге итеп бәяләнә. «Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган.  Вакыйгалар үткәннәрне искә төшерү белән үрелеп бара. Анда сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә. Әсәрдә авылның тормыш – көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тулы картина булып безнең күз алдыбызга килеп баса. «Өч аяклы ат» повестеның кыйммәте, бик сирәк үзенчәлеге тагы шунда - монда кеше булмаган ҖАН ИЯСЕ, бу очракта ат малкае әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әйткәнебезчә, дөнья әдәбиятында бу - сирәк очрый торган, язучыдан гаять дәрәҗәдә осталык, нечкәлек һәм талант таләп итә торган күренеш. Әле кеше хәтле кешене образ дәрәҗәсенә күтәрү гаять авыр һәм катлаулы эш, ә монда телсез җан ияce турында җан тетрәндерерлек, җан җылатырлык образ тудырырга кирәк! Бу эшне бары тик зур талант иясе генә булдыра ала.

Милли мәсьәләләр – һәр халык өчен мәңгелек. А.Хәлимнең беренче карашка исеме укучы өчен сәер яңгыраган “Хунвэйбин” романы милләтнең асыл үзенчәлеге, үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында. Айдар Хәлим әсәрендә бүгенге заманыбызның гади дә, гыйбрәтле язмышлы да, иманын югалтмаган дистәләгән якты кешеләрне яратып, сокланып тасвирлаган. Әсәрдә чиксез олы талант белән тасвирланганы –¬ бүгенге татарыбызның мәдәнияте, мәдәни тарихы, халкыбыз энҗе-мәрҗәннәре – аның шагыйрьләры, шигърияте. Автор нинди олы нәзәкәт белән, искиткеч урынлы итеп Тукаебыз, Гафуриебыз, Закир, Сагыйт Рәмиевларыбыз, Такташыбыз иҗаты аша җәмгыятьнең фәлсәфи халәтен, җанын, рухын күрсәтә алган. Романның мавыктыргыч та, бик моңлы да булып тууында, андагы хатын-кызларның бик тә матур, татарларга гына хас сөйкемле итеп, самими күңелле итеп тасвирлануы да сәбәпле булыр – аларның хадислардагы “оҗмах ул әниләр аяк астында” диюгә тәңгәл килүендәдер. Илаһи җанлы Мәдинәсе, дөньяга бәхет алып килергә, бәхетле булырга яратылган Сихәт сылу, Сагыйдә

сылу, башкорт чәчәге Зөһрә сылу – аларны сагынасың, хәерле язмыш теләп каласың. Әсәрнең тагын бер үзенчәлеге – аның телендә – ул әдәби татар телендә генә түгел – ул әдәби ТАТАР ИЛЕ телендә. Баштарак сәеррәк тоелса да, соңыннан инде шул чаклы ул телне хуш итәсең, андый татар дөньясын тасвирлаган эпик әсәр, нәк шул татар иле телендә язылырга тиешлегенә инанасың.

Ә «Татар вакыты» исә – әдәбиятыбыз тарихына кереп калырлык, әдәби вакыйга булырлык әсәр. Символ буларак, Мотаһарның татар халкын хәтерләтүе бәхәссез. Бу сурәттә милләтнең бүгенге сыйфатына, аның тарихи язмышына тиң тетрәндергеч хакыйкать чагыла.

Айдар Хәлим — олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия. Димәк, хикмәт, кайберәүләр инанганча, жанр зурлыгында яисә вакыйгалар чиксезлегендә түгел, ә кыска, тыгыз, динамикалы сюжет кысаларында сурәтләнгән конкрет тормыш күренешенә күңелгә нык тәэсир итәрдәй тирән мәгънә сала белүдә икән.Аның әсәрләре яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, өмет һәм иман белән яшәргә өйрәтә.

Кулланылган әдәбият

1. Ак һәм кара көрәше. – Казан утлары. –2002. –№12. –119-128 б.
2. Китап киштәсендә ниләр бар? – Казан утлары. – 2016. – №1. – 132-136 б.
3. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
4. Шагыйрь, әдип, милләтхадиме. – Казан утлары. – 2002. – №1. – 82-83 б.

**Гыйльфанова Ф.М..**
**Яр Чаллы шәһәре**
**МАГББУ «Гали Акыш исемендәге**
**84 нче лицей-интернат»**

## Галимҗан Гыйльманов шигъриятенең тәрбияви әһәмияте.

Язучы, шагыйрь, драматург, әдәбият галиме Галимҗан Хәмитҗан улы Гыйльманов 1957 елның 1 февралендә Башкортостан Республикасының Дүртөйле районы Әсән авылында дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1974-1979 елларда ул Казан дәүләт университетында белем ала. Укуын тәмамлагач, 1980-1986 елларда әлеге уку йортының татар әдәбияты кафедрасында әдәбият укыта, аннары 1999 елга кадәр Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире булып эшли. 1999-2005 елларда - Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары. Хәзерге вакытта Татарстан Министрлар Кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлегендә баш консультант булып эшли. Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе лауреаты.

Галимҗан Гыйльманов – татар әдәбиятында танылган язучы. Өлкәннәр белән бергә балалар өчен дә бик уңышлы иҗат итә: шагыйрь, прозаик һәм драматург, фәнни хезмәткәр, җыр текстлары авторы. Язучы бер истәлегендә: «Мәктәптә укыган елларда ук үз язмышымны әдәбият, иҗат эшчәнлеге белән бәйләргә ният кылдым,» - лип яза. Чыннан да, 1972 елда район газетасында дөнья күргән беренче шигырьләреннән соң, менә инде күп еллар буена татар әдәбияты төрле жанрда аның әсәрләре белән байый.

Г.Гыйльмановның балалар өчен иҗаты үзенең стиле, яңгырашы белән башкалардан аерылып тора. Шигырьләрендә көчле интонация, диклоратив пафос юк. Алар гади, лирик, тормышчан, күпчелеге шаян рух, юмор белән сугарылган. Болар барысы – лирика, юмор һәм кайбер очракларда җиңелчә сатира – бергә кушылып, язучының интонациясен тудыра. Ялыктыргыч, озын-озак, җитди фикер йөртү Г.Гыйльманов шигъриятенә, нигездә, хас түгел. Шуңа күрә әсәрләрен гади генә итеп, «күңелле шигырьләр» дип тә атарга мөмкин булыр иде. Шигърияте оптимизм белән сугарылган, баланың төрле рухи халәтенә дә зур игътибар бирелгән. Мисалга, тәрбияви максат үзәккә куелган, «Су корты» герое чиста, яңгыравыклы, күтәренке тавыш белән укучыларга үз кичерешләрен җиткерә:

Кайчакта ютәлләп алам,

Кайчагында төчкерәм.

Түзәм…

Чөнки мин су сибеп,

Үз-үземне үстерәм!

Автор шигъриятендә таныш, бала белгән һәм ияләнгән күренешләргә мөрәҗәгать итә: туган йорт, якын туганнар, уенчыклар, табигать. Ягъни, Г.Гыйльманов кечкенә һәм урта яшьтәге балаларның игътибарын җәлеп итәрдәй материалга туктала, аны җаны аша үткәреп, уңышлыларын сайлап ала.  Әти-әни, әби-бабай, якын туганнар – шагыйрь иҗатында еш кабатланган образлар. Гаилә әгъзалары белән бәйле аерым вакыйгалар аның бер шигыреннән икенчесенә күчерелеп, отышлы рәвештә үстерелә бара. Нәтиҗәдә, эчкерсез мөнәсәбәт, мәрхәмәтлелекнең гаиләне һәм нәни геройны берләштерүе ассызыклана. Мисалга, бергә генә риза булмыйча, гаилә өчен күп итеп «бәхет пилмәннәре» ясаган Алия, әлеге эшен түбәндәгечә аңлата:

«Кү-ү-п булсын, - ди, - бәхетебез!..»    *(«Алиянең «бәхетләре»)*

“Өндәге төшем” шигырендәге герой өйләрендә булган мөнәсәбәткә шатланып, рәхәтлектән өнендә “төш күреп” ята: әнисе елмаеп-көлеп тора, әтисе аны бик-бик ярата, әбисе коймак пешерә, бабалары өйләренә нур иңдереп намаз укый. Ә герой шуларның барысына сөенеп, түшәгендә изрәп, эреп ята.

Гаилә – балага үзенең хис-кичерешләрен, яратуын күрсәтү өчен беренче уңай шарт. Шунлыктан, мондый шигырьләрдәге хис-кичерешләр нигездә беренче зат исеменнән сөйләнелә. Төп герой – «шагыйрь-бала». Ул кайвакыт оялчан, хисчән, акыллы, гаиләсен яратучы һәм башкалар. Ягъни, автор үзенең балачагын ничек хәтерли – әсәрләрендә аны шул рәвешле чагылдырырга омтыла.

Әнисенең «үлеп-үлеп яратам» дигән сүзенә каршы, «Үлмә, әнием!» шигыре герое, мәсәлән, менә нәрсә ди:

- ¬Ничек инде – үлеп-үлеп?

Үлсәң... синсез нишләрмен?

Моннан соң бер дә еламам

Ни кушсаң да эшләрмен!..

Күп шигырьләр геройның эчке монологы яки дуслары белән сөйләшү-аралашуы буларак яңгырый. Ул – язучы һәм лирик герой – укучыда тыңлый белүче, кичерүче һәм аңа кайгыларны, шикне, бик шәхси кичерешләрне ышанып сөйләргә мөмкин: “Хыял-ат”, “Әбием сихерче бугай”, “Әнисенә охшаган”, “Үз башыма өйрәттем”, “Кызык итәрмен әле” һәм башкалар – шундыйлардан:

Бәйләнмәгез! Бүген сезгә

Бар серемне таратам:

Мин әнигә охшаганмын,

Чөнки аны өзелеп-өзелеп

Өзелеп-өзелеп яратам!

Күп шигырьләрдә лирик герой яратып кына калмый, бәлки, якыннары хакында аерым “капризлар”ыннан ваз кичәргә дә риза. Тормышчан, гаиләнең эш-борчылуларында катнашып яшәүче бала күпләргә үрнәк булырлык. Әле кечкенә булса да, мондый яшәеш – аның да тормыш мәгънәсе. Мисалга, туганнар һәм ипи кадере бала авызыннан аеруча үзенчәлекле яңгырый:

Әле дә әни бар,

Әти бар. Әле дә...

Әле дә Ипи бар. *(“Әни ипи пешерә”)*

Г.Гыйльманов шигърияте психологик кичерешләргә бай. Шунлыктан, әлеге шигырьдә дә хәрәкәт беркадәр кимегән. Әмма аны, уңышлы рәвештә, кабатлаулар тәэсирендә туган эмоция алмаштыра. Икенче бер “Әни булам” әсәре исә күтәрелгән проблемасы ягыннан гына түгел, көтелмәгән нәтиҗә, эмоциональ халәтнең кинәт, яшен суккандай үзгәрүе белән дә игътибарны үзенә тарта:

Әйтеп куя: “Бу дөньяда
Кабат туасым килә...
Баласын ташламый торган
Әни буласым килә...”

Дуслары төрле кызыклы һөнәр сайлаганда, кайчандыр әнисе ташлап киткән кызның “әни профессиясен” сайлавы, әлбәттә, гаҗәп түгел. Гомумән, Г.Гыйльмановның эчтәлеге ике катлам мәгънәдән торган шигырьләре байтак. Мондый әсәрләрне язу өчен күренеш түгел, көчле хис-эмоция кирәк. Ә бу сыйфат шагыйрь талантына хас. Шуңа күрә шигырьләр җиңел укыла, фикер тыгызлыгы, ритм һәм рифманың төгәллеге шигырьләрне бербөтен итә.

Г.Гыйльманов шигъриятендә үткен күз белән вак, әмма бала өчен тормыш матурлыгын тудыручы әһәмиятле материалны бирә ала. Бик еш шаян шигъри юллар белән бала портретын, аның тормышындагы аерым вакыйгаларны сәнгатьчә яктырта. Ул балалар “оҗмах”ына юмор аша карап, аларның “җәннәт” теле белән сөйләшергә риза. Шунлыктан, шагыйрь бала тәрбияләүче кырыс реалист ролендә түгел, бәлки, аларча булырга теләп, “кешечекләр”дән беркатлылыкка өйрәнергә омтыла кебек. Нәтиҗәдә, шигырьләрдә баланы тәртипкә өйрәтү урынына, ярату хисе күпкә ачыграк яңгырый: “Куркак батыр”, “Менә шундый хәл”, “Койма буядым”, “Кызык авыру”, “Ярату”, “Шапшак кыз” һәм башкалар – моның матур мисалы.

“Куркак батыр” шигырендә сабантуйда көрәшеп беренче урынга чыккан Рәсим дә, Г.Гыйльмановка хас булганча, көтелмәгән юнәлештә ачыла:

Әзмәвердәй Рәсимебез
Тәкәдән курка икән!

Гомумән, Г.Гыйльманов шигъриятендәге хис, вакыйга-хәрәкәтнең еш алмашынуы, җанлылык, көтелмәгән йомгак-нәтиҗә бала игътибарын үзенә тарта, балалар шагыйре буларак әдипнең талантын билгели.

Галимҗан Гыйльманов, 90 нчы еллар башында әдәбиятка килеп, балалар шигырендә үз юлын салган иҗатчы – шагыйрь дә, язучы да, драматург та, тәнкыйтьче дә, әдәбият белгече дә. Аның үз стиле күптән формалашкан: образлы фикер бер-бер артлы тезелеп бара да, строфаның соңгы юлларында көтелмәгән көлкеле күренешкә очрап юмор тудыра. Аның шигырьләрендәге хикмәт һәр строфада. Шагыйрьнең бу стильдә иҗат итүе юктан барлыкка килмәгән, ә алдагы буыннан күчкән күркәм традицияләрнең берсе. Күренгәнчә, Галимҗан Гыйльманов әлеге алымны самими юмор хисабына камилләштерә.

Әбисе бүген Алсуга
Күчтәнәчләр китергән,
“Бик аз”, - дип елый-елый,
Алсу гауга күтәргән.
Шул арада күчтәнәчен
Мәче ашап бетергән. (“Күчтәнәч”)

Авторның тәрбияви максат үзәккә куелган “Чишмәгә бардык” шигырендә лирик герой чишмә суын мактый. Аның сәламәтлек өчен файдасы күбрәк һәм “самавыр”да кайнаган су белән эчкән чәйдән дә тәмлерәк чәй булмый ди:

Чишмә суын мактый әби:
- Тәнгә бик шифалы, - ди. -
Самавырга җитми инде,
Кирәкми “Тифалы”, - ди.
... Очраган бөтен кешегә
Әбидән сәлам әйттек.
Бер чиләк су алып кайттык,
Бер чиләк - сәламәтлек!

Шулай ук “Иртә белән” шигырендә дә тәрбияви максат үзәккә куелган. Кош, нәни генә булса да, үзен чиста йөртә. Һәр таңда чирәмдәге чык суында коена, нәни генә томшыгы белән канатларын ышкып ала. Әлеге хәлләрне күзәткән герой, үзенең юынырга

онытканлыгын исенә төшереп, тизрәк өенә кереп китә һәм үзенә кошлар кебек һәрвакыт чиста булырга максат куя:

... Юынырга онытканмын,
Тизрәк керим әле.
Урамдагы кошлар кебек,
Чип-чиста йөрим әле!

Автор үзенең шигырьләрендә туган як темасын да читтә калдырмый. “Курай”, “Бер болыт яшәгән, ди...”, “Җәй белән хушлашу”, “Кайтаваз” шигырьләре шундыйлардан. Мәсәлән, “Курай” шигырендә кырлар догасы да, чишмә тавышы да, туган як гаме, кеше сагышы, һәр аткан таң да – барысы бергә курай моңында чагыла. Курай ул тылсымлы, моңның өе ди автор. Шушы кечкенә генә курай укучыга авторның хис-кичерешләрен әйтеп бирә ала. Шигырьләрендә табигатьнең төрле-төрле гүзәл һәм серле күренешләрен ача. Менә аның “Тылсымлы кич” шигыре:

Кич. Тынлык. Елга. Яр буе.
Су өстендә - ярым ай.
Үрелеп кенә алыр идем,
Тылсым бетә - ярамай!
Кулны алсам – җан үреләә...
Чак тыеп торам: “Тимә!..”
Минем алда – сабый чакта
Суга җибәргән көймә...

Бу юлларны укыгач, үзеңне шул яр буенда басып torgандай тоясың, балачагың искә төшә.

“Эт аталар” шигырендә автор лирик геройның нечкә һәм самими күңел кичерешләрен тасвирлый. Нәни Булат төнлә булган вакыйгага сызлана, “кай җиредер” авыртып йөзен чыта. Аның кеп-кечкенә күңелендә зур давыл куба, ул әлеге хәлләрне аңлап бетерә алмый, ләкин ни булганын сизенә, кыймшанырга да куркып, тәрәзәдән карап тора.

Әдип балалар әдәбиятында яратып, җиң сызганып, балаларны үз итеп эшли. Нәтиҗәдә, заманча, балаларның үзләре кебек үк тынгысыз, шаян әсәрләр барлыкка килә. Шигырьләрендә, кечкенә шаян хикәяләрендә бала үз дөньясын күрә, шатлана, үзенчә борчыла. Мисалга, “Өч кызым булды” шигырендә лирик герой башка кызларның әтиләре юклыкка борчылып, елап кайтып керә. Башка кызларга бер генә тапкыр булса да, “кызым” дип әйт инде, дип үтенә.

Галимҗан Гыйльмановның шигырьләре заманча яңгырашлы булуы белән дә үзенчәлекле, аларда бүгенге тормыш геройлары да урын ала. Мәсәлән, «Уйныйбыз» шигыренә күз салыйк:

Безнең өйдә бөтен кеше уйнап йөри.
Тагын ниләр уйныйм, диеп, уйлап йөри…
Әти уйный көннәр буе компьютерда,
Әби орчык белән уйный, урыны түрдә.
Мин дә уйныйм туп тибешеп, - футболист мин.
Месси белән Роналдудан һич калышмыйм.

Шулай ук тормышның моңсу күренешләрен дә игътибарсыз калдырмый. Мәсәлән, «География» шигыре:

«Нурихан өй эшен эшли,
Алдында карта ята.
Карашлары – тәрәзәдә, -
Бар авыл карда ята…
Авыл диярлек тә түгел,
Тугыз йорт-җире калган.
Кемдер аңа «өметсез» дип,
Кара мөһерен салган.
…Биш бала бар. Алар йөргән

Мәктәп күптән ябылган.
Укырга баралар алар
Ерактагы авылга…
Нурихан боек. Бүген ул
Тамагына капмады.
Чөнки ул ил картасында
Үз авылын тапмады…

Тормышыбызда ата-ана һәм бала, үзара сәламәт хисләр, гомумән, гаилә ныклыгын саклаучы, язылмаган, әмма күпләрнең йөрәк түрендә саклана торган кануннар бар. Бу мәсьәләләр язучының шигъриятендә кат-кат күтәрелде. Г.Гыйльманов балалар тормышын, нәрсә белән кызыксынуларын белеп, алар психологиясен аңлап яза. Табышлары күп һәм кызыклы, конфликтлар көн кадагына суккан проблемалар белән бәйле. Гомумән, Г.Гыйльманов бүгенге көндә татар балалар әдәбиятында да ныклы урын алып тора. Аның әсәрләре тәрбияви кыйммәткә ия. Татар классик шигъриятен үрнәк итү, халык авыз иҗаты материалларыннан уңышлы файдалану һәм татар балалар әдәбиятында яшәп килгән традицияләрне (Г.Тукай, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин иҗатларына хас традицияләр) дәвам итү аның иҗатын югары баскычка күтәрә.

**Әдәбият:**


1. Гыйльманов Г. Йөгерек гөрләвек: Шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1998
2. Гыйльманов Г. Көмеш тарак: Пьесалар, шигырьләр. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1999
3. Минһаҗева Л.И, Мияссарова И.Х. Татар балалар әдәбияты. - Казан-ТаРИХ, 2003
4. Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш. – Казан, Тат.кит.нәшр., 2010
5. «Ялкын» журналы, февраль, 2017



**Закирҗанова Л. М.**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестендә Кәбир образы

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзенең иҗат мирасының шактый саллы, күләмле булуы белән аерылып тора. Ул – шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, публицист.

Шигъриятьтә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хис¬ләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, бал¬ладалары белән билгеле. Алар арасында «Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапкан¬да», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ.б. шундый билгеле шигырьләре бар.

Айдар Хәлим – драматургиядә дә иҗади көчен сынап кара¬ган каләм остасы. Пьесаларыннан «Җан-чишмә» (1983), «Пәри туе» (1990) әсәрләре заманында Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш казаналар, ә балалар өчен язган «Биктырыш» исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.

Айдар Хәлимнең исемен киң таныткан публи¬цистик әсәрләре һәм китаплары бар: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книга печали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997). Алар көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар.

Айдар Хәлимнең сәнгатьле проза жанрында да иҗат ителгән «Өч аяклы ат» (1992)

повесте, «Казыктагы итальян» (1999) новелласы, «Кыйбла», «Берлинга хат», «Авылдаш», «Берлинга хат» хикәяләре һәм «Татар вакыты» (1998) исемле кечкенә романы бүгенге татар прозасының яңа казанышы итеп бәяләнә.

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте 1985-1990 нчы еллар аралыгында язылып башта 1993 елда «Казан утлары» журналында, аннан 1998 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Повесть һәрберсе «Ычкындык, болай булгач!», «Без алаай түгел идек», «Бөкебаш һөҗүмгә күчә», «Чегәннәрдән котылдык», «Мин тагын килдем, Нәстүк!», «Үзең белән ал, Кәбир!...», «Ат кунасында», «Иманлек таулары биек...» дип исемләнгән сигез бүлектән тора.

«Өч аяклы ат» әсәренең сюжет-композиция төзелеше артык катлаулы түгел. Повестьтагы вакыйга сугыштан соңгы елларда, Ырынбур чикләрендә урнашкан татар авылында бара. Әсәрнең төп герое – унике-унөч яшьләрдәге Кәбир исемле малай һәм Бамбук дигән байтал. Малай шушы атны жигеп әнисе белән ерактагы туганнарының хәлен белергә бара һәм килгән төнне үк мал абзарына бүре төшеп, бияне яралый. Ат өч аякка кала һәм ана белән бала туган авылларына үзләре генә кайтып китәләр. Сугыштан соңгы кырыс еллар законы белән малайның әнисен, атка зыян салганы өчен дип, утыртып куялар. Малай ничек кенә булса да атны исән-имин туган авылына алып кайтып күрсәтергә, шулай итеп, әнисен төрмәдән коткарып калырга ниятли. Өч аяклы ат һәм атасыз ятим бала, зур газаплар һәм мажаралар күреп, 50 чакрым араны өч көндә үтә.

Әсәрнең азагы тетрәндергеч һәм фажигале бетә: мең газап белән өч аягында авылына кайтып егылган буаз бияне шунда ук иткә суялар... Колынкаеның мәетен исә котырган этләр бүлешә...

Язманың төп герое – үсмер малай, әсәр үзе дә аның аша тасвирлана. Әсәрдәге хәл-вакыйгалар малайның хәтерендә яңара яки юл дәвамында бара.

Юлдагы вакыйгалар повестьта символика дәрәҗәсенә күтәрелеп тасвирлана, әсәрнең үзәк линиясен дә алар тәшкил итә. Ат һәм малайлыктан чыгып килгән яшүсмер шушы юлда бер тәнгә, бер жанга, бер образга әйләнәләр – ир-атка!

Әсәргә, бик нечкә генә чорналып, сиздермичә генә малайның әнисе – Сания образы, аның бөтен нәсел фаҗигасе килеп керә... Шушы затлы нәселдән үч алырга, аларны төрмәдә черетергә тешләрен шыгырдатып торган Бөкебаш Галләметдиннәр, участковый Сәйфуллиннар, депутат Саҗидәләр, явыз бүре кебек, әсәрнең буеннан-буена бу нәселне «куа баралар».

Әтисе сугышта үлгән малай-Кәбирнең, өйләрендәге бөтен мал-мөлкәтен салым җыючылар талап алып чыгып киткән, кайчандыр бай, укымышлы нәсел булган бу гаилә ачлыктан интегә. Инде менә, атны сәбәп итеп, малайның әнисен дә утыртып куялар: «бер башак өчен – бер ел, ике башак өчен ике елга утырта торган» вакытлар. Әгәр атка берәр нәрсә булса, ул юкка чыкса, малайның үзен дә төрмәдә черетәчәкләр. Бөтен дөнья бу балага каршы.

50 чакрым арада малай белән ат өч зур вакыйга-сынау аша үтәләр. Беренче вакыйга – чегәннәр белән очрашу күренеше. Атны исән-имин авылга алып кайтып күрсәтим, дип юлга чыккан малай сәяхәтенең башында ук ат каракларына очрый. Чегәннәр, сөйләшеп тә тормыйча, аның атын талап алалар. Бу исә – малайның әнисе гомерен төрмәдә үткәрә, дигән сүз, нәселләре өстенә кара тап төшә, малайның үзен дә төрмә көтә, дигән сүз. Әмма иң куркынычы – чегәннәр бу өч аяклы атны суеп ашарга мөмкиннәр, чөнки алар өчен ул башкага ярамый. Менә шушы зур фаҗигане, өстенә килгән афәтне, бөтен йөрәге белән сизгән малай, үлгәнен-калганын белмичә, пәке белән чегәннәр өстенә ташлана. Әмма – кая ул! Үзе – бер якка, пәкесе икенче якка очып барып төшә. Шулчак малай: «Мә, алыгыз, барысын да алыгыз! Тик атка гына кагылмагыз!» [Хәлим 1998: 57] дип, өстендәге күлмәк-ыштанын салып, чегәннәргә ыргыта. Урман уртасында анадан-тума калган ир баланың, сугыш инде болай да талап коры сөяккә калдырган ятим баланың, ат өчен, дип, мал хакына дип шулай өзгәләнүе дөнья күргән чегәннәрне дә айнытып җибәрә. Гөнаһсыз баланы алдарга, таларга ярамавын алар да аңлый.

– Без ятимнәргә тимибез, – диләр чегәннәр, һәм малайның кулына атын тоттырып,

ялан тәпиләренә шыгырдап торган чүәкләр кидереп, урманнан чыгарып җибәрәләр. Кыргый чегәннәр малайга тими, ә Бүләк авылыннан Бөкебашлар, атка утырып, малайны куа чыгалар. Аларга үз сүзләрен өстә калдырырга кирәк, атны юк итеп күрсәтергә кирәк, башбирмәс бу нәселне төрмәдә черетеп, үзләренә гомер буе хакимлек итәргә кирәк... Бүре булып бүре ат һәм малайны эзәрлекләвеннән туктап кала, котырган этләр дә урман башына кадәр генә куа баралар, ат караклары чегәннәр дә аларга тимиләр – әмма авылдаш татарлар арттан куа чыгалар! 50 чакрым буе куа киләләр.

Бүреләрдән дә, ач этләрдән, чегәннәрдән дә котылган ат һәм малай инде кешеләрдән кача башлый. Юлда авылларны әйләнеп үтә-үтә, төн кунарга да алар татар авылларына түгел, чуашларнын ат алачыгына барып керәләр. Кәбир инде ат алырга барышлый биредә кунган була, хәзер дә бу алачык аңа дөньяның иң тыныч, иң ямьле урыны булып күренә. Биредә табигатьнең үзе кебек чиста һәм эчкерсез чуаш кызы Нәстүк һәм ярдәмчел Чтапан дәдәй яши. Бу изге кешеләрнең дә үз фаҗигаләре. Ат алачыгында көн саен Шекспир трагедияләренә тиң фаҗигаләр бара, мәхәббәт һәм нәфрәт, хыял һәм хыянәт бәрелешә...

Үз кайгысы да түбәсеннән ашкан Кәбир-малай ат алачыгында шушы фаҗигаләрнең шаһиты була. Әмма малайлыгыннан инде яшьлегенә кереп барган үсмер ир бала тормышның бу кара якларына озак тукталып тормый, анын күңеле барыбер яктылык, матурлык эзли һәм ат алачыгында да илаһи матурлыкны таба үсмер егет күңеле, ул – буй җитеп килгән чуаш кызы Нәстүк. Яшьлек беркайчан да авырлык, каралык, өметсезлек белән килешми, тормышның бу ягын кабул итми, аңа буйсынмый, ул һәрвакыт үз тирәсендә мәхәббәттән хасил булган саклану һәм соклану боҗрасын кора. Шулай итеп караңгы ат алачыгында да бу ике бала, ике үсмер, ике яшь йөрәк бер мизгел эчендә үзләре өчен әкият дөньясы корып өлгерәләр.

Чуаш Чтапан дәдәй Кәбирнең атын бала караган кебек карый, яраларын бәйли, азык һәм даруларын биреп, ат һәм малайны тагы юлга озата. Әмма Бөкебашлар да тик ятмый, алар козгын кебек шушы ятимнәр өстендә бөтереләләр, авыл саен кереп, аларны эзлиләр, үзләренең мәкерләрен коралар. Әмма Кәбир дә инде курка-курка качып юлга чыккан малай түгел, ул үзендә яңа бер көч-гайрәт сизә. Ул инде юлның күп өлешен үтте, котырган этләрдән дә, чегәннәрдән дә исән калды. Ул гынамы, кем генә очраса да аңа ярдәм итте, көч бирде. Ә чуаш кызы Нәстүк аңа гомерендә беренче тапкыр ир-ат итеп, үзенең сыендыручысы, яклаучысы итеп карады, һәм хатын-кызның шушы бөек ышанычы, өмете Кәбир малайны күз алдында курку белмәс гайрәтле ир-атка әйләндерә, тормышка карата да дәртен, ыргылышын, омтылышын арттыра. Кәбирнең бу мизгелдәге уй-фикерләрен, кичерешләрен автор менә ничек тасвирлый:

«Кәбирдә курку дигән нәрсә бетте, Бөкебашларның алда түгел, артта булуы аңа нишләптер тынычлану китерде. Бамбукның үз җае белән генә сикеренгәләп баруы аңа һәрнәрсәгә фәлсәфи нәтиҗә ясау мөмкинлеген бирде. Юлга чыксаң, анда таң калырлык тормыш ыгы-зыгысы икән; кырмыска түмгәгендә дә, агач ботагындагы карга оясында да, сарут төбендәге тычкан өнендә дә, күзең кичерә, зиһенең сыйдыра алган һәр төштә, һәр адымда яшәү өчен көрәш бара икән; бөтенләй таныш түгел кешеләр туганыннан да якын туганга әверелә икән; юл ач итми, ул ашата һәм эчертә, чөнки ул кешеләр һәм язмышлар кайнашкан чиксезлеккә алып бара...» [Хәлим 1998: 93].

Инде туган авылына кайтып җиттем дигәндә генә, урман уртасында авызларын ыржайтып, бу бичара баланы төпсез сазлык көтеп тора. Кешеләрдән кача-кача бара торгач, кара урман уртасында, кара төндә табигать куйган капкынга очрый ул. Кәбирне ат караучы Нәби агай коткара.

Инде авылларына кайтып җиттем дигәндә, соңгы урман авызында, ул үзен куа килгән Бөкебаш Галләметдине һәм участковый Сәйфуллин белән маңгайга-мангай очраша язып кала. Бәхете: малай алдан сизенеп, атын урман эченә яшереп өлгергән була. Куа килүчеләрнең салмыш булулары, урман авызында да ашап-эчүдән һәм сүгенү-мактанышудан ерак китә алмаулары малайны һәм атны коткарып кала. Аларның сөйләшүләреннән малай үзе өчен сөенечле дә, көенечле дә хәбәрләр ишетә. Сөенечлесе шул – авыл халкы, имза җыеп, малайның әнисен коткаруны сораган, иртәгә ул авылга

кайтырга тиеш икән. Хәбәрнең көенечлесе дә бар – әнисе белән ул өйдә югында, бу бандитлар кереп, сандыктан әнисенең соңгы алка-беләзекләрен урлаганнар. Җитмәсә, әтисенең «похоронка»сын ертып ташлаганнар. Әле Кәбирнең үзен төрмәдә черетергә дә ант итешәләр... Болар урыс авылыннан: «ат бүредән түгел, ә ялланып бүрәнә ташыганда җәрәхәтләнгән», дигән язу алып кайтып киләләр икән. Алар өчен хәзер иң мөһиме – атның авылга кайтып җитмәве. Ул вакытта боларның сүзе өскә чыга, ә «халык дошманы» нәселе булган ана белән бала төрмәдә черияčәкләр...

Ә ат барыбер кайта! Өч аягында булса да өстерәлеп, дүртенчегә малайның ябык гәүдәсен терәү итеп, ат барыбер авылга кайтып егыла...

Авылдан бала булып чыгып киткән Кәбир бу кадәр явызлыкларны күргәч, олыгайган ир-ат кебек, үзенә сорау бирә:

«Салкын кышларда әгәр таудан тауга түбәне япсаң, бар авыл халкы бер өйдә яшәп, бер самавыр чәйдән җылына алыр кебек. Әмма нигә алай түгел? Нигә бертугандай яшәргә тиешле кешеләр бер-берсенен бугазыннан буып бара? Юклык шулай иттерәме? Гомеренең башында туган шушы бик гади сорау Көбирне шулай ук гомере буе җәфалар: нигә? Җир шары өйләнүдән туктагач кына туктармы мондый аһ-зар һәм рәнҗеш?» [Хәлим 1998: 124]

Шушы сорауга җавап бирү өчен, инде өч аягында да басып тора алмаган аягүрә хырылдап җан бирә башлаган байталны малай үз йөрәгенә күтәреп диярлек авылга алып кайтып җиткерә. Бер авыл халкы каршында булса да дөреслекне исбат итү өчен, бер карыш җирдә булса да явызлыкны җиңү өчен...

Образлар системасы ягыннан караганда, малай образы әсәрдә – иң тере, әдәбият өчен ин яңа образларның берсе. Кәбир – сугыш, ятимлек, ачлык һәм зур гаделсезлекләр сәбәпле, акылы белән вакытыннан элек олыгая. Бу кечкенә бала җанында эчкерсез сабый күңеле белән хәстәрле, чама белән эш йөртүче агай акылы бергә сыешкан. Балалыгы белән авыр хәлләргә калса да (чегәннәр белән очрашу, сазлыкка бату һ.б.), авыл агайларына хас зирәклеге, төптән күрә белүе, кирәк икән, төп башына да утырта алуы белән ул бу хәлләрдән чыгу җаен да таба. Юк, малайда хәйлә-мәкер юк, чөнки ихласлык белән хәйлә-мәкер бер җанга сыеша алмыйлар, әмма малайда, вакыты-вакыты белән исәп -хисапка корылган салкын акыл да сизелеп китә. Әйтик, бала күңеле белән ул гарип атны мондый озын юлга алып чыгарга җәлли, атны кызганып, аны муенныннан кочып елый. Шул ук вакытта малай бик яхшы аклый: әгәр ат янында елап кына утырса, аның әнисе мәңге төрмәдән чыкмаячак, дөреслек аста калачак. Атны һәм үзен тиңсез газапларга салып булса да, җаны белән моның гарип атка карата рәхимсезлек икәнен аңласа да, малай бу юлны үтә, үзенекен исбатлау өчен үз җаны аша да атлап уза... Моңа кадәр әдәбиятта тасвирланган «урра патриотизм» яки әкияти батырлык түгел, ә вакытыннан алда өлгергән баланың мәкергә һәм явызлыкка каршы һәр күзәнәгеңдә үз-үзен саклау тойгысы барлыкка килүен күрсәтә торган күренеш. Малай «мин көрәшче булам», дип үсми, әмма малайның һәр күзәнәге үз-үзен сакларга һәм якларга әзер тора, куркыныч заманга каршы тору өчен малай үз-үзен шулай программалаган, көрәшеп исән калуга көйләгән. Айдар Хәлим бу образ турында, «менә ул көрәшә, менә ул җиңә», дип бер сүз дә әйтми, туктаусыз башка төеп тормый. Ул көрәшче характеры тууын катлаулы психологик һәм экстремаль халәттә күрсәтә. Малай – кайнап-актарылып торган холыклы һәм укучы күз алдында үскән, формалашкан, укучы белән бергә көрәшергә һәм җиңәргә өйрәнгән яңа герой, яшь герой. Гаять нечкә күңелле, үзе туып үскән бу урман-кырларны тыны-сулышы белән өзелеп яраткан, бу урман-аланнарда үскән һәр агачны, һәр чәчкә-яфракны танып белгән, шулар белән сөйләшеп-аңлашып, бөек бер күңел гармониясендә яшәп яткан авыл баласы ул Кәбир. Шул ук вакытта аның тынгысыз аңы инде баш өстеннән очкан самолетлар артыннан күккә күтәрелә, үзе бер тапкыр да күрмәгән Кремльләргә хәтле килеп җитә, сугыш вакытында әтисен мәңгегә алып калган Татра тауларына китеп бара ул... Туган ил, Ватан турында да ирләрчә уйлый башлый. Малай атны җитәкләп алып барган кебек, вакыты-вакыты белән автор да малайның акылын үз югарылыгына күтәреп, аны мәңгелек фикер дөньясыннан җитәкләп диярлек алып бара. Үз артыннан алып бара, ияртеп алып бара...

«Мәңгегә атасыз, өлегә хәтта анасыз, күкрәкләрендә үр җилләре кураен уйнатып, кеше биргән күлмәк-ыштанда, кеше биргән кәвешләрдә, сугышларны үтеп исән калган, явызлар пычагы астыннан очраклы гына котылган атны этәреп, черегән ботак-сатак, мурыган үлән, тамырлар исе белән пошлыгып яткан урман төпкелләреннән йөрәге сыман күтәреп алып чыгып килгән малай – кемен булыр ул синең, туган ил? Кем өчендер бик тә кадерле, кем өчеңдер бик тә кадерсез, туфрактан яралган, кояшта карайган, җилдә җилләнгән, кырда көрәйгән, илдә илөнгән, төптән, бик тирәннән күтәрелгән бу тере тамыр, тормышның зирәк һәм хисле бер күзәнәге – кемен булыр ул синең, туган ил? Кешелек басуының тук бөртекләр белән тулышырга ният тоткан бер башагы, болыннар чәчкәсенең күзләве, иртәсен дә, кичен дә дөньяга инәлеп, мәңгелек сагыну авазлары салган, явызлык белән очрашканда сыкраган-сыктаган, янартау булып күкрәп чыккан бу сабыең – кемең булыр ул синең, туган ил?» [Хәлим 1998: 124]

Әнә шулай итеп, автор образы белән малай образы, автор сөйләме белән малай сөйләме вакыты-вакыты белән берләшеп, кушылып китә. Әсәр, нигездә, малай образы, малай сөйләме аша бирелсә дә, автор һәрвакыт аның позициясендә.

Ат жаны белән кушылып беткән Кәбир-малай, атасыз һәм әсәр ахырында атсыз да калган бер татар баласы – укучы күз алдында үзе иргә һәм атка гашыйк бер нәни көрәшче – тормыштагы гаделсезлеккә каршы үзенең гамәләләре белән каршы чыга. Һәм шул сират күперен исән-имин үтә ала.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк: Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестенда сугыш чоры баласы – Кәбир шул чорда барлыкка килгән гаделсезлеккә каршы протест белдереп, көрәшче образ буларак сурәтләнә. Әсәрдә сугыш вакыйгасы белән бергә милләт, халык фаҗигасе дә кушылып китә.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Айдар Хәлим: Биобиблиографик күрсәткеч / Татарстан Республикасы Милли китапханәсе; Төз. Л.М. Заһитова; Җап. мөхәррире И.Г. Һадиев. – Казан: Милли китап, 2001. – 480 б.
2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / Төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б.
3. Хәлим А. Өч аяклы ат: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 143 б.



**Закирова Р.А. (1 квалификацион категория),**
**Муллагалиева Х.М. (югары квалификацион категория),**
**Татарстан Республикасы**
**Менделеев муниципаль районының**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**“Гимназия №1”, Менделеев шәһәре**


## 9нчы сыйныфта “Бибинур” фильмы буенча үткәрелгән дәрес эшкәртмәсе.

**Тема:** Кеше язмышы кем кулында?

**Максат:** Әдәбиятның образлы дөньясын кино сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрнең эстетик ягын кабул итү; татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен якынайту; әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру, татар киносына кызыксыну уяту.

**Дәрес формасы:** “Йолдыз сәгате” уены.

**Техник чаралар:** проектор

**Дәрес барышы:**

**I.Оештыру, ориентлашу.**

Хәерле көн, укучылар. Узган дәрестә без сезнең белән “Бибинур” фильмын карадык. Бу кино берегезне дә битараф калдырмады, күңелләрегездә каршылыклы хисләр уятты дигән фикергә килдек. Шуңа күрә без сезнең белән бүген тагын бер тапкыр каралган

вакыйгаларга әйләнеп кайтып, бер-беребез белән аралашып алырбыз. Дәресебез үзенчәлекле – уен формасында узачак. Шуңа күрә дә без сезне ике командага бүлдек. Сезнең максат – караганнарны искә төшереп, мөмкин кадәр сорауларга дөрес җавап бирү. Һәр дөрес өчен командага фишкалар бирелә. Дәрес ахырында фишкалар санына карап, җиңүчеләр ачыкланачак. Шулай итеп, уеныбызны башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен чишү этабы.**

**1. “Бибинур” фильмы буенча кереш сораулар.**

1.1. Фильм ничәнче елда төшерелгән? (2009)
1.2. Фильмның режиссёры кем? (Юрий Фетинг)
1.3. Өлкән Бибинурны кайсы артист уйный? (Фирдәвес Әхтәмова)
1.4. Руслан Мустафин нинди персонажны уйный? (Мансур)
1.5. Фирдәвес Әхтәмова - нинди театр артисты? (Г. Камал)
1.6. Фильм нинди конкурста ике бүләккә лаек була? (6 халыкара мөселман киносы фестивалендә)
1.7. Фильм нинди киностудиядә төшерелә? (Сабантуй)
1.8. Фильмда Бибинур ролен ничә кеше уйный? (3)
1.9. Фильм нинди әсәргә нигезләнеп төшерелгән? (Аяз Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән...”)
1.10. Җиһангир ролен кем уйный? (Эрнест Тимерханов)

**2. Бер атналык тормыш.**

2.1. Фильм нинди күренештән башлана? (Бибинурның төшеннән)
2.2. Төшендә Бибинурга Вәли нәрсә бирә? (шырпы)
2.3. Бибинур иртән нәрсә көтүенә очрый? (сарык)
2.4. Мансур туңдырманы ничә сумга сата? (12)
2.5. Бибинур почта аша посылкада малаена нәрсә җибәрергә тели? (кильки, карабодай ярмасы, алма)
2.6. Телеграммага нинди сүзләр яздырырга тели? (җомга көн кич белән үләм, кайт)
2.7. Этнең кушаматы ничек? (Кызылбай)
2.8. Балаларны Ленинградка җибәрмәс өчен, Бибинур печәтле кәгазьне нишләтә? (ашый)
2.9. Бибинур почтага посылка җибәрергә атнаның кайсы көнендә бара? (сишәмбе)
2.10. Җиһангир бөтен җирләрен кемгә калдыра? (Мансурга)

**3. Кем сүзләре?**

3.1.“Шырпы – ут, ут – үлем” (Вәли)
3.2. “Америкага ризык җибәрергә ярамый” (почтальон кыз)
3.3. “Нәрсә, ничәмә еллар буе миңа җиңел булдымы әллә? Мин бит гел синең турында гына уйладым” (Мирзаһит)
3.4. “Барысы да Аллаһ кулында” (Бибинур)
3.5. “Бездырам мин сезне. Барыбер минемчә булачак” (Зөһрә)
3.6. “Бүгеннән башлап бөтен җирләр – Маркиз Карабасныкы” (Җиһангир)
3.7. “Мин барыбер җиңәм. Минем тавышым үзенчәлекле” (Мансур)
3.8. “Шикләнмә, Ленинградта балаларга рәхәт булыр” (Зәмирә)
3.9. “Әти, сиңа кылыч бирәләрме?” (Нәҗип)
3.10. “Син нәрсә инде, Бибинур, Мин бит сугышка китмим” (Габдулла)

**4. “Театр нурга илтә...”**

Ике команда да өчәр минутлык кино буенча сәхнәләштерелгән өзек әзерләргә тиеш иде. Хәзер шуларны карап китәбез.

**5.Финал.**

Фильм төшерелгән киностудия исеменнән, ягъни САБАНТУЙ сүзендәге хәрефләрдән мөмкин кадәр күбрәк сүзләр төзергә кирәк (ата, ана, саба, туй, ант, тай ...)

**III. Рефлексия.**

Укучылар, сезгә фильм ошадымы? Тагын татар фильмнарын карарга теләгегез бармы? Нинди темаларга карыйсыгыз килә?

Әйдәгез, дәрес башында куйган сорауга җавап биреп карыйк әле: чыннан да, кеше язмышы кем кулында соң? (фикерләр тыңланыла)

Уен тәмам. Җиңүчеләр билгеле. Барыгызга да уңышлар телибез.

**Зиннәтуллина А.С.**
**Ікв.категорияле**
**татар телеһәм әдәбияты укытучысы**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**ДБГБУ "Н.Кайманов исмендәге кадет мәктәбе"**

## Экраннарда әдәбият дәресе

(Дәресләрдә татар кино һәм спектакльләрен куллану буенча тәҗрибә)

Без яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, тормышта әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Үсеш-үзгәрешләр уку-укыту, тәрбия процессына да кагыла. Укыту-тәрбия өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар, чаралар гамәлгә керә, таныш булган метод-алымнар үзгәреш кичерә, камилләшә.

Ә менә әдәбиятны экраннарда алып баруны дөрес итеп ничек кулланырга? Сорау гади түгел. Бүгенге көндә без әдәбиятны әз укучы, чит ил кинолары белән мавыгучы балаларны укытабыз.

Гадәттә тормышта хәзерге заман балаларының игътибарын телевизор экраннары һәм компьютер җәлеп итә. Шуннан чыгып, экран сәнгате башка төр сәнгатьләреннән өстен тора. Бала кинолар, спектакьләр, мультфильмнар карап аны аңлый. Аны карап, үзендә канәгатьләнү хисе тоя һәм тагын да карыйсы килү теләге кала. Моның өчен күп көч тә таләп ителми.

Ә уку сәнгате ул катлаулырак: сүзнең тавышы да, төсе дә, хәрәкәте дә юк. Уку сәнгатендә конкрет образларны җанландыра белү кирәк. Ә бу хәзерге заман балаларына, бигрәк тә авыр үзләштерүче укучыларга авыр бирелә.

Хәзерге җәмгыять һәм укучы тарафыннан бер генә әсәр дә тирән итеп, үзләштерелә алмый, әгәр дә ул экраннарда яктырылмаса.

Укытучы алдында сорау туа: "Нәрсә эшләргә?" Ә бит, әдәбият дәресләре, бернигә карамастан, ныклы кызыксыну уятырга тиеш.

Үземнең тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: кино, спектакльне дәрестә куллanудан курыкмаска кирәк. Аларны әдәбиятның "дошманнары" итәргә ярамый. Киресенчә, дәрестә кино, спектакльләрне карау әдәбият дәресләренең ярдәмчесенә әйләндерергә кирәк.

Хәзер экраннарда кинолар күбәйде:

Г.Әпсәләмов "Ак чәчәкләр"

А.Хәлим "Өч аяклы ат"

Г.Исхакый "Зөләйха" һ.б.

Спектакльләр:

Г.Ибраһимов "Алмачуар" хикәясе

Г.Камал "Беренче театр"

К.Тинчурин "Зәңгәр шәл"

Т.Миңнуллин "Диләфрүзгә дүрт кияү"

Т.Миңнуллин "Әлдермештән Әлмәндәр" һ.б.

Г.Әпсәләмов "Ак чәчәкләр" , А.Хәлим "Өч аяклы ат" рус, башка милләт укучылары өчен тәрҗемә белән эшләнгән.

Укучыга татар киноларын экраннардан карау мөмкинлеге булгач бу укучы өчен өчен зур уңыш. Киноларны туган телеңдә карау барыбер икенче икән шул. Осталык булганда, татар теле китап теле генә түгел, мультик, спектакль, кино теле дә була ала. Татар теленә камил тәрҗемә, образларның чын һәм кызыклы булуы татар теленең үсешен тагын да югары дәрәҗәгә күтәрә һәм аның киләчәге барлыгын күрсәтә. Укучылар, бигрәк тә татар

балалары татар телендә кино карый алгач, милләтнең әле киләчәге бар диясе килә.

Киноларны, спектакльләрне дәрестә куллану кайбер мәсьәләләрне чишәргә булыша:

1) Логик фикерләү сәләтен үстерә;
2) Телдән сөйләм үсеше үсә, сүз байлыгы арта;
3) Актерлык сәләте үсә;
4) Әдәбият дәресенә кызыксыну арта.

Гомумән, укучыларның әдәбиятка мөнәсәбәтләре сыйфатлы итеп үзгәрә.

Кинолар китапны гәүдәләндерә, мавыктыра, уйларга һәм күзәтергә өйрәтә. Китап сүзләре укучыларның күзалдына килеп баса.

Ә иң мөһиме кинодан кире китапка кайткач, укучылар аны бөтенләй башка төрле күзаллыйлар, тирәнрәк карыйлар һәм күбрәк күрәләр.

Әлбәттә, берьяктан караганда – режиссер китапның әчтәлеген җитәрлек ачык итеп чагылдыра аламы соң? Укучы бит, китапны укып алдагы геройларның тышкы кыяфәтен, хәрәкәтләрен, тавышын үзенчә күзалдына китерә.

Икенче яктан, әсәрләрне экраннарда күрсәтү укучыга китапны режиссер күзлегеннән карарга ярдәм итә.

XX гасырда күп кенә методистлар дәрестә киноны әсәрне укыгач кына карарга кирәк дип санаганнар. Беренче чиратта уку булырга тиеш дигәннәр.

Ә хәзер бу метод заман укучысына туры килми.

Моның өчен дәресне тиешле шартларда үткәрергә кирәк:

1) Киноны карый башлаганчы башта укучыны кинематограф сәнгате белән таныштырырга;

2) Кино яки спектаклны карагач, проблемалы ситуация тудырылырга тиеш;

3) Карау һәм уку эшчәнлеге берничә этап үтәргә тиеш:

- укучыны киноны карауга әзерләү;
- киноны карагач, укучылар белән әңгәмә, укучыларның фикерләре;
- әсәрне уку;
- әсәр белән киноны чагыштыру, анализлау.

Дәрестә киноны куллану эзлекле үткәрелгәч кенә, дәрес кызыклы була. Системалы, эзлекле алып барылмаса, мондый дәресләр уңышлы булмый.

Заманча фикерләүгә омтылган укытучы гына укучысын үз фикере,бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп тәрбияли ала.

Укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгак итеп, шуны әйтер идем: әгәр дә укытучы дәресне эзлекле, киноны, яки спектакльләрне күрсәтеп тиешле дәрәҗәдә кулланса, ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк. Һәм бу хәзерге вакытта татар телен саклап калуда һәм үстерүдә зур өлеш кертәчәк.

**Ибатуллина Ф. Ә.,**
**югары квалификацион категория**
**Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәренең**
**1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

## Фәнил Гыйләҗев шигырьләрендә Тукай образы

I.Кереш

XXI йөз башы татар әдәбияты мәйданына бер төркем яшь әдипләр дәррау килеп кереп, мәдәниятебезне, әдәбиятыбызны баетуда яңа көч тәшкил итәләр. Аларның үз көчләренә ышанып, иҗатларында милләт язмышы, тел үсеше кебек җитди проблемаларны күтәреп килүендә “Әллүки” әдәби иҗат берләшмәсенең дә роле зур була. Шушы берләшмәдә көч җыйган, чыныккан, шагыйрь Ленар Шәех тарафыннан иҗаты “көчле милли үзаң, төпле акыл, тирән хис һәм фәлсәфә” [6: 3] белән сугарылган дип тасвирланган каләм әһелләренең

берсе – Фәнил Гыйләҗев. Шунысы куанычлы – яшь шагыйрь иҗаты аталган сыйфатлары белән дә, иҗатындагы образ, мотивлары белән дә татар шигъриятенең иң якты йолдызы, аның символы булган атаклы Тукайга тартым. Алай гына да түгел, шагыйрь үзе дә, Тукай китапларын укып:

“Шул ук хәлләр, берни үзгәрмәгән.

Шул ук гасыр, дәвер, шул ук чор”, – дип яза [2: 49].

Хәзерге вакытта милли проблеманың көнүзәк мәсьәлә тәшкил итүен, аны чишү өчен Тукай дәвамчыларының сүзе, гамәле кирәклеген искә алып, фәнни эшем өчен сайланган теманы актуаль дип саныйм.

Эшнең максаты – Ф.Гыйләҗев иҗатында Тукай образының бирелешен өйрәнү. Бурычлар буларак түбәндәгеләр куелды:

1) Ф.Гыйләҗев иҗатында Тукай образына тасвирлама бирү, аның ролен күрсәтү;
2) Ф.Гыйләҗевнең милли темага язылган шигырьләрен өйрәнеп, аларда Тукай мотивларын барлау.

Кулланылган методлар арасында әйдәп баручы булып тасвирлама, чагыштырма методлар сайланды.

Фәнни эшнең структурасы түбәндәгечә корылды: кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге.

## II. 1 нче бүлек. Ф.Гыйләҗев шигырьләрендә Тукай образы

Г.Тукайны әдәби остаз дип таныган, аның эшчәнлеге һәм мирасының татар милләте өчен кыйммәтен яхшы аңлаган әдипләр иҗатларында әдип образына еш мөрәҗәгать итәләр. Прозада да, поэзиядә дә, драматургиядә дә Г.Тукай шәхесенә мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләр шактый. Һәркемнең Тукае үзгә: М.Әгъләм Тукае туры, гадел Тукай, Э.Шәрифуллина Тукае халыкка якын Тукай, С.Хәким белән И.Юзеев Тукае зур бәхетсезлекләргә, авыр тормыш шартларына, сәяси эзәрлекләүләргә дучар булган Тукай, Р.Харис Тукае – фәрештә, юламан, шагыйрь, Р.Батулла Тукае – татар милләтенең җаны. Болар янында Ф.Гыйләҗев шигырьләрендә урын алган Тукай турында да халкы, милләте өчен бакыйлыкта да борчылучы, милләт кызлары һәм улларының гамәлләрен күзәтүче дип әйтәсебез килә. Ф.Гыйләҗев шигырьләреннән аңлашылганча, “күктән күзәтүче Тукай” бүгенге татар тормышы белән канәгать була алмый, бу канәгатьсезлек шул кадәр зур, ул аның үпкә өянәген яңадан кузгата ала:

Тукай багып әче күләр сыман,
Тукай көләр бездән кычкырып.
Һәм ютәлләр ил ютәле белән:
“Бетәсез бит, – диеп, – тончыгып [2: 49].

Милләт язмышының казанында кайнаган, журналист буларак та эшләгән Ф.Гыйләҗев илдәге сәяси ситуацияне яхшы аңлый, аны иң рәнҗеткәне – арасында Тукай кебек шәхесләр дә булган татар язмышында биш гасыр буе берни үзгәрмәве:

Шул ук хәлләр, берни үзгәрмәгән.
Шул ук гасыр, дәвер, шул ук чор.
Хурлыгыңа түзә алмаганнан
Ни яшь агыз шунда, ни кычкыр... [2: 49].

Тарих сәхифәләрен чагыштырып карасак, асылда татар милләтенең чыннан да XX йөз башыннан алып алга таба атлавы сизелмәве ачык күренә: Тукай, “Тотса мәскәүләр якаң” дигән шигырендә, Мәскәүгә каршы чыгуның төрмә белән тәмамланачагы турында сөйләсә, Ф.Гыйләҗев, Мәскәүнең чал Казанны харап итүен ассызыклый (“Хәтер көнендә уйлану”); Г.Тукай татарның халәтен ассызыклап, милли үзаң, хөрлек өчен көрәшү теләге уятырга теләп, “Татар халкы! Син үләргә мәхкүм инде, Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмум инде”, дип язса, Ф.Гыйләҗев авыруын онытырга теләп, хәмергә бирелгән татарны тасвирлый: “Татар йолкыш хәлдә... Йокы бүлеп, Ярты төндә хәмер чөмерә” дип яза.

Тукай ютәле мотивы “Тарих өземтәсе” шигырендә дә дәвам иттерелә:

“Башкаланың татар бистәләре
Чумып бара заман тузанына.

Тукай үпкәсенең өянәге
Шул тузанны сулап кузгалыр да
Бер ютәлләр, ишеп диварларын" [2: 36].

Милләтебезнең алгарышы өчен көрәшүнең төп шарты да шагыйрьләр тарафыннан уртак итеп танылa: ГТукай:

Биһүдәдер! Сорыкорттан көтмәк гыйлаҗ,
Син бер гали, сатылмаслык иргә мохтаҗ", дип яза [5: 91].

Ф.Гыйләҗев юллары исә пессимистик тонда язылган, соңгы еллардагы вакыйгаларга күз салу, "сатылмаслык ир", ягъни хаким турындагы уйлануларның хыялга якын булуын күздә тотып, ул "Бар да үткән, бар да сатылган", дигән нәтиҗәгә килә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Ф.Гыйләҗев милләтне инкыйраздан кисәтү өчен аның алгарышы өчен иң күп эшләгән шәхес – Г.Тукай образына мөрәҗәгать итә. Татар милләтенең язмышы турындагы уйлануларында ул милләтне коткаручы итеп бары Тукайны, аның дәвамчыларын гына күрә, хәтта бөек шагыйрьнең ютәле дә кысып торткан диварларны җимерергә сәләтле, ди. Әмма соңгы еллардагы вакыйгалар кысасында яшь шагыйрь иҗатында төшенкелек мотивлары да яңгыраш ала.

## 2 нче бүлек. Ф.Гыйләҗевның милләт язмышы турындагы шигырьләрендә Г.Тукай аһәңнәре

XX гасыр башында туып, нибары 27 ел яшәп, кыйммәте буенча әле дә тиңнәре табылмаган әдәби мирас калдырган Г.Тукай замандашларына да, үзеннән соң әдәбият мәйданына аяк басучыларга да гаҗәеп олы йогынты ясый, кыйбла, өлге, үрнәк булып тора. Безнең һәм бездән алдагы буын турында "Еники, Мәһдиевләрне укымыйча үскән буын", дип атаулары очрый, мондый сүзләр артында "әдәбиятның кыйммәтен аңламый торган, әдәби әсәр укымаган, әдәп-әхлак кануннарын белмәгән, аңлмаган буын" дигән фикер яшеренгәнен аңлау кыен түгел. Бу сүзләрдә хаклык бөтенләй юк, дип әйтеп булмаса да, җәмгыятьтә, мәдәни тормыштагы икенче күренешне күзәтү куандыра: Тукай китапларын укып, Тукай иҗатын һәм эшчәнлеген өлге итеп алган шагыйрьләр дә яши, иҗат итә. Шундыйларның берсе – Ф.Гыйләҗев. Фәнни эшемне язу барышында шуны күзәттем: туры сүзле, милләт өчен януы белән әлеге шагыйрь Г.Тукайга тартым. Милләт яшәеше, алгарышы өчен янып гомер иткән Г.Тукайның Казандагы Шәрекъ клубында кадерле кунак булуы, кайбер вакытларда лекцияләр укуы билгеле. Әлеге клубның милли җанлы татарлар өчен әһәмиятен ассызыклап, галим Р.Исламов болай дип яза: "Шәрекъ клубы" ачылу белән, анда шул заманның бөтен аңлы яшьләре, яшь фикерле сәүдәгәрләре, укучылары, укытучылары, зыялылары, язучылары үзенә хас бер кайнар дәрт, күтәренке күңел белән йөри башладылар" [3: 28]. Чынлыкта да, әлеге клубның халыкта милли үзаң үстерүдә, милли элита тәрбияләүдә роле зур була. XXI йөз башында мондый рольне Иҗтимагый Үзәк башкара. Ф.Гыйләҗев шигырендә язылганча:

Монда иңә җанга милли хисләр,
Һәм оеткы милли үзаңга [2: 54].

Яшь шагыйрьнең икенче бер шигырендә:

Мин Тукайны укып уйга калам:
Берни үзгәрмәгән, шул ук чор, – дип язылa [2: 49].

Шагыйрь сүзләренең хаклыгы "Шәрекъ клубы" һәм Иҗтимагый Үзәк биналары язмышында да чагылыш таба. 1915 елда клуб бинасы хәрби госпитальгә әверелдерелә, һәм аның эшчәнлеге бөтенләй туктатыла. Дөрес, Г.Тукай бу вакыйгадан хәбәрдар була алмый, каты авыру аны 1913 елның апрелендә үк бакыйлыкка күчәргә мәҗбүр итә. Иҗтимагый Үзәк бинасы 2013 елда аукционда сатыла һәм эшмәкәр Илдус Гыймадов тарафыннан үзләштерелә. Активистларның судларга мөрәҗәгать итүе дә, ачлык игълан итүе дә файда китерми, "Дөрес, бездә дә гаеп булды, аны вакытында хосусыйлаштыру турында уйларга кирәк булган. Вакытында андый сорау күтәрелгән дә иде, ләкин каршы чыктылар. Казанның үзә¬ген¬дә татарларга урын табалмаслык көннәр җитәчәгенә кем ышанган", – дип әйтәләр алар [1].

Ф.Гыйләҗевнең "Җәмәгать урыннарында эшләүчеләргә" шигыре, уйлавымча,

Г.Тукайның “Китмибез!” әсәре белән аһәңдәш. Мәгълүм булганча, “Шигырь Патша Думасындагы депутатларның мөселманнарга карата: “Русиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез”, – дигән чыгышларына каршы язылган [4]. Ф.Гыйләҗевне каләм алырга мәҗбүр иткән хәл – җәмгыять урынында эшләүче рус хезмәткәрләренең берсенең Казандагы төп халык – татар вәкилен “Читләр монда рус телендә сөйләшә”, дип кисәтүе. Шагыйрьнең җавабы тукайча туры һәм тукайча кыю:

– Читләр урысчалап сөйли! – дисең,
Без чит түгел монда, төп Халык!
Килмешәкләр калыбына кертмә,
Буташтырма, йөрмә буталып [2: 46].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Ф.Гыйләҗев иҗатында Г.Тукай шигърияте, эшчәнлеге белән аваздашлык күзәтелә: икесе дә татарлар өчен әдәбият, сәнгать турында сөйләшүләр, милли кичәләр үткәрү мөмкинлеге булган оешмаларның әһәмиятен яхшы аңлыйлар; милләткә зыян китерүчеләргә, татарларны кимсетеп караганнарга ачы ирония белән җавап бирәләр; икесенең шигырьләре дә публицистик рух сизелеп тора.

## III. Йомгак

Әлеге фәнни эш яшь, әмма кыю, Л.Шәех тарафыннан хаклы рәвештә “өлгергән шагыйрь” дип аталган Ф.Гыйләҗевнең “Атсыз татар”, “Иҗтимагый үзәк бинасын яклап”, “Кул астымда Тукай китаплары”, “Хәтер көнендә уйлану”, “Тарих өземтәсе” шигырьләрен укып, аларда тудырылган Тукай образы, алардагы Тукай мотивлары, Тукай иҗатының аһәңнәрен өйрәнү нәтиҗәсендә язылды. Эшемдә мондый нәтиҗәләргә килдем:

1) Г.Тукай тормышы, эшчәнлеге, иҗаты яңа гасыр шагыйрьләренең кыю, милли җанлы булып формалашуына һаман да йогынты ясый, аның әсәрләре һаманда яратып укыла, милли җанлы шәхес формалашуга этәргеч бирә.
2) Ф.Гыйләҗев шигырьләрендә тудырылган Тукай күктән, шагыйрьләр күзе аркылы милләт язмышын күзәтеп бара, әмма сөенерлек вакыйгалар күрми, “ачы көләргә” мәҗбүр була, татарны “тончыгып үлүдән” сакланырга чакыра.
3) Ф.Гыйләҗев иҗатын күзәтү аның бөек шагыйрьне остаз итеп тануы охшаш мотивлар, публицистик рухның хакимлек итүеннән дә күренә. Ике шагыйрь дә милләт язмышы өчен борчылып яши һәм иҗат итә; икесе дә милләтне хөрлек өчен көрәшкә чакыра; милләтне кимсетүчеләргә ачы ирония белән җавап кайтара.
4) Ике шагыйрь иҗатындагы охшашлык чорлар арасындагы уртак яклар белән аңлатыла. Ф.Гыйләҗев моны “Кул астымда Тукай китаплары” шигырендә дә кат-кат ассызыклый, тарихи һәм иҗтимагый аренада барган вакыйгалар да моңа дәлил булып тора.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтер идем: әдәбият һәрвакыт җәмгыятькә тәэсир итүче көчле корал итеп танылa. Халкыбыз арасыннан Тукайны өлге итеп алган тәвәккәл, кыю сүзле яшь шагыйрьләр үсеп килә икән, инкыйраз турында сөйләргә иртәрәк әле.

### Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Бикмөхәммәтова Р. Татар иҗтимагый үзәге бинасы сатылды // Ватаным Татарстан. – 2013. – URL: http://matbugat.ru/news/?id=8568 (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.03.2018).
2. Гыйләҗев Ф. Ризасызлык: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 127 б.
3. Исламов Р. Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 191 б.
4. Китмибез! // Википедия материаллары. – URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/Китмибез! (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.03.2018).
5. Тукай Г. Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 255 б.
6. Шәех Л. Өлгергән шагыйрь. Кереш сүз. // Ф. Гыйләҗев. Ризасызлык: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 3-4.

**Каюмова Г.Р.**
**Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**«33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»**

## Бүгенге көн татар киносының торышы.

### Кереш өлеш

Бүген фотоаппарат тоткан һәркем кино төшерә ала. Заманча фотокамералар зур экранда күрсәтерлек сыйфатлы фильмнар төшерергә мөмкинлек бирә. Кинода баш рольне уйнарга яки режиссер булырга хыялланган кешеләргә дә юл ачык. Ә без – 21 нче гасыр кешеләре – үзебезне кино һәм телевидениедән башка күз алдына да китерә алмыйбыз.

“Бүгенге көн татар киносының торышы” дип аталган эшемдә төп максат – бүгенге чор татар киносына бәя бирү. Максатка ирешү өчен, түбәндәге мәсьәләләрне чишүне бурыч итеп куям:

1) татар киносының тарихын, килеп чыгышын өйрәнү;
2) татар киносының бүгенге хәлен тасвирлау;
3) хәзерге татар фильмнарын төрләргә **ж**анрларга аеру;
4) киноның кешегә тәэсире турында гомумиләштерү ясау;

Эшне башкарганда, мин кино сәнгате турында мәкаләләр белән таныштым, татар фильмнарын карадым, алар буенча тәнкыйть язмаларын өйрәндем, татар кино һәм спектакльләрен дәресләрдә куллану буенча булган тәҗрибәләремне гомумиләштердем.

Нәтиҗәләргә ирешү өчен, анализ һәм синтез алымнарына, чагыштыру, гомумиләштерү, капма – каршы кую кебек фикерләү ысулларына өстенлек бирдем. **Төп өлеш**

### Нәрсә ул кино?

Кинематограф – мәдәниятнең бер катламы. Ул хәрәкәтләнүче объектлар ярдәмендә кешеләргә төрле тарих, вакыйгаларны җиткерү ысулы. Кыскасы, кино 3 сәнгать төрен берләштерә: рәсем сәнгате, әдәбият һәм музыка.

### Татар киносының тарихы, килеп чыгышы

Кино – сәнгать төрләренең иң яшьләренең берсе. Әдәбият һәм музыка шикелле сәнгать төрләренең тарихы гасырлар белән исәпләнсә, кинематография тарихын дистәләгән еллар белән генә санарга туры килә. 1895 елда Парижда бертуган Люмьерлар. Берлинда – Складановский, һәм Местерлар, 1896 елны Россиядә Самарский һәм Акимовлар уйлап чыгарган аппарат – рәсемнәрне хәрәкәттә күрсәтүче “синематограф” яңа бер тамашаның тууына сәбәпче була. Шушы техник ачышка һәм яңа тамашага нигезләнеп, сәнгатьнең яңа бер төре туа.

Кино чагыштырмача тиз арада халыкчан сәнгать төрләренең берсенә әверелә. Патша Россиясендә баштарак чит илләрдән, аеруча Франциядән сатып алынган фильмнар күрсәтелә. 20нче йөзнең башларында инде Россиянең үзендә Дранков һәм Ханжонков кинофирмалары тарафыннан нәфис, документаль һәм һәртөрле трюкларга корылган фильмнар эшләнә башлый.

Яңа сәнгатьтән Идел һәм Чулман буе халыклары да читтә калмый. Мәсәлән, Казан губернасында Октябрь инкыйлабына кадәр тугыз киноустановка эшләгәне билгеле. Шундый ук киноустановкалар татарлар яши торган башка губерналарды да булган. Мәсәлән бертуган Кәримовлар Уфаның иң күркәм урыннарының берсендә – шәһәр бакчасында кинематограф ачалар, аңа “Йолдыз” дип шигъри исем кушалар, татар һәм башкорт халыкларын беренче буларак яңа тамаша белән таныштыралар.

Әлбәттә кинематограф халыкка җиңел генә, каршылыксыз гына керми. Татар халкы өчен аның дингә бәйле өстәмә авырлыклары була. Кино үзенең асылы белән – хәрәкәтләнүче җалы сурәтләрне күрсәтүе белән ислам кануннарына сыеша алмый.

Киноны беренче күрү, әлбәттә, татар тамашачысы өчен могҗиза санала. Ләкин сәер тамашаны тамашачы башта ук яратып һәм аңлап кабул итә. Авылларда кино килүне

балалар гына түгел, зурларның да күтеп алулары минем әти-әниләрнең дә хәтерендә. Кино сәнгатен татар халкының җиңел кабул итүе нәсә белән аңлатыла соң? Бу күренеш татар халкының сурәтле фикерләве кинематографик фикерләүгә бик якын булуы турында сөйли. Чыннан да, халык җырларына гына мөрәҗәгать итеп карыйк. Аларда табигать күренешләре белән лирик геройның рухи халәтен янәшә кую, символлар, метафоралар белән эш итү, сөйгән кешенең портретын сурәтләү еш очрый бит.

Әлбәттә, кино – катлаулы сәнгать. Аны бөтен тирәнлеге белән аңлау өчен билгеле бер кинематографик культурага ия булу кирәк. Еллар үтү белән, кино көнкүрешкә тирәнрәк керү белән, кино карау культурасы да үсә бара.

Кино әдәби чыганакка – сценарийга нигезләнеп туа. Киноларның башта тавышсыз, сүзсез булып, 30нчы еллар башында “сүзле” булып китүе әдәбият белән киноны тагын да туганлаштыра.

Эшнең нигезе буларак,  татар киносценарийлары тарихына күзәтү ясыйм. Татар әдәбиятында сценарийлар иҗат итүгә омтылыш 30нчы елларга туры килә.Татар җәмәгатьчелеге Октябрь инкыйлабының ун еллыгын әдәбият, театр, музыка өлкәсендәге уңышлар белән генә түгел, татар тормышына багышлап иҗат ителгән беренче кинофильм белән дә каршыларга омтыла. 1927 елда “Булат батыр” исемле фильмны төшерү өчен эш башлана. Кинога төшерү өчен тарихи тема – татарларның Пугачев хәрәкәтендә катнашулары алына. Татар халкының тормышыннан куелган икенче фильм – “ Койрыклы йолдыз”. Ул 1929нчы елда төшерелә. Шул ук елны җәмәгатьчелеккә күрсәтелә.

Кино сәнгатенең үсеше татар әдәбияты һәм язучыларга да бик тәэсир итә. Кино сәнгате халыкны түге, язучыны да эстетик тәрбияләүдә катнаша. Язучының матурлык тойгыларын тәрбияләүдә халык авыз иҗаты әсәрләреннән тыш, әдәбиятның үз жанрларыннан тыш, кино кебек сәнгать төрләре дә катнаша. Муса Җәлил, мәсәлән, 20нче елларда кино карарга аеруча бер үҗәтлек белән йөри торган була. Хәзерге язучылар да киноны яшьлектә әкияттән ким яратмаганнарын, хәзер дә яхшы фильмнарны яратып карауларын әйтерләр.

Гомеренең соңгы елларында кино сәнгате белән Һ. Такташ та нык кызыксына. Мәсәлән, ул 1930нчы елда үзенең “Камил” дигән драмасын нигез итеп алып, , рус кино эшлеклесе Е.М.Дубровский  белән бергә “Камил” киносценариен яза. Ул экранда җанлана алмый, кино архивлары киштәсендә генә урын ала.

Габдрахман Минскийның 1934-1938нче елларда киноинститутта сценарийлар язу буенча махсус белем алганы билгеле. Ул Астрахань татарларына багышлап “Кара Айдар” исемле киносценарий яза, нефтьчеләр турында берничә документаль киноочерк, 1941нче елның көзендә “Ватан улы” исемле нәфис фильм куелуы билгеле.

Язучы Әхмәт Фәйзи дә кино сәнгате белән мавыга. Ул “Тукай” кинолибреттосын төзи. Аның архив материаллары арасында “Тарих рычагы”, “Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа” кино сценарийлары табыла.

Менә шулай кино сәнгате кабызган иҗат ялкыннары бер кабынып, бер сүнеп торганнар. Архивлар раслаганча, сәнгатьнең яңа һәм яшь төре булган кино һәрвакыт татар культура эшлеклеләрен, әдипләрен үзенә тартып торган.

### Татар киносының бүгенге хәле

Бүгенге татар киносының хәле ничек соң? Бүгенге көндә Татарстанның үз кинематографистлар берлеге бар. Аны Россия кинематографистлар берлеге әгъзасы талантлы режиссер Илдар Ягъфәров җитәкли. Киноның ролен Мансур Гыйләҗев болай бәяли: “Бүген милләт үзен кино аша күрсәтә ала. Аны барлыкка китермәсәк, безнең киләчәгебез дә бәхәсле”.

### Хәзерге татар фильмнарын төрләргә,  жанрларга аеру

Кинематография төрләре дигәндә, нәфис фильмнарны, мультфильмнарны һәм документаль фильмнарны күз алдында тотабыз. Үзем барлаган нәфис фильмнарны кушымта өлешендә китерәм. Сан буенча күпчелек иҗат Рамил Төхфәтуллин һәм Нурания Җамалига туры килә.

Мультфильмнарны русчадан тәрҗемә итү эшен “Барс медиа” кампаниясе башлап җибәрә. “АКСУ кампаниясе” студиясе дә совет мультфильмнарын тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Безнең буын тәрбияләнеп үскән герой Винни-пух, Простоквашино авылы белән бәйле картиналар тәрҗемәсе аеруча уңышлы. Чын татар мультфильмнары төшерү эшен Казанда 2009нчы елда “Татармультфильм” оешмасы оештыра. Габдулла Тукай иҗаты буенча мультфильмнар җыентыгы – аларның хезмәте. Балалар тәрбияләүдә зур өлеш керткән мультфильмнар исемлегенә Г.Сәйфетдиновның “Су анасы”, “Таңбатыр”, Р. Төхфәтуллинның “Шүрәле”, “Ана бәйрәме” мультфильмнарын кертергә була.

Кинематографиянең киләсе төре - документаль фильмнар. Аларның саны бик күп булуы ачыкланды. Танылган шәхесләребез Г.Тукай (Тукай **ж**ив, Г. Исхакый (“На пути к свободе”), Дәрдмәнд (“Золото Дардмана”), Ф. Әмирхан (“На перепутье”) турында, Болгар дәүләте, Казан шәһәре һәм башка темаларга бик күп документаль фильмнар бар. Ләкин, ни кызганыч, алар рус телендә. Безнең тарих, безнең мәдәният, гомумән, безнең халык турында булганга, бу картиналар бик кыйммәтле.

Кинофильмнарның **жанрларына тукталам. Кинематография белеме буенча барлык нәфис фил**ьм **жанрларына да татар киносында әле эз салынмаган. Р. Төхфәтуллинның “Зөләйха” картинасын - тарихи драма, Юрий Фетингның “Бибинур”ын – драма, Байбулат Батулланың “Язмыш сынавы”н – уен-фил**ьм, Альберт Шакировның “Бабай” фильмын – психологик драма, Р. Төхфәтуллинның “Упкын”ын – криминалистик драма, Нурания Җамалиның “Кияү-балакай” фильмын – комедия, Фәрит Дәүләтшинның “Бичаракай” фильмын – мелодрама **жанр төрләренә бүлеп чыктым.**

**Татар киносының тәэсире турында гомумиләштерү**

Үз милли кинобыз булу – сөенечле хәл. Нинди төрдә, **жанрда иҗат ителүенә карамастан, кино бары тик булсын гына, дибез. Татар киносы:**

- уйларга, аңларга, фикер йөртергә өйрәтә (“Бибинур”);
- тарихны ача, аңлата (“Зөләйха”);
- күңелне күтәрә, кәефне яхшырта (сериаллар);
- тәрбияли, әхлак кагыйдәләрен үзләштерергә булыша;
- телгә якынайта;
- тамашачы культурасын булдыра;

**Йомгаклау. Эш нәтиҗәләре**

“Бүгенге көн татар киносының торышы” дип аталган эш үземә канәгатьләнү бирде. Татар киносы турында бәхәсләр, уйланулар бик күп. Үземнең нәтиҗәләрем мондый:

- Татарстан кинематографистлар берлеге бар, талантлы ре**жиссерлар, с**ц**енарий осталары бар, кадрлар әзерләүгә мәдәният институтында махсус факул**ьтет бар, төрле театрлардан рольләргә алынырдай артистлар бар, үз картиналарыбыз туып тора, димәк, татар киносы бар;
- тикшерү эше барышында татар кинолары белән аз мәгълүматлы булуым ачыкланды, киноларны тәкъдим итү җитми, прокат мәсьәләсе аксый;
- мин – ана теле һәм әдәбияты укытучысы, әлеге сәнгать төрен аңлаучы, телне белүче, зәвыклы тамашачылар тәрбияләү эше миңа да йөкләнгән;

**Кулланылган әдәбият**


1. Галиуллина М. Татар киносы нинди хәлдә. – Сәхнә. – 2016.
2. Гыйләҗев А. Җомга көн кич белән. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982
3. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы Хәтер нәшрияты (Тарих), 2004.-511б.
4. Мартыненко Ю.Я. Документальное киноискусство.- «Знание», 1979
5. Мостафина Ф. Татарстанда кино бар. Татар киносы юк. – Безнең гәҗит. – 2014. - №37
6. Хәлим А. Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2002. – 157-294 б.
7. Юзиев Н. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1969. 272 б.

8. shubino-video.ru
9. tatarkino.ru
10. tatarkino.jimdo.com
11. tatarfilmsonline.wordpress.com
http://tatbash.ru/tatarskie/filmy

**Корбанова А. И,**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кинолардан файдалану (А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәре буенча)

Без яшәгән җәмгыять гел үсеш-үзгәрештә. Җәмгыять үсешенә бәйле рәвештә, укыту процессы да һәрвакыт үсеш-үзгәреш кичерә. Даими рәвештә үзгәреп торган заманнан артта калмас өчен бүгенге көн укытучысы аның белән бергә атларга тиеш. Бүгенге көндә балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Шуңа күрә укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту, аларның игътибарын җәлеп итү максатыннан мөгаллим дә әлеге мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында киң кулланырга бурычлы. Татар әдәбияты дәресләрендә язучы-әдипләрнең әсәрләрен өйрәнгәндә, кино карау оештырылса, әсәрне өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә.

Телевидение әдәбиятны һәм сәнгатьне пропагандалауда әһәмиятле эш башкара. Түбәндәге әсәрләр буенча үткән соңгы елларда куелган кино һәм фильмнар әдәбият укытучылары, киң масса укучылар күңеленә хуш килде: "Өч аяклы ат" (А. Хәлим), "Бибинур" (А. Гыйләҗев), "Ак чәчәкләр" (Г. Әпсәләмов), "Тапшырылмаган хатлар" (Г. Кутуй), "Моңлы бер җыр" (Т.Миңнуллин) һ.б.

Фәнни эшебезнең максаты: татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кинолардан файдалану (А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәре буенча) юлларын карау. Максатыбыздан чыгып, түбәндге бурычлар билгеләдек:

1. Әсәргә анализ бирү;
2. А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" фильмына күзәтү ясау;
3. "Өч аяклы ат" әсәре буенча дәреснең план-конспектын тәкъдим итү.

Шагыйрь, язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим кайсы чор турында һәм нинди генә темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын чынбарлыктагы милли, тарихи-иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.

«Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган. Анда сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә. Әсәрдә авылның тормыш-көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тулы картина булып безнең күз алдыбызга килеп баса. Әсәр табигатьнең үзе кебек: караңгы төне дә, кояшлы көне дә бар. Әйе, яшәү җиңел булмаячак. Әмма яшәргә, тырышырга кирәк. Сугыш дигән олы афәт тудырган ул елларны.

Сугыш арты еллары бик авыр чор. Әтисез калган ятимнәргә тагын да авыр. Кечкенә малай Кәбир һәм аның әнисе Сания апа шул чор корбаннары. Колхоз бик авырлык белән генә сөйрәлә. Техника юк, барлык авыр эшкә атлар җигелә. Әле аның анысы да санаулы гына. Күп атлар сугышка җибәрелеп, шунда башларын салганнар. Ашарга да юк диярлек. Җизнәсе һәм апасы Зөлхиҗәләрдән хат килеп төшкәч, алар янына барырга булалар. Алар тормышындагы кара көннәр шушы төннән башлана да инде.

Әсәрнең исеме – «Өч аяклы ат» . Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый – өч аяклы: менә-менә егылам дип тора. Бер эшкә яраксыз Галләметдин ишеләр власть белән идарә иткәндә шулай була инде ул.

Әсәрдән әчке бер җылылык бөркелеп тора. Әсәрнең төп герое – Кәбир исемле үсмер малай. Ул үзенең ихласлыгы һәм авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухы

белән безнең күңелләрне яулый. Ул ат җанлы. Андыйлар турында «хайван җене кагылган» дип әйтәләр. Аның атка булган мөнәсәбәте дә сокландыргыч.

Колхоз бригадиры Галләметдин, лейтенант Шәрифуллин ишеләр үз вазифаларыннан файдаланып, хезмәт ияләренә кол итеп карап, аларны төрлечә мәсхәрәләргә һәм кешелек сыйфатларын санга сукмаска тырышалар. Кәбирнең күңелендә әлеге хаксыз рәнҗетүләр, мыскыллауларга карата көчле протест уяна. Фильмны дәрестә караганда, малайның хич-кичерешләренә аеруча игътибар итәргә кирәк. Шулай да ул җебеп төшми, үзендә алга таба барырга тагы да зуррак көч туплый бара. Әсәрнең ахыры үкенечле бетә. Дөрес, Галләметдин җәза ала алуын. Атны суйдырган өчен, авыл халкы, абзарда тезләндереп, аңа тизәк ашата. Санияне дә өенә кайтаралар, әнисен дә Галләметдин ише адәмнәрдән якларга сүз бирәләр. Тик менә Кәбир генә Бамбуксыз кала.

Әсәр искиткеч матур тел белән язылган. Ул – җырлы һәм догалы тел.

Нәби абый намаз ахрында мондый теләкләр тели: "Хәтәр сугышларда башлары югалган ватандашларым, барлык тере һәм тере булмаган рухлар ихтыярына кабул ит, илаһым. Үз табигатең һәм чит табигатьләр иминлеге хакына! Балаларым, балаларымның балалары хакына ошбу Кәбир атлы ятим сабыйны, рыясыз ат җаны – Бамбук кардәшемне сугышларда исән-аман саклап калдырган канатым итеп, барлык сырхаулардан азат итеп, күктән очырт, җирдән йөгерт, илаһым! Ошбу ир-ат җанын кош-корт күзеннән, кешебашлы козгыннар кулыннан сакла, илаһым!" [2, б. 106].

«Өч аяклы ат» фильмының «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, йөздән артык әсәр арасында җиңеп, унлыкка керүе билгеле. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч. Аның дөньяга танылу көнен татар киносы туу көне буларак билгеләп куйдылар. Аның режиссеры – безгә күп кенә татар фильмнары аша таныш Нурания Җамали. Укучыларга фильмны карар алдыннан әлеге мәгълүматны җиткерергә кирәк. «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивале турында укучылардан сөйләтергә була. Хәзерге яшьләрдә битарафлык, күңел бушлыгы, гамьсезлек, ваемсызлык хөкем сөргән заманда бу фильмның дөньяга туу зур сөенеч булды.

Эшебезне төгәлләп, шуны әйтәсе килә: әдәбият укыту процессында кино һәм фильмнардан эффектлы файдалану программа материалын тирәнрәк үзләштерергә мөмкинлек бирә. Безнең тарафтан татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кинолардан файдалану (А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәре буенча) фәнни эше тәкъдим ителде. Укыту процессында эшебезнең әһәмияте булыр дигән ышанычта калабыз.

Әдәбият


1. Хәлим А. Өч аяклы ат / Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман / А.Хәлим. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2002. – 383 б.

2. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 7. – Б. 88-129


**Кушымта**

(тәкъдим ителгән)

А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәре буенча дәреснең план-конспекты

Тема: А. Хәлим "Өч аяклы ат".

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Метапредмет – әсәрдә тасвирланган чор турында балаларга мәгълүмат бирү. Тарихка, халкыбыз язмышына хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Предмет – укучыларның Айдар Хәлим иҗаты турындагы белемнәрен ныгыту; "Өч аяклы ат" повестеның төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәтү, повесть турында төшенчәне ныгыту.

Шәхескә кагылышлы – укучыларда кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: Айдар Хәлим портреты, мультимедиа, презентация, интернет челтәреннән Айдар Хәлим повесте буенча эшләнгән "Өч аяклы ат" фильмы.

Дәрес барышы

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

*Дәресне оештыру*

Исәнләшү, хәлләр сорашу, яхшы кәеф теләп, дәресне башлау.

Психологик уңай халәт булдыру.

– Хәерле көн, барыгызга!

Имин булсын көнегез!

Сәламәтлек юлдаш булсын,

Шатлык чәчсен йөзегез!

*Актуальләштерү*

1) Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү.

2) Укытучы, юнәлдерүче сораулар биреп, укучылар белән авыл тормышы, атлар турында әңгәмә оештыра.

– Сезнең элеккеге авыл тормышын сурәтләгән фильмнар караганыгыз бармы?

– Тарих буенча искә төшерик: “кулак” дип кемгә әйтәләр? Ни өчен?

– Атларның авыл кешеләре тормышындагы роле нинди?

3) Һәр дәрестә яңа бүлекне укый башлаганчы, әсәрнең авторы Айдар Хәлим турында, алда укылган бүлекләр эчтәлеге буенча кыска әңгәмә.

– Алга таба вакыйгалар ничек барыр дип уйлыйсыз? (Укучыларның үз фикерләрен тыңлау, яңа бүлекне укырга кызыксыну уяту).

II. Уку мәсьәләсен кую

Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” повестеның эчтәлеге белән танышырбыз, әсәрдәге образлар өстендә эшләрбез, тарихка күз салып, элеккеге авыл тормышы үзенчәлекләре белән танышырбыз.

III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Автор белән танышу.

Укытучы, язучының китапларын күрсәтеп, тормышы һәм иҗаты белән таныштыра (презентацияләрдән файдалану).

Бер укучы дәреслектән Айдар Хәлим турында белешмәне укый.

Интернет челтәреннән Айдар Хәлим повесте буенча эшләнгән фильмның өзеген күрсәтү.

“Өч аяклы ат” фильмының, “Алтын мөнбәр” халыкара кино фестивалендә катнашып, 100дән артык әсәр арасында беренче унлыкка керүе билгеле булды. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч китерде. Аның дөньяга танылу көнен татар киносы туу көне буларак билгеләп куйдылар. Аның режиссёры – безгә күп кенә татар фильмнары аша таныш Нурания Җамали.

2. Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” повестеның беренче өлешен уку.

3. Укытучы эчтәлекне ачу өчен сораулар бирә:

– Әсәрнең беренче өлешендә без кемнәр белән танышабыз?

а) Зөлхиҗә әби;

ә) Муса бабай;

б) Кәбир;

в) Кәбирнең әнисе Сания;

г) Бамбук исемле ат.

– Кәбир әнисе белән кая килә?

– Биредә аларны ничек каршы алалар?

– Текстта авыл тормышы ничек сурәтләнә? Шул урыннарны табып уку.

4. Әсәргә укытучы ярдәме белән анализ ясала.

Кәбир һәм аның әнисе Зөлхиҗә әби белән Муса бабайга кунакка килә.

– Укучылар, әйтегез әле, вакыйгалар кайда, кайсы чорда бара?

– Зөлхиҗә әби белән Муса бабай кунакларны ничек каршы ала? (Шат күңел белән, елмаеп).

– Зөлхиҗә әби белән Муса бабай Кәбирләргә кайсы яктан туган? (Зөлхиҗә әби – Кәбир әнисенең апасы, Муса бабай – җизни тиешле кеше).

– Зөлхиҗә әби белән Муса бабай образларына характеристика бирегез.

Зөлхиҗә әби – Кәбирнең әнисенең апасы. Әсәрдә без аның ачык йөзле булуын,

хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүен күрәбез.

Муса бабай – шаян бабай. Әсәрдә аның турында менә ниләр язылган: "Утызынчы еллар башында Муса бабаларын, кулаклыкта гаепләп, балалары-ниләре белән кышкы суыкта өйләреннән оекчан куып чыгарып, Акчунга озаталар, имеш. Инәсе ягыннан картинәсе белән картатасын да озаталар сөргенгә. Йортларын тартып алалар. Хәзер анда – кәнсәләр. Кәбир белә: ат

дворының каравыл йорты – картатасының келәте. Мәктәпнең алгы ягы – Муса бабасыныкы. Сөргеннән котылгач, Муса бабалары, нишләптер, кире авылга кайтмады, алар менә шушы совхозга килеп урнашканнар иде... "

IV. Рефлексив бәяләү

– Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Нинди образлар белән очраштык? (Зөлхиҗә әби, Муса бабай.)

Бәяләү. Укучыларның дәрестә катнашулары бәяләнеп, билгеләр куела.

Өй эше: а) повестьны укырга, эчтәлеген өйрәнергә;

ә) әсәр буенча сорауларга җавап әзерләргә;

б) Илдә утызынчы елларда булган вакыйгалар турында әсәрдә нәрсәләр сөйләнелә? Репрессияләнгән кешеләр язмышы турында тарихтан ниләр беләсез? Шул турыда фикер алышырга әзерләнеп килергә.

Дәресне тәмамлау. Саубуллашу.

**Кутуева Р. М. ,**
**югары квалификацияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Г.С.Боровиков исемендәге 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе**

## Кино ул - тәрбия чарасы

Р.М.Кутуева, югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Г.С.Боровиков исемендәге 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе

### Кереш.

20- гасырның 60- нчы еллары. Балачакның якты бер хатирәсе – авыл клубында балалар өчен кино күрсәткән көннәр. Ничек итеп әти- әнидән ялына- ялына 5 тиен акча сораган мизгелләр һич онытылмый. Акчаны яулап алу өчен шактый хезмәт куярга кирәк була иде. Кайвакыт, әти- әнидән акча эләкмәгәндә, кетәклектән бер йомырка алып, күрше әбигә алып кереп, 6 тиенгә алыштыра идек. авыл клубына барып, ишек төбендә җыелып торган акчасыз балаларны аралап, зур горурлык һәм шатлык хисе белән, клуб эченә үтә идек. Билет сатучы Мөнирә апаның миһербанлыгына ышанып, ишек төбеннән китмичә көтеп торган акчасыз балалар, ниһаять, ярты фильм беткәч булса да, клубка үтеп, экран каршында идәнгә тезелешеп утыралар иде. Телевизорлар әле ул вакытта сирәк йортларда гына бар иде. Шуңа күрә без, үсмер балалар өчен мәдәният белән бәйләнеш ,беренче чиратта, авыл клубында күрсәтелгән фильмнар аша барды. Бәлки шуңа күрәдер дә, балачактан "нәфис фильм**"** атамасы белән күңелгә кереп калган мәдәни тәрбия чарасы минем күңелдә һәрвакыт җылы хатирәләр булып сакланып киләләр. Бәлки шуңадыр да, бүгенге иҗади мәҗлестә чыгыш ясау өчен **"Кино ул - тәрбия чарасы"** темасын сайлап алуым да юкка гына түгел.

### *Татар киносының юлбашы*

Татар киносының тарихы шулайрак башланып киткән, дип фаразлыйк.

1926 нчы елда "Таткино" инициативасы белән "феодализм , басып алулар һәм шул чордагы татар тормышы һәм көнкүрешен тасвирлау"чы ике сценарийга бәйге игълан ителә. Бәйгедә Әгерҗедән партиянең яшь әһеле Габдрахман Шакировның әсәре җиңеп чыга. Аның гаризасы буенча танылган кинодраматург **Натан Зархи** сценарий яза һәм аны режиссёр **Юрий Тарич** тормышка ашыра.Ә аның ярдәмчесе совет кинорежиссеры, беренче татар кинорежиссер - документалист Поздняков Каюм Хөсәен улы (1897-1960) була.

Татар милли рухын чагылдырган беренче фильм булып **"Булат-Батыр"** санала. Бу

фильмның премьерасы 1928 елның **22** февралендә Казанның “Электра” кинотеатрында күрсәтелә. Аклы- каралы форматта төшерелгән бу тавышсыз фильмда геройларның сөйләмен экрандагы титрлар белән язылган кыскача аңлатмалар алыштыра.

Шулай итеп, ТАССР кинематографиясенең чәчәк ата башлау чоры дип 1920- еллар исәпләнә

Картинаның сюжетын 17 гасыр ахыры 18 гасыр башында Русиянең Пугачев хәрәкәтенә бәйле социаль - сәяси вакыйгалар ташкыны белән янәшә үрелеп барган качкыннар башлыгы Булат батырның шәхси драмасы тәшкил итә.

“Булат Батыр” фильмы билгеле бер шартларда кенәз Потемкинга тәрбиягә эләккән татар малае Әсфәннең язмышы турында сөйли.” Канәчкеч хакимияткә каршы барырга җөрьәт иткән ярлы халыкны яклап чыккан хөр күңелле, ирек сөючән Әсфән турындагы романтик рух белән сугарылган бу тарих маҗаралы жанрга тартым”- дип бәялиләр аны кинематография белгечләре.

Бервакыт прапорщик чинындагы Әсфан җәза бирү отряды белән туган якларына килеп чыга һәм әтисе Булатның баш күтәргән крестьяннарны җитәкләве турында ишетә. Ахырда әтисен дошманнардан коткарып, аның белән бергә пугачевлылар ягына күчә.

Бу фильм хәтта чит илдә дә гаҗәеп зур популярлык казана.1930 нчы елгы матбугат чараларында фильмның чит илдә күрсәтелүенең кызыклы фактлары сурәтләнә: “Германиядә “Булат- Батыр” фильмы экраннарга чыкканнан соң Антонов- Иванов фамилияле ниндидер ак эмигрант, проекцион будкага кереп, фильмны юкка чыгарырга маташа.”

Фильмны иҗат итүчеләр, өч гасыр элек булган вакыйгаларны төшерү урыннарын сайлаган вакытта, тарихи - документаль төгәллекне сакларга тырышалар. Шул чордагы матбугатта күрсәтелгәнчә, бу моңа кадәр Казанда үткәрелгән кино төшерүләрнең гаять зурысы була.

Элбәттә, бүгенге көндә дә “Булат - Батыр “ фильмы игътибардан читтә калмый.

Тарих фәннәре кандидаты, Россия Кинематографистлар берлеге әгъзасы Елена Алексеева архивларда кызыклы истәлекләр эзләп тапкан. Аларның берсен күренекле композиторыбыз Җәүдәт Фәйзи язып калдырган.

Менә берничә көн инде, Мәскәүдән «Булат-Батыр» фильмын төшерергә киләләр, дип, бөтен Казан шаулый. Киноны Кремльдә, Казансу елгасы ярында төшерәләр икән. Бер көнне анда мин дә барасы иттем. Кремльнең сул ягыннан күпергә таба халык агымы агыла да агыла. Кремль диварлары янында, Казансу елгасы ярында, Сөембикә манарасының аскы катларында чуар киенгән кешеләр күренә. Аларның күбесе өсләренә чапан ябынган, башларына чалма ураган, - дип язган композитор Җәүдәт Фәйзи.- Капка янындагы биеклекләрдә пушкалар, Екатерина чорындагы патша армиясе солдатлары...

Менә каяндыр режиссер һәм баш утырган машина килеп чыга. Режиссер рупор аша берничә команда бирде дә китеп барды, һәм шунда кремль капкалары янында чын сугыш җәелде! Кораллар ата,кылычлар ялтырый, “пики”лар оча. Бөтен тирә - якта “ура!” тавышлары...”

Балачакта бу фильмны карадыммы - юкмы, хәтерләмим. Хәзерге интернет заманында теләсә кайсы чорның теләсә кайсы фильмын карарга мөмкинлек булганда, “Булат Батыр” фильмын кабат- кабат карарга туры килде. Әлбәттә, тавышсыз фильмнар карау безнең өчен күптән ят нәрсә. Артистлар уйнавында беркатлылык та күзгә ташлана. Ә менә күзләрендәге очкын, мәгънәле, тирән караш аша, күзләр ярдәмендә аңлашуны күрсәтә белү- артистларның осталыгы һәм режиссерның иҗади табышы итеп кабул ителә. Тамашачы аларның тавышларын ишетмәсә дә, күз карашлары аша сөйләшүнең мәгънәсен аңлый: мәхәббәтме бу, нәфрәтме, бер- берсен танып алумы... Гомумән, күз карашлары аша “фикерләрне әйтә белү” - тавышсыз фильмнар өчен мөһим алымнарның берсе булгандыр...

Әлбәттә, татар халкының тормышы һәм көнкүреше темасын тасвирлаган “Булат –Батыр” фильмы татар киносы тарихының юлбашында киләчәккә фатыйха биргән “беренче карлыгач” булып калачак.

**“Бүген безгә көчле кино кирәк...” (М.Гыйләҗев)**

Интернеттан татар фильмнарын барлап утырганда, “Шәһри Казан” газетасының 2016 ел 4 нче февраль санында басылып чыккан “Иң истә калган татар фильмнары “исеме астында исемлеккә тап булдым (Кушымта №1) Бу исемлектә 31 татар фильмы күрсәтелгән. Татар тамашачысы өчен татар дөньясын төрле яктан ачып бирә алган татарча фильмнарны күпләп төшерә башлау- 21нче гасыр татар кинематографиясенең уңышлы башлангычы дип санарга кирәк. Ә фильмнарның сыйфатларына килгәндә, аларның үз тамашачысы, үз тәнкыйтьчесе бар...

Мин кино сәнгате белгече түгел. Мин – 41 ел хезмәт стажым булган гади укытучы. Ләкин гомерем буе кинолар карарга яраттым һәм аларны , әдәби китаплар шикелле үк, кешеләргә рухи азык бирүнең иң мөһим һәм үтемле чараларыннан берсе дип исәпләдем.Әлбәттә, без - рус телендә фильмнар карап үскән буын. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, татар телендә төшерелгән киноларның кирәклеген һәрдаим тоеп яшәдем. Гомерем буе рус мөхитендә яшәп, рус мәктәбендә эшләдем. Татар гаиләсендә яшәүче балаларны рус мөхитенең ничек итеп үзенә йота баруы, татар баласының рус телле татарга әверелүе минем күз алдымда барды. Татар теле укытучысы бу процесс алдында көчсез иде. ”Их без, татарлар, кая тәгәрибез!- кебек күңелне әрнеткеч уйларны бер мин генә түгел, бөтен татар теле укытучылары да кичерәдер , дип уйлыйм мин. Кая китә соң бүгенге татарның милли горурлык хисе? Үз милләтенә, үз туган теленә хөрмәт дигән төшенчә бөтенләй югалу куркынычы астында түгелме соң?..

Илебез тарихы, аның халкының тарихы турында без китаплардан укып кына түгел, ә кинофильмнар аша да белеп килдек. “Война и мир”, “Они сражались за Родину”, “Государственная граница”, “Повесть о настоящем человеке” кебек бик күп фильмнар безне илебезнең патриотлары итеп тәрбияләүдә йогынты ясамый калмадылар, әлбәттә. 1968 нче елда режиссер Леонид Квинихидзе тарафыннан “Ленфильм” киностудиясендә төшерелгән “Моабитская тетрадь» фильмын бөтен мәктәп укучылары белән бергә ничек дулкынланып һәм горурланып каравыбыз әле дә хәтеремдә. Татар халкының Муса Җәлил кебек каһарманы турында рус телендә төшерелгән бу фильм, әлбәттә, бөтен Советлар иленә үзе составында Татар Автономияле Республикасы, аның халкы, Җәлил кебек батырлары барлыгын янәдән искәрткән мөһим бер вакыйга булгандыр. Татар шәхесләренә багышланган мондый фильмнар илебез кинематографиясе тарихында аерым эпизодлар итеп кенә кабул ителә. Режиссер Г.Габайның “49 көн” фильмын 60 нчы еллар яшьләре бик яхшы хәтерлидер. Үзенең өч флотташ дусты белән Тын океан тоткынлыгында идарәсен югалткан үзйөрешле баржада 49 көн буе яшәү өчен көрәшкән татар егете Әсхәт Җиһаншинга да багышланган иде ул фильм. Аларның батырлыгын ул вакытта Ю. Гагарин батырлыгыннан соң икенче урынга тиңлиләр иде.

Хәзерге көндә татар халкының яшәешен үз телендә, үз киносында күрсәтү зарурлыгы көнүзәк мәсьәлә булып килеп басты. Кино белгече танылган драматург Мансур Гыйләҗев 2018 нче елның 22 гыйнварында Мәскәү зыялылары белән очрашу вакытында бүгенге көндә татар киносына мохтаҗлык бик зур булуын ассызыклап билгеләп үтте: “... киноны барлыкка китерү, аны көчәйтү - безнең милләтебез өчен актуаль проблема. Мәсәлән, татар дөньясы - без операсыз, балетсыз күп еллар яшәгәнбез, киләчәктә дә яшәрбез (минем һич тә операны кимсетәсем килми). Ә киносыз берничек тә яшәп булмый. Бүген милләт үзен кино аша күрсәтә ала. Аны барлыкка китермәсәк, безнең киләчәгебез дә бәхәсле. Билгеле, театрыбыз бик көчле, әдәбиятыбыз көчле. Ләкин заман таләпләре буенча, бүген безгә көчле кино кирәк. Бәләкәй генә милләтләр дә, мәсәлән, якутлар, бурятлар бу өлкәдә шундый актив эшлиләр, аларның үзләренең прокат дигән нәрсәләре бар. Салкында машинаны кабызып җибәрү авыр бит. Ә бездә кино шул хәлдә... Кино төшерердәй бик күп тарихи язмаларыбыз бар, ләкин аларны әлегә тормышка ашырып булмый, чөнки тәҗрибә җитми.”

Мансур Гыйләҗев үзенең бу чыгышында соңгы елларның уңышлы фильмнары дип “Зөләйха”, “Бибинур” фильмнарын атый.

Әлбәттә, бу ике фильмның да татар кино сәнгатенә керткән роле искиткеч зур булуы бәхәссез. Әмма мин башка ике татар фильмына тукталып китәргә телим.

## Кино ул - тәрбия чарасы

Безнең бүгенге очрашуыбызның максатларының берсе - тәҗрибә уртаклашу булуны исәпкә алып, ничек итеп татар киносы аша белем бирүне оештыру турында сөйләргә телим.

Быелгы уку елы барышында татар теле һәм әдәбиятын укытуга кагылышлы мәсьәләләр буенча килеп чыккан проблемалар, шул исәптән, бу фәннәрне дәүләт теле буларак түгел, әти- әниләрнең гаризалары буенча туган тел һәм туган тел әдәбияты буларак укытуга күчү нәтиҗәсендә, укучылар беренче сыйныфтан укып килгән рус һәм татар төркемнәре таркалды. Татар телен туган тел буларак сайлаган татар укучысы белән бер төркемгә татар телен өйрәнергә теләгән рус телле балалар да килеп кушылды. Укыту программаларын рус һәм татар телле балаларның бер төркемдә укуын исәпкә алып үзгәртеп төзергә дә туры килде.

Татар төркемнәрендә укучы балалар белән эшләгәндә , әлбәттә, "Мәдәният дөньясында" тапшыруларының видеоязмаларын, татарча фильмнардан өзекләр кулланып эшләү бигрәк тә үтемле була. Балалар белән хәтта әхлакый темаларга сценарий язып, кыска метражлы фильм яки спектакль эшләү мөмкинлеге дә ачыла. Һәрхәлдә, татар балалары белән "Оҗмах әниләрнең аяк астында" спектакле шулай туган иде.

Катнаш төркемнәрдә эшләгәндә, беренче урынга татар телен тел буларак өйрәтүдән дә бигрәк, милли- региональ һәм этнокультура компонентын исәпкә алып эшләү кирәклеге алга килеп басты. Рус балаларының татар теленә, татар халкының тарихына, гореф-гадәтләренә кызыксынуын югалтмау максатыннан, дәресләрдә фильмнар куллануны мөһим шартларның берсе дип саныйм. Ләкин рус баласы белән эшләгәндә фильмнарны сайлап алу мөмкинлеге чикләнгән. Бу рус телле укучы өчен татар фильмнарын тәрҗемәсез карауның аңлау өчен шактый авыр булуы белән бәйләнгән.

Катнаш аудиторияләрдә һәм рус төркемнәрендә фильмнарны аңлап карау бары тик тәрҗемә ярдәмендә генә мөмкин була. Мин укучыларымның ничек итеп татар фильмнарын карауларын күзәтергә яратам. Фильмның "эченә кереп китеп" караучылар шунда ук күзгә ташлана. Эчтәлекне аңлап бетермәгән балаларның тынычсызлануын күрү белән, фильмны туктатып, караган өлеше буенча укучыларның аңлап бару дәрәҗәсен тикшереп, аңлау өчен юнәлеш бирүне мөһим алым дип саныйм. Әгәр укучы сюжетның билгеле бер өлешендә аңламый кала икән, калган өлешен карауга кызыксыну югалырга һәм вакытны бушка уздыру гына килеп чыгарга мөмкин. Әлбәттә, фильмда тәрҗемәнең ничек куелуы да мөһим дип уйлыйм. Тамашачы артистларның сөйләмен, тавыш куелуын, артистларның сөйләм аша бирелгән хис- тойгыларын ишетергә һәм күрергә тиеш. Моның өчен иң кулай һәм дөрес тәрҗемә- субтитрлар ярдәмендә тәрҗемә дип уйлыйм мин. Субтитрларның экранның өске өлешендә түгел, ә аскы өлешендә булуы да мөһим фактор дип уйлыйм. Күзәтүләрдән чыгып әйтә алам: мондый тәрҗемә баланың игътибарын һич кенә дә читкә җибәрми. Ә тавышлы тәрҗемә ике телдә сөйләмне бергә буташтырып, артист сөйләмен икенче планга калдыра һәм, югарыда әйтеп кителгәнчә, тамашачыга артистның тавышы аша бирелгән эмоциональ кичерешләрне тулысынча тоярга комачаулый. Мондый фильмны караганда бала тынычсызлана, игътибарын туплый алмый. Әлбәттә, тәрҗемә ул - шактый четерекле мәсьәлә. Минем белән бәхәскә керүчеләр дә булырга мөмкин. Ләкин мин бу фикерләремне шәхси күзәтүләремнән чыгып яздым.

## "Югалту" фильмы – зур табыш ул

Ә хәзер фильмнар турында. Танылган режиссер Илдар Ягъфәровның "Югалту" фильмын, без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, күктән төшкән бер бүләк итеп кабул иттек. Татарның хәзерге чынбарлыгын шулкадәр дөрес һәм төгәл итеп күрсәткән иң уңышлы фильмнарның берсе дип әйтер идем мин. Әлбәттә, өлкәннәр аудиториясе бу фильмда кутәрелгән проблемаларны бернинди бәхәссез кабул итте. Минем өчен балаларның фильмны ничек аңлаулары һәм нинди нәтиҗә ясаулары бик мөһим иде. Җәмгыять күләмендә, шул исәптән, татар халкы тормышында барлыкка килгән глобаль проблемаларны күтәргән "Югалту"ны мин укучыларыма хөкүмәтебез татар теленә карата билгеле бер карар кабул итеп, рус һәм татар балаларын әти-әниләр гаризасы белән бер "родной (татарский) язык" төркеменә кертеп утырткан беренче дәрестә күрсәттем. Ике

дәрескә сузылган шактый озын фильмны балалар тын да алмыйча карадылар.

Сюжет артык катлаулы түгел. Вакыйга әти (Равил Шәрәфиев) һәм аның улларының мөнәсәбәтләре тирәсендә бара. Фильм башында авылда яшәүче Әнвәр (Ирек Хафизов) шәһәрдәге бертуганнарын авылга чакыртып ала, чөнки авылда кинәттән әтиләре югала. Ташландык авылда аның кайда икәнлеген беркем белми. Шәһәрдән кайтып төшкән композитор Шамил (Радик Сәлимов) һәм төзүче Марсель (Марсель Тимофеев) әтиләрен эзләргә керешә. Әтине эзләү дәверендә бертуганнар бер-берсенә якыная, тамырларын искә төшерә, бер максат өчен берләшә. Ызгышлар да, талашлар да булып ала, әмма ахыр чиктә әтиләре йортка үзе кайта.

"Бу тормышта иң кыйммәтлесе нәрсә? - дип башлый үзенең иншасын 8 нче сыйныфта укучым Азалия Әсфәндиярова.- Үзеңнең киләчәгең ышанычлы, нык булсын өчен, нәрсәне югалтмаска кирәк?..

Без Илдар Ягъфаровның "Югалту фильмын карадык. Бу фильмда зур проблема күтәрелә. Ул - туган телне саклау. Кызганычка каршы, күп кенә татарлар үз телләрен оныталар. Шамил, шәһәргә китеп, үзенең туган телен һәм туган нигезен үткәндә калдыра. Әтисенең югалу хәбәреннән соң авылга кайткач, абыйлары белән татарча сөйләшә алмый. Шуның аркасында туганнары белән дә тиз генә якыная алмый.

Кеше туган телен онытса, туган нигезен, тамырын, гореф- гадәтләрен оныта. "Тамырларын югалткан кеше- сукбай эт кебек",- ди әтиләре. Бу бик дөрес әйтелгән. "Югалту" фильмы безгә зур акыл, сабак бирә торган фильм. Бүген без, Шамил кебек, үз туган телебезне онытсак, югалтсак, киләчәктә үзебезнең балаларыбызны кемнәр итеп тәрбияләрбез икән? Бу гафу ителмәслек гамәл булачак...

Фильм өчен Илдар абый Ягафаровка бөтен татарлар исеменнән бик зур рәхмәт әйтергә кирәк."

*Илсаф Зарипов (8нче сыйныф укучысы):* " Мәктәптән өйгә кайткач, "Югалту" фильмын мин әти- әниләремә дә күрсәтергә уйладым һәм алар белән бергә яңадан утырып карадым. Ул әти- әниемә дә, миңа да бик ошады. Фильмдагы проблема минем өчен дә бик актуаль. Мин үзем өйдә гел татарча гына сөйләшәм, ә мәктәпкә баргач, туган телемне "онытам".

Мин дөрес эшләмим. Өйдән чыгып киткәч тә, фильмдагы Шамил кебек, үзеңнең татар икәнлегеңне, туган телеңне онытырга ярамый.

Без, татарлар, туган телебез белән горурланырга һәм аны сакларга тиеш!"

Ольга Макеева (10 нчы сыйныф)

"Фильм "Югалту" показался очень интересным. В нем раскрывается несколько проблем. Одна из них - это взаимоотношение между отцом и детьми. Надо всегда помнить о своих родных, ведь многие вспоминают только тогда, когда что - то случается. ( В фильме пропал отец, значит, надо приехать…).

Надо помнить о своей Родине, о своем родном языке. Надо ценить это наше богатство. Эта еще одна из немаловажных проблем…

Отец, поняв проблему о взаимоотношениях между братьями, решил, что необходимо сплотить их.

Такие фильмы, как «Югалту», воспитывают в нас любовь к своей Родине, к языку, к семье, раскрывают семейные ценности».

Света Исаева( 10 нчы сыйныф).

"В фильме повествуется о потере близких людей, о братьях, которые возобновили общение при поисках отца. Братья за многолетнюю пору изменились и даже не поддерживали общение. У каждого из них были свои взгляды на жизнь.

Также в фильме поднимается проблема о сохранении родного языка. Человек всегда должен разговаривать на таком языке, на котором учили разговаривать родители.

Мы, молодое поколение, тоже должны задуматься о семейных ценностях, всегда поддерживать общение с близкими нам людьми, ведь чувствуя поддержку, человек

развивается и достигает больших успехов.”

Күргәнебезчә, укучылар, төрле милләттән булуларына карамастан, “Югалту” фильмының асылына төшенеп, үзләре өчен тиешле нәтиҗәне дә ясый алган.

Төп фикерне, әлбәттә, режиссер Илдар Ягафаров үзе җиткерә: ***«Фильм татарлар турында. Без югалмыйбыз, безгә нибары берләшергә генә кирәк дип әйтергә теләдем. Бу фильмны әти белән үк уйлый башлаган идек. Хәзер мин дә олыгая барам, кызым үсеп килә. Бу проблема минем өчен дә бик актуаль икәнлеген аңладым. Фильмдагы Әти - ул безнең туган телебез. Фильмда Әти югалмый, ә туган тел югала. Мин шуны әйтергә теләдем»***

Сценарий төркемендә Илдар Ягафаров һәм Адель Хәеров белән беррәттән, төп геройларны уйнаган Ирек Хафизов, Радик Сәлимов, Марсель Тимофеевның да эшләве фильмны тагы да югарырак баскычка күтәрергә ярдәм иткәндер. Композитор Радик Сәлимовның ( Шамилнең) фильм өчен язган музыкасы әсәрне чын тормышчан итеп кабул итәргә бер этәргеч булды. Бөтен иҗат төркеменә “Афәрин!” дип әйтәсе килә. Радик Сәлимов- Шамилнең, фильм ахырында, кинәт исеп куйган саф җил тәэсирендә җиңел сулап кую эпизодыннан соң, күп тамашачы бу иҗат төркеменә бик зур өндәү билесе куйгандыр, дип уйлыйм.

**“Өч аяклы ат” фильмы- каһарманлык үрнәге**

Укучыларым һәм аларның әти-әниләре күңелендә гаҗәеп җылы тәэсир калдырган икенче фильм, әлбәттә, Айдар Хәлим повесте буенча режиссер Нурания Җамали җитәкчелегендә төшерелгән “Өч аяклы ат” фильмы булды. 2008 нче елда **Алтын Мөнбәр** Халыкара бәйгесендә катнашкан бу фильм 1948 ел вакыйгаларын тасвирлый. Авыл малае Кәбир “Бамбук” атлы аксак аты белән авыр һәм куркыныч сәяхәткә чыга: Кәбирнең әнисе, фронтовикның тол калган хатыны Санияне төрмәдән коткарыр өчен алар тиз арада туган авылларына барып җитәргә тиеш. Санияне совет милкенә зарар китерүдә гаеплиләр.

Укучыларым белән фильмны карауга әзерлек процессы зур вакытны алмаса да, карау барышында, илебез тарихы белән беррәттән, татар халкының тарихы буенча, шулай ук сугыштан соңгы елларда халыкның яшәеш шартлары, колхозлашу, кулакларга каршы көрәш, хөкүмәт чыгарган төрле карарлар буенча да аңлатмалар биреп бару зарур иде. Укучылар фильмны ничек кабул итте соң?

<u>Адилә Мәхмүтова,(8 нче сыйныф):</u> “ Мин бу фильмны әнием белән бергә карадым. Фикерләрне дә әнием белән бергә яздык.

Айдар абый Хәлимов әсәре буенча язылган “Өч аяклы ат” әсәрен карау минем өчен бик җиңел булмады.Чөнки фильмның төп сюжетын халкыбыз өчен иң авыр булган , Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллар тәшкил итә. Бу турыда иске өйләр, авыллар, әтисез- әнисез калган гаиләләр,ачлык, яланаяк чабып йөрүче Кәбир һәм аның дуслары дәлил булып тора.

Шул ук вакытта, Сания апа кебек гади авыл хатынының, Галләметдин кебек урындагы “влач” кулыннан җәберләнеп тә, буйсынмавы, фронтта ятып калган иренә тугрылык хисен саклап калуы мөселман хатын- кызларында горурлык хисен уята.

Ачлык, авыр замана булуга да карамастан, Степан дәдә, Нәби абзыйлар ярдәм кулы сузалар, ризык белән бүлешәләр. Бу гади халыкның ярдәмчел булуы турында сөйли.

Чынлыкта мин фильмның төп герое итеп “Бамбук” исемле атны куяр идем. Чөнки табигать тарафыннан иң матур итеп яратылган бу җан иясенең күзләре дә күп нәрсә турында сөйли.

Нәби абзыйның Бамбукны танып, фронтташы итеп сөеп каравы йөрәкләрне тетрәндерә. Ә ахырда сугыш кырларын үткән атның суелуын, дусты Кәбирнең әрнеп елауларын күз яшьләрсез карау мөмкин түгел.

Икенче төп герой - әнисенең яклаучысы булган яланаяклы Кәбир, әлбәттә. Әнисен, якыннарын, дусларын һәрвакыт якларга әзер торуы, бернидән курыкмыйча, Бамбукны авылга алып кайтуы, ач- ялангач йөреп тә, барлык авырлыкларга чыдам булуы минем сыйныфташ малайларга гына түгел, хәтта олы яшьтәге ирләр өчен дә үрнәк була алырлык.”

<u>Георгий Курятников (10 нчы сыныф)</u>: “Данный фильм тронул за живое Все сюжетные линии фильма тесно перекликаются с судьбами главных героев. В нем ярко показаны события послевоенного периода, когда страна была в разрухе. В колхозах и на

предприятиях работали женщины, так как много мужчин погибло на войне...

Финал фильма оказался непредсказуемым и очень трогательным. Когда закололи лошадь, Кабир сильно горевал об этом. Он со своим другом похоронил сердце “Бамбука” и даже решил поставить памятник со звездой и полумесяцем на могилу .

Фильм мне понравился, поскольку он показался мне очень правдивым. Посмотрев фильм, я сделал вывод, что многие фильмы рассказывают об исторических событиях из жизни того или другого народа. Поэтому их нужно смотреть, чтобы лучше знать историю народов, а также историю нужно знать, чтобы правильно понимать такие фильмы...

Я думаю, что этот замечательный жизненный фильм вполне можно использовать в качестве примера при написании сочинения ЕГЭ.”

## Йомгаклау

Күргәнебезчә, “Өч аяклы ат” фильмы өлкәннәрне дә, укучыларны да битараф калдырмады. Моның башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Берничә сюжет линиясен бер-берсенә үреп бирә белүче Нурания Җамалиның режиссер осталыгын күрсәтү белән беррәттән, шагыйрь, драматург, прозаик һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең кабатланмас, тормышчан әсәрләр иҗат итүче каләм иясе икәненә дә дәлил булып тора бу фильм.

Кулланылган әдәбият:

1.”Булат-батыр” фильмы;
2.”Югалту” фильмы;
3.”Өч аяклы ат” фильмы;
4. Интернет-ресурслар;
5. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
6. Шагыйрь, әдип, милләт хадиме. // Казан утлары. – 2002. – №1. – 82-83 б.

**Латыпова Э. Г.**
**Татарстан Республикасы,**
**Яр Чаллы шәһәре13 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## “Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин иҗатында милләт язмышы”

**Тикшерү эшенең темасы**: Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин әсәрләрендә милләт язмышы

**Эшнең максаты**: Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин әсәрләрендә туган телне, гореф- гадәтләрне, милләтне саклау проблемасы

**Тикшерү объекты**: Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин әсәрләре

**Тикшерү методлары**: эвристик ысул - эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару.

**Алымнар**: Язучыларның тормыш юлы, иҗаты, аның әсәрләре белән танышу, музейда, китапханәдә эшләргә өйрәнү;

**Кереш өлеш.**

« Сатмас егет илен алтын көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын.
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

Ил, милләт язмышы өчен кайгырып, ил борчуы белән борчылып яшәүче
һәм иҗат итүче олуг затлар, фидакарь шәхесләр татар әдәбиятыбызда бик күп. Алар язган әсәрләр, бу исемнәр тарих чоңгылларында бата-чума мең бәлаләр кичеп бүгенге көнгә килеп җиткән татар язмышына бик тә аваздаш...

Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин әсәрләренең барысы буенча да кызыл җеп булып барган проблема — туган телне, гореф- гадәтләрне, милләтне саклау

проблемасы. Язучылар бүгенге җәмгыятьтә бик актуаль булган татар милләтенең язмышы турында сөйлиләр, аның киләчәген кайгырталар.. Үзгәртеп корулар чоры тудырган проблемаларны алдан күрә һәм әсәрләрендә чыгара белделәр. Шундый проблемаларның берсе – аны һәрвакыт борчып-бимазалап торганы, ул-халкыбызның бүгенге язмышы, үткәне һәм киләчәге. Гомумән дә, безнең язучыларның күпчелеге милләтебез язмышына борчылмый калмаган һәм ул бүген дә шулай.

**Максатыбызга ирешү өчен түбәндәге бурычларны билгеләдем:**

-Татар халкының әдәбияты һәм мәдәниятына зур өлеш керткән шәхесләребез - Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин иҗади эшчәнлеген өйрәнү.

-Аларның иҗатын өйрәнү һәм педагогик җәмәгатьчелеккә таныту, пропагандалдау һәм популярлаштыру.

-Язучыларыбыз Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин иҗатын өйрәнү аша халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләүне, буыннар бәйләнешен тәэмин итү.

**Төп өлеш.**

Айдар Хәлим – хәзерге милли сүз сәнгатен әйдәп баручы халыкчан, милләтпәрвар язучысы. Ул прозада да, поэзиядә дә, драматургиядә дә актив иҗат итә, оста публицист буларак та чыгыш ясый, зурлар өчен дә, балалар өчен дә яза. А.Хәлим тәүге әсәрләреннән үк милләт язмышын алгы планга чыгаручы реалист язучы буларак татар әдәбиятына килеп керде. Аның һәрбер әсәренең нигезен милли идея, концепция тәшкил итә. Шулай ук милли рух һәм халыкчанлык белән сугарылган, үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсе куелган әсәрләре татар балалар әдәбиятында зур урын алып тора.

Шушы җөмләләрне дәлилләү өчен, мин А.Хәлим иҗатын өйрәнүне максат итеп алдым.

Айдар Хәлимнең иҗаты күп кырлы һәм мул уңдырышлы. Беренче әсәрләреннән үк сиземләнгән язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Кайсы чор турында һәм нинди генә темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш – гамәлләрен гуманистик идея- эстетик карашлар югарылыгыннан торып анализларга тырыша. Аларны чынбарлыктагы милли, тарихи – иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.

А.Хәлим прозасы – яшәешебезнең көзгесе, милли сурәтебезнең гарип формаларга керүен татарның үзенә күрсәтү, ваемсызлык йокысына талган милләттәшне уяту идеясенең нечкә сәнгать алымнарына төренеп, әдәби формада чагылыш табуы.

**“Тал баласы Талхаветдин” әсәре**

А.Хәлимнең “Тал баласы Талхаветдин” әсәре тартмалы композиция хасил итеп, анда 19 хикәя бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп тулы бербөтенгә оеша. Әсәрнең һәр бүлеге татар милләтенең, татар халкының тарихын, үсеш чорын тасвирлый. Әсәрнең төп герое тал баласы Талхаветдин символ дәрәҗәсенә җиткерелеп, милләтнең киләчәге кебек мәгънәви эчтәлекне үзенә беркетә. Бу әсәрендә А. Хәлимнең милли концепциясе тарих һәм дин төшенчәләрен берләштерә. Тал баласы Талхаветдин образына бик күп катлаулы мәсьәләрне ачу вазыйфасы йөкләтелгән. Мәсәлән, тарихны белмәү, татар авылларының бетүе, әхлаксызлык, имансызлык һ.б.

Әлеге әсәрнең кызыклы ягы тагын шунда, автор балаларга фикерне әйтеп бетерми, балада сорау туу мөмкинлеге, уйлану өчен җирлек калдыра. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Айдар Хәлимнең милли идея белән сугарылган “Тал баласы Талхаветдин” әсәре балаларда милли рух, үз милләтеңне, туган телеңне ярату хисләре тәрбияли.

**“Казыктагы тальян” әсәре**

Айдар Хәлимнең “Казыктагы тальян” хикәясе субъектив образ, ягъни хикәяләүче исеменнән бәян ителә. Әсәрнең хикәяләүчесе – үз позициясен, мөнәсәбәтен ачык белдерүче зат. Аның үз героен Бәгъремне тасвирлавы, егетнең уй-фикерләрендә, хис-

кичерешләрендә калкып чыккан каршылыкларга битараф калмавы күзгә ташлана.

Әдәби әсәрдә образлар тулы бер тәртип – система хасил итә. Алар арасында төп рольне, әлбәттә, кеше образлары уйный. Хикәядә объектив кеше образлары күп, алар әсәрне укучыга җиткерүдә төп рольне башкара. *Төп герой* Бәгърем, *ярдәмче* – Разия. *Эпизодикка* Гыймакай бабай (Гыйльметдин) һәм Айсин керәләр. Язучы аларның портретын бирә, аерым вакыйгаларда аларның уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен дә өлешчә тергезә. Гыймакай бабай ул Бәгъремне ярата, аңа ярдәм итә, яклый. Ә Айсин аны җәберли ("тумыштан туган"), аның тальян гармунын тартып алып кырандас астына ташлый. Асылда, әлеге эпизодик геройлар, вакыйгаларда катнашып, сюжет хасил итүче ситуация тудырырга ярдәм итә һәм төп геройны тирәнрәк ачарга мөмкинлек бирә. Шулай ук эпизодик геройларга тагын Бәгъремнең яшьтәшләре Ихсан һәм Сабирҗан, Зимагур Зиннәтулла, Чулак Гамир, Раһиба җиңги – Разияның әнисе, Разия, Кысык Күз, Разияның әнисенең туган энесе – Мәсгуть, картинәсе Өммегөлсем керәләр.

Төп сурәтләү предметы кеше булган әдәбиятта *кеше образлары* иң әһәмиятле рольне башкара. Кеше образлары бирелеше катлаулы күренеш хасил итә. Образ тудыру вакытында тышкы кыяфәт, портрет, психологик анализ, характер, автор бәяләмәсе, геройны башкалар белән янәшә яки каршы кую тәэсир ясый. *Төп герой* Бәгърем характер буларак ачылган. Әсәрнең күп өлеше шушы образны төрле яклап тудыруга хезмәт итә.

А.Хәлим – символлар теле белән эш итә белгән нечкә тоемлы язучы. Ә бу тел бары тик талант ияләренә генә буйсына һәм аларга гына үзенең серләрен ача. *Ясалма* образлардан автор символларга мөрәҗәгать итә. *Бәгърем* образы символ булып килә. Туры мәгънәсендә егет исеме сөю хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе символ була. Егетнең әнисе Тәнзилә үлгәндә "улыма Бәгърем исеме кушыгыз" ди. Әйе, яраткан кешегә без төрле матур сүзләр белән эндәшәбез. Мәсәлән, бәгырь кисәгем, бәгырем кисәге, сөеклем, җаным һ.б. Әсәрдә мондый өзек бирелә: *"Аңлагансыздыр: Бәгърем исемле ул. Бәгърем исемле бегърем, димәк. Аңлагансыздыр: аның исемендә үк нindидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде. Уйлап кына карагыз: Бәгърем кадәр бегъремне яратмаска, инкяр итәргә, аеруча ташлап китәргә мөмкинме? Мөмкин түгел. Шуңа күрә дә Бәгърем бит ул. Син Бәгъремгә: "Мин сине яратмыйм, Бәгърем" – дип әйтеп кенә кара!.."*

Шулай итеп, хикәядә Бәгърем образы, характеры үзәктә тора. Бәгъремнең характер буларак тулы итеп тудырылуы егеттәге акыл һәм хис көрәшенең, аның кечкенә чактан ук бергә уйнап үскән дусты Разиясын югалту һ.б. ышандырырлык итеп укучыга җиткерергә булыша.

Бу хикәясендә автор фаҗиганы персонажларның күңел дөньясында барган кичерешләр аша тасвирлый. Монда совет чорының кешелексез сәясәте һәм татарның үз битарафлыгы нәтиҗәсендә туган катлаулы кичерешләрнең сурәтләнеше дә, аларга авторның төгәл бәясе дә урын тапкан.

**«Өч аяклы ат» әсәре**

Әсәрнең исеме - «Өч аяклы ат» . Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый - өч аяклы: менә - менә егылам дип тора.

«Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган. Вакыйгалар үткәннәрне искә төшерү белән үрелеп бара. Анда сугыштан соңгы еллардагы татар авылы, аның гади, эшчән, әмма авыр сынауга дучар ителгән кешеләре сурәтләнә. Әсәрдә авылның тормыш – көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тулы картина булып безнең күз алдыбызга килеп баса. Әсәр табигатьнең үзе кебек: караңгы төне дә, кояшлы көне дә бар. Әйе, яшәү җиңел булмаячак. Әмма яшәргә, тырышырга кирәк. Сугыш дигән олы афәт тудырган ул елларны.

А.Хәлимнең әлеге әсәрендә ил, халык язмышының аеруча катлаулы һәм фаҗигале дәвере – крестьяннарны көчләп күмәкләштерүгә мөнәсәбәте дә чагылыш тапкан. Бу чорда акыллы һәм таза тормышлы игенчеләрнең үрнәк хуҗалыкларын туздырып, аларның хәләл көч белән тупланган мал – мөлкәтләрен ирексездән тартып алып, ил икътисадына һәм

аның абруена, рухи байлыгына иксез – чиксез зыян китерелә. Сугыштан соңгы елларда авыл халкы җәбер – җәфаны, интегүләрне байтак күргән шул. Хезмәт көненә берни бирмиләр диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфалыйлар! Еллар буе берни бирмиләр, еллар буе барын халыктан гына сорыйлар. Кесәңнән бер башак табылса, бер ел төрмә, ике башак табылса, ике ел төрмә каралган. Ә бер кесә ашлык белән тотылсаң, башыңны ун елга төрмәгә тыгалар. Ә шушы чорда ат хәтле атны сафтан чыгарсаң, бу колхозны сафтан чыгару дигән сүз. Димәк, башың гомерең буе төрмәдә чериячәк.

Сугыш арты еллары бик авыр чор. Әтисез калган ятимнәргә тагын да авыр. Үз көннәрен үзләре күрергә өйрәнеп, авырлыкларны җиңә - җиңә яшәгән чак. Бөтен тормыш авырлыгы хатын – кыз һәм балалар җилкәсендә. Ирләр юк дәрәҗәсендә. Кечкенә малай Кәбир һәм аның әнисе Сания апа шул чор корбаннары   Ана кеше бердәнбер юанычы - малае Кәбиргә зур өметләр баглап, сабырлыгын җыеп, бөтен көчен эшкә бирә. Сания апа ниләр генә күрми, нинди авырлыкларга гына түзми! Аның чыдамлыгына, түземлегенә сокланмау мөмкин түгел. Сугышта батырларча үлеп калган иренә булган мәхәббәтне олы бер хис итеп саклый. Мәхәббәтенә хыянәт итүне ул уйлап та карый алмый. Күпме газап-михнәтләр чиксә чигәр, башкайлары төрмәләргә керсә керер, ләкин ул намусына тап төшермәс!

Әсәрнең төп герое - Кәбир исемле үсмер малай. Ул үзенең ихласлыгы һәм авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухлы үсмер булып безнең күңелләрне яулый. Ул ат җанлы. Андыйлар турында «хайван җене кагылган» дип әйтәләр. Бамбук малай өчен бик якын җан иясе. Атны суйганда өзәләнеп кычкырулары әле дә колагымда яңгырый. Дусты белән ат йөрәген кадерләп күмүләрен генә искә төшерик… Ике дус җирне тырмый – тырмый кабер казый. Бамбук каберенә киләчәктә һәйкәл кую, ай һәм йолдыз сурәте төшерү уйларында. Әйе, Кәбир нечкә күңелле. Аның атка булган мөнәсәбәте дә сокландыргыч. Атны иң олы ярату белән ярата белә шул ул.

Нинди генә кыенлыклар, кимсетелү- җәберләүләр , михнәт – газаплар күрергә туры килми аларга?! Әнисен хаксызга мыскыл иткән колхоз бригадирының ямьсез гамәлләренә ул түзеп тора алмый. Явызлык, намуссызлык, шәфкатьсезлек хакимлек итмәскә тиеш! Алар тиешле җәзаларын алырга тиешләр!

Әсәрнең ахыры үкенечле бетә. Дөрес, Галләметдин җәза ала алуын. Атны суйдырган өчен, авыл халкы, абзарда тезләндереп, аңа тизәк ашата. Санияне дә өенә кайтаралар, әнисен дә Галләметдин ише адәмнәрдән якларга сүз бирәләр. Тик…Тик менә Кәбир генә Бамбуксыз кала…

Бу әсәр буенча татар телендә фильм да төшерелде. «Өч аяклы ат» фильмының «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, йөздән артык әсәр арасында җиңеп, унлыкка керүе билгеле булды. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч китерде.

**Гаяз Исхакый әсәрләре**

Безнең язучыларның күпчелеге милләтебез язмышына борчылмый калмаган һәм ул бүген дә шулай. Моның сәбәбе дә ачык,  билгеле. Нинди генә акыл иясе моңа битараф калсын?! Гаяз Исхакыйны гына алыйк.  Без моны “Зөләйха”, “Мөгаллимә”,” Олуг Мөхәммәд” әсәрләрендә ачык күрәбез.Минем милләтем — бөек татар милләте. Ләкин ничә еллар дәвамында изелеп яшәгән ул. Көчләп чукындыру, телне оныттыру Рәсәй хөкүмәтенең төп бурычы булып китә.

Г. Исхакыйның «Зөләйха» фаҗигасе шушы вакыйгаларны күз алдына тулырак китерергә булыша. Чын күңеленнән дингә табынган гаиләне көчләп чукындыралар. Аларга, мулла кушкан мөселман исемнәрен бозып, чит урыс исемнәре тагалар. Зөләйханы яраткан иреннән аерып, бер урыска кияүгә бирәләр. Бу, әлбәттә, Зөләйхага түзә алмаслык хәсрәт булып төшә.  Кешенең шәхси тормышына тыкшынырга, аңа нәрсә эшләргә кирәклеген өйрәтергә кемнең ни хакы бар?! Бу вакыйгалардан соң Зөләйха тыныч кына яши алмый, көрәшергә, үз халкы һәм үз милләте, дине өчен үч алырга сүз бирә. Үзе өчен әзерләгән агуны биреп урыс ирен үтерә, моның өчен аны зинданга ябалар. Монда Зөләйха бик күп тән һәм җан җәрәхәтләре ала, ләкин аның рухы ирektә була — ул рәхәтләнеп намазын укый,

Аллаһы Тәгалә белән икәүдән-икәү генә калып, бик күп уйлана.

Зөләйха кебек каһарман кешеләр булганда гына татар халкы мәңге яшәр! Чөнки дин бетсә, тел дә бетә. Ә инде тел бетсә, халык халык булудан туктый.

**Туфан Миңнуллин әсәрләре**

Милләтебезнең эреп югалуына алып барачак төп сәбәпләрнең берсен Гаяз Исхакый динебезне, милләтебезне югалтуда күргән иде. “Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык, милләт үзе бетә”,-дип язган ул. Мәсәлән, ”Зөләйха” исемле драмасы ул көчләп чукындыруга каршы чыккан әсәр булса, Туфан Миңнуллин бу фикерне дәвам итә, алай гына да түгел, тирәнәйтә. Милләтебезнең акрынлап сыегая баруын ул рус һәм татар арасындагы катнаш никахларда да күрә. Әгәр дә урыс татарны катнаштырган никахлары белән канәгатьләнә һәм горурлана алса, без, “кече милләт” вәкилләре, моны әйтә алмыйбыз. Ни өчен? Моңа ачык җавапны Т.Миңнуллинның үзгәртеп корулар чорындагы иң көчле әсәрләреннән берсе булган **“**Илгизәр +Вера”(1992) пьесасында табарга мөмкин. Татар театры тарихында аерым урын алып торган, тамашачыны еларга һәм көләргә мәҗбүр иткән иң уңышлы, халыкчан комедияләрнең берсе, әлбәттә, “Әлдермештән Әлмәндәр”(1976). Драматург Әлмәндәр карт образына татар халкының рухи ныклыгын, тирән акылын, гүзәл гореф-гадәтләрен , намуслы яшәү рәвешләрен салып биргән.

Телне саклау мәсьәләсенә килгәндә дә, мин тулысы белән Туфан аганың сүзләре белән килешәм: «Телне, милләтне саклау җәмгыятьнең әйдәп баручы кешеләреннән тора», — ди ул.

**Нәтиҗә** ясап шуны әйтәсе килә: Айдар Хәлим, Гаяз Исхакый, Туфан Миңнуллин – безнең тормышыбызның аналитиклары, андагы кара күренешләрнең тамырын эзләүче һәм табучы, татарның саф сыйфатларына мөкиббән киткән гашыйгы, милли рухның югалуына әрнүче һәм чаң сугучы фидакарь әдипләр. Киләчәктә дә аларның әсәрләрләре армый- талмый милләтебезгә хезмәт итсен. Сезнең татар халкына эшләгән игелекләрегез дәвамлы булып, милләтебезне дан- шөһрәткә күмсен!

Мин сайлаган тема бик актуаль дип саныйм. Чөнки, беренчедән, язучыларның үзгәртеп корулар чоры тудырган проблемаларны, аеруча халкыбызның бүгенге язмышы, үткәне һәм киләчәге өчен борчылып, үз әсәрләрендә күрсәтә алдылар. Икенчедән, язучыларыбыз кеше язмышын җәмгыять һәм милләт язмышы белән бәйләнештә карап, халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен тасвирлау аша һәр кешенең үз алдындагы торган бурычларын онытмаска тиешлеген искәртте. Өченчедән, әсәр геройлары аша халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен, иң матур сыйфатларын-хезмәтне ярату, өлкәннәргә хөрмәт, буыннар арасында рухи бәйләнеш, яшәү дәрте, әхлакый кануннарга тугрылык һәм башкаларны яктырта алдылар. Ул еллар үтеп тә югалмас, алтыннарга тиң зур мирас.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. - Казан: “Мәгариф” нәшр., 2004, 247 б.
2. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. - Казан: “Мәгариф” нәшр., 2005, 111 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. / Казан: Татар. кит. нәш., I том – 1977, 476 б., II том – 1979, 726 б., III том – 1981, 832 б.
4. Хализев В.Е. Теория литературы. – М., 1999.
5. Фәтхерахманов Р. Йөрәкнең җеназасы.// Казан утлары. – 2003. - № 11. – 132-138 б.
6. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. - Казан: Раннур, 2002, 352 б.
7. Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002, 383 б.
8. Хәлимов Б.Н. Тал баласы Талхаветдин: балалр өчен нәни хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшер., 2014. – 48 б.701.Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Казан:Мәгариф ,2007.-223б.
9. Нуруллин И. Кеше һәм драматург! . Мирас. 1995. — №19. – Б.53.
10. Т. Миңнуллин. Сайланма әсәрләр. 5том. Казан, Татар китап нәшрияты, 2002. б.

Т.Миңнуллин. Утырып уйлар уйладым. Казан, Татар китап нәшрияты,1997.
11. Ф.Мусин Тарих һәм заман. Соңгы еллар прозасы турында. Тат. Кит. Нәшр. 1974. 82-86 бит

**Мавлеева Р.М.**
**Менделеев шәһәре, 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

## Балалар өчен язылган шигъләренең үзенчәлекләре

Роберт Миңнуллинның татар әдәбиятында кабатланмас, үзенчәлекле үз урыны бар. Билгеле булганча, ул олылар өчен дә, балалар өчен дә яза. Әмма аның балалар өчен язган әсәрләре үзе бер олы өлкә. Р.Миңнуллин чын мәгънәсендә бүгенге татар балалар әдәбиятын әйдәп баручы, аның алгы сызыгында торучы шагыйрьләрнең берсе.

Р.Миңнуллин татар балалар әдәбиятында Г.Тукай, Б.Рәхмәт, Ә.Фәйзи, Ш.Галиев һ.б. традицияләрен дәвам итә. Шагыйрьнең уңышы – заман сулышын тоеп, традиция һәм яңалыкны бергә туплап, бербөтен итеп бирә алуында. Ә бу исә иҗатны көн яңалыклары, заман темалары белән баета. Яңалыкка омтылыш шагыйрь фантазиясендә балалар өчен "чучкабаш", "кәштәкә", "төлкерпе", "юлбарыслан", "Күркәҗә" һ.б. серле образлар һәм хыялый вакыйгалар туугa да сәбәпче. "Әкәмәт җанварлар", "Ми-8А", "Алмазның гаражы" һ.б. шигырьләре моңа ачык мисал.

Мәсәлән, "Әкәмәт җанварлар" шигырендә шагыйрь болан белән антилопа, шимпанзе белән зебра кебек җанварларның исемнәреннән бер сүз китереп чыгара һәм нәни геройны шулай юри "буташтыра". Мондый алым да кызыклы. Ул балаларда бөреләнә башлаган зирәклек, игътибарлылык, зиһен үткенлеге кебек мөһим сыйфатларның ныгып китүенә булыша.

Роберт Миңнуллин, баланың фикерләү дәрәҗәсен үстерү өчен, киек җәнлекләр, йорт хайваннары белән җисемнәрне бер-берсенә җиңелчә итеп, нәниләр аңларлык дәрәҗәдә мөнәсәбәт кылдыра. Бу нәүбәттән, "Югалган хәрефләр" циклына тупланган биш табышмак-шигырь игътибарга лаек. Шагыйрь нәни укучысына күпмедер дәрәҗәдә таныш булган яки көндәлек тормышта очраган кайбер җәнлекләрнең бер үзенчәлеген тотып алган да шуңа игътибарын көчәйткән. Билгеле, бераз зиһен кыймылдатмый торып, мондый характердагы табышмакларны чишү җиңел эш түгел. Ләкин бу әсәрләр дә нәни укучыны битараф калдырмыйлар, аның күңел дөньясын киңәйтеп җибәрәләр, иҗат активлыгын уяталар.

Р.Миңнуллин иҗатында аның үзе уйлап чыгарган жанрлар да бар: сүз кечкенә әкиятләр турында бара. Билгеле, булганча, халык иҗатында әкият жанры һәм аның берничә аерым шактый үзенчәлекле төркемнәре бар. Тик анда кечкенәкият дигән жанр юк, гәрчә күләме ягыннан әллә ни зур булмаган әкиятләр байтак кына булса да. Димәк, әлеге жанр төрен дә, исемен дә Роберт Миңнуллин үзе иҗат иткән. Димәк, шул исем белән билгеләнгән әсәрләрнең үзләренә генә хас әдәби үзенчәлекләре дә булырга тиеш! Һәм бу чыннан да шулай: Р.Миңнуллин иҗатында, башка күп кенә шагыйрь сюжетына нигезләнгән бер генә әсәр дә юк! Дөрес, аның кечкенәкиятләрендә халык әкиятләре һәм фольклорның башка төрләре белән бәйле аерым мотивлар, сүз тезмәләре булырга мөмкин. Тик шулай да кечкенәкиятләр тулысынча аның үз иҗат җимешләре.

Шуның аерым мисалларына тукталып үтик. Барыннан да элек, аларның барысы да төгәл һәм һич тә традицион булмаган, безнең көннәр вакыйгалары-хәлләре белән бәйле сюжетларга нигезләнәләр. Бу яктан Р.Миңнуллинның кечкенәкиятләре татар халык әкиятләренең барысыннан да һәм принципиаль рәвештә аерылып торалар. Әлеге әсәрләрнең төп үзенчәлеге дә шунда ки, алар балалар психологиясен, күңел серләрен бик яхшы белгән безнең заман шагыйре тарафыннан тулысынча мөстәкыйль иҗат ителгәннәр. Мәсьәләнең бу ягын төгәлрәк ачыклау өчен "Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенәкият"не күрсәтеп үтәргә мөмкин. Әйе, кайсыбыз гына инде кечкенә вакытта туп тибеп, сугып, бәреп, ыргытып уйнарга яратмаган? Һәр нормаль бала кечкенә вакытта туп белән уйнарга ярата! Хәер, малай-шалай гына түгел, егетләр дә туп тибеп, кызлар күбрәк

туп ыргытып уйнарга яратмыймыни? Футбол һәм баскетбол бөтен дөньяда яшьләрнең яң яраткан уены түгелмени? Әйе, бу һичшиксез шулай! Әмма шагыйрь мәсьәләнең бөтенләй икенче ягына игътибар итеп: "туп тибү" һәм "шар сугып йөрү" сүзләренең мәгънәләрен шактый якынайта. Нәтиҗәдә капма-каршы фикер туа:

Бер малай Туймаган!

Туп уйнаган,
Туп белән
Күп уйнаган,
Әй уйнаган,
Үскәчтен
Чын футболчы
Булам диеп
Уйлаган.
Ул көн буе уйнаган:
Әнисенең сүзләрен
Колагына
Элмәгән,
Өйгә кайтып
Кермәгән.

Беренче карашка, әлеге малайның нияте бик изге: ул чын футболчы булам дип хыяллана. Тик ул кирәгеннән артыграк мавыгып китә. Көннәр буе туп уйнап, әнисенең сүзен тыңламый, өйгә кайтып керми, бернинди эш эшләми, дәресләренә әзерләнми, укытучы сөйләгәннәренә төшенми... Нишләргә соң инде бу очракта? Ничек туктатырга малайны әлеге "азгынлыктан"? Бу катлаулы сорауларга җавап эзләп, шагыйрь бернинди дидактикага, акыл өйрәтүләргә, киңәш бирүләргә, орышу-кыйнауларга мөрәҗәгать итми! Шагыйрь, халык әкиятләрендә кулланыла торган сюжетка тукталып, тәрбия эшен малай яраткан тупның үзенә тапшыра. Башта туп малайга акыл өйрәтеп карый: гел икеле генә алып йөргән малайга тупның да ачуы килә бит инде! Әмма тупның сүзләре дә ярдәм итмәгәч, ул үзе хәрәкәт итә башлый: малай бер тибүгә туп очып китә дә, әйләнеп төшми. Икенче, өченче һ.б. туплар да шулай очып китеп юкка чыгалар. Кечкенәкият түбәндәге сүзләр белән бетә:

Белмим, хәзер ул малай
Бераз
Үзгәрде микән?
Бераз
Төзәлде микән?
Ләкин ул шул хәлдән соң
Туп тибүдән туктаган.
Хәзер инде күрсә дә
Курка, ди, ул туплардан!

Нәрсә бу? Әкиятме? Чынбарлыкмы? Биредә әкият тә, чынбарлык та бергә укмашкан. Тик анда акыл сату, орышу, тиргәү генә күренми. Һәм моның һич тә кирәге юк! Шигырь-кечкенәкият үзе мөһим тәрбия чарасы булып тора.

"Кояш буласы килгән кызыл шар турында кечкенәкият" әсәре дә аерым бер игътибарга лаек. Жанрның иң борынгы төрләреннән саналган тылсымлы әкиятләрендәге кебек, әсәр тулысынча диярлек һәркемне берсүзсез ышандыра торган уйдырмага нигезләнгән. Әмма аның сюжеты, эчтәлеге барыннан да элек кечкенә балаларга якын. Р.Миңнуллин әсәре нәкъ әнә шул стильдә башлана да:

Яшәгән, ди,
Кызыл шар,
Яшәгән, ди,
Кызык шар...
Шарны элеп
Куйгач та,
Өскәрәк, биеккәрәк,
Охшаган, ди, кояшка!

Әлеге шар югарыга күтәрелеп, кояшка да охшап куйгач, табигый, аның горурлыгы арта; өстәвенә, шундагы бала-чага әлеге шарны гел мактап, "Син нәкъ кояш шикелле!" дип, үсендереп тә торгач! Бу мактау шарга бик тә ошый, аның горурлыгы, тәкәбберлеге артканнан-арта бара, аның нәни, тик кояш кебек түгәрәк башына мәкерле бер уй килә: "Миңа һичкичекмәстән кояш булырга кирәк!" дип, ничек кенә ышанса да, аны шикле

фикерләр дә борчый. Киңәш өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә инде? Аның өчен иң якын зат - бердәнбер әнисе! Сабый балага әнисеннән дә якын кеше булмый бит! Табигый, ул үз серләрен, "изге хыялын" әнисенә ача:

Әйткән әнисенә дә:
- Мин кояш булам! - дигән, -
Биеккә кунам! - дигән.

Әмма газиз әнкәсе сабый баласының беркайчан да тормышка ашмас хыялына кискен каршы чыккан. Җитмәсә, әнисенең шикләнүләре дә бик нигезле: әгәр ул шар чыннан да кояш булып, югары күккә күтәрелсә, юньсез малайларның аны шартлатып ташлавы да мөмкин бит яки рәхимсез җил очыртып, әллә кая алып китәр... Әгәр шулай булып чыкса, "Без кояшсыз калырбыз, Аннан каян алырбыз?!" - дип, чын күңелдән борчыла шарның әнисе. әнә шундый куркыныч кисәтүләрдән соң шар үзе дә уйга калган:

| | |
|---|---|
| Ул әнисен | Ул бик дөрес |
| Тыңлаган - | Эшләгән, |
| Кояш булып | Әйбәт бер эш |
| Тормаган. | Эшләгән!.. |

Сезгә дә, дусларым, берүк,
Әйтсәләр дә,
Күнмәгез -
Кояш була
Күрмәгез!

Шагыйрьнең башка кечкенәкиятләре дә шундый ук җиңел, матур, саф татар телендә язылган.

Шушы ук юнәлештә язылган "Ничекнигәниөчен" шигырендә дә ул "Кайчанничеккайда", "кайчанничекнинди", "кайчанничекниөчен" кебек "яңа" сүзләр куллана. Алар барысы да татар балалар әдәбиятының бүгенге көндәге оригиналь казанышлары, уңышлары булып санала. Бу әсәрләрнең тәрбияви әһәмияте дә зур: аларда төрле тәрбияви моментлар бергә үрелеп-кушылып, синтезлашып китәләр.

Р.Миңнуллин иҗатында "уен-шигырьләр" лаеклы урын алып торалар. Шагыйрь аларны төрле формада бирә. Мәсәлән, "Өчпочмак" дип аталган шигырьнең юллары да өчпочмак формасында, ә "Түгәрәк шигырь"нең эчтәлеге исә түгәрәк рәвешендә бирелгән. "Читлек" дип аталган шигырьдә кошлар, табигать, ирекне чикләү кебек бик җитди темалар күтәрелгән. Шигъри юллар читлек формасына урнаштырылган. Бу мәгънәне көчәйтә, тәэсирлекне арттыра.

"Баскыч", "Борма-борма шигырь" ләренең график сурәтләре балаларга бер күз карашы ташлауга берникадәр мәгълүмат бирәләр.

Р.Миңнуллинның уен-шигырьләре арасында төрле шрифтлар кулланып язылганнары бар. Р.Миңнуллин уен-шигырьләрдә зур шрифт белән я мәгънәви яктан әһәмиятле сүзләрне, я юмор тудыра торган иҗекләрне, сүзләрне, сүзтезмәләрне балаларга аерып күрсәтә. Мәсәлән, "Ни өчен олы?", "Яра", "К" лар тулган бакчага" шигыре туган телебезгә игътибарны арттыра, кечкенә укучыларны яңа "ачыш"лар ясарга өйрәтә:

Бу бакчага ни булган?
Бакча "К" белән тулган.
КАРЛЫГАН һәм КӘБЕСТӘ,
КИШЕР, КАРБЫЗ һәм КАБАК,
КРЫЖОВНИК һәм КУКУРУЗ,
КЫЯР, КАВЫН, КУЗГАЛАК...
Әйдә, рәхим итегез!
Авыз итеп китегез!

Р. Миңнуллин җыр жанрында иң актив эшләүче шагыйрь. Күп кенә шигырьләренә композиторлар көй салган. Алар Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин, Резеда Ахиярова, Илгиз Закиров һ. б...

"Әйлән-бәйлән", "Яратыгыз", "Әни кирәк", "Яңгыр җыры" һ.б. җырларын балалар

яратып җырлыйлар.

Роберт Миңнуллин киңкырлы, талантлы шәхес. Аның иҗаты күпләргә үрнәк.

Р.Миңнуллинның әсәрләре бүгенге татар балалары рухи тормышының аерып булмаслык бер өлешенә әверелде: алар мәктәп укучылары тарафыннан өйрәнелә, төрле кичәләрдә, концертларда еш яңгырый.

Гомумән алганда, Р.Миңнуллинның һәр шигыре – үзе бер оригиналь поэтик табыш, үзе бер иҗади ачыш, үзе бер әдәби җәүһәр.

**Мингалеева Р. Ә.**
**"Татарстан республикасы Яр Чаллы шәһәре**
**муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе**
**"51 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"**

## Кайнар йөрәкле әдип

Фәнни-тикшеренү эшенең темасы: "Мине яратмаска мөмкин түгел – талант өчен" дип атала. Язучының бурычы – кешене шәхес итеп, татарны милләт итеп, дөньяны камил итеп саклап калу" - дип язган Туфан Миңнуллин. Айдар ага Хәлим шул бурычны тулысынча үтәгән шәхес. Аның публицистик хезмәтләренә, тәнкыйть мәкаләлренә күз салу да җитә. Үз халкының тарихын, гореф – гадәтләрен, яшәешен тирән белүче гаять акыллы язучы ул. Язучыны мактау, аның дәрәҗәсен төшерә дигән әйтем бар. Шулай булса да әйтеп үтәсе килә, беренче юллардан ук акыл белән сугарылган язмаларны уку, без укучыларга рухи азык бирә, автор белән бергә милләт язмышы өчен борчыла башлауыңны сизми дә каласың.

Аның иҗатын мин ботаклы утын түмәренә тиңләр идем. Менә шул чагыштыру мине А. Хәлим хезмәтләрен өйрәнүгә, эзләнү – тикшеренү эшен башлап җибәрергә этәргеч булды да инде. Утын түмәрен тиз генә ярырмын димә, аның өчен көч куярга һәм оста булырга кирәк. Язучының да гомере буе иҗат иткән хезмәтләрен, аның безгә җиткерергә теләгән фикерләрен, әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларны өстән – өстән генә укып чыгып аңлап булмый шул. Утын түмәрен ярган кебек җиң сызганып эшкә керешү кирәк.

Танылган әдип иҗатын һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә аңлый һәм бәя бирә, шуңа күрә аның иҗаты турында яңалыклар безнең фикерләвебездә дә кызыклы булыр дип саныйм. Димәк, эшнең темасы актуаль.Өйрәнүгә ачыклык кертеп, Айдар ага Хәлимнең иңнәренә милләт вазыйфасын йөкләгән язучы булганын исбатлау максатын да куйдым.

Иҗади эшкә керешкәндә мондый бурычларны күзалладым:

1. Айдар Хәлимнең публицистика һәм тәнкыйть өлкәсендә булган хезмәтләрен барлау,

2. Әдип иҗатында күтәрелгән проблемаларны өйрәнү;

3. Аның эшчәнлеге турында каләмдәшләре нинди фикердә икәнен ачыклау;

Фәнни – тикшеренү эше "Айдар Хәлим иҗатында күтәрелгән проблемалар" һәм "Әдипнең дөньяга карашы" дигән бүлекләрдән тора.

Эзләнү-тикшеренү өлкәсе: язучы иҗатының бүгенге көн кадагында торган проблемаларны ачуы турында теоретик һәм практик дәлилләр.

Эзләнү-тикшеренү предметы: татар халкының күренекле шәхесләрен барлау

Эзләнү-тикшеренү эшенең максаты: Айдар ага Хәлимнең иңнәренә милләт вазыйфасын йөкләгән язучы булганын исбатлау максатын да куйдым.

Эзләнү-тикшеренү эшенә билгеләмә: Эзләнү-тикшеренү эше ул-теоретик белемнәрне практика белән бәйләп күрсәтелгән иҗади эш яки фәнни хезмәт.

**I.Каләм тибрәтү.**

« Язучылар пәриле була, аларның күбесе җәмгыять системасын мактап яздылар һәм язалар. Ә Айдар Хәлимнең пәрие гомере буе халык мәнфәгатен кайгыртты. Ул һәрвакыт милләт язмышы белән яшәде. Каләменнән татарны данлый, яклый торган әсәрләр тамды"

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов

Туксанынчы елларда А.Хәлим сәнгатьле проза өлкәсендә дә зур иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992), «Казыктагы итальян» (1999) повестьлары, «Кыйбла», «Берлинга хат», «Авылдаш», «Җырлар вакыт» һәм башка күпсанлы хикәяләре һәм бигрәк тә «Татар вакыты» исемле кечкенә романы (1998) әдәби тәнкыйтьтә бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге итеп бәяләнә.

"Проза бит ул шундый нәрсә, көтмәгәндә берәү килеп чыга..." дип әйткән Аяз Гыйләҗев. Айдар Хәлим дә шулай җилләнеп килеп керә белә проза өлкәсенә. Язучының стиле үзенчәлекле. Вакыйгалар сюжет буенча кисәк – дуамал ыргымнар белән алып бара укучыны. Шул ук вакытта Айдар Хәлимнең әсәренең төзелеше, аңа салынган эчке накал, сюжет кору осталыгы, образлы сурәтлелек, фикер ягыннан булсын, без укучыларны җәлеп итәрдәй кызыклы, гыйбрәтле. Аның геройлары үз чоры авырлыкларына эләгеп, изелеп басынкыланган, йончыган татар кешеләре. Автор шул образларга тереклек суы бөрки, персонажларга башларын күтәреп як – якка карарга мәҗбүр итә, татарны татарлыгы өчен кыздыра – кыздыра , аларны тормышка, яшәешкә өстери.

**1.1. Айдар Хәлим иҗатында күтәрелгән проблемалар.**

– "Өч аяклы ат" – колхозлашу чорында кешене генә түгел, аның малын да (бу очракта биясен), сыйнфый дошман итеп, тумаган колыны-ние белән бергә, күмәк казанга салу. Куелганы бар идеме бу проблеманың дөнья әдәбиятында болай итеп? Юк иде! Төп герой Кәбир, әсәр үзе дә аның аша тасвирлана. уктаусыз кырыс һәм рәхимсез тормыш сулышы бәреп торган бу әсәргә сиздерми генә малайның әнисе – Сания апа образы, аның бөтен нәсел фаҗигасе килеп керә. Шушы затлы нәселдән үч алырга, аларны төрмәдә черетергә атлыгып торган Бөекбаш Галләметдиннәр, участковый Сәйфуллинар, депутат Саҗидәләр, явыз бүре кебек нәселне буыннан – буынга куа баралар. Әсәрнең кыйммәте, сирәк үзенчәлеге шунда – монда кеше булмаган җан иясе байтал - Бамбукның әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелүе.

"Кыйбла". Сугыш вакытында үзен, баласын эзәрлекләүләрдән качып туган ягына кайтып килгән Өммегөлсем поездда үлгән сабыен җирләр өчен станцада төшә һәм йорттан йортка кереп, милләттәшләреннән ярдәм эзли. Әмма теләгенә ирешә алмыйча, бу ярдәмне милләте белән рус һәм христиан булган Никодим карт белән Марфа түткидән таба. Кешелеклелек бу очракта милли һәм дини тойгылардан өстенрәк булып чыга. Әйе, Айдар Хәлим туган телнең барлык бизәкләрен нечкә сиземләп яза. Аның бу әсәре безне, ягъни укучыларны кайта-кайта уйландыра, яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, иман белән яшәргә өйрәтә.

"Татар вакыты". Сугыш ветераны, тома сукыр Мотаһар абзыйның Казанда Мәскәү вакыты белән яшәгән тугыз яшьлек оныгы Вадим стенадагы нәсел сәгатенең чаң суккан тавышы телевизор карарга комачаулый дип, сәгатьне көн саен чалшайтып туктата. Тома сукыр Мотаһар абзый исә, оныгы укырга киткәч, шулай ук көн саен Казан радиосыннан чын вакытны белешеп, капшанып килеп, капшанып урындыкка басып, туктаган сәгатьнең укларын дөресләп, балаларына үз вакытларын табарга ярдәм итә һәм шул юлда һәлак була.

Монда тормыш кырыслыгы, халыкның ачы язмышы, җавапсыз йөрәк ашкынуы, иманга кайтуның авыр юлларын, рухи геноцидка китерелгән шартлар һәм империянең тоткасына әверелгән күрә карачы үз татарларыбыз сурәтләнә.

2003 нче елда күп санлы хезмәтләре өчен Айдар ХәлимгәТатарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе бирелә.

**II. Әдипнең дөньяга карашы.**

Публицистика жанрындагы әсәрләр Айдар Хәлимне киң таныткан китаплар булып торалар. Аларда милли темалар яктыртыла, төрле халыкларның милли азатлык өчен көрәшүе сурәтләнелә

"Шигырьият, чәчмә әсәрләр, публицистика,драматургия юнәлешләрендә шул көннәрдә туган планнарны мин гомерем буе язсам да , мин генә түгел, миндә туган шул планнарны тулы ер язучылар берлеге, тулы бер институт гомере буе язган булса да язып бетерә алмас

иде. Шул ук вакытта минем башымда гомерем буе мин нинди жанрдан нинди жанрга күчәчәгем тамгаланып калган иде. Минем шигырьияттән публицистикага, публицистикадан драматургиягә һәм соңлап прозага күчәчәгем бары тик минем үзем өчен генә билгеле һәм табигый халәт иде. ” – дип бәян итте күпкырлы иҗади шәхес үзе турында.

Аның тормыш юлы, иҗаты белән танышканда тынгы белмәс шәхес икәнлеген аңладым. Татар әдәбияты киңлегендә кем белән чагыштырп, кайсы язучы иҗаты белән паралель үткәреп була икән дип тагын да үҗәтләнеберәк өйрәнергә тотындым. Ләкин Айдар ага уникаль, кабатланмас иҗат кешесе икәнлеген аңладым. Татар халкы өчен аның тарафыннан язылган публицистик хезмәтләре, тәнкыйтьләре, чыгышлары гына да милләт өчен васыять сыман язылган. Иң мүкләгән татарны да уятырлык фикерләр, акыллы киңәшләр бар монда.

Моңа мисал итеп А.Хәлимнең 1994 нче елда басылган “Акылга мәдхия” китабын алырга була. Шул елларда ук ул татарда булган проблемаларны күрә алган һәм чаң суккан язучы. Алай гына да түгел шул проблемаларны чишәргә алынучы җәмгыять эшлеклесе. Бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый аның кайбер язмалары. Мәсәлән сәнгать өлкәсенә кагылышы булган мәкаләсендә “Татар җыры” конкурслары оештырылу “моңлы мәнсезлек” барлыкка китерде, ди. Җырчылар һәм яңа көйчеләр күбәйгән саен татарның халыкчан моңы кимеде дип белдерде. Бүгенге көндә дә бу хәл күзәтелә. Бигрәк тә соңгы елларда вакытлы матбугатка, интернет челтәрләргә татар җыры өчен борчылып язган хатлар күбәя бара. Шул еллардагы борчулы фикерләренә каршы җавап итеп әдип бүгенге көндә татар дөньясына “Моң кайтты” новелласын иҗат итте. Әсәр татар халкының буыннан - буынга күчеп килгән җыр мирасын бүгенге көндә дә сакланып кала алуына зур өлеш керткән гаилә сандугачлары Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхәбиева тормышына багышланган. Сабирҗан образы аша автор укучыларның игътибарын, ун – егерме миллион татардан бер – берсен тапкан, бергә, бер сәхнәдә, бер жанрда, бер милләткә, бер Ватанга хезмәт иткән ике шәхес – ике сандугач иҗатына кызыксыну, мәхәббәт уяткан. Чит –ят якларда күпне күргән кичергән кеше буларак Сабирҗан, моң – шәхси күрсәткеч булудан бигрәк, ул иҗтимагый, социаль күрсәткеч икәненә инанган.

А.Хәлим – әдәби тәнкыйть өлкәсендә иң актив эшләүче каләм осталарының берсе. Аның аерым әдәби әсәрләргә яки язучылар иҗатына багышлап язылган мәкаләләре көчле аналитик фикер куәсенә, әдәби күренешне тарихи яссылыкта заман проблемалары белән тыгыз бәйләп аңлату осталыгына ия булуы турында сөйлиләр. «Казан утлары» журналында «Заман герое» темасына оештырылган дискуссия уңае белән басылган һәм бөтен татар әдәбиятын күздән кичереп, үзенең үтә тәнкыйди принципиаль фикерләрен турыдан-туры бәян иткән «Сез беләмсез кая барганны?» исемле зур мәкаләсе әдәби җәмәгатьчелектә көчле резонанс уята һәм фикри бәхәсләргә сәбәп була.

1964–2007 еллар арасында язылган иҗади сурәтләмнәр, әдәби бәхәсләр, әңгәмәләр, ачык хатлар һәм чыгышларны үз эченә алган икетомлыгы «Йөрәгебез белән мөстәкыйль» XX гасырның икенче яртысы – XXI гасырның башындагы татар әдәби этик-эстетик фикеренең куәтле мисалы булып тора.

Әдипнең күпсанлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Имәнем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш», (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Алар гамьле укучыны да битараф калдырмадылар.

Шулай да Айдар Хәлимнең исемен киң таныткан, бер каләмдәше әйтмешли, «кислород бомбасы»дай шартлау ясаган әсәрләре — туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр

«Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книга печали, или Записки аборигена», 1991)

«Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996)Язучының «Җиңелмәс ул чечен» китабы документаль материаллар нигезендә каһарман чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен хәрби техниканың иң соңгы казанышлары белән коралланган

«явызлык империясе»нең миллионлы армиясенә каршы бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелүен, анны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күзалдына китереп бастыра.

«Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997) китабында да чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи һәм хәзерге фаҗигале язмышына юнәлтелә.

«Боза-боза паспортны, арттырабыз башкортны...» (2002) дигән китапларында язучы башкорт шовинизмына эчкел аборатор анализ бирә. , Мәскәү хакимияте һәм җирле түрәләр алып барган сәясәт нәтиҗәсендә ике тугандаш халыкны — татар белән башкортны үзара ызгыштырырга маташуы документлар һәм гыйбрәтле вакыйгалар мисалында бәян ителә.

Әлеге китапның дәвамы рәвешендә язылган «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» әсәрендә автор, татар халкының хокукларын даулап, фикердәшләре белән бергә Уфа каласының үзәк мәйданында ун көнлек ачлык вахтасына басуы, шундагы кичерешләре турында сөйли һәм, шул вакыйгаларга бәйләп, сиксәненче-туксанынчы елларда татар халкы, аның намуслы шәхесләре алып барган катлаулы, каршылыклы сәяси көрәшнең документаль елъязмасы, аның иң тәэсирле сәхифәләре белән таныштыра. Миллионер Латыйф Хәкимовның мәдрәсәләргә матди ярдәме турында яза. Латыйф абзыйның Түнтәрнеке булуы (чыбык очлары Түнтәрдә яши) билгеле. Түнтәргә ел саен кайтып, мондагы кибетенең еллык табышын иганә итеп халыкка өләшкән. Уфада һәм Ырынбурда, Малмыжда кибетләр, гаскәр тоткан. Хәкимовның Петербургка дәрәҗәле кунак сыйфатында, Патша хәзрәтләре янына килүен күрүче, ул вакытта солдат хезмәтен үтүче Кәримов Камалның сөйләве хак. Революция булуга, Латыйф абзый бар мөлкәтен Совет хөкүмәтенә тапшыра. Алга таба үзе Башкортстанның җир эшләре буенча халык комиссары дәрәҗәсенә күтәрелә. 1936 елларда юкка чыга.

Кайсы гына жанрда язуга алынмасын әдип, һәр хезмәтен энәсеннән җебенә кадәр тикшереп, башлаган эшен ахыргача җиткереп иҗат итә белә.  Гомумән, әдипнең бу дүрт публицистик китабы мәгълүм сәбәпләр аркасында милләт буларак югалган яки әкренләп югала барган, ватаныннан аерылган, җиреннән-суыннан сөрелгән, аракыга батырылган, динсезләндерелгән, шулар аркасында биологик, физиологик һәм рухи сырхауларга дучар ителгән, шул ук вакытта зур тарихлы, мәдәниятле һәм горур табигатьле халыкларның йөрәк авазы булып яңгырый.

Публицистика өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен А.Хәлим 2003 елда Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый, Бөгелмә җәмәгатьчелегенең мәгариф буенча Һ.Атласи исемендәге әдәби бүләгенә 1995 нче елда лаек була.

**Йомгаклау**

“Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле” – дип язып калдырган Тукаебыз. Мин йомгаклау өлешендә шагыйрь сүзләрен башлам итеп алдым. Әйе, килде ул заманнар. Әсәрләрен рәхәтләнеп укып ләззт алырдай әдипләр күп татарда.

Фәнни-тикшеренү эшенең темасы: “Мине яратмаска мөмкин түгел – талант өчен”Әлбәттә , бирелгән бүлекләр һәм параграфларда мин алдыма куелган бурычларымны чиштем дип уйлыйм. Минем өчен язучының публицистик хезмәтләре өйрәнү кызыклы булды.Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган каләм ияләре арасында Айдар Хәлим лаеклы урын тота. Ул татар шигърияте, татар прозасы, татар драматургиясе, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли.Айдар Хәлим безнең тормышның аналитигы, андагы кара күренешләрнең тамырын эзләүче һәм табучы, татарның саф сыйфатларына мөкибән киткән гашыйгы, милли рухның югалуына әрнүче һәм чаң сугучы фидакарь әдип. Әсәрләренең кайсын гына алсак та, милләт язмышының аянычлыгына, милли сыйфатларның тапталып юкка чыгуына җан атып сызланучы шәхеснең тирән уйларына тап булабыз. Әдипнең төп мотивы шуннан гыйбарәт.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: татар халкы арасында милләт сагында торучы Айдар

Хәлим һәм Фәүзия Бәйрәмовалар кебек кайнар йөрәкләр булганда туган телебез югалмас дип уйлыйм мин.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Айдар Хәлим “Акылга мәдхия” Казан, Татарстан газета һәм журналлар типографиясе, 1994.
2. Айдар Хәлим “Моң кайтты” ” Мәйдан” журналы, 03.2012.
3. Айдар Хәлим “Урта Азиядәге урткларымда”” Мәйдан” журналы, 03.2012.
4. Айдар Хәлим “Шигырь бар”, ” Мәйдан” журналы, 11.2017.

Айдар Хәлим “Яңа сагыш китабы”, “Казан утлары”журналы, 09.2002.

5. Миргазиян Юныс “Бәхетле мескенлек” , “Казан утлары”журналы, 02.2000.
6. Ришат Фәтхрахманов “Йөрәкнең җеназасы”, “Казан утлары”журналы, 11.2003.
7. Татар әдипләре. Татарстан милли китапханәсе. Казан,”Милли китап” нәшрияты, 2001.
8. Факил Сафин “Гыйбрәт алыйм дисәң” , “Казан утлары”журналы, 09.2002.
9. Фәүзия Бәйрәмова “Ак һәм кара көрәше”, “Казан утлары”журналы, 12.2001



**Минигареева А. М. ,**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**18 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## А. Хәлимнең “Өч аяклы ат” повестенда яшь кешенең характеры формалашу.

Җанны тетрәндереп, күңелләрне айкап чыгарырлык әсәрләр күп язылмый. Андыйлар унъеллыкларда да бармак белән санарлык кына туа. Әдәби елларның кайберләре бөтенләй ук кысыр булып чыккан чаклар да юк түгел. Күрәсең, бу әдәби процессның табигый халәтедер. Бәхетнең чын тәмен кайгы-хәсрәт килгәч кенә аңлаган кебек, талантлы әсәрнең зурлыгына да уртакул әдәбиятны укып шактый ук талчыккач кына төшенәсең. Ялган ташлар арасында балкыган асылташ төсле, йөрәккә үзенең нуры белән үтеп керә торган, рухны уята торган чын әдәби җәүһәргә тап булу – сирәк очраучы бәхет.

Әлеге фәнни эшнең *актуальлеге* шунда ки, татар теленә бетү куркынычы янаган чорда аны яклап, саклап чыккан язучы иҗаты хөрмәткә һәм ихтирамга лаек. Яшь буын тәрбияләүдә мөһим роль уйнаган йогынтыларны билгеләп, алга таба да чын кешеләр үстерер өчен зур сабак алырга мөмкин.

Әлеге тема А. Хәлим иҗаты мисалында аз өйрәнелгән. Бары тик кайбер каләмдәшләре тарафыннан төрле хезмәтләрдә әйтелеп кенә үтелә.

*Максатыбыз* А. Хәлим әсәрендә яшь кешенең формалашуына йогынты ясаган факторларны, ул яшәгән, үскән мохитне өйрәнеп, кешене кеше итүче күрсәткечләрне билгеләү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге *бурычлар* куелды:

1. Айдар Хәлим иҗатына кагылышлы материалларны туплау һәм өйрәнү;
2. әсәрендә яшь кеше характерын тудыруда йогынты ясаган факторларны ачыклау.

Айдар Хәлим язган әсәрләр нәкъ менә күңелләрне айкап чыгарлык көчкә ия. Татар халкының язмышы өчен янып-көюче, аның киләчәген кайгыртучы язучы, шагыйрь, публицист, тәнкыйтче иҗатын читләтеп үтү зур хата булыр иде. Шуңа күрә дә без эшебезнең *объекты* итеп А. Хәлим иҗатын алырга булдык. *Предметы* итеп исә, А. Хәлимнең “Өч аяклы ат” повестенда яшь кешенең характеры формалашу темасын сайладык.

Әлеге фәнни эшне язган вакытта таяну ноктасы булган төп хезмәтләр – Ф. Бәйрәмова, Р. Шәрәфиев, Р. Фәтхрахманов һ.б. мәкаләләре.

Фәнни эшнең *структурасына* килгәндә, ул кереш өлештән, төп өлештән, йомгак һәм библиографиядән тора.

### I бүлек

## Айдар Хәлимнең тормыш юлы һәм иҗаты

Язучы, публицист Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында туган.

Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда "беренче карлыгачлар" сериясендә басылып чыга. Шигърияттә А. Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары ( "Беренчеләр", "Ун елда", "Өмә", "Печән чапканда", "Нарат белән Нәфисә турында хикәят", "Яралы бөртек", "Эксперимент – 86" һ.б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә чыккан "Йөрәк ташы" (1990), "Милли шигырьләр" (2001), "Тилергән сиреньнәр" (2003) җыентыкларында урын алган.

А. Хәлим – драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм иясе. Аның "Җан-чишмә" (1983), "Пәри туе" (1990), балалар өчен язылган "Биктырыш" әсәрләре сәхнәләштерелде.

Шулай да язучының исемен киң таныткан әсәре – туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: "Сагыш китабы, яки Абориген язмалары" ("Книга печали, или Записки аборигена", 1991), "Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән" (1996), "Җиңелмәс ул чечен" ("Этот непобедимый чеченец", 1996) һәм "Империяне үтерергә!" ("Убить империю", 1997).

Әдипнең туган төбәгенә һәм якташларына багышланган "Минем Түгәрәк Иманем" (1999), халык саны алу уңае белән язылган "Яңа сагыш" (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар.

А. Хәлим сәнгатьле проза бабында да иҗади уңышларга ирешә. Аның "Өч аяклы ат" (1992) повесте, "Казыктагы тальян" (1999) новелласы һәм бигрәк тә "Татар вакыты" (1998) исемле кечкенә романы бүгенге татар прозасының яңа казанышы дип бәяләнде. Язучының проза әсәрләрен – роман, повесть, хикәяләрен туплаган "Татар моңы" (2002) һәм "Кыйбла" (2005) китаплары дөнья күрде.

А. Хәлим – Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе.

## II бүлек
## Әсәрдә чор һәм шәхес көрәше

"Өч аяклы ат" әсәре татар әдәбиятын яңа адымга этәргән әсәрләрнең берсе булып тора. Бу әсәр сугыштан соңгы аяусыз, ачы, ялангач еллар турында бәян итә. Шул ук вакытта, татар халкы, аның үткәне-киләчәге турында да онытмый. Ир-атларның "ир һәм ат" компонентларыннан торуы, аларның аерылгысыз булуы тагын бер кат дәлилләнә.

Төп герой Кәбир исемле малай һәм Бамбук кушаматлы "пашпортлы" ат. Ачлык башланган чор. Кәбирнең әтисе сугыштан кайтмаган, җитмәсә аның әнисе кулак нәселеннән. Элегрәк аталары комсомол булганы аларны азрак сакласа да, хәзер ярдәм итүче беркемнәре дә юк. Әнисенең сеңлесе кунакка чакырып хат яза. Алар озак уйлап тормый, колхозның иң яхшы атын җигеп, кунакка баралар. Ләкин "хәерчегә җил каршы" дигәндәй, бабаларының абзарларына бүре кереп, Бамбукны яралый. Ат аягының сеңерен өздерә. Ул хәзер өч аяклы. Ә ат өчен анасына җавап бирергә кирәк. "III интернационал" атын харап иткән өчен аны башыннан сыйпамаячакларын ул яхшы белә. Ләкин ни булса да булыр дип, атны җизнәсенә тәрбиягә калдырып, кайтып китә. Күп тә үтми Кәбирнең анасын төрмәгә алып та китәләр.

Малай, озак уйлап тормыйча, әнисен коткару җаен таба. Атны алып кайта (үз аякларында), әмма Бамбукның үлеме аянычлы була. Буаз килеш, бурлы бия нәселен харап итәләр. Ир белән атны мәңгегә аералар. Бәлки, кайчандыр аларны бергә кушачаклар. Бу кешеләр кавеме әле үсеп кенә килә.

Кәбир – кечкенә малай дисәк, дөрес булмастыр. Ул нәкъ олыларча фикер йөртеп, зурлардан да акыллырак эшләр башкарырга сәләтле кеше. Аның фәлсәфи уйланулары безне дә дөнья тирәнлегенә алып төшә: "Әйе, бердән, икедән, өчтән башлана икән дөньяны танып белү. Беренчел тормышның иң кадерле, иң мөкатдәс бөҗрасы дүрт шарттан тора. Шушы дүрт шартның берсе җитешмәсә, бөҗра өзелә һәм мәңге ялгана алмый. Нәрсә ул

бер? Атасыз яшәп кара. Малай атасыз яшәп карамый – яши. Нәрсә ул ике? Инәсез яшәп кара? Нинди бәхет – аның инәсе бар. Менә әле ул инәсез яшәп карый. Төрмәдә утыра әле әнисе. Җиңелме Кәбиргә? Үзе белә. Нәрсә ул өч? Бертуганнарыңнан башка яшәп кара. Нәрсә ул дүрт? Бердәнбер дуссыз, дуслыктан башка яшәп кара. Җиңелме? Үзе белә”.[1] Кечкенә генә малай башында менә шундый уйлар кайный. Әлеге уйланулар автор позициясе белән аваздаш. Шул ук вакытта автор Кәбирнең гадәти малай икәнлеге турында да онытмый: “Яшиләр, менәтерәк! Малайда нәселләре өчен горурлану тойгысы туды. Шундый ырадиу-електрлы туганнары бармы аның яшьтәшләренең? Бар ди, пычагым!”[2]

Бөкебаш – Ябалак – Елак аларның нәселләрен корытырга теләп, җир җимереп йөри. Бу гаиләнең һәрбер эшенә каршы төшә, аяк чала. Бу бәндә Кәбирнең картинәләрен, картаталарын да сөргенгә җибәреп, кулак дип интектергән. Үләргә дип кайтып төпләнгән бабасына да тынгы бирми Бөкебаш. Моның сере дә бик гади булып чыга. Яшьлегендә Ябалак Кәбирнең әнисе артыннан йөргән була. Тик ул башка егетне сайлый. Шул ачу, шуңа булган үч итү теләге каныктыра да инде аны Кәбирләргә. Малайның әнисен Ябалактан бик яклыйсы килә. Ләкин үзенең көчсез икәнен аңлый: “Кәбирнең инәсен кочаклыйсы, әллә нинди иркә сүзләр белән юатасы, атныд тереләчәгенә, ә Бөкебашларның аларга бернинди явызлык та эшли алмаячагына, аннан, үскәч, үзенең көчле дә, акыллы да, эшчән дә булачагына ышандырасы килде – тик тән хәрәкәтсез, тел исә йозаклы иде”[3]. Кәбирне алда әле тагын бик күп сынаулар көтә. Аның бала җанын чыныгырга мәҗбүр иткән вакыйгалар бик күп булачак әле.

Бамбук белән кайтырга чыккач, ат бервакыт аны өстерәп кача. Шунда җирдә ятканда Кәбир ир һәм ат турында уйлый, легенданы исенә төшерә. Бүгенге генә түгел, үткәннәр дә кызыксындыра малайны. Бәлки, ул киләчәктә, галим дә булыр иде.

Әле башланып кына килгән гомеренең беренче сәхифәләрендә ул үзе дә сизмәстән сабыйлыгыннан иртә, бик иртә ваз кичеп, олы бер сагыну һәм гарьләнү белән атасының рухын чакырды”[4]. Кәбир өчен әти-әнисе иң беренче урында торалар. Бу шулай булырга тиеш тә. Димәк, киләчәк буында өмет бар.

Авырлыклар кешене чыныктыра, каты сынмас характерлар тудыра. Кәбир чын имәндәй нык терәк булып җитешә. Автор аны яратып, үз итеп, киләчәккә ышаныч баглап: “Мәңгегә атасыз, әлегә хәтта анасыз, күкрәкләрендә үр җилләре кураен уйнатып, кеше биргән күлмәк-ыштанда, кеше биргән кәвешләрдә, сугышларны үтеп исән калган, явызлар пычагы астыннан очраклы гына котылган атны этәреп ... чыгып килгән малай...”[5]

Шулай итеп, яшьләрнең характер формалашуына күп кенә тарихи вакыйгалар, шәхси, иҗтимагый факторлар йогынты ясаганнар. Моны Кәбир мисалында ачык күрдек.

## Йомгак

Сиксәненче елларның уртасында сәяси мәйданда үзен башбирмәс көрәшче итеп таныткан Айдар Хәлимне күпләр аңлап бетермәделәр, милли хәрәкәттә катнашканда үз мәнфәгатьләрен алга куйган кешеләр белән бутадылар, милләтләр арасында каршылык китереп чыгаруда гаепләргә тырышучылар булды. Шул чакларда сәяси мәйданда давыллы һәм гаугалы итеп хакыйкатьне игълан иткән әдипкә астыртын каршылык күрсәтеп, тынычлык саклаучы булып күренергә тырышучыларның гамәле артында үз мәнфәгатьләре ятканлыгы иртәме-соңмы милләткә фаш була, тарих һәрнәрсәне үз урынына куя. Чын әдипнең фидакарьлеге артында исә гаделлек хисе ята. Айдар Хәлим милләтчелеге нигезенә балачактан ук тәрбияләнгән хакыйкатькә омтылыш салынган. Аның көрәше милләтләргә каршы түгел, ә икейөзле сәясәткә каршы юнәлтелгән. Шулай ук үзенең әсәрләрендә милләтнең югалуы, юкка чыгуы, исереклеккә бирелүе турында ачынып яза. Татар кызларын һәм улларын милләтне салап калуга өнди!

Автор әсәренең мәгънәсен укучыга тапшыру вазифасын символларга йөкли. Һәм

[1] Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты, 2003. – 445 б.
[2] Шунда ук. - 450 б.
[3] Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты, 2003. – 455 б.
[4] Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты, 2003. – 500 б.
[5] Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР “Хәтер” нәшрияты, 2003. – 556 б.

шушы ат, йөрәк, әтләр төркеме, туа алмаган колын һ.б. символлары әсәрнең төп фикерен ачып бирүче ачкыч ролен үтиләр. Затлы нәселдән булган атны суялар, колыны туа алмыйча кала – татар милләте һәм аның киләчәге; йөрәк – кечкенә малай кулындагы якты, өметле киләчәк; әтләр – киләчәк буын кешеләренә киная.

А. Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәре татар милләтенең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген күрсәтүче күрәзә шары.

Шулай итеп, яшьләрнең характер формалашуына күп кенә тарихи вакыйгалар, шәхси, иҗтимагый факторлар йогынты ясыйлар. Мәсәлән, әтисез калган малайның чын ирләрчә фикер йөртергә өйрәнүе, инәсен якларга атлыгып торуы, мал җанлы булып формалашуы, нинди генә вакыйга булса да, Кеше булып кала белүе горурлык хисе тудыра.

**Библиография**


*Чыганаклар:*

1. Хәлим, А. Кыйбла: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2005. – 177 б.
2. Хәлим, А. Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман. – Казан, 2002.

*Фәнни-теоретик әдәбият:*

3. Заһидуллина, Д.Ф. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – 89-90 б.
4. Закирова, Г.Р., Гыйззәтуллина, Л.Ә. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – 115-116 б.
5. Сәлахов, И. Каерылган канатлар // Мәдәни җомга. - 23 июнь. - 2006. – 16 б.
6. Бәйрәмова, Ф. Ак һәм кара көрәше // Казан утлары. – 2001. - №12. – 119-128 б.
7. Фәтхрахманов, Р. Йөрәкнең җеназасы // Казан утлары. – 2003. - №11. – 131-138 б.
8. Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР "Хәтер" нәшрияты, 2003. – 577-578 б.
9. Шәрәфиев, Р.К. Безме могзиҗалар күрмәгән? Татар эзләү. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2006. – 106-111 б.



**Миниешаехова Ф.Д.**
**Яр Чаллы шәһәре, 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## Роберт Миңнуллинның татар балалар поэзиясенә алып килгән яңалыгы .

Роберт Миңнуллинның татар әдәбиятында кабатланмас, үзенчәлекле үз урыны бар. Билгеле булганча, ул олылар өчен дә, балалар өчен дә яза. Әмма аның балалар өчен язган әсәрләре үзе бер олы өлкә. Р.Миңнуллин чын мәгънәсендә бүгенге татар балалар әдәбиятын әйдәп баручы, аның алгы сызыгында торучы шагыйрьләрнең берсе.

Р.Миңнуллин татар балалар әдәбиятында Г.Тукай, Б.Рәхмәт, Ә.Фәйзи, Ш.Галиев һ.б. традицияләрен дәвам итә. Шагыйрьнең уңышы – заман сулышын тоеп, традиция һәм яңалыкны бергә туплап, бербөтен итеп бирә алуында. Ә бу исә иҗатны көн яңалыклары, заман темалары белән баета. Яңалыкка омтылыш шагыйрь фантазиясендә балалар өчен "чучкабаш", "кәштәкә", "төлкерпе", "юлбарыслан", "Күркәҗә" һ.б. серле образлар һәм хыялый вакыйгалар тууга да сәбәпче. "Әкәмәт җанварлар", "Ми-8А", "Алмазның гаражы" һ.б. шигырьләре моңа ачык мисал.

Мәсәлән, "Әкәмәт җанварлар" шигырендә шагыйрь болан белән антилопа, шимпанзе белән зебра кебек җанварларның исемнәреннән бер сүз китереп чыгара һәм нәни геройны шулай юри "буташтыра". Мондый алым да кызыклы. Ул балаларда бөреләнә башлаган зирәклек, игътибарлылык, зиһен үткенлеге кебек мөһим сыйфатларның ныгып китүенә булыша.

Роберт Миңнуллин, баланың фикерләү дәрәҗәсен үстерү өчен, киек җәнлекләр, йорт хайваннары белән җисемнәрне бер-берсенә җиңелчә итеп, нәниләр аңларлык дәрәҗәдә мөнәсәбәт кылдыра. Бу нәүбәттән, "Югалган хәрефләр" циклына тупланган биш табышмак-шигырь игътибарга лаек. Шагыйрь нәни укучысына күпмедер дәрәҗәдә таныш булган яки көндәлек тормышта очраган кайбер җәнлекләрнең бер үзенчәлеген тотып алган да шуңа

игътибарын көчәйткән. Билгеле, бераз зиһен кыймылдатмый торып, мондый характердагы табышмакларны чишү җиңел эш түгел. Ләкин бу әсәрләр дә нәни укучыны битараф калдырмыйлар, аның күңел дөньясын киңәйтеп җибәрәләр, иҗат активлыгын уяталар.

Р.Миңнуллин иҗатында аның үзе уйлап чыгарган жанрлар да бар: сүз кечкенә әкиятләр турында бара. Билгеле, булганча, халык иҗатында әкият жанры һәм аның берничә аерым шактый үзенчәлекле төркемнәре бар. Тик анда кечкенәкият дигән жанр юк, гәрчә күләме ягыннан әллә ни зур булмаган әкиятләр байтак кына булса да. Димәк, әлеге жанр төрен дә, исемен дә Роберт Миңнуллин үзе иҗат иткән. Димәк, шул исем белән билгеләнгән әсәрләрнең үзләренә генә хас әдәби үзенчәлекләре дә булырга тиеш! Һәм бу чыннан да шулай: Р.Миңнуллин иҗатында, башка күп кенә шагыйрь сюжетына нигезләнгән бер генә әсәр дә юк! Дөрес, аның кечкенәкиятләрендә халык әкиятләре һәм фольклорның башка төрләре белән бәйле аерым мотивлар, сүз тезмәләре булырга мөмкин. Тик шулай да кечкенәкиятләр тулысынча аның үз иҗат җимешләре.

Шуның аерым мисалларына тукталып үтик. Барыннан да элек, аларның барысы да төгәл һәм һич тә традицион булмаган, безнең көннәр вакыйгалары-хәлләре белән бәйле сюжетларга нигезләнәләр. Бу яктан Р.Миңнуллинның кечкенәкиятләре татар халык әкиятләренең барысыннан да һәм принципиаль рәвештә аерылып торалар. Әлеге әсәрләрнең төп үзенчәлеге дә шунда ки, алар балалар психологиясен, күңел серләрен бик яхшы белгән безнең заман шагыйре тарафыннан тулысынча мөстәкыйль иҗат ителгәннәр. Мәсьәләнең бу ягын төгәлрәк ачыклау өчен "Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенәкият”не күрсәтеп үтәргә мөмкин. Әйе, кайсыбыз гына инде кечкенә вакытта туп тибеп, сугып, бәреп, ыргытып уйнарга яратмаган? Һәр нормаль бала кечкенә вакытта туп белән уйнарга ярата! Хәер, малай-шалай гына түгел, егетләр дә туп тибеп, кызлар күбрәк туп ыргытып уйнарга яратмыймыни? Футбол һәм баскетбол бөтен дөньяда яшьләрнең яң яраткан уены түгелмени? Әйе, бу һичшиксез шулай! Әмма шагыйрь мәсьәләнең бөтенләй икенче ягына игътибар итеп: "туп тибү” һәм "шар сугып йөрү” сүзләренең мәгънәләрен шактый якынайта. Нәтиҗәдә капма-каршы фикер туа:

Бер малай Туймаган!

Туп уйнаган,
Туп белән
Күп уйнаган,
Әй уйнаган,
Ул көн буе уйнаган:
Әнисенең сүзләрен
Колагына
Элмәгән,
Өйгә кайтып
Кермәгән.

Үскәчтен
Чын футболчы
Булам диеп
Уйлаган.

Беренче карашка, әлеге малайның нияте бик изге: ул чын футболчы булам дип хыяллана. Тик ул кирәгеннән артыграк мавыгып китә. Көннәр буе туп уйнап, әнисенең сүзен тыңламый, өйгә кайтып керми, бернинди эш эшләми, дәресләренә әзерләнми, укытучы сөйләгәннәренә төшенми... Нишләргә соң инде бу очракта? Ничек туктатырга малайны әлеге "азгынлыктан”? Бу катлаулы сорауларга җавап эзләп, шагыйрь бернинди дидактикага, акыл өйрәтүләргә, киңәш бирүләргә, орышу-кыйнауларга мөрәҗәгать итми! Шагыйрь, халык әкиятләрендә кулланыла торган сюжетка тукталып, тәрбия эшен малай яраткан тупның үзенә тапшыра. Башта туп малайга акыл өйрәтеп карый: гел икеле генә алып йөргән малайга тупның да ачуы килә бит инде! Әмма тупның сүзләре дә ярдәм итмәгәч, ул үзе хәрәкәт итә башлый: малай бер тибүгә туп очып китә дә, әйләнеп төшми. Икенче, өченче һ.б. туплар да шулай очып китеп юкка чыгалар. Кечкенәкият түбәндәге сүзләр белән бетә:

Белмим, хәзер ул малай
Бераз
Үзгәрде микән?

Бераз
Төзәлде микән?
Ләкин ул шул хәлдән соң
Туп тибүдән туктаган.
Хәзер инде күрсә дә
Курка, ди, ул туплардан!

Нәрсә бу? Әкиятме? Чынбарлыкмы? Биредә әкият тә, чынбарлык та бергә укмашкан. Тик анда акыл сату, орышу, тиргәү генә күренми. Һәм моның һич тә кирәге юк! Шигырь-кечкенәкият үзе мөһим тәрбия чарасы булып тора.

"Кояш буласы килгән кызыл шар турында кечкенәкият" әсәре дә аерым бер игътибарга лаек. Жанрның иң борынгы төрләреннән саналган тылсымлы әкиятләрендәге кебек, әсәр тулысынча диярлек һәркемне берсүзсез ышандыра торган уйдырмага нигезләнгән. Әмма аның сюжеты, эчтәлеге барыннан да элек кечкенә балаларга якын. Р.Миңнуллин әсәре нәкъ әнә шул стильдә башлана да:

Яшәгән, ди,
Кызыл шар,
Яшәгән, ди,
Кызык шар...

Шарны элеп
Куйгач та,
Өскәрәк, биеккәрәк,
Охшаган, ди, кояшка!

Әлеге шар югарыга күтәрелеп, кояшка да охшап куйгач, табигый, аның горурлыгы арта; өстәвенә, шундагы бала-чага әлеге шарны гел мактап, "Син нәкъ кояш шикелле!" дип, үсендереп тә торгач! Бу мактау шарга бик тә ошый, аның горурлыгы, тәкәбберлеге артканнан-арта бара, аның нәни, тик кояш кебек түгәрәк башына мәкерле бер уй килә: "Миңа һичкичекмәстән кояш булырга кирәк!" дип, ничек кенә ышанса да, аны шикле фикерләр дә борчый. Киңәш өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә инде? Аның өчен иң якын зат - бердәнбер әнисе! Сабый балага әнисеннән дә якын кеше булмый бит! Табигый, ул үз серләрен, "изге хыялын" әнисенә ача:

Әйткән әнисенә дә:
- Мин кояш булам! - дигән, -
Биеккә кунам! - дигән.

Әмма газиз әнкәсе сабый баласының беркайчан да тормышка ашмас хыялына кискен каршы чыккан. Җитмәсә, әнисенең шикләнүләре дә бик нигезле: әгәр ул шар чыннан да кояш булып, югары күккә күтәрелсә, юньсез малайларның аны шартлатып ташлавы да мөмкин бит яки рәхимсез җил очыртып, әллә кая алып китәр... Әгәр шулай булып чыкса, "Без кояшсыз калырбыз, Аннан каян алырбыз?!" - дип, чын күңелдән борчыла шарның әнисе. әнә шундый куркыныч кисәтүләрдән соң шар үзе дә уйга калган:

Ул әнисен
Тыңлаган -
Кояш булып
Тормаган.

Ул бик дөрес
Эшләгән,
Әйбәт бер эш
Эшләгән!..

Сезгә дә, дусларым, берүк,
Әйтсәләр дә,
Күнмәгез -
Кояш була
Күрмәгез!

Шагыйрьнең башка кечкенәкиятләре дә шундый ук җиңел, матур, саф татар телендә язылган.

Шушы ук юнәлештә язылган "Ничекнигәниөчен" шигырендә дә ул "Кайчанничеккайда", "кайчанничекнинди", "кайчанничекниөчен" кебек "яңа" сүзләр куллана. Алар барысы да татар балалар әдәбиятының бүгенге көндәге оригиналь казанышлары, уңышлары булып санала. Бу әсәрләрнең тәрбияви әһәмияте дә зур: аларда төрле тәрбияви моментлар бергә үрелеп-кушылып, синтезлашып китәләр.

Р.Миңнуллин иҗатында "уен-шигырьләр" лаеклы урын алып торалар. Шагыйрь аларны төрле формада бирә. Мәсәлән, "Өчпочмак" дип аталган шигырьнең юллары да

өчпочмак формасында, ә “Түгәрәк шигырь”нең эчтәлеге исә түгәрәк рәвешендә бирелгән. “Читлек” дип аталган шигырьдә кошлар, табигать, ирекне чикләү кебек бик җитди темалар күтәрелгән. Шигъри юллар читлек формасына урнаштырылган. Бу мәгънәне көчәйтә, тәэсирлекне арттыра.

“Баскыч”, “Борма-борма шигырь” ләренең график сурәтләре балаларга бер күз карашы ташлауга берникадәр мәгълүмат бирәләр.

Р.Миңнуллинның уен-шигырьләре арасында төрле шрифтлар кулланып язылганнары бар. Р.Миңнуллин уен-шигырьләрдә зур шрифт белән я мәгънәви яктан әһәмиятле сүзләрне, я юмор тудыра торган иҗекләрне, сүзләрне, сүзтезмәләрне балаларга аерып күрсәтә. Мәсәлән, “Ни өчен олы?”, “Яра”, “К” лар тулган бакчага” шигыре туган телебезгә игътибарны арттыра, кечкенә укучыларны яңа “ачыш”лар ясарга өйрәтә:

Бу бакчага ни булган?
Бакча “К” белән тулган.
КАРЛЫГАН һәм КӘБЕСТӘ,
КИШЕР, КАРБЫЗ һәм КАБАК,
КРЫЖОВНИК һәм КУКУРУЗ,
КЫЯР, КАВЫН, КУЗГАЛАК...
Әйдә, рәхим итегез!
Авыз итеп китегез!

Р. Миңнуллин җыр жанрында иң актив эшләүче шагыйрь. Күп кенә шигырьләренә композиторлар көй салган. Алар Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин, Резеда Ахиярова, Илгиз Закиров һ. б...

“Әйлән-бәйлән”, “Яратыгыз”, “Әни кирәк”, “Яңгыр җыры” һ.б. җырларын балалар яратып җырлыйлар.

Роберт Миңнуллин киңкырлы, талантлы шәхес. Аның иҗаты күпләргә үрнәк.

Р.Миңнуллинның әсәрләре бүгенге татар балалары рухи тормышының аерып булмаслык бер өлешенә әверелде: алар мәктәп укучылары тарафыннан өйрәнелә, төрле кичәләрдә, концертларда еш яңгырый.

Гомумән алганда, Р.Миңнуллинның һәр шигыре – үзе бер оригиналь поэтик табыш, үзе бер иҗади ачыш, үзе бер әдәби җәүһәр.

**Минсадыкова Р.Ф.**
**Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**«33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»**

## Дәресләрдә татар кино һәм спектакльләрен куллану буенча тәҗрибә

### Кереш өлеш

Соңгы араларда без тел белән бәйле бәхәсле вакыйгаларны кичердек. Килеп чыккан борчулы вәзгыятьне без – татар кешеләре, бигрәк тә татар теле мөгаллимнәре, аңыбыз белән кабул итәргә теләмәдек. Әмма кемнәндер ярдәм көтү, кул кушырып утыруның чичелеш булмавын бик тиз аңладык. Телне саклауның катлаулы ысулы юк. Үзебезнең татар милләте балалары турында әйткәндә, мондый мәсьәлә гаиләдә хәл ителә. Ата-анасын, әби-бабасын хөрмәт иткән кеше үз телен сакларга тиеш һәм моңа үз балаларын да өйрәтергә бурычлы. Ә татар булмаган милләт балаларын дәүләт телендә сөйләшергә өйрәтүгә килгәндә, инглиз телен дә мәктәп укучысының сөйләм дәрәҗәсендә белмәвен искәртеп узарга телим. Билгеле, бу очракта теләк, ихтыяҗ кебек мотивлар булмауны төшереп калдырырга теләмим. Рус балаларына телне сөйләшү дәрәҗәсендә өйрәтеп булмаганда, нигә әле дәресләрне татар халкы сәнгате материаллары ярдәмендә оештырмаска. Татар баласы да сәнгатьне тел ярдәмендә кабул итәргә тиеш. Мәдәни

чараны аңлар өчен, аңа телне белергә кирәк. Ә телне куллану өчен (бу очракта аңлар өчен), яхшы үтемле сәнгать төре кирәк. Шулай итеп, бүгенге эш юнәлешем буенча, телне саклауда мәдәният, сәнгать төп рольләрне уйный дип саныйм. Әдәбият, җыр сәнгате, кино, театр һәм башка сәнгать төрләрен дәресләрдә куллану буенча иң кулай нәтиҗәле эш формаларын оештыру – бүгенге татар теле һәм әдәбияты укытучысы алдында торган бурычларның берсе.

"Дәресләрдә татар кино һәм спектакльләрен куллану" дип аталган эшемдә төп максат – татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә татар киноларын кулланырга этәргеч бирү, тәҗрибә уртаклашу. Максатка ирешү өчен, түбәндәге мәсьәләләрне чишүне бурыч итеп куям:

5) кино һәм спектакльләрне туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә куллану юнәлешләрен аерып күрсәтү;

6) дәресләр өчен татар киноларын, спектакльләрен сайларга булышу;

Эшне башкарганда, мин кино сәнгате турында мәкаләләр белән таныштым, татар фильмнарын карадым, алар буенча тәнкыйть язмаларын өйрәндем, татар кино һәм спектакльләрен дәресләрдә куллану буенча булган тәҗрибәләремне гомумиләштердем.

Нәтиҗәләргә ирешү өчен, анализ һәм синтез алымнарына, чагыштыру, гомумиләштерү, капма – каршы кую кебек фикерләү ысулларына өстенлек бирдем.**Төп өлеш**

Туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә татар кино һәм спектакльләрен куллану зарурлыгын берничә төргә бүлеп карыйм. **Беренчедән,** туган телебез турында бүгенге хәлләр яктылыгында уку-укыту программасында туган үзгәрешләр тел һәм әдәбият предметы эчтәлеге үзгәрү, дәресләр күләме кимү, ихтыярый укыту кебек үзгәрешләрне бәян итә. Ә мәсьәләне чишү барыбер мөгаллимнәрнең үз җилкәләрендә кала бирә. Сыйфатлы татар киносы, спектакльләр, татарча мультфильмнар, төрле мультимедиа чаралары ярдәме белән эшләнгән роликлар кызыксындыру чаралары итеп эшкә җигелә. **Икенчедән,** замана җәмгыяте мәктәп кысаларында һәрьяклы үсеш алган шәхесләр тәрбияләүне бурыч итеп куя. Тел һәм әдәбият дәресләре бу бурычны үтәүдә соңгы урында тормый. Ә федераль стандартлар укыту программаларын Мәскәүнеке белән тәңгәлләштерү өстендә эшли торгач, җыр, рәсем дәресләре программасыннан татар мәдәнияте белән бәйле темалар бөтенләй юкка чыкты. Әдәбият дәресе укучыларны җыр, бию, рәсем, кино, театр сәнгатьләре белән берьюлы таныштыручы бердәнбер дәрес булып кала бирә. **Өченчедән,** без әдәби әсәрләрне аз укучы яки бөтенләй укымаучы балаларга әдәбият укытабыз. Замана балаларының бөтен игътибары телевизор экраннарында, ә күпчелек - компьютор мониторларында. Шуңа күрә экран сәнгате башка сәнгать төрләреннән өстенрәк була бара. Укучы бала китап уку хезмәтен бик катлаулыга саный, дөресрәге – әдәбиятнең күзгә күренгән төсе, хәрәкәте, тавышы булмау баланы укудан читләштерә. Укучылар әдәби сүзгә битараф булмасын, кызыксынсын өчен нишләргә соң? Әдәби әсәрләр укуга, аларны аңлап кабул итәргә бүтән чыганаклар – кино һәм театр аша якын килергә. Теләсә кайсы кинофильмны карауга үз максатыбызны куярга, ягъни аны предметка эшләтергә кирәк. Бер сәнгатьне икенче сәнгать белән алыштырмыйча, берсен берсенә өстәмә итеп кабул итәргә кирәк.

Кино һәм спектакльләрне әдәбият дәресләрендә куллану эшен түбәндәге **этапларга** бүлеп башкарырга була.

**1. Әзерлек этабы**

Укытучы, укучыдан калышмыйча, заман белән бергә атлый. Юлларын таба-ера компьютер, экран, бик идеаль вариантта интерактив такта булдырырга тырыша. Мультимедиа мөмкинлекләрен өйрәнә.

Укытучы теоретик белемнәр белән коралллана: кино сәнгате үзенчәлекләре, композиция, жанр төрлелеге, кино теле, аның әдәбият белән бәйләнеше темаларына мөрәҗәгать итә.

Дәресләрне үткәрү методикасына, дәреснең үзенә тотынганчы, карау материалларын, чыганакларын табарга кирәк. Әлбәттә, интернетта татарча яки татар тормышына

кагылышлы фильмнарны бушлай күчереп алырга мөмкинлек бирә торган сайтлар бар. Ләкин интернет тизлеге белән кыенлыклар, я булмаса күчереп алган роликны мәктәп компьютеры танымау кебек кыенлыкларны алдан күреп, иң кулае – үз шәхси фильмотеканы, медиатеканы төзеп кую.

Кайвкыт фильмнарда уңышсызрак образлар, укучылар яшенә туры килмәгән, әхлакларына ятрак урыннар булу укучының фильмны карау, әдәби өсәр белән танышу теләген сүндерергә мөмкин. Шуңа күрә укучы аудиториясенә тәкъдим иткәнче, укытучы фильмны үзе яхшылап карарга, көчле һәм көчсез урыннарын билгеләргә, ким дигәндә кулланырга яраклы эпизодларны әзерләп куярга тиеш.

Исемлек әзер булгач, фильм сюжетлары белән предметны уку-укыту программасында бәйләнешләр эзләргә, ягъни темаларга яраклаштырып, кино һәм спектакльләрне планга кертергә кирәк.

**2. Нәфис фильм һәм спектакльләр белән эш этабы.**

Киноны аңлап карау-карамауны, иътибарлылыкны тикшерү максатында сюжет, авторлар, образ һәм актерлар буенча тест эшләре үткәрергә була.

Кинофильм, әдәби чыганак, спектакльләр буенча фикер алышу оештырыла:

- диспут, әңгәмә;
- түгәрәк өстәл;
- конференция;

Кинофильм, спектакльга карата рецензияләр язарга мөмкин. Аларның якынча планы мондый була ала:

- гомуми тәэсирләр;
- режиссер һәм автор;
- актер һәм образларда тәңгәллек һәм аерма (иң уңышлы роль, иң уңышсыз роль);
- иң көчле күренеш;
- музыка;
- оператор хезмәте;
- нәтиҗә, картинаны карамаган кешеләргә киңәшләр;

Уен-бәйгеләр оештыру укучыларны кино сәнгатенә тагы да якынайта, сөйләмнәрен баета, образлы уйлау сәләтләрен үстерә, кыскасы, тормышка әзерли. Мондый эш төрләре:

- тамашачы симпатиясенә лаек актерны сайлау, аңа бүләк уйлап табу;
- режиссерролендә сынау: актерлар составын сыйныф укучыларыннан сайлау,
- өзекләрне сәхнәләштерү;
- русча мультфильмнарны татарчага тәрҗемә итү, тавыш яздыру;
- сыйныфның үз киносын булдыру;

**Шәхси тәҗрибә**

Яратып кабул ителгән фильмнарның берсе – шәһәрдәшебез Айдар Хәлим повесте буенча Нурания Җамали режиссерлыгында куелган **“Өч аяклы ат” фильмы.** Фильмны уку-укыту программасы буенча дәресләрдә куллану даирәсе:

- “Төбәк язучылары иҗаты”
- югары сыйныфларда – “Бөек Ватан сугышыннан соңгы чор”
- “Хәзерге заман әдәбияты”
- рус төркемнәрендә – “Дүрт аяклы дуслар” лексик-грамматик темасы
- тәрбия сәгатьләре, һ.б.

Һәр уку елы сентябрьдә Казанда уза торган Халыкара Мөселман кинофестивале белән башланып китә. Татар теле укытучыларыннан башка укучы балаларны әлеге мөһим вакыйга белән таныштыручы да юк. Нигә әле үз вакытында (2008 ел) бу мәртәбәле фестивальдә катнашып, “Иң яхшы оператор хезмәте” номинациясендә җиңүче кино белән мактанмаска, укучыларны да горурланырга өйрәтмәскә. Киноның тәэсир көче турында шуны әйтергә телим: өлкәннәр тарафыннан атны юк итү күренеше куркыныч монстрлар турында карап каешланган замана баласын да елата ала. Ә фильмга анализ дәрәҗәсе “аксак атка охшый барган халык язмышы” дәрәҗәсенә җитмәскә лә мөмкин. Төп максат - Кәбир образы мисалында балаларны максатлы булырга өндәү, аларны максатка ирешү

юлында кыенлыкларга бирешмәскә, дөрес кыйбла билгели белергә чакыру.

Сүз уңаеннан, Айдар Хәлим иҗатында кинолар өчен әзер җирлек тулып ятуын басып ясап әйтәсем килә. “Татар вакыты”, “Татар солдаты”, ... Кем генә боларны төшерергә алыныр икән.

Дәресләрдә куллану тәҗрибәмнән тагын бер фильм – Аяз Гыйләҗевның “Өч аршын җир”, “Җомга көн кич белән” әсәрләренә нигезләнеп, Мансур Гыйләҗев язган сценарий буенча, Юрий Фетинг режиссерлыгында куелган “Бибинур” фильмы. Әлеге картинаны дәресләрдә куллану юнәлешләре:

- укучы балаларга фильмның 6нчы Халыкара Мөселман кинофестивалендә “Иң яхшы хатын-кыз роле” номинациясе буенча гран при алуын, тагын 14 престиж бәйгеләрдә җиңүче буларак билгеләнүен җиткерү;
- фильм һәм әдәби әсәрне чагыштыру (образлар, сюжет, идея-проблематика);
- Мансур образына ставка ясау (максатчан булу);
- рус төркемнәрендә укучы балалар өчен “Өлкәннәр һәм кечкенәләр” лексик - грамматик темасына яраклаштыру (Бибинур мисалында агрессив, дорфа яшьләрне яратып тәрбияләү);
- кино эпизодларын балаларны реаль тормыштан ераклаштыручы аферизмнан (интернет, виртуаль тормыш, секталар) ерак тору яссылыгында куллану;
- Бибинур карчык тәрбияләп торган агачны Шәҗәрә агачы югарылыгында карау;

Чагыштыру барышында үзенчәлекләр уңышлырак ачыла. Гаяз Исхакыйның драмасы буенча Рамил Төхфәтуллин режиссерлыгында куелган “Зөләйха” фильмы да югары сыйныф укучыларына әдәбият темаларына яраклаштырып күрсәтелә ала. Әмма киноны күрсәтүдә бик сак адымнар сорала. Сыйныфның әлеге чор тарихы белән хәбәрдәрлеген, диннәргә карашларын чамаламый торып, картинаны күрсәтергә алынмаска киңәш итәр идем. Әсәрне укудан алган тәэсирләргә караганда актерлар уены көчлерәк дип саныйм.

Татар спектакльләрен куллану да санап үтелгән татар киноларын өйрәнү юнәлешләре белән тәңгәл килә. Кинолар белән чагыштырганда, спектакьләргә кытлык юк. Теләсә кайсы театрның спектаклен интернет челтәрендә табарга мөмкин. Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” повесть-поэмасына Фаил Ибраһимов куйган мелодрама Чаллы драма театры артистлары тарафыннан инде ничәмә еллар сәхнәдән төшми. Әзер төшерелгән вариантны карауга караганда, артислар уйнавын барып күрү күпкә отышлы.

Совет заманнарында (1968 ел) Ленфильм киностудиясендә төшерелгән бер рус фильмын да, татарныкы санап, дәресләрдә кулланам мин. Ул – “Моабитская тетрадь” фильмы. Аның сценариесен Владимир Григорьев, Эдуард Дубровский, Сергей Потепаловлар язган, режиссеры – Леонид Квинихидзе. Ә Муса Җәлилне “Тихий Дон”, “Поднятая целина”, “Семнадцать мгновений весны” фильмнары белән танылган актер Петр Чернов уйный. Фильмны “үзебезнеке” дип санауның сәбәпләре:

- сюжетка татар Герое Муса Җәлилнең Бөек Ватан сугышында Любанск операциясе вакытында пленга төшүеннән башлап, җәзалап үтерелүенә кадәр узган юлы салынган;
- фашист концлагерьларында оешкан “Идел-Урал” легионы, аның тарихы, эшчәнлеге тасвирланган;
- рольләрне татар артистлары Әзһәр Шакиров (Абдулла Алиш), Рәфкать Бикчәнтәев (Шәфи Алмаз), Илдар Хәйруллин (үсмер Зәйни) дә уйный;
- кинода татарча сөйләмле, җырлы, көй-музыкалы эпизодлар да җитәрлек;

Шулай итеп, киноны Муса Җәлил батырлыгын раслауда, “Моабит дәфтәре”нең язмышын аңлатуда бер үтемле сәнгать чарасы итеп кулланырга мөмкин.

## Йомгаклау. Эш нәтиҗәләре

“Дәресләрдә татар кино һәм спектакльләрен куллану” дип аталган эшем белән үземне зур ачышлар ясадым дип санамыйм. Чыгышым белән һәр туган теле һәм әдәбияты дәресендә кино яки спектакль карап утырырга өндәмим. Әмма алар ярдәмендә укучы балаларны әлеге сәнгать төрләренә якынайтырга, алар аша үзебезнен тарих, шәхесләр, татар артистлары белән таныштырырга, алар белән әдәбиятта чагылган мәңгелек темаларны үзләштерергә мөмкин. Мондый дәресләр булачак режиссер, оператор, артист-

актерларга киләчәк өчен юнәлеш тә була ала.

Кино сәнгатенең парадоксрак ягына тукталам. Белгечләр язуына караганда, поэзия башка жанрларга караганда кино сәнгатенә якынрак тора икән. Бу турыда В. Маяковский: “Сценарист һөнәре белән шагыйрь һөнәре асыллары белән нигездә берүк нәрсә”, - дип язган. Ә үз вакытларында Һ.Такташ, соңрак Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләрнең үз сәләтләрен кино өлкәсендә сынап караулары шигъри фикерләү белән кинематографик фикерләүнең якынлыгы турында сөйли. Мин дә чыгышымны шигъри юллар белән тәмамлыйм.

Тормыш үзе - әзер кино...
Мизгелләр тиз алышына...
Тормыш баскычлары буйлап
Кадр арты кадр туа...
Һәркем фильмын үзе яза,
Үзе куя, үзе сыный.
Нинди ирек: актер-кеше
Бар рольләрдә үзе уйный.
Тик бу яшәү сюжетының
Ни башы, ни азагы юк.
Адәмнең үз киносын
Карарга да вакыты юк.
Тормыш үзе – әзер кино...
Кино кую берни тормый...
Кеше шулай, уйный-уйный,
Үткәненә кулын болгый.**Кулланылган әдәбият**

12. Галиуллина М. Татар киносы нинди хәлдә. – Сәхнә. – 2016.
13. Гыйләҗев А. Җомга көн кич белән. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1982
14. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр. – Хәтер. – 2004.- 511 б.
15. Мостафина Ф. Татарстанда кино бар. Татар киносы юк. – Безнең гәҗит. – 2014. - №37
16. Хәлим А. Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2002. – 157-294 б.
17. Юзиев Н. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1969. 272 б.
18. shubino-video.ru
19. tatarkino.ru
20. tatarkino.jimdo.com
21. tatarfilmsonline.wordpress.com
22. http://tatbash.ru/tatarskie/filmy

**Мөхәмәтшина Г. М.,**
**Яр Чаллы шәһәре, 37 нче мәктәп**

## Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы

Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек. Утрау... Ачылмаган утрау...

Шагыйрь, прозаик, публицист, драматург, җәмәгать эшлеклесе...

Каләмдәше Рәдиф Гаташча әйтсәк, «тынгысыз җанлы, күпьяклы талант, гаҗәеп уңган шагыйрь». Шагыйрьләр, әлбәттә, «уңмыйлар», алар йә булалар, йә булмыйлар гына. Бу сүздә замандаш шагыйрьләрнең үз каләмдәшләрен ничек тану юлларының авырлыгы чагыла түгелме? Әйе, шагыйрь. Нинди генә жанрда иҗат итсә дә шагыйрь булып кала ул. Тукай кебек туры сүзле, кыю. Такташ кебек моңлы.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның

беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга.
Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган.
А.Хәлим — драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм остасы. Пьесаларыннан «Җан-чишмә» (1983), «Пәри туе» (1990) әсәрләре заманында Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш казаналар, ә балалар өчен язган «Биктырыш» исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.
Шулай да Айдар Хәлимнең исемен киң таныткан, бер каләмдәше әйтмешли, «кислород бомбасы»дай шартлау ясаган әсәрләре — туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книгапечали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997). Боларның беренчесендә Башкорт-стандагы миллион ярым татарның тоталитар режим чорында милли хокукларыннан мәхрүм ителүе, мәктәпләре, матбугат органнары ябылуы, Мәскәү хакимияте һәм җирле түрәләр алып барган сәясәт нәтиҗәсендә ике тугандаш халыкны — татар белән башкортны үзара ызгыштырырга маташуы документлар һәм гыйбрәтле вакыйгалар мисалында бәян ителә. Әлеге китапның дәвамы рәвешендә язылган «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» әсәрендә автор, татар халкының хокукларын даулап, фикердәшләре белән бергә Уфа каласының үзәк мәйданында ун көнлек ачлык вахтасына басуы, шундагы кичерешләре турында сөйли һәм, шул вакыйгаларга бәйләп, сиксәненче-туксанынчы елларда татар халкы, аның намуслы шәхесләре алып барган катлаулы, каршылыклы сәяси көрәшнең документаль елъязмасы, аның иң тәэсирле сәхифәләре белән таныштыра.
«Җиңелмәс ул чечен» китабы, шулай ук мул документаль материаллар нигезендә, чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да язучы-публицист каләменә хас җете буяулар белән чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи фаҗигале язмышын һәм хәзерге иҗтимагый-сәяси тормышын тасвирлауга юнәл телгән. Гомумән, әдипнең бу дүрт публицистик китабы мәгълүм сәбәпләр аркасында милләт буларак югалган яки әкренләп югала барган, ватаныннан аерылган, җиреннән-суыннан сөрелгән, аракыга батырылган, динсезләндерелгән, шулар аркасында биологик, физиологик һәм рухи сырхауларга дучар ителгән, шул ук вакытта зур тарихлы, мәдәниятле һәм горур табигатьле халыкларның йөрәк авазы булып яңгырый.
Әдипнең егерменче гасырның ахыргы, яңа гасырның беренче елларында иҗат ителгән күп санлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Иманем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш» (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Алар гамьле укучыны да битараф калдырмадылар.
Бу елларда А. Хәлим сәнгатьле проза бабында да мәгълүм иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992) повесте, «Казыктагы итальян» (1999) новелласы һәм бигрәк тә «Татар вакыты» (1998) исемле кечкенә роман бүгенге татар прозасының яңа казанышы итеп бәяләнде.
Айдар Хәлим үткән гасырның 90 нчы елларында мәйданга чыккан милли-иҗтимагый оешмалар эшендә башлап йөри. Ул 1992 елдан татар халкының Милли Мәҗлесе депутаты, 1997—2001 елларда Мәҗлеснең рәисе. 1992 һәм 1997 елларда җыелган Беренче һәм

Икенче Бөтендөнья татар конгрессында делегат булып катнашты.
Айдар Хәлим — 1976 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2003).

**Нафикова А. Э.**
**ГБОУ «Нижнетабынская школа-интернат для детей с ОВЗ»**
**РТ Муслюмовский район Д.Нижний Табын**

**“Рәхмәт халкым, хак язмышым итеп**
**Үз телеңне бирдең иң элек”** (Айдар Хәлим поэзиясе һәм прозасы)

Айдар Хәлим 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә. Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959–1960 елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961–1964 елларда – Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә.

1968 елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлагач, А. Хәлим Татарстанның Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында мөһәндис, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли. Түбән Камада яшьләрнең хакимият җитәкчелегенә буйсынмаган беренче «нәформаль» (формаль булмаган) иҗади-сәяси оешмасын – «Кама таңнары» исемле берләшмәне җанландырып җибәрә һәм шундагы эшчәнлеге өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, 1971 елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була.

1971–1975 елларда А. Хәлим Уфада «Совет Башкортстаны» газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып танала. Аннары ул алты ел дәвамында Себер-Урал магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә өлкән мөһәндис вазифасында Түбән Варта – Курган – Әлмәт һәм Түбән Варта – Курган – Самар нефтьүткәргечләре салуда катнаша. 1981 елда аны Уфадагы Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983–1985 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала. 1985–1991 елларда Айдар Хәлим – язучы -профессионал, ә 1991 елдан 1996 елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугаи басма – «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган.

Язучы Айдар Хәлимнең Чаллыда яңа китабы басылып чыкты. Ул үзенчәлекле - анда

автор 1968 елда балалар өчен үзе язган “Биктырыш” китабына дөньякүләм, урыс һәм татар балалар шигърияте яссылыгында бәя бирә. Үз китабыңа бәя биреп, яңа китап язу татар әдәбиятында яңа күренешкә охшап тора.

“Татар балалар әдәбияты һәм “орчык малай” Биктырыш” дигән соңгы китабының кереш өлешендә А.Хәлим болай дип яза:

“Әдәби тәнкыйтебез булмагач, “Биктырыш” китабы тиешле бәясен алмагач, эш башындагылар аны күрмәгәч, я күрергә теләмәгәч, үз хезмәтемнең барлык дөнья әдәбиятында тоткан урынын билгеләү хокукы бардыр бит?! Үз әсәреңне, аның белән бергә замандаш әсәрләрне шәрехләп язуда, минемчә, ихтыяҗ бар иде. Һәм ул ихтыяҗ зурдан иде”, ди язучы.

Китапның кереш өлешендә мондый юллар да бар: “Сизенәм, язмам басылып чыккан хәлдә, бу балалар шигърияте дип аталган кырмыска оясына таяк тыгып бутауга тиң булачак. Мин моңардан курыкмыйм”.

Шушы басма белән бергә Хәлимнең “Тәрҗемәләр” дигән китабы да дөнья күрде. Анысында инде күбрәк җыелма әсәрләр җыелды, ди автор.

“Тәрҗемәләр”дә гомер буе җыеп, асыл дип саналган әсәрләр тупланган. 1965 елдан бүгенгә кадәр шактый гына шигырь җыелган икән. Шуларны туплап чыгара алдым һәм бу зур куаныч китерде. Куанычтан бигрәк мине татар балалар шигърияте борчый. Чөнки татар балалар шигърияте белән без бала тәрбиялибез. Аларга рухи азык бирәбез. Ул азыкка татарның киләчәге бәйләнгән.

“Биктырыш” дигән китабым 1968 елда язылып, Уфада башкорт, Мәскәүдә берничә тапкыр урыс телендә басылып танылу алды. 40 елга якын китап Татарстанда читләштерелеп торылды. Бары 1996 елда гына, үз хисабыма, Казанда басылды.

Соңгы вакытта “Биктырыш” китабының татар балалар шигъриятендә тоткан урыны хакында уйлана башладым, бөтендөнья балалар шигърияте белән булганча таныштым. Аннан урыс балалар әдәбиятын, замандашларыбыз иҗатын айкап чыгарга туры килде. Шулар арасында “Биктырыш”ымның тоткан урынын билгелисем килде. Шушы юнәлештә “Татар балалар шигърияте һәм “орчык малай “Биктырыш” дигән китабымны яздым. Ул минем 10 ел гомеремне алды.

Укучыга бу әсәр тиешле азык китерер, дип уйлыйм. Тәнкыйть кешенең бимазасына тимичә, ачык булырга тиеш. Балаларга нәрсә бирәбез – белү зарур. Без – Тукайлы халык. Аның эшен дәвам итәргә тиешбез.

Ырдык-шырдык көлдергеч шигырьләр белән бала мәнфәгатен тарайту дөрес түгел. Соңгы 30-40 елда тәнкыйтебез бетү аркасында татар балалар шигъриятенә тиешле сүзебезне әйтмәдек. Мин шушы китап аша үз фикеремне әйттем һәм һич тә үкенмим”, ди А.Хәлим.

Айдар Хәлимнең балалар шигъриятенә анализ ясап язган яңа китабы әлегә язучылар һәм шагыйрьләргә генә таныштыр. Китапны укыган язучы Дөлфәт Хәрби аңа карата үз фикерен белдерде.

“А.Хәлимнең балалар шигъриятен тирән анализ белән тәнкыйтьләвен уникаль күренеш, дип атыйм. Ул балалар шигырьләре язып, зур исемнәр алган шәхесләр алдында да “ләббәйкә” дип тормый, аларның кайбер шигырьләрен балалар өчен зарарлы, дип тә яза”, диде ул.

“Айдар Хәлимнең “Биктырыш”ын укыган бала алга таба милләткә хезмәт итәчәк, китап балалар өчен файдалы. Соңгы китаптагы тәнкыйтьләр дә нигезле. А.Хәлим һәр иҗат кешесенә игътибарлы. Ул дөнья әдәбияты белән якыннан таныш. Көчле шәхес буларак, чәнечкеле дә. Аңа үпкәләргә ярамый”, дигән фикердә тора Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Айрат Суфиянов.

**Нурисламова Э. Ә.**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**

## АЙДАР ХӘЛИМ ШИГЪРИЯТЕНДӘ АНА ОБРАЗЫ

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Төпчек улы Борис туып өченче көн узгач, әтисен фронтка алалар. Ул Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булган, шулай итеп әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә.

Әнисе - Минсорур Шиһабетдин кызы Хисамова хакында әдип болай яза : «Инәй гомер буе колхозда изелде. Гаделлеге өчен аны еш кына авыл Советына «липутат» итеп сайлыйлар иде. Эшчән, җыр-моң, үткен сүз остасы булуы, бихисап башка сыйфатлары белән тирә-якка дан казанган анабызның гомере нибары илле бер яшендә баш миенә кан савудан өзелде. Урыннары оҗмахта булсын. Ул чакта мин хәрби хезмәттә идем. Инәйне җирләргә берничә сәгатькә кенә өлгерми калдым»[6].

Борис - гаиләдә дүртенче малай. Олы абыйсы Гали -12, Нияз абыйсы -8, Ингел абыйсы 6 яшькә өлкән. Җырга-моңга осталык нәселдән килә, өздереп гармунда уйныйлар, такмаклар чыгаралар. Тик ятим калган гаиләгә олы кайгы килә:1946 нчы елда унике яшьлек Нияз абыйсы вафат була..

Ул еллардан тагын бер җанны тетрәндерерлек истәлек: «1946 елның салкын кышында бугай, күршеләребез бездән ашъяулыгыбызны алып торып кире керткәч, мин аны «берәр ашый торган нәрсә калмады микән?» дип идәнгә җилпегән һәм аннан ипигә охшаган валчык төшеп, аны ә дигәнче чәйнәгән һәм ул кер сабыны булып чыккан иде.»[7]

«Шушы кадәр юксыллыкта үземне ятим итеп тоярга бирмәгән.

Бөек Җан иясе – Әнкәм, мине салкыннардан каплаган, мин тәндә җан асрый алсынга кәлҗемә коймагы әвәләр өчен черегән бәрәңге эзләп бакчалардан бакчаларга чапкан, берсеннән-берсе моңлырак җырчы-шигырьче, кирәк чакта гетти-геттигә такмак әйтеп, гармун, кирәк чакта зеңгелдәп, мандолинга әйләнгән Гали, Нияз, Ингель агаларым ята», - дип яза әдип.

Борис Бәләкәй Кәркәленең башлангыч белем ала. Икенче сыйныфта чакта ул түбәндәге шигырен яза:

Бер, ике, өч!
Биргән приказларга буйсынып без
Кулга автоматлар алырбыз,
Кулга автоматлар алырбыз да
Дошманнарны кырып салырбыз…

Кызык та, кызганыч та! 6-7 яшь бала инде сәяси формалашкан шәхес!

Укуга хирыс, хәтере яхшы Бориска уку җиңел бирелә. Күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлый. Шушы елларда булачак шагыйрьнең иҗат чишмәсе хис тулы йөрәктән саркый башлый.

1958 нче елда авыл сәхнәсенә менеп, үзе иҗат иткән «Әниемә» шигырен укый[8], ул шигырь әдипнең "Куен җылысы" китабында урын алган . Шигырьгә сылтама өлешендә автор самимилек бөркелеп торган әсәренә тәнкыйть күзлегеннән бәя биреп: "Сизәм... Бик начарлар, начар. Эшләргә кирәк!.." –дип яза. Әйе, хактан да, мондый беркатлы эчтәлектәге шигырь белән бүгенге көн укучысын шаккатырып булмый, әниләргә багышлап язылган дежур шигырьләр радиодан котлаулар булып һәрдаим яңгырап торалар. Ләкин Айдар Хәлимнең бу шигырь гадилеге хакына яклау таба,

чөнки ул 16 яшьлек яшүсмернең балаларын саклап, тәрбияләп үстергән әнисенә рәхмәтен белдерү , ирләрчә сүз бирү акты булып яңгырый.

---

[6] Хәлим А. Тилергән сирень-Казан: Рухият.,2003-Б.6
[7] А.Хәлим Фәлсәфи-гамәли хикәят «Көчле кеше»
[8] Хәлим А. Куен җылысы-Яр Чаллы: Диамант.,2016-Б.27

”Менә синең улың, шигырь язам,
Әни, бәгърем, синең исемеңә.
Йөз кызармас сиңа минем өчен,
Тап төшермәм данлы исмеңә”- дип язган егет иҗатының буеннан буена шушы вәгъдәсенә тугры кала.

Шигырьнең сәнгатьчә эшләнеше ягына килгәндә, төрле стильгә караган сүзләрнең кушылуы күзәтелә: тәэмин иттең (публицистик), чәчкә (сөйләмә), нужа күреп (сөйләмә), тап төшермәм данлы исмеңә (публицистик), шуның

бәрабәренә әсәр яңгыраш аһәңен югалта төшә. Әни теләкләрен яз гөле белән чагыштыру , авыр еллар, тәмле сүз кебек эпитетлар әдәби образ тудыру өчен омтылыш кебек бәяләнә.

1959—1960 елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда белем ала. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. Бу елларда Борис белән әнисен җылы хатлар бәйли. «Анам хаты» исемле шигыре шул күңел сөйләшүләренең шаһите.[9] 1960 нчы елда язылып, шулай ук “Куен җылысы” китабында урын алган “Анам хаты” шигыре. Әдипнең көндәлегенә кертелгән бу шигырьләрне тикшерүнең әһәмияте шунда: алар әдипнең күңел куәсендә ничә еллар сакланып, аннан ташкын булып ярсып чыгачак, “Тальян моңы”, “Ул елда”. “Әнкәм кабрендә”әсәрләренең беренче шытымнары булган.

“Анам хаты” шигыре лирик яңгырашы ягыннан Сибгат Хәким шигырьләреннән кайтыш түгел. Шигырьдә“Мин анамнан бүген хат алдым.

Хат кечкенә – таудай дәрт алдым”, –юлларының тезмә рефрен булып килүе фикерне укучыга сурәтле, тәэсирле, тойгыны көчлерәк итү максатыннан уңышлы поэтик синтаксик чара буларак әһәмиятле роль уйный.

“Мин анамнан бүген хат алдым.
Суын эчте “Кызыл Коеның.”-
җөмләләре метафораның матур үрнәге булудан тыш, поэтик образ тудыру чарасы булып хезмәт итә.

Әдәби белемгә ия булмаган вакытта иҗат ителгән әлеге шигырь хис-кичерешнең тирәнлеге, сурәтләү чараларының күпкә үсүе белән үзбәясен ала. 1961—1964 елларда — Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә хезмәт итә. Әнисенең вафатын авыр кичергән Борис көндәлегенә «Ике ана» дигән дүртьюллык яза. Ятим калган җанның сыкрап елавыннан туган юлларда бу үлемне кабул итмәүне тоемларга мөмкин.[10]

1966 нчы елда иҗат ителгән “Тальян моңы”, шигыре - әдип иҗатында кыска вакыт арасында тормыш сынаулары аша җитлеккән шагыйрьнең әдәбият мәйданына чыгуын хәбәр итә. Бу шигырьне анализлауга алыну – безнең өчен бер батырлык, чөнки шигърият закончалыгына эчтәлеге һәм формасы белән тәңгәл килгән матур әсәрнең камил якларын ачып бетереп булмас кебек тоела. Әсәрдә Ана-Туган Ил-Намус-Мәңгелек Мәхәббәт төшенчәләре поэтик образ югарылыгына күтәрелә.Улын солдат хезмәтенә озатканда, Ананың хәер-фатихасы фәлсәфи канун булып яңгырый:

“Җырыңны югалтсаң
Кайтасың юк, балам, бу якка!”

Лирик геройның Ана белән соңгы саубуллашуын һәм Ана теләгенең көчен искәртеп, яшен яшьни, айкап күз алмасын (!) - нинди отышлы табыш-метафора!.. Ә инде Ананың ак ташка басып калуы грек әдәбиятында юрау-алым итеп бәяләнер иде. Илне саклау теләге белән янган егетнең ярсу ак кашкага утырып юлга чыгуы һәм Ананың үлем хәбәрен алгач, шул ак кашкадай тоякларын как ташка бәреп, туган якка үксүе гаҗәеп якты образ тудыра.

“Солдат юлы йөгерек сукмак түгел,

---

[9] Хәлим А. Куен җылысы-Яр Чаллы: Диамант.,2016-Б.51
[10] Хәлим А. Куен җылысы-Яр Чаллы: Диамант.,2016-Б.72

Хисләр анда түгәрәк төс ала.
Хезмәт - бөек,
Ул таш йөрәккә дә
Җир тойгысы дигән җим сала", - дигән строфа Миргазыян Юныс әсәрләренә хас лирик чигенеш формасындагы фәлсәфи-бәяләмә, фәлсәфи-төшенчә формасын хәтергә китерә.

Әсәрдә ак таш, гади хакыйкать, солдат юлы, йөгерек сукмак, таш йөрәк, җир тойгысы, зәңгәр җил, кара болыт кебек эпитетлар әдәби сурәт тудыруның сәнгатьле чараларын тәшкил итәләр.

Тауларны җанландыру аша шагыйрь кайгылы хәбәрнең хаклыгын раслый, гүя аның кайгысы таудай зур, ташлары какланган.

Шигырьнең кульминацион ноктасы:

«Ана үлсә – илгә кайгы ята,
Бер кайгыга мең шатлыгың бата», - юлларына салынган. Ананы югалту сагышыннан лирик геройны моң гына коткара ала, бу әдипнең әрнегән күңеленә юаныч бирә. Әдипнең күңел дәрьясы кайнап-актарылып чыккан, шуңа күрә ул үзе өчен Ана төшенчәсе белән Ил төшенчәсен янәшә куеп, әсәрен түбәндәге юллар белән тәмамлый:

"Җыр югалтсам, җирдә ни кала?
Син йөрәгем төере, Ил-Ана..."

Гаҗәеп матур, гамьле әсәр!

«Тальян моңы» шигырендә: «Ана үлсә – илгә кайгы ята, бер кайгыга мең шатлык бата» - дигән юллары аша югалту хисенең дәрәҗәсен билгели.[11]

Айдар Хәлимнең әнисе Миңлесорур Шиһаб кызы һәм аның улы Няз абыйсының якты истәлегенә багышланган "Ул елда" поэмасы 1980 нче елда языла. Бу СССР таркалганчы язылган әсәр никадәр гөнаһсыз корбаннар суырып алу хисабына сугыштан соң төзелгән ил тормышын сурәтли. Бу әсәр тыл арбасын җан ачысы белән тарткан газиз аналарга гимн булып яңгырый.

1946 ел. Илдәге ачлык, наданлык, кешеләр арасындагы явызлык корбаны - унөч яшьлек сабый. Иң аянычы шул: сугыш чорында балаларын үлемнән күз карасыдай саклаган Ананың газиз баласын үлем тырнагыннан саклап кала алмавы. Әдип шул чор Аналарның җыелма образын тудырганда,төсләр колоритыннан ак һәм кара төсләр белән эш итә:

"1946.
Нужалар чигеп.
Үр менә колхоз хатыны
Сыерын җигеп.
Тора әни...Ак яулыклы
Иңенә шуган.
Кайгысы, йөрәктән үрмәләп
Алкымын буган.
Дошман күмергә калдырган
Авыл эчендә _
Хәрабәләр арасында
Язмыш кичергән
Ак мич сымак тора ул –
Яшәү хәтере.
Көлгә әйләнсә дә нигез,
Учагы тере.
Үзе горур, үзе гарьле,
Үзе сылукай.
Үзе моңлы, үзе шомлы,

[11] Хәлим А. Тилергән сирень-Казан: Рухият.,2003-Б.29

Үзе җылыкай.”

Бу юллар безнең күз алдына “Хатынь-мемориаль комплексы”н китерә. Авылдагы өйләр урынында тырпаеп торган мичләр һәм кешеләргә шул еллар кайтавазын искәртеп торучы чаңнар... Татар әдәбиятында чорны бу кадәр төгәл тудырган Ана образы укучы алдында бөтенләй башка амплуада ачыла.

“Ана, ана! Без исән-сау
Ә син юк күптән.
Хәтерең, факел кабызып,
Йолдызлы күктән
Яна безнең күкрәкләрдә
Һәм мәңге сүнми-
Әнидә үлмәсә Ватан,
Балада үлми.”

Димәк, Аналар рухы яшәгәдә, Ватан үлми. Яшел уҗым кебек сугыш ачлыгыннан исән калган балалар, бертуганнарын югалтканда, кайгы-сынау каршында бер йодрык булып җыелалар. Ә авыл халкының кайгы килгән ятим гаиләгә карата никадәр киң күңелле, кешелекле булуы матур әхлак үрнәге булып яңгырый. Балачакта кичергән ачы югалту һәм шул югалтулар аша тәрбияләнгән гомумкешелек кыйммәтләре Айдар Хәлимнең иҗат юлын башка әдипләрнекеннән хис-тойгыларның тирәнлеге белән аерып тора; шәхси күңел кичерешләрен сурәтләгәндә, шагыйрь каләмен шул еллар карасына манып язарга җирлек тудыра, менә шул сәбәпле Айдар Хәлим иҗат иткән Ана образы татар әдәбиятын яңа төсмерләр белән баета. “Айдар Хәлимгә Табигать ана нечкә тоемлау, тынгысыз йөрәк биргән. Бала чагы югалтулы тирән кичерешләр, мәңге әрнүле язмыш алып килгән”.[12]

Айдар Хәлим – безнең тормышның аналитигы, андагы кара күренешләрнең тамырын эзләүче һәм табучы, татарның саф сыйфатларына мөкиббән киткән гашыйгы, милли рухның югалуына әрнүче һәм чаң сугучы фидакарь әдип.[13] Бу юллар белән Айдар Хәлимнең шигъриятtә Ана образы тудыруда тапкан табышлары да бәяләнергә хаклы.

7

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: хезмәтебездә без эстет-шагыйрь Айдар Хәлим иҗатының бер читен генә ачып өйрәндек. Әдип тудырган гаҗәеп матур әсәрләр фәнни эзләнү-тикшеренү өчен сөрелмәгән басу кебек киң, иркен. Айдар Хәлимнең әсәрләрен укыгач, Аналарның фидакарьлегенә, табигать тарафыннан нәфис зат итеп яратылып, заман авырлыкларына бирешмәгән, сынмаган-сыгылмаган Аналар сабырлыгына соклanaсың; ил гаме белән яшәп, үзләренең гомерләрен корбан китергән Аналарны кызганып, энҗедәй саф күз яшьләрен түгәсең. Бу исә Айдар Хәлимнең чын мәгънәсендә талантлы шәхес булуын раслый.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Мөхияр Р.//Шигъри бизәкләр-методик кулланма -Яр Чаллы ЧДПИ, 2008-198 б.
2.Хәлим А. Тальян моңы // Тилергән сирень – Казан:Рухият нәшр., 2003 -.29-30 б.
3.Хәлим А. Ул елда //Печән чапканда - Казан:Татарстан китап нәшр., 2004 - 169-185б.
4.Хәлим А .// Мәйдан. - 2012. - №3. - .8-17б.

**Сабирова Г.Ш., беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «41 нче урта гомуми белем биру мәктәбе»**

[12] Равил Рахмани Тилергән сирень-Казан: Рухият.,2003-Б.562
[13] Фәтхерахманов Р. Йөрәкнең җеназасы.// Казан утлары. – 2003. - № 11. – 132-133 б.

## Әлфия Ситдыйкова иҗатында туган як темасы.

Һәр чорның халык күңеленә якын, халык йөрәге тибешен җаны-тәне белән тоеп иҗат итүче, замана белән бер сулышта атлаучы, тапкыр үткен сүзле әдипләре була. Әлфия Ситдыйкова да татар шигъриятенә кинәт кенә килеп кереп үзенең якты йолдызын кабызды. Ул әдәбиятка тирән уйланулар һәм нечкә хисләр поэзиясе белән килеп керде. Татар поэзиясен яңа образлар, лириканың яңа үрнәкләре белән баетты. Әдәбиятка урау юллар үтеп килгән бу мөлаем ханымның шигърияткә мөкиббән булуы түбәндәге шигырь юлларында да ачык күренә.

Минем җаным шигырь белән сулый
Яшәешем минем шигырьдә.
Язмыш язган бәхетемне таптым
Шигырь белән үргән гомердә.

Әлфия Ситдыйкова – асылда лирик шагыйрь. Мәхәббәт, табигать, туган як, ил, милләт, кеше язмышы- шагыйрәнең иҗатын колачлаган темалар. Шул мөһим мәсьәләләрне шагыйрә түземле,авырлыкларга баш имәүче, тормышка олы мәхәббәтле, куйган максатыннан тайпылмыйча алга атлаучы лирик образ аша сүрәтли.

Тау-ташларны кайчак иңгә салып
Үргә менәр көчләр табыла.
Бер караштан йөрәкләрдә җанны
Балкытырлык ялкын кабына,- дип яза шагыйрә үзенең “Көч” шигырендә.

**Үземнең фәнни эшемдә менә шундый үзенчәлекле шагыйрәнең шигырьләрендә туган як, табигать темасын барлау, шагыйрә иҗатына кызыксыну уяту максат итеп куелды.**

**Фәнни тикшеренү эшемнең темасы: Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова иҗатында туган як темасы.**

**Алга куелган бурычлар:**

1. шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын тирәнтен өйрәнү;
2. поэзиясендә туган як темасын ачыклау, табигать, туган җир белән бәйле образларга күзәтү ясау;

Тикшеренү объекты итеп Әлфия Ситдыйкованың төрле елларда ижат ителгән шигырь җыентыклары алынды.

Туган як, туган ил, туган җир... Беренче тапкыр җиргә аяк басудан алып гомернең соңгы көннәренә кадәр безгә көч-таяныч бирүче, онытылмас моң булып озатып йөрүче төшенчәләр..

Туган туфрагында кеше аягына баса, тәпиләп китә, шунда аның теле ачыла, ул тәүге сүзен әйтә.Соңрак белем дөньясына керә.Агым суларның киңлеге, тауларның биеклеге, тук башаклар чайкалган басуларның, урманнарның шаулавы аны гашыйк итә.

Туган як, туган җир дигәндә кырыс шәһәр тормышы түгел, ә авыл һәм аның бер өлеше булып торган гүзәл табигать күз алдына килә. Әлфия Ситдыйкова иҗатында да бу төшенчәләр әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Ул да башка әдипләр кебек үк авыл белән табигатьне бербөтен итеп үз шигыръләрендә чагылдыра.

Алып кайтты язмыш кабат мине
Яшьлек язым калган аланга.
Карап торам исем китеп уттай
Янып пешкән кызыл баланга. (“Балан шигыре)

Туган җир- шагыйрә өчен гади генә сүз түгел.Бу төшенчә күпкә мәгънәлерәк әһәмияткә ия.Аның өчен туган җир шаян күзле балачак та, сандугачлар моңы сеңгән таллар да, кочак җәеп каршы алучы әни дә, яшәү өчен көрәшергә өндәп пыскып янучы шәм яктысы да....

Әлфия Ситдыйкованың табигатькә мәхәббәте, туган җиренә карата соклану хисе чагылган шигырьләре байтак. Табигать һәм лирик герой кичерешләре авторга үзенең

туган ягына булган мөнәсәбәтен белдерергә булыша.

Туган ягым! Чишмәң, күзең ачып
Сәлам бирә челтер тавыш белән.
Сусавымны басып, дәрман алып,
Үрләреңә,тауларыңа менәм. (“Сиңа кайткач”)

Әлфия Ситдыйкова- авылны һәм аның кешеләрен яхшы белә, авылча уйлый, авыл кешеләречә фикер йөртә. Шәһәрдә дә ул- авыл кешесе.Олыгайгач туган илгә, туган җиргә мәхәббәт сагыну- сагыш төсмерен ала.Туган яктан читтә яшәп көн күрүче кеше язмышы түбәндәге юлларда ачык чагыла.

Туган авылым,һәр ел саен сиңа,
Читтә йөреп арып,
Зарыкканнар кайтып башын ия.
Кем булсаң да җирдә,
Туган туфрак
Башны идертерлек көчкә ия.( “Туган авылым, һәр ел саен сина..”)

Шагыйрәне тагын бер борчыган мәсьәлә- авылларның бетеп баруы. Чыннан да, авыл бетмәсен дисәк, аның мәктәбен дә сакларга, яшь гаиләләр өчен тормыш таләп иткән шартларны да булдырырга кирәк. Шулай булмаса, нигезләр таралып, авыл үзе картаеп, көннәрдән бер көнне бөтенләй юкка да чыгачак. Туган нигездә кемнәр калыр? “Авыл дәшә” әсәрендә автор яңа туган сабый баланы тал ботагын бишек иткән былбыл белән янәшә куеп сүрәтли. Авылны коткарса, бары тик , яңа туган сабыйлар гына коткарачагын ассызыклый автор.

“ Татар авылы”ның язмышы турында шагыйрә ачынып түбәндәге юллар белән әйтеп тә бирә.

Авыл гүя мәрткә китеп бара,
Ятим калган күпме ихата.
Авып барган койма такталары
Зарын сөйли җилгә шул хакта.
Юк,юк,заман ялгышасың,җитте!
Тукта мизгел! Үлмә, авылым!
Ничә гасыр яшәгәнсең яшьнәп,
Җиңеп утлы еллар давылын. (“Авыл дәшә”)

Табигать- сәнгатьнең мәңгелек сурәтләү өлкәсе. Һәр халыкның да әдәбияты үсешенең башлангыч баскычларыннан ук дөньяны әдәби танып белүдә пейзажны мөһим чаралардан санады. Пейзаж лирикасы нигезендә табигать белән бәйле хис-кичереш, тойгы, халәт ята.“ Әлбәттә, туган як, туган авыл темасына бәйләнештә шигырьләргә табигать күренешләренең күпләп килеп керүе табигый. Татар халык поэзиясендә пейзаж лирикасы үстерелеше Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Туфан, Миңнуллин һ.б. шигырьләрендә аеруча ачык чагыла.Бу традиция Ә.Ситдыйкова иҗатында да дәвам итә. Аның туган якка багышланган шигырьләренә табигатьне ихлас ярату, аңа баш ию, табигать рухын тою кебек төшенчәләр хас.Каләме төрле сүрәтләү чараларына бай.Түбәндәге әсәрендә автор сынландыру алымнарын кулланып балачагының инде кире әйләнеп кайтмасын, гомер көзенә аяк басканын бәян итә.

Гомер үткән, көзгә кереп барам...
Чык тамчысы минем күзләрдә.
Балачакның якты ал кояшы,
Төсле күбәләкле ямьле җәе
Озата бара алтын көзләргә.

Пейзаж лирикасында хисләр алышынырга да мөмкин. Бу вакытта хиснең сәбәбе үзгәрә, табигатькә мөнәсәбәттә туган хисне башка, ешрак лирик геройның үз язмышы белән бәйле тойгы алыштыра.Бу яктан Ә.Ситдыйкованың “Яз” шигырен мисалга китереп була. Шигырьнең беренче өлешендә лирик геройның чарасызлыгы , сагышы чагылса, икенче өлештә исә бу хис өмет-ышаныч белән алышына.

Таралды сагыш болыты,
Язгы җил тәрәз какты.
Дөньяга үзгә ямь өстәп,
Гөлләрем чәчәк атты. (“Язгы җыр”)

Милли поэзиябезне берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр белән баеткан Әлфия Ситдыйкова–үзенчәлекле шәхес иясе. Аның иҗаты халыкчанлык традицияләренә нигезләнгән. Беренче карашка иҗаты гади , самими булса, икенче яктан шушы гадилек аны югары биеклеккә күтәрә дә инде. Шуны әйтергә кирәк, бу гадилек эчендә зур мәгънә тирәнлеге яшеренгән. Биредә Әлфия Ситдыйкова шигъриятенә генә хас аерым үзенчәлекләрне тагын бер тапкыр күрсәтеп үтәргә кирәктер. Барыннан да элек, Әлфия Ситдыйкова шигърияте аның үз тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән, шагыйрьнең бик күп иҗат җимешләре үз язмышының турыдан-туры чагылышы булып тора.Лирик “мин” исеменнән хикәяләү шагыйрәдән үзең чынбарлыкта тойган, кичергәнне сүрәтләүне таләп итә. Бәлки ,нәкъ әнә шуңа күрәдер, аның шигъриятендә үзенә генә хас шигъри күзаллавы, образлар системасы, халыкчан үткен теле бар. Шуңа да аның әсәрләре укучы күңелендә яңгыраш табалар.

**Сабирянова Р.Н..**
**I кв. категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**«Татарстан Республикасы**
**Әлмәт шәһәренең 12 нче урта**
**гомуми белем бирү мәктәбе”**

## АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ ПОЭЗИЯСЕ ҺӘМ ПРОЗАСЫ

**Кереш**

Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган каләм ияләре арасында Айдар Хәлим лаеклы урын тота. Ул татар шигърияте, татар прозасы, татар драматургиясе, татар публицистикасы өлкәләрендә зур активлык белән эшли.
Танылган әдип иҗатын һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә аңлый һәм бәя бирә, шуңа күрә аның иҗаты безнең фикерләвебездә дә кызыклы булыр дип саныйбыз. Иҗади эшемне башкарганда мин түбәндәге максатларны күз алдында тоттым:
– укучыларда татар әдәбиятына кызыксыну уяту;
– Айдар Хәлим турындагы белемнәрен киңәйтү;
– мөстәкыйль укылган әдәби әсәрне аңларга, бәяләргә өйрәтү;
– укучыларда эзләнү – тикшеренү күнекмәләре формалаштыру, иҗади эшләү сәләтләрен үстерүгә шартлар тудыру.
Мин эшемдә күңелемә тирән кереп урнашкан һәм яраткан әсәрләремне чагылдырдым.
Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары белән билгеле.
Проза өлкәсендә дә уңышка ирешә. Аның "Өч аяклы ат" повесте, "Казыктагы итальян" новелласы бүгенге татар прозасының яңа казанышы итеп бәяләнде.

**“Рәхмәт халкым, хак язмышым итеп**
**Үз телеңне бирдең иң элек”**

Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек.Утрау... Ачылмаган утрау... Шагыйрь, прозаик, публицист, драматург, җәмәгать эшлеклесе...
Язучы – татар шигърияте, татар прозасының иң күренекле һәм үзенчәлекле вәкилләреннән берсе. Шагыйрь буларак аның беренче әсәрләре татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга.
Шигърияттә А.Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары «Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикайәт»,

«Яралы бөркет», «Эксперимент-86» белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда Казан һәм Чаллы нәшриятларында басылып чыккан җыентыкларында «Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сирень», «Печән чапканда» урын ала.

Туксанынчы елларда А.Хәлим сәнгатьле проза өлкәсендә дә зур иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992), «Казыктагы итальян» (1999) повестьлары, «Кыйбла», «Берлинга хат», «Авылдаш», «Җырлар вакыт» һәм башка күпсанлы хикәяләре һәм бигрәк тә «Татар вакыты» исемле кечкенә романы (1998) әдәби тәнкыйтьтә бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге итеп бәяләнә.

А.Хәлим прозасы – яшәешебезнең көзгесе, милли сурәтебезнең гарип формаларга керүен татарның үзенә күрсәтү, ваемсызлык йокысына талган милләттәшне уяту идеясенең нечкә сәнгать алымнарына төренеп, әдәби формада чагылыш табуы. Айдар Хәлим – безнең тормышның аналитигы, андагы кара күренешләрнең тамырын эзләүче һәм табучы, татарның саф сыйфатларына мөкиббән киткән гашыйгы, милли рухның югалуына әрнүче һәм чаң сугучы фидакарь әдип.

Әдәби әсәрдә образлар тулы бер тәртип – система хасил итә. Алар арасында төп рольне, әлбәттә, кеше образлары уйный. Кеше образлары ике төрле: әдәби әсәр тергезгән тормыш моделендә хәрәкәт итүче, катнашучы; һәм шул дөньяны сурәтләүче, хикәяләүче булырга мөмкин.

Айдар Хәлимнең “Казыктагы тальян” хикәясе хикәяләүче исеменнән бәян ителә. Эпик әсәрдә хикәяләүче – автор белән якынаерга да, нейтраль яки үз позициясен ачык белдерүче булырга да мөмкин. Әсәрнең хикәяләүчесе – үз позициясен, мөнәсәбәтен ачык белдерүче зат. Аның үз героен Бәгъремне тасвирлавы, егетнең уй-фикерләрендә, хис-кичерешләрендә калкып чыккан каршылыкларга битараф калмавы күзгә ташлана.

Төп сурәтләү предметы кеше булган әдәбиятта кеше образлары иң әһәмиятле рольне башкара. Кеше образлары бирелеше катлаулы күренеш хасил итә. Образ тудыру вакытында тышкы кыяфәт, портрет, психологик анализ, характер, автор бәяләмәсе, геройны башкалар белән янәшә яки каршы кую тәэсир ясый. Төп герой Бәгърем характер буларак ачылган. Әсәрнең күп өлеше шушы образны төрле яклап тудыруга хезмәт итә. Бәгърем образының бирелеше берничә яссылыкта күзәтелә ала. Язучы аның портретын әсәр буена “сибеп” бара: “Күп кенә ирләр алтмыш алтыны ваклап та кое казыта алмыйча китеп баралар. Ә син ... уналтыда гына! Болай булса, авылда бер җегет кеше туа, димәк.” “Туган Колтамагына арып-талып, сераеп түгел, ә башын югары чөеп, хәрби җинүче адымнары белән кайтып керде.”; “Ә менә Разия өчен ул җир шарында иң чибәр кеше”; Әйе, авылда аны юкка гына “Җиз маңгай” дип йөретмиләр икән шул. Аның маңгае, чынлап та, гүяки сандалда чүкеч белән чүкелгән җиз кебек эзле һәм батынкы икән... Ияге дә дүрт почмаклы, теш казнасы да бары тик азык күшәү өчен ярытылган!..” Гыймакай бабай:“Бар тирә-якка даны таралган мич чыгаручы, бура бураучы Гыймакай бабалары яратмаган кешесенә эшләү түгел, сөйләшеп тә тормый. Теле дә аның чалгы кебек: кыеп кына ала.” “Берничә ел элек карчыгыннан ятим калган, бүгенге көндә улы-килене белән бергә яшәп яткан карт, яшьләрчә тәвәккәллек белән, табынның күрәгәчесе булырга җөрьәт иткән, ә?” Айсин: “Колхозга яңа рәис булып Мәскәүнең үзеннән үк килгән Хрущев “утыз меңчесе” Кызык телле һәм холыклы, үз бурычын үтәр өчен теләсә нинди пычракка кереп барган беркатлы, эчкерсез кеше иде ул.”

А.Хәлим – символлар теле белән эш итә белгән нечкә тоемлы язучы. Ә бу тел бары тик талант ияләренә генә буйсына һәм аларга гына үзенең серләрен ача. Ясалма образлардан автор символларга мөрәҗәгать итә. Бәгърем образы символ булып килә. Туры мәгънәсендә егет исеме сөю хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе символ була. Егетнең әнисе Тәнзилә үлгәндә “улыма Бәгърем исеме кушыгыз” ди. Әйе, яраткан кешегә без төрле матур сүзләр белән эндәшәбез. Мәсәлән, бәгырь кисәгем, бәгырем кисәге, сөеклем, җаным. Әсәрдә мондый өзек бирелә:“Аңлагансыздыр: Бәгърем исемле ул. Бәгърем исемле бегърем, димәк. Аңлагансыздыр: аның исемендә үк ниндидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде. Уйлап

кына карагыз: Бәгърем кадәр бегъремне яратмаска, инкяр итәргә, аеруча ташлап китәргә мөмкинме? Мөмкин түгел. Шуңа күрә дә Бәгърем бит ул. Син Бәгъремгә: “Мин сине яратмыйм, Бәгърем” – дип әйтеп кенә кара!..”

Шулай итеп, хикәядә Бәгърем образы, характеры үзәктә тора. Бәгъремнең характер буларак тулы итеп тудырылуы егеттәге акыл һәм хис көрәшенең, аның кечкенә чактан ук бергә уйнап үскән дусты Разиясын югалту һәм башкаларга ышандырырлык итеп укучыга җиткерергә булыша.

Бу хикәясендә автор фаҗиганы персонажларның күңел дөньясында барган кичерешләр аша тасвирлый. Монда совет чорының кешелексез сәясәте һәм татарның үз битарафлыгы нәтиҗәсендә туган катлаулы кичерешләрнең сурәтләнеше дә, аларга авторның төгәл бәясе дә урын тапкан. Танылган әдип иҗатын һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә аңлый һәм бәя бирә.

Минем күңелемә тирән кереп урнашкан һәм яраткан әсәрем булган “Өч аяклы ат” повестена тукталдым. Повестьның төп герое – Кәбир. Аңа әле 12 яшь кенә. Ләкин инде ул тормышта күп авырлыклар күргән. Әтисе сугышта һәлак була.

Әсәрдә гомергә күңелдә кала торган образларның берсе – Бамбук. Кәбир образын аннан башка карап булмый. “Ир канаты – ат” дигән борынгылар. Бамбук – искиткеч акыллы, зирәк хайван. Аның да язмышы – Кәбир, Сания апа, Степан дәдәйләрнеке кебек аянычлы. Бамбук сугышта булган. Ул хуҗасы Нәби абыйны үлемнән коткара, ләкин үзе авыр яралана. Яралары төзәлгәч, аны тылга җибәрәләр. Һәм бу акыллы хайван көне-төне авыр хезмәттә. Ачлы-туклы яши. Сәми бабай, Кәбир кебек мәрхәмәтле кешеләрнең мәхәббәте яшәтә аны. Ул да – шул чорда хөкем сөргән гаделсезлек корбаны. Кәбирнең кулак дип читкә сөрелгән бабалары асраган затлы ат нәселеннән булган өчен суялар аны. Бөкебаш хәтта хайваннан да үч ала.

Әсәрнең сюжеты артык катлаулы түгел, ләкин мавыктыргыч, кызыклы һәм үзенчәлекле. Әсәр искиткеч матур тел белән язылган. Ул – җырлы һәм догалы тел. Әсәр төрле сурәтләү чараларына бик бай. Әсәрнең теле башыннан алып ахырына кадәр әнә шулай бизәкле. Әйе, Айдар Хәлим туган телнең барлык бизәкләрен нечкә сиземләп яза. Аның бу әсәре безне, ягъни укучыларны кайта-кайта уйландыра, яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, иман белән яшәргә өйрәтә. Өметеңне өзмичә, бәхеткә омтылып, кешелекле булып, янәшәңдәге кешеләргә йөрәк җылыңны биреп яшәсәң, бу дөньяда авырлыкларны җиңеп-җиңеләйтеп, тирә-ягыбызны сафландырып була дип уйлыйм.

## Йомгаклау

А.Хәлим хикәяләренең повесть дип атарга мөмкин булганнарының байтагында төп геройлар – сабыйлар яисә сабыйлыктан яшүсмерлеккә чыгып килүчеләр. Тормышка сабый күзләре белән карау, күренешләрне яшүсмерләр хөкеме аша үлчәү, шуларның күңел бизмәннәренә салып, бәхет-хәсрәт, гаделлек-имансызлык, матурлык-сыйфатсызлык, миһербанлылык-юньсезлек кебек күренешләрне бәяләү, шуларны күрә-күрә, дөньяны-яшәешне аңларга, бу тигезсез һәм мәрхәмәтсез тормышта үз урыныңны табарга тырышу – менә Айдар Хәлим әсәрләрендә еш очрый торган мотивларның кайберләре.

Боларның барысы да язучыныкы. Әдип бу урында ялганлый да, укучысын адаштыра да алмый: булган вакыйгалар – фәкать үзе күргән, үзе кичергән, алданган, җәберләнгән, рәнҗетелгән, үзе ышанган шатлык-хәсрәтләре, өметләре, омтылышлары, хыяллары ята. Кайсы гына яктан – ул гражданлык, социаль-иҗтимагый, сәяси яки эстетик аспект буларак карасаң да, бүгенге татар әдәбиятында Айдар Хәлимнән башка аеруча кыю, үзенчә уйлаучы, үтә дә хөр фикерле бүтән иҗатчыны очратуы кыен. Әлегә сүз бүгенге көн турында гына бара. Мондый могиканнарның соңгысы бездә, мөгаен, Мөхәммәт Мәһдиев булгандыр – әмма аның иҗат диапазоны күбрәк әдәбият-сәнгать һәм көнкүреш мәсьәләләре белән чикләнә иде сыман. Ә монысы үзфикерлелеккә, оригинальлеккә теләсә кайсы өлкәдә, шул исәптән милли рух, милли азатлык белән бәйләнешле аспектларда да дәгъва итәргә омтыла. Шул ук сюжет, жанр, композиция белән бәйләнешле мәсьәләләрне чишкәндә дә А.Хәлим оригиналь, мөстәкыйль фикерләү сәләтен һәм индивидуаль иҗат алымнарын

сакларга тырыша.

**Кулланылган әдәбият**
1. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
2. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 6. – 52-101б.

**Салахова И. Х.**
**Югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

**Биктырыш "Әлифба" укый**
**( Айдар Хәлим һәм башка татар шагыйрьләренең иҗатында бүгенгә көн чагылышы)**

*Йә үсәрмен, йә үләрмен*
*Үлемсезлегем өчен.*
*Гасырларны тулгак тоткан*
*Мине тудыру өчен...*

Милләт язмышы, туган телебез язмышы – әдәбиятта күптән чагылыш тапкан тема. Татар шагыйрьләренең иҗатында бүгенгә көн чагылышы ,милли проблемалар белән сугарылган әсәрләр күп. Туган телебез – татар теле мәсьәләсе, хәзерге вакытта иң актуаль, иң җитди сәяси-иҗтимагый проблема булып тора. Без беләбез, тел булмаса — хәтер юк, хәтер булмаса – тарих юк, тарих булмаса – халык юк. Теләсә нинди милләтне барыннан да элек аның күренекле кешеләре аша беләләр, чөнки аларның каһарманлыгы, таланты, җәмгыять өчен кылган хезмәтләре бер милләт эчендә генә кала алмый, ә бәлки бөтенкешелек күләмендә әһәмиятле була.

Айдар Хәлим – хәзерге милли сүз сәнгатен әйдәп баручы халыкчан, милләтпәрвар язучысы. Ул прозада да, поэзиядә дә, драматургиядә дә актив иҗат итә, оста публицист буларак та чыгыш ясый, зурлар өчен дә, балалар өчен дә яза. А.Хәлим тәүге әсәрләреннән үк милләт язмышын алгы планга чыгаручы реалист язучы буларак татар әдәбиятына килеп керде. Аның һәрбер әсәренең нигезен милли идея, концепция тәшкил итә. Шулай ук милли рух һәм халыкчанлык белән сугарылган, үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсе куелган әсәрләре татар балалар әдәбиятында зур урын алып тора.

Татарстан фәннәр академиясенең вице-президенты, академик Рузәл Габдуллаҗан улы Йосыпов "Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр" дигән чыгышында татар теленең бүгенге халәтен чынбарлыкта тасвирлый. Ул татар теленең хәзерге торышына караган ике проблеманы аерып күрсәтә. Болар – кулланылыш дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты. Кулланылыш дәрәҗәсе татарларның туган телләрен күпмесе белүен һәм ни дәрәҗәдә куллануын күрсәтә. "Мин соңгы елларда үз телләрендә иркен сөйләшә торган татарларның саны арта барадыр дип әйтергә базмас идем. Киресенчә, андыйларның саны кими барадыр дип уйларга нигез бар", – ди ул чыгышында. Сәбәбен татар авылларының кими баруы белән аңлата. Танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев: –Безгә, бер-беребезнең уй-фикерләрен белешергә, мөмкин булган кадәр шушы уй-фикерләргә куәт өстәргә һәм үз бергәлегебезне, зур милләт икәнлегебезне тоеп, күңелебезгә сеңдерергә кирәк. Милли җәмгыятьләр, татар берләшмәләре, илкүләм оешмалар оештырырга кирәк. Югыйсә Финляндиядә – 800, Америкада – берничә мең, Төркиядә ничәдер йөз мең кеше тупланмый икән, барыбер үзебезне зур милләт итеп сизә алмаячакбыз" – дип язды [Вәлиев, 2007: 364].

Мәҗит Гафури да гомер буе милләтне ирекле, телле итү турында хыяллана. Ул үзенең иҗатын, илдә искене җимереп яңа тормыш төзү өчен, милли азатлыкка, көрәшкә таба юнәлтә.Милли уй-омтылышлар белән яшәгән әдип «Азатлык хөрмәтенә» шигырен яза. Ул халкыбызның аяныч хәлен түбәндәге юлларда күрсәтә:

Яп-яңа, чиксез караңгы, куркынычлы төн иде;
Бар халык мәзлум иде, мескен иде, мәхкүм иде.

Шул караңгылык эчендә кычкыру мәмнугъ иде,
Кузгалырга, эзләнергә һич тә рөхсәт юк иде.

Октябрь ревалюциясен дә зур өметләр белән каршылый. Аның бу өметләре шул елда язылган «Татар байрагы» һәм »Кызыл байрак» дигән шигырьләрендә ачык чагыла.

М. Гафури һәм Г. Тукай иҗаты да охшаш.

Тукай дигәндә – татар халкы күздә тотылса, татарлар дип әйтүгә – Габдулла Тукай дигән исем күңелгә килә. Тукайның милләт шагыйре, халык шагыйре булуы аның барлык әсәрләрендә дә чагыла. «Мужик йокысы» шигырендә дә:

Тор, уян, күтәрел!
Үз- үзеңә кара:
Кем идең, кем булдың?
Нәрсә бар милкеңдә? –

дип, йоклап ятмаска, үз мәнфәгатьләре турында кайгыртырга, алга киткән милләтләрнең хәленнән үрнәк алып, «егъла-тора алга таба атлыйк» дип өнди.

Айдар Хәлим: “Бектырыш” дигән китабым 1968 елда язылып, Уфада башкорт, Мәскәүдә берничә тапкыр урыс телендә басылып танылу алды. 40 елга якын китап Татарстанда читләштерелеп торылды. Бары 1996 елда гына, үз хисабыма, Казанда басылды.Соңгы вакытта “Биктырыш” китабының татар балалар шигъриятендә тоткан урыны хакында уйлана башладым, бөтендөнья балалар шигърияте белән булганча таныштым. Аннан урыс балалар әдәбиятын, замандашларыбыз иҗатын айкап чыгарга туры килде. Шулар арасында “Биктырыш”ымның тоткан урынын билгелисем килде. Шушы юнәлештә “Татар балалар шигърияте һәм “орчык малай “Биктырыш” дигән китабымны яздым. Ул минем 10 ел гомеремне алды.Укучыга бу әсәр тиешле азык китерер, дип уйлыйм. Тәнкыйть кешенең бимазасына тимичә, ачык булырга тиеш. Балаларга нәрсә бирәбез – белү зарур. Без – Тукайлы халык. Аның эшен дәвам итәргә тиешбез. “Ырдык-шырдык көлдергеч шигырьләр белән бала мәнфәгатен тарайту дөрес түгел. Соңгы 30-40 елда тәнкыйтебез бетү аркасында татар балалар шигъриятенә тиешле сүзебезне әйтмәдек. Мин шушы китап аша үз фикеремне әйттем һәм һич тә үкенмим”, - дип язды. Айдар Хәлимнең шигырьләре митинг өчен язылган сыман транспарантларга охшаш, һәм алар, әлбәттә, үзенең яңгырашы, төрле юлларның кабатлаулары белән аерылып тора. Мәсәлән, «Без исән!» исемле әсәре:

Безне талап, алар баемады,
Хәер сорашалар – син күрсәң!
Без һаман бай, чөнки таңнан торып,
Милләтебез эшли –
Без исән,
Без исән!
Без исән! [2]

Айдар Хәлим иҗатында Казан образы татар милләтенең иң фаҗигале вакыйгалары белән бәйле. Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге югалуы турында сүз бара. Чыннан да, шагыйрь шәһри Казанны үз иҗатында нәкъ шул вакыйгалар белән бәйләп искә ала:

Җимертелгән Шәһри Казан сыман
Атылырга рәткә тезелсәң,
Җәһәннәмнән кабат күтәрелеп,
Әйтү ләззәт икән:
Без исән! [2]

Айдар Хәлимнең балалар шигъриятенә анализ ясап язган яңа китабы турында язучы Дөлфәт Хәрби аңа карата үз фикерен белдерде.

“А.Хәлимнең балалар шигъриятен тирән анализ белән тәнкыйтьләвен уникаль күренеш, дип атыйм. Ул балалар шигырьләре язып, зур исемнәр алган шәхесләр алдында да “ләббәйкә” дип тормый, аларның кайбер шигырьләрен балалар өчен зарарлы, дип тә яза”, диде ул.

“Айдар Хәлимнең “Биктырыш”ын укыган бала алга таба милләткә хезмәт итәчәк, китап

балалар өчен файдалы. Соңгы китаптагы тәнкыйтьләр дә нигезле. А.Хәлим һәр иҗат кешесенә игътибарлы. Ул дөнья әдәбияты белән якыннан таныш. Көчле шәхес буларак, чәнечкеле дә. Аңа үпкәләргә ярамый", дигән фикердә тора Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Айрат Суфиянов та.

Соңгы арада интернет челтәрләрендә күп кенә кешеләрнең язмаларын, Әлифба китабының фотосын кертүләрен күрергә туры килде. Һәм иң гаҗәпләндергәне, бу фото гади генә түгел иде. Китап тышлыгындагы шушы сөйкемле малайның авызын каплап куюларын күрү минем өчен бик авыр булды. Бүгенге көндә туган телебез – татар теленә каршы бик каты, астыртын көрәш алып барыла башлады. Әлеге хәлләрдән соң, киләчәк турында уйларга куркыныч булып китә. Бер максатта, бер фикердә булган очракта гына, бу куркынычны җиңеп чыга алырбыз һәм әлеге фаҗиганы булдырмый калырбыз дип өметләнеп калам.

Безнең бүгенге яшәешебез, уебыз, теләкләребез, гамәлебез бары бер генә максатка – милли телебезне саклау, үстерүгә юнәлтелергә тиеш.

Тел – халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – зыялы һәр кешенең изге бурычы.

Бүгенге көндә телебездәге ялгышларның күбесе татарларның, нигездә, ике телле булуы, ягъни туган телләрендә дә һәм рус телендә дә сөйләүләре, язулары белән бәйле. Рус телендә эш итә торган татар кешесе еш кына үзе дә сизмәстән туган теленә урынсызга рус сүзләре китереп кертә, һәм ул рус телендәге әйләнмәләрне, әйтемнәрне ялгыш (хәрефкә – хәреф) тәрҗемә итеп, туган тел өчен табигый булмаган әйтемнәр, сүзтезмәләр куллана башлый. Шулай итеп, татар телендә табигый булмаган, ясалма әйләнмәләрнең саны көннән-көн арта бара. Телнең бозылуы дәвам итә.

Кызганычка каршы, татар теленең даирәсе кими. Татар – бик практик халык. Әгәр дә кеше җәмгыятьтә татар теленә ихтыяҗ кимегәнен сизә икән, ул тиз арада үзенә кирәкле булганын үзләштерә. Бездә кеше кирәкме, юкмы дип тел белән сатулашырга күнеккән. Андый караш булырга тиеш түгел. Тел ул – мирас, ата-бабаларыбыздан калган казаныш, дәүләт эшләрен алып баручы, иҗат итүче. Туган телгә, мәдәниятккә мөнәсәбәтне бишектән үк тәрбияләү мөһим. Әгәр дә телгә карашыбызны үзгәртмәсәк, ул югала баруын дәвам итәчәк

Татар теле гаиләдә сакланып калырга тиеш дип билгеләп үтәргә яраталар. Минемчә, бар нәрсәне дә гаиләгә генә кайтарып калдырырга ярамый, дәүләт күләмендә дә чаралар күрергә кирәк.

Фәнни-эзләнү эшемне язганда, мин үземә түбәндәге нәтиҗәләрне ясадым:

Иң элек милләттәшебез, бөек шәхес Садри Максуди сүзләре белән әйтәсем килә: "Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап, без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер".

Минем уйлавымча, бүген татар халкы ниндидер бер чик алдында тора. Әгәр без бүген берләшеп, низаг һәм ыгы-зыгыларны онытып, милләт язмышы, аның киләчәге турында ныгытып уйланмыйбыз икән, безнең хәлләр бик тә мөшкел булачак.

Әдәбият


1. Вәлиев Р. Әсәрләр: Публицистик язмалар. Дүрт томда. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2007. –Т. 4. – 672 б.
2. Татар шигърияте: 1980-2000 еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 290.
3. Моратова Р. Тел язмышы - милләт язмышы. "Мәйдан" №9 2002
.
4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 511 б.



**Салихова Г.А.**
**Ікв. категорияле**

**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**"Татарстан Республикасы**
**Әлмәт муниципаль районының**
**Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбе**

**«Татар дөньясы – операсыз һәм балетсыз яши алыр, ә киносыз яши алмаячак»**
**(М.Гыйләҗев)**

( Дәресләрдә татар киносын куллану буенча тәҗрибә)

Бәйге өчен әзерләнгән әдәбият дәресем, «Татар дөньясы – операсыз һәм балетсыз яши алыр, ә киносыз яши алмаячак» һәм Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре буенча төшерелгән фильмына күзәтү экскурсия- дәрес рәвешендә алынды.

Дәреснең тибы: бәйләнешле сөйләм теле үстерү

Эш төрләре (алымнар): сорау-җавап, карточкалар белән эш.

Дәреснең төзелеше:

1.Оештыру өлеше.

2.Белемнәрне актуальләштерү

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре буенча сораулар биреп, төгәл җавап алуга ирешү.

3.Уку мәсьәләсе кую

Максат: укучылар белән берлектә дәрес-экскурсиягә бәйләнешле сүзне табу.

4.Төп өлеш. Төп өлеш заллардан тора. **I зал. «Кино-китаптан башлана». IIзал. Кино-күмәк хезмәт. Кемнәр кино төшерә? IIIзал. Видеозал.**

Физпауза

5. **Рефлексия.**

Бәяләү.

Өй эше: **IV зал- иҗади эшләр залы.**

Дәреснең темасы программада, бәйләнешле сөйләм теле үстерү дәресе тибында А.Хәлимнең «Өч аяклы ат»әсәрен кино сәнгате белән бәйләп бирелде. Тема 1 дәрес (сәгать) итеп өйрәнелә.

Дәрес-экскурсияне укучыларның яшь үзенчәлекләрен, белемнәрен, тормыш белән бәйләнешен исәпкә алып төзедем.

Әлеге дәрестә укытуның төрле алымнарын кулландым: сорау-җавап, карточкалар белән эш, эзләнү.

Белем һәм тәрбия бирүгә якын килеп, дәресемдә балаларның тәрбиялелеген күтәрү өстендә дә эшләргә тырыштым.

Дәресемә түбәндәге максатларны куйдым:

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре буенча төшерелгән фильмы белән өстәмә материаллар аша танышу; кино сәнгате турында сөйләшү;

- тема белән бәйләп укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү;
-сүз байлыгын арттыру; логик фикерләү сәләтен үстерү;
-уен элементлары кулланып, укучыларда татар теле һәм әдәбияты дәресләренә кызыксыну уяту;
- мөстәкыйльлелек, игътибарлылык, оешканлылык сыйфатлары тәрбияләү;
- укучыларның үз фикерләрен әйтә алулары белән үзләрен күркәм холыклы шәхес итеп тоярга мөмкинчелек тудыру;
- тормыш белән бәйләнешне күздә тотып, яшәешкә дөрес караш тәрбияләү;
- укылган повесть һәм каралган кино аша укучыларда ата-анага, якын кешеләргә карата мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү;
-мин-минлек, эгоистлык сыйфатларының начар булуына төшендерү.

Өй эше итеп, **IV залны үзебез иҗади оештырырга** тәкъдим ителде. Куелган максатымнан чыгып, дәресемне Р.Фәхреддин сүзе белән йомгаклыйсым килә. «Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү – укытучының беренче эше булыр».

**Сафина Ф. С.**
**Яр Чаллы шәһәре**
**МБГББУ “54 нче гимназия”нең**
**башлангыч сыйныф укытучысы**

**Айдар Хәлимнең чәчмә әсәрләре (прозасы)**

I. Кереш

Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган каләм ияләре арасында Айдар Хәлим лаеклы урын тота. Ул татар шигърияте, татар прозасы, татар драматургиясе тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Танылган әдип иҗатын һәркем үзенчә күз алдына китерә, үзенчә аңлый һәм бәя бирә, шуңа күрә аның иҗаты минем фикерләвемдә дә кызыклы булыр дип саныйм. Фәнни-тикшерү эшемне башкарганда мин түбәндәге максатларны күз алдында тоттым:

1. Айдар Хәлим иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, күбрәк материал туплау һәм өйрәнү.
2. Айдар Хәлимнең прозасы белән ныграк танышу.

Бурычлары:

1. Айдар Хәлим иҗаты турында материалларны туплау һәм куллану.
2. Айдар Хәлимнең әсәрләрен уку, тематикасын барлау, телен өйрәнү.

Бу тикшеренү эшенә әзерләнгәндә, Айдар Хәлимнең әсәрләрен, әдәбият тарихы һәм теориясенә караган китаплар, газета-журналлар, аның турында язылган истәлекләрне укыдым.

II. Төп өлеш

1. Айдар Хәлимнең тормыш юлына кыскача күзәтү

Айдар Хәлим 1942 нче елның 1нче гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Рече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Гаиләдә дүрт бала. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак була. Әнисе дә бу якты дөньяны бик иртә калдырып китә. Айдар Хәлим дүрт яшендә балалар йортына урнаштырыла. Булачак әдип бала чактан ук ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә [1].Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959-1960 нчы елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961-1964 нче елларда – Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә.

Айдар Хәлим ишегалды җыештыручы һәм “Спартак” комбинаты балалар бакчасында каравылчы хезмәтләрен башкарып, көндезге бүлектә укып, 1968 нче елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлый. Аннары, Татарстанның Түбән Кама шәһәренә килеп, нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында инженер, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли. Түбән Камада яшьләрнең хакимият җитәкчелегенә буйсынмаган беренче формаль булмаган иҗади-сәяси оешмасын – “Кама таңнары” исемле берләшмәне җанландырып җибәрә һәм шундагы эшчәнлеге өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, 1971 нче елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була [4].

1971–1975 нче елларда Айдар Хәлим Уфада “Совет Башкортстаны” газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып танылa. Аннары ул алты ел дәвамында Себер-Урал магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә өлкән инженер вазифасында нефтьүткәргечләре салуда катнаша [1].

1981 нче елда аны Уфадагы Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983–1985 нче

елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала.

1991нче елдан 1996 нчы елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугат басма – «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли [1].

2003 нче елда Татарстан Язучылары берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек була [1]. Бүген Айдар Хәлим Яр Чаллы шәһәрендә яши һәм ару-талуны белми иҗат итә.

2.Айдар Хәлимнең чәчмә әсәрләре (прозасы)

Айдар Хәлимнең беренче зур чәчмә әсәре - "Өч аяклы ат" повесте "Казан утлары" журналының 1991 елдагы июнь, июль сан¬нарында басылып чыга һәм җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Бу повесть 1998 елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та дөнья күрә. Биредә автор сугыштан соңгы татар авылы язмышын ат һәм унике яшьлек ир бала язмышы, ягъни борынгыдан татар менталитетының үзәген, яшәү мәгънәсен тәшкил иткән "ир-ат", "ир-егеткәй белән ат башы" төшенчәләре аша ача. Сыйныфлар арасында уйлап табылган сугышта "җиңү" өчен партия номенклатурасы һәм ул гына "сәнәктән көрәк иткән" Бөкебашлар ир-ат нәселе белән бер рәттән хәтта "дошманнарның" хосусый милкен тәшкил иткән мал-туар нәселен дә юк итү юлына баса. Та¬гар авылы, шулай итеп, башта ирсез, аннан атсыз кала һәм бу авыл, автор сурәтләвенчә, ир белән ат кушылмый һәм бербөтен "ир-ат"ны тәшкил итми торып, беркайчан да аякка басмаячак һәм мантымаячак. Биредә ат, әлбәттә, символ-тамга итеп алына.

Әсәрнең сюжеты нигезендә авторның туган авылы һәм үз язмышындагы вакыйгалар алына. Аның теле хәзер Башкортстан дип аталган Бөгелмә - Бәләбәй калкулыгында, Дим Өязе елгалары бассейнында яшәп яткан татар кавеме теле, сурәтләнгән табигате дә шул тарафлар табигате.

1996 елда башта "Ватаным Татарстан" газетасында, аннан "Аргамак" (9 нчы сан) журналында басылып чыккан "Эңгер" хикәясенең сюжеты Чаллы, КамАЗ җирлегеннән алынган. Анда "дөнья цивилизациясенең соңгы сүзе" була-рак төзелгән Чаллы каласында "коммунистик әхлак" хакына кеше кыйнауны гадәти күренеш итеп гамәлгә керткән татар түрәсе Гегель Әфләтүнович, мактана-мактана үз оешмасы¬ның гомумторагы белән таныштырып йөргәндә, Ангарскилардан килеп урнашкан икенче бер килмешәк урыс Таракановтан Минзәләдән килгән татар үсмеренә "Запомни, я Мет¬рострой построил!" дип сугып җибәреп, күзен чыгарттыра. Болдырдан шаркылдап көлгән исерек Тараканов һәм аның тарафыннан язгы пычракка ыргытылган, шул пычрактан тезләнеп, агып чыккан канлы күзе белән кансыз дөньяга ял¬варып карап торган "якташыбыз" - Минзәлә баласы арасын¬да "бүгенге коммунистик шартларда" бернинди конфликт юк һәм ул булырга да тиеш түгел иде кебек. Кичә генә туган авылыннан Чаллыга килеп урнашкан тыйнаклардан тыйнак, юньле-рәтле урысча да белмәгән егеткәй гомумторакка керү юлында"төшермеш" хәлдә басып торган ике "зур нәчәнник" арасыннан үткәндә Таракановка кагылып кына китә дә бит югыйсә. Әмма конфликтны шул ук Тараканов булмаса да китереп чыгара, чөнки аның татар дөньясын борынгыдан, 1552 елдан килгән конфликт белән ясалма рәвештә туды¬рылган конфликтлар белән куркытып торасы килә. "Эңгер" хикәясендә Айдар Хәлим иҗатында тора-бара төп инвективага әйләнәчәк "Кол - колбиләүче" арасындагы һич киле¬шенмәс каршылыклар беренче тапкыр шулай калку һәм ачык итеп сурәтләнә башлый.

Раскулачиваниедән качып китеп, сугышлар һәм эзәрлек ләнүләр аша ничек җитте исән кала алган һәм илле елдан соң "туган якларында көпә-көндез" кыйбла эзләгән Гарифулла белән Өммегөлсемнәр ("Кыйбла", "Казан утлары, 8,1996), ерак Ялтада, көтмәгәндә генә кырымтатар һәм чечен темаларын тетрәткеч рәвештә бергә китереп ялгаган до¬кументаль хикәя каһарманы – украин язучысы Григорий Бу¬лах ("Көнбагыш чәчкәсе", "Аргамак", №1, 1997), марҗа бе¬лән гомер кичереп, урысча бозып сөйләсә дә, үзебезнең ут-күршебез булган татар җирләре - "Тәләтти калаларында"- кальбе белән урыска әйләнеп, Александрлар үстергән Сөен¬дек ("Авылдаш", "Казан утлары", №7,1998), Бөек Ватан

су¬гышындагы җиде абыйсы арасыннан исән калган һәм җиңү¬нең бер еллыгы көннәрендә Берлинның үзендә үк хезмәт итеп яткан бердәнбер абыйсына “күптин күп, чуктин чук” сәламле хат язып азапланган унбер яшьлек Кадерҗан (“Бер¬линга хат”, “Аргамак”, №8,1998)-болар барысы да импе¬рия тегерменендә язмышларын канлы он итеп тарттырган фаҗигале шәхесләр.

Айдар Хәлим прозасының үзенчәлекләреннән берсе - әсәрләрдәге тән белән җанның бербөтен булып кушылуы. Алар үтә дә тыгыз бәдәнле. Теле сирәк дәрәҗәдә бай. Образ¬ларны сурәтләүдә, төп идеяне ачуда автор телнең булган барлык мөмкинлекләрен файдалана һәм бу өлкәдә үзенең остазлары итеп Фатыйх Хөсни, Әмирхан Еники, Рафаэль Төхфәтуллин, Миргазиян Юнысларны исәпли. Айдар Хәлим эстафета таягын алар туктаган җирдә - алар кулыннан ала һәм үз юлына чыга. Бу үзе генә дә буыннар бәйләнешенең бер гүзәл, табигый күренеше булып гәүдәләнә түгелме?

Язучы тудырган бу образлар ниндидер тамга-символдан яктырып чыккан нурлар кебек ерактан күренә. Аларның тормышка карашы, бәяләре без күреп һәм ишетеп өйрәнгән¬чә түгел, алар үзләре белән татар иҗтимагый чынбарлыгына башка дөреслек, бөтенләй башка концепция алып киләләр. Алар белән элеккеге әдәбиятның образлары арасында искит¬кеч зур аерма бар, гүя алар үзләреннән алдагыларның сәяси коллык халәтен тулысынча инкарь итеп, берүк вакытта ниндидер микъдарда аларның дәвамы да булырга мәҗбүрләр. Әйтерсең бу каһарман образлар татар совет әдәбиятының каһарман образлары түшәлеп үлгән җирдән җиһатка күтәре¬ләләр. Болар үзләренең эчләрендәге коллык бацилласы бар¬лыгын мотлак беләләр, көчләре җитсә, иманга кайтып, җиһат юлына басалар, калебләрендәге бу коллык бациллала¬рын шартлаталар, шартлата алмаган хәлдә, түбәнлеккә тәгә¬риләр һәм һәлак булалар. Милләттән читтә бәхетнең булуы мөмкин түгел - XX гасыр азагындагы татар әдәбиятенә Ай¬дар Хәлим алып килгән, билгеле күләмдә бөек Гаяз Исхакый традицияләрен яңарткан сәяси-эстетик һәм әхлакый концеп¬цияләрнең берсе менә шулдыр. Милли матурлыктан башка батырлык, батырлыктан башка милли матурлык та була ал¬мый. Милләт һәм тел азатлыгы - Җир шарындагы стабиль¬лекнең, сыешып тыныч яшәүнең, гармониянең нигез ташы. Коллыктан азат халәткә кайту. Шуның хакына дөньяның прогрессив җәмәгатьчелегенә, коллыкка каршы халыкара документларга нигезләнеп, империаль көчләргә каршы яна гыйсъян, яңа җиһат игълан итү. Коллыктан азат булу очен башта үзеңдә, аннан тирә-як мохитеңдә җиһат игълан шу кирәк. Шунсыз күзне тирестән күтәреп, бөгелгән билне турайтып булмый.

Туып кына килгән “Яңа гыйсъян” әдәбиятында Айдар Хәлим ялгыз түгел. Чәчмә әсәрләр жанрында төп нигез ташларын ул салган бу яңа юнәлештә инде менә ничә еллар Нурихан Фәттах, Җәмит Рәхимов, Миргазиян Юныс, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Солтан Шәмси, Фәнзаман Баттал, Тәүфыйкъ Әйдиләр эшләп килә. Биредә язучы һәм аның шәхесе, еш кына без моңа кадәр күреп өйрәнгәнчә, бер берсеннән качып, аерым яши алмыйлар, ә бәлки киресенчә, аерылгысыз бербөтен булып укмашкан җан һәм тәнне тәнкил итәләр.

Авторның бар әсәрләре аша да җиһат юлы - татарда иман һәм татар моңын эзләү бурычы якты җеп булып сузы¬ла. Бу җәһәттән 1998 елның 20 - 27 октябрь саннарында “Ватаным Татарстан” газетасында басылган “Җырлар ва¬кыт” хикәясе аеруча игътибарга лаек. Биредә татар моңы¬ның, татар талантының күптәнге һәм иң әшәке дошманы бу¬лып сәхнәгә татар тарлыгы, татар көнчелеге чыга.

Татарның рухи коллыгы темасы авторның “Татар вакы¬ты” (“Казан утлары”, №3, 1999) романында аеруча кискен тасвирлана. Ул татар әдәбиятында иң кыска роман дигән бәя алды. Шул ук вакытта татар әдәбияты тарихында җиде йөз биткә сузылган “Гомеремнең ун көне” дигән иң озын фелье¬тонның да авторы була безнең Айдар Хәлимебез.

Монда төп символ итеп гаиләгә бер мирас рәвешендә килгән гади бер дивар сәгате алына. Аны әсәрнең төп каһар¬маны - Ватан сугышы янбалиты, тома сукыр татар Мотаһар Чанборисовның сигез-тугыз яшьлек оныгы татар Вадим “телевизор карарга комачаулый” дип көн саен чалшайтып туктатып торса, дәүәтисе сукыр Мотаһар Чанборисов оныгы туктаткан сәгатьне, ул мәктәпкә киткәч, дивар буйлап кап¬шанып килеп, урындыкка

капшанып үрмәләп, көн саен җибәреп торырга мәҗбүр. Ахырда бу сәгать Мотаһарның үз кызы тарафыннан урлана. Урланса да, татарның сәгате югала дип булмый, татарның барыбер сәгате бар, аның тик ҮЗ ВАКЫТЫ гына юк - чөнки анысы - Мәскәү байлыгы. Кыскасы, "Казаннарда сәгать ничә икән, Казаннарда Мәскәү вакыты".

Автор үзенең һәр әсәрендә дип әйтерлек татар милли фаҗигасен гаилә, ата - ана - бала өчпочмагы аша сурәтли дип әйтергә мөмкин. Мәсьәлә "Татар вакыты" романында да шулай хәл ителгән. Анда милләтнең киләчәге итеп "перестройка һәм Татарстан мөстәкыйльлеге символы булган кечкенә,әмма бик тә мәгънәле образ - мәктәптә укучы "яшел биш¬мәтле" Заһир кертелә. Кайдадыр Түмән тирәсендә ата-анасы белән автокатастрофага эләгеп, бары тик машина тәрәзәсе аша очып чыгып кына исән кала алган Заһир дәүәнисе тәр¬биясендә ятим үссә дә, ул рухи коллыктан үзен генә түгел, барлык туган милләтен коткарыр кебек.

Әсәргә беренче булып тирән анализны күренекле татар язучысы Миргазиян Юныс ясады. "Казан утлары" (№4, 1997) журналында ул авторның "Кыйбла" әсәренә дә югары бәя биргән иде.

"Әдипнең төп хезмәте нидән гыйбарәт?" - дигән сорау куя Миргазиян Юныс һәм шунда ук соравына җавап та би¬рә. - "Язган әсәрендә чынбарлыкны мөмкин булган дәрәҗә¬дә төгәл, җете сурәтле итеп, дөрес һәм тирәнтен чагылдыру¬да. Юк, графоманнардагыча, казылык тутырган шикелле тормыш детальләрен әсәргә төеп тутыру ярдәмендә эшлән¬ми бу. Әдип укучының мәрткә китә башлаган иманын уя-тып, аны битарафлыктан сөйрәп чыгара алырлык кайнар тәэсирле сүз тылсымы тудыра алу белән үзенең вазифасын раслый булса кирәк. Ләкин бусы - аерым бер тема. Бу мәсь¬әләгә кагылуымның сәбәбе исә "Татар вакыты"нда шушы эшнең моңа кадәр татар әдәбиятында күрелмәгән дәрәҗәдә башкарылуын әйтер идем. Чыннан да, Айдар Хәлимнең уңышы - татар әдәбиятының уңышы бит. Без, әдипләр, бу әсәр белән горурланырга хаклы". ("Казан утлары", 2, 2000).

III. Йомгаклау.

Фәнни-тикшеренү эшемнең максаты күренекле шагыйрь һәм драматург, прозаик һәм публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим иҗаты турында төрле чыганаклардан файдаланып, күбрәк материал туплау һәм өйрәнү; милләт язмышы өчен көрәшүче язучыны безнең буынга һәрьяклап үрнәк итеп куюю иде. Фәнни-тикшеренү эше барышында максатыма ирештем дип уйлыйм. Татар халкының горурлыгы Айдар Хәлим турында билгелекүләм материал тупланды, иҗатында кулланган тәгъбирләр билгеле бер системага салынды, язучының фикер сөреше, иҗатының гаять бай дәрәҗәсе күрсәтелде.

IV. Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар.

1. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
2. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 6. – 52-101б.
3. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 7. – 88-129 б.
4. Шагыйрь, әдип, милләт хадиме. // Казан утлары. – 2002. – №1. – 82-83 б.
5.Татар моңы: Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.– 384 б.
6. «Татарстан» журналы, 2001, 11 нче сан, 2002, 1 нче сан.

**Сәлимҗанова К.Г., 1 квалификацион категория**
**Яр Чаллы шәһәренең "Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе"**

## АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАШКА ШАГЫЙРЬЛӘРНЕҢ ИҖАТЫНДА БҮГЕНГЕ КӨН ЧАГЫЛЫШЫ

Без катлаулы чорда яшибез. Телебезне төрле яклап, төрле сәбәпләр табып, юкка чыгарырга тырышалар. Тел бетсә, халык бетә , дәүләт бетә дигән шомлы сүзләрне һич тә башка сыйдырып булмый. Ләкин татар халкының аянычлы тарихы бу сүзләрне истән чыгарырга ирек бирми. Башта төрле сораулар туа. Ничек итеп, нинди юллар белән һәм кемнәр бу проблеманы чишә ала соң?

21 гасыр - фән-техника чоры. Буыннан-буынга күчеп килгән әхлакый сыйфатларның әкренләп юкка чыга бара торган чоры. Шушы үзгәртеп корулар җәмгыять, мәгариф системасы алдында яңа бурычлар куя. Телебезне, дәүләтебезне, гореф-гадәтләрне саклап калу кемнәр өстенә төшә соң?

Минемчә, бу ,иң беренче чиратта, татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм язучыларыбызның бурычы. Мәктәптә татар теленә кызыксыну уяту, милли аң тәрбияләү, укучыларның күңел кылларын тибрәтеп, җаннарын уятырлык итеп олы тормыш юлына алып чыгу - аларның изге бурычы.

Мин үзем күп еллар инде 34нче мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытам.Үземнең балаларымны, оныкларымны үз татар телебездә дөрес һәм матур итеп сөйләшергә, халкыбызның гореф-гадәтләренә нигезләнеп тәрбияләргә тырышам. Алар гаиләдә һәм дуслары-туганнары белән үз телләрендә иркенләп сөйләшәләр. Быелга кадәр мәктәптә балаларга да татар теле һәм әдәбияты укыту барышында авырлыклар бик сизелмәгән иде. Татар һәм рус балалары, бергәләшеп татар телен өйрәнеп, аралашып яшәделәр. Ләкин быелгы уку елындагы үзгәрешләр күп нәрсәләргә башка күз белән карарга мәҗбүр итте. Без телебезне саклап калу өчен кулдан килгәннең барсын да эшләдекме соң? Кайда ялгыш-хата ясадык? Алда ничек һәм нинди юллар белән бу проблеманы чишеп була соң?

Яшь буында милли үзаң, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү – бу юнәлештә җитди эшләрнең берсе булып тора. Ә әхлак җтәрбиясе хезмәт тәрбиясе белән бер баскычта тора.

Язучы Айдар Хәлимнең иҗатына күз салыйк. Аның балалар өчен язылган әсәрләре күп түгел. Аның әсәрләре мәҗбүри укытылырга тиеш булган әсәрләр исемлегенә дә кертелмәгән иде. Шулай да “Биктырыш” шигъри бәяне берничә әсәрне алыштыра ала. Язучы балаларга мөрәҗәгать итеп болай ди: “ Без бәхетле идек һәм үзебезнең шатлыгыбызны да өйгә- әниләребезгә, апа-сеңелләребезгә, абый-энеләребезгә өләшергә ашыга идек. Әти-әнигә ярдәм итәр өчен, аны сөендерер өчен, яхшылык эшләргә кирәк иде. Без бик тырыштык, чөнки тырышмыйча булмый иде” (1, 6б.)

Әсәрнең теле бик гади , балаларга аңлаешлы, ләкин шул ук вакытта баланың зиһененә сеңеп калырлык итеп, халыкчан шаянлык, юмор аша бирелә. Шулай булгач, бала аларны җиңел кабул итә һәм үзләштерә. Бәян “Орчык кадәр малай” шигыре белән башланып китә һәм шунда ук укучыларда кызыксыну уята. Кем соң ул Биктырыш, андый исем татар телендә бармы, булмаса, каян алынган? Башта укучы шушы сорауларга җавап эзли һәм ул, аны тапкач, сөенә, шатлана. Малайның чын исеме-Илбатыр. Ләкин ул бик тырыш, эш сөя торган булганга, аңа барсы да Биктырыш дип эндәшәләр. Ул әле кечкенә малай, ләкин аның эш-гадәтләре буенча аңа кечкенә дип әйтергә дә тел бармый. Әти-әнисенең һәр кушкан эшен яратып, тырышып башкара. Ул үзен ишегалдында да хуҗаларча тота. Ач чебешләрне ашатырга да, самавыр куярга да, катык оетырга да вакыт таба, бакчада уңыш җыярга да өлгерә ул. Малай бу эшләрне шундый теләп, җиңеллек белән эшли. Биктырыш шул ук вакытта милләте кебек тыйнак та.

Әйе, бу әсәр укучыларыбыз алдына зур сорау куя. Барлык балалар да Биктырыш кебек эш сөючәнме соң? Хәзерге буын нинди хыяллар белән яши, алдагы тормышларын ничек итеп күз алдына китерә, туган җиренә, халкына ничек итеп хезмәт итәргә , файда китерергә уйлый? Бүгенге тормыш шартлары аларның күңелләрен катырып, йөрәкләрен әрнетә ... Чагыштыру өчен Резедә Вәлиеваның “Барый телевизор карый” шигырен алыйк. Бу инде бөтенләй икенче бала: аның ялкаулыгы чиктән ашкан. Бернәрсә белән дә кызыксынмый, көне буе телевизор алдында утыра. Ул үзенең шул начар гадәте аркасында сыйныфында утырып кала. Биктырыш бөтенләй башка. Ул үзлегеннән әлифба укырга өйрәнә. Язучы бу мизгелләрне искиткеч итеп сурәтли. Ихтырсыздан үзеңнең дә шул юлларны кабат-кабат укыйсың килә:

“ Күзләреннән нур тама,
Дулкынланып тын ала,
Китап белән мәш килә” (1, 36 б. )

Белем алу, уку темасы башка шагыйрь һәм язучыларның да иҗатында күп күзәтелә. Мәсәлән, Салават Рәхмәтулланың “Әлифба”, Сания Әхмәтҗанованың “Татлы бишлеләр”,

Сәгыйть Рәмиевнең “Уку”, Гамил Афзалның “Ана теле” һәм инде , әлбәттә, Габдулла Тукайның “Китап” шигыре. Бу шигырьләр укуга, белем алуга чакыра , белемле кешенең тормышта югалып калмавын күрсәтә.

Әйе, “белем алу- энә белән кое казу”,- ди халык. Җиңел түгел. Шул ук вакытта Айдар Хәлим Биктырышның укырга өйрәнү вакытын кызык һәм мавыктыргыч итеп сурәтли. Аңа бар нәрсә җиңел бирелә. Биктырыш бик кызыксынучан, һәрнәрсәгә исе китеп караучы малай.

Хәзерге заманның башка проблемалары да Айдар Хәлимнең әсәрләрендә ярылып ята. Әдәплелек, ата-аналарга, укытучыларга, өлкән буын кешеләренә ихтирамлы, игътибарлы булу. Биктырыш бу яктан да башкаларга үрнәк булып тора. Әти-әнисенең сүзен тыңлый, тракторчы әтисенең дә һөнәре белән горурлана, дус-ишләрен хөрмәт итә. Балаларда бу сыйфатларны тәрбияләү җиңел түгел. Хәзер күп кенә яшь буын балалары эшләп ашарга иренә, аңа китереп бирергә кирәк. Факил Сафинның “Ишек” шигыренә генә күз салыйк. Бала ишекне аягы белән тибеп ачып чыгып китә. Бу инде сиңа әдәпле Биктырыш түгел. Андый балаларны изгелекле итеп тәрбияләү – укытучы , язучыларыбызның бурычы. Әлфия Ситдыйкованың “Ярый әле әбием бар”, “Бәлеш “, Салават Рәхмәтулланың “Иң тәмле чәй”, Сания Әхмәтҗанованың “Әни пешергән бәлеш” шигырьләре китап укучыларны ата-анага , олы буын кешеләренә хөрмәт белән карарга өйрәтүдә үрнәк булып тора.

Айдар Хәлимнең әсәрләрендә тагын бер проблема кызыл җеп булып үрелеп бара. Ул-туган җир, аның табигате белән кызыксыну, аны сакларга кирәклеген һәр балага төшендерү. Биктырыш табигать дәресендә, исе китеп, чаган агачы яфрагының кеше кулларына охшавын күзәтә, шул яфракка бөтен галәм сыйганын аңлый, табигать серләренә төшенергә тырыша. Язучының “Тал баласы Талхаветдин” китабына кергән нәни хикәяләрендә шулай ук табигатьне ярату, аның серләренә төшенергә тырышу ята. Малай һәрнәрсәгә исе китеп карый, әнисенә төрле сораулар бирә, үзе дә табигать серләренә төшенергә тырыша. “ Кояш, син нигә бу кадәр якты?” (3, 6б) , “Минем туган Ватаным да... туган йортым ихатасында чын атым да, этем дә, песием дә бар...(3, 19б.) Туган як табигате бер баланы да хиссез калдырмыйдыр. Туган якка, аның табигатенә соклану хисләре күп әдипләребезнең иҗатында чагыла. Сания Әхмәтҗанованың “Көз ахыры”, “Алтын көз”, “Яңгырлы көз”, Салават Рәхмәтулланың “Таулардагы яңгыр”, Әлфия Ситдыйкованың “Җил”, Роберт Миңнуллинның “Шундый минем туган ягым”, Сирень Якупованың “Җәйге иртә”, “Ай” шигырьләре туган як табигатенә соклану җырлыйлар. “Биктырыш” шигъри бәянендә без баланың хайваннарга, җәнлекләргә җылы, игътибарлы карашын күрәбез. “Җим сип инде, агаем” шигырендә чебеш зарланып малайга килә. Ә Биктырыш аңа шундый сүзләр белән җавап кайтара:

“Син ояңа кайтсана,
Әнкәеңә әйтсәнә,
Биктырыш белә, диген,
Мәм-мәм китерә, диген!” (1, 24 б.)

Шушы гади генә сүзләрдә баланың эчкерсезлеген, йомшак табигатле булуын күрәбез. Шулай ук үзенең дусты Актырнак белән дә сабый кешеләрчә, риясыз сөйләшә:

“Юкка борчылма алай!
Синең кебек тугры дусны
Ташлыйлар диме шулай?” (1, 128 б.)

“Булмаганны чүпли” хикәясендә Талхаветдиннең чыпчык белән булган сөйләшүе бик кызыклы һәм мавыктыргыч. Ул чыпчыкның җирдән нидер чүпләвен күреп ала, ләкин анда бернәрсә дә юк. Нишләп син булмаганны чүплисең, дип сорый. Чыпчык баласы шундый сүзләр белән җавап кайтара:

“Җирдә һәркемнең үз эше бар. Син югарыда, биектә яшисең. Кошлар сиңа кунып сайрарга, син аларны тукландырырга, арыган-талганнарын ял иттерергә бурычлы... Ә мин инде булмаганда да булганны эзләп түбәндә, җирдә йөрергә, ә аннары, югарыга кунып, яшел яфракларыңны, кайрыңны, тамырларыңны кимерә, корыта торган бөҗәкләрдән сине

коткарырга тиешмен!.. (1, 40 б.)”. Бу сүзләр бала күңеленә кереп калып, анда кызыксыну хисләре белән бергә, кошларга карата уңай караш тәрбияли.

Хайваннарга, кош-кортларга мәрхәмәтлелек күп кенә шагыйрьләрнең иҗатында күренә. Роберт Миңнуллинның “Әни, мин көчек күрдем”, Салисә Гәрәеваның “Колыным” шигырьләре, Ф.Сафинның “Тулганай” әсәре матур әдәбият үрнәге булып тора. “Тулганай “ әсәрендә балалар әтиләренә шәфкатьлелек дәресләре бирәләр. Хуҗасыз калган этне үзләренә алырга күндерәләр.

Әйе, Айдар Хәлимнең балалар өчен язылган һәр әсәре аларны төрле яктан тәрбияләүгә максат итеп куелган . Без моны югарыдагы күзәтүләрдә бик яхшы күрәбез.

Хәзер үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып, Айдар Хәлимнең әсәрләрен татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә ничек, нинди максатларда гамәли кулланганымны бераз сөйләп үтәм. Айдар Хәлим иҗаты белән күптәннән таныш дисәм, бик үк дөрес булмас. Беренче тапкыр мин аның “Биктырыш” китабын 2009 нчы елда кулга алдым. Ул китаптан төрле шигырьләрне укучыларга дәреснең башында укый торган булдым. Укучыларның кызыксыну дәрәҗәләре арткannан- арта барды , шуңа күрә без спектакль куярга уйладык. Рус төркемендә укучы балалар белән өзекләрдән чыгышлар әзерләдек. Сценарийны үзем төзедем. Балалар бик теләп эшкә керештеләр. Үз куллары белән төрле хайван маскалары ясадылар. Сүзләрне ятлаганда да проблемалар булмады, чөнки шигырь юллары үзеннән-үзе истә кала, бик тиз ятлана. Бу әсәрдән өзекне , Айдар Хәлим безнең мәктәпкә очрашуга килгәч, сәхнәдә куйдык. Аны зурлар белән бергә балалар да алкышлап каршыладылар (презентация).

“Тал баласы Талхаветдин” китабы белән беренче танышуыбыз 2015 нче елда Айдар Хәлим мәктәпкә очрашуга килгәч булды. Ул үзенең шушы китабын безнең мәктәп укытучыларына бүләк итте. Үзем башта бик җентекләп, игътибар белән укып чыктым. Кат-кат укыдым. Дөресен әйтергә кирәк, беренче тапкыр укыганда аптырап калдым. Кемнәр өчен язылган бу әсәр? Берничә тапкыр укып чыкканнан соң гаҗәпләнү тойгылары кичердем.

Балалар һәм зурлар өчен икән бит. Ул китапны укыган саен яңа тойгылар кичерәсең. Тал баласы теле белән сөйләнгән хикәяләр сине табигатьнең серләре белән яңача таныштыралар, аңа башка күз белән карарга мәҗбүр итәләр.

Язучының “Өч аяклы ат” повесте буенча эшләнгән фильм турында . Бу әсәр үзе аерым игътибарга лаек. Ул китап укучыларны бер-берләренә ярдәмләшеп яшәргә, башка милләт халкы белән дус булырга, ата-ананы хөрмәт итәргә, тормышта аларның таянычы булырга өйрәтә.

Айдар Хәлим әсәрләре искиткеч матур тел белән язылган. Алардагы төрле сурәтләү чаралары, чагыштырулар, кабатлаулар, эпитетлар, риторик эндәшүләр әсәрләрнең телен баеталар, көчен арттыралар.

“Әй әлифба, әлифба!
Мәңге тере җанлы син,
Әллә нинди ямьле син, Әй әлифба, әлифба!..(1, 40 б.)
“Беркөнне күктән, сары томан булып, бал яуды.” (3, 30 б.)
“Тәпиегез сары ука,
Сары ука була юка,
Йомшак йомгак, ал канат,
Сокланам сезгә карап.” (1, 26 б.)
“Самавырга көч керде,
“Әп-че-һеү” дип төчкерде”. (1, 32 б.)

Әйе, язучы телнең барлык бизәкләрен тоеп, сиземләп яза. Шуңа күрә аның әсәрләре бала күңеленә тиз сеңә, анда матур тойгылар уята , укучыларны яхшылыкка өнди.

**Кулланылган әдәбият**

1.Хәлим Айдар. Биктырыш // Казан. “Мәгариф нәшрияты. 2008.
2.Хәлим Айдар. Татар балалар шигрияте һәм “орчык –малай” Биктырыш.
// Чаллы, “Диамант” нәшрияты. 2010.

3.Хәлим Айдар. Тал баласы Талхаветдин. //Татарстан китап нәшрияты. 2014.
4. Л.М.Заһитова. Татар әдипләре. Айдар Хәлим. // Казан. “Милли китап” нәшрияты. 2001.

**Сәхәбиева А.Г.**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**

Туган телебезне саклыйк!

Туган телнең бөеклеген
Тоеп, горурланып яшим.
Татар мәктәбен тәмамлап,
Татар авылында яшим.

Саф татарча сөйләшергә
Нәниләремне өйрәтәм.
Ике кызым: “Әнием!” – дисә,
Сөенечтән эреп китәм.

Урыс телле балаларга
Татар теле укытам мин.
Уйный-җырлый телебезгә
Кызыксыну уятам мин.

Нәни беренчеләремнең
Мине күргәч, сөенүләрен –
Уңышым дип кабул итәм,
Күтәрелә күңелләрем.

Рәхмәт укыйм әниемә
Бишек җыр-көйләре өчен.
Әтиемә, тойдырганга,
Туган телнең газизлеген.

Әкиятләр сөйләдегез
Уйлап чыгарып үзегез.
Һәр көн саен – яңа әкият,
Ничек җитте түземегез?

Әти-әни рәнҗер безгә
Туган телне сакламасак.
Телебезгә мәхәббәтне
Башкаларда уятмасак.

Туган телнең бөеклеген
Тоеп, горурланып яшик!
Авырлыклар артта калыр –
Яхшылыкка өметләник!

**Харисова Гөлфия  Салимхан кызы**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган**
**31 нче урта   гомуми белем бирү мәктәбе»**

**А.Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. А.Хәлим иҗаты турында башка язучыларның фикерләре.**

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә. Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959—1960 елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961—1964 елларда — Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә. 1968 елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлагач, А. Хәлим Татарстанның Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында инженер, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли. Түбән Камада яшьләрнең хакимият җитәкчелегенә буйсынмаган беренче «неформаль» (формаль булмаган) иҗади-сәяси оешмасын — «Кама таңнары» исемле берләшмәне җанландырып җибәрә һәм шундагы эшчәнлеге өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, 1971 елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була. 1971—1975 елларда А. Хәлим Уфада «Совет Башкортстаны» газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып таныла. Аннары ул алты ел дәвамында Себер-Урал магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә өлкән инженер вазифасында Түбән Варта — Курган — Әлмәт һәм Түбән Варта — Курган -Самара нефтьүткәргечләре салуда катнаша. 1981 елда аны Уфадагы М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983—1985 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала. 1985—1991 елларда А. Хәлим — язучы-профес-сионал, ә 1991 елдан 1996 елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугаи басма — «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигъриятtә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә

турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган.

А.Хәлим — драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм остасы. Пьесаларыннан «Җан-чишмә» (1983), «Пәри туе» (1990) әсәрләре заманында Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш казаналар, ә балалар өчен язган «Биктырыш» исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.

Шулай да Айдар Хәлимнең исемен киң таныткан, бер каләмдәше әйтмешли, «кислород бомбасы»дай шартлау ясаган әсәрләре — туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книгапечали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997). Боларның беренчесендә Башкортстандагы миллион ярым татарның тоталитар режим чорында милли хокукларыннан мәхрүм ителүе, мәктәпләре, матбугат органнары ябылуы, Мәскәү хакимияте һәм җирле түрәләр алып барган сәясәт нәтиҗәсендә ике тугандаш халыкны — татар белән башкортны үзара ызгыштырырга маташуы документлар һәм гыйбрәтле вакыйгалар мисалында бәян ителә. Әлеге китапның дәвамы рәвешендә язылган «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» әсәрендә автор, татар халкының хокукларын даулап, фикердәшләре белән бергә Уфа каласының үзәк мәйданында ун көнлек ачлык вахтасына басуы, шундагы кичерешләре турында сөйли һәм, шул вакыйгаларга бәйләп, сиксәненче-туксанынчы елларда татар халкы, аның намуслы шәхесләре алып барган катлаулы, каршылыклы сәяси көрәшнең документаль елъязмасы, аның иң тәэсирле сәхифәләре белән таныштыра.

«Җиңелмәс ул чечен» китабы, шулай ук мул документаль материаллар нигезендә, чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да язучы-публицист каләменә хас җете буяулар белән чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи фаҗигале язмышын һәм хәзерге иҗтимагый-сәяси тормышын тасвирлауга юнәл телгән. Гомумән, әдипнең бу дүрт публицистик китабы мәгълүм сәбәпләр аркасында милләт буларак югалган яки әкренләп югала барган, ватаныннан аерылган, җиреннән-суыннан сөрелгән, аракыга батырылган, динсезләндерелгән, шулар аркасында биологик, физиологик һәм рухи сырхауларга дучар ителгән, шул ук вакытта зур тарихлы, мәдәниятле һәм горур табигатьле халыкларның йөрәк авазы булып яңгырый.

Әдипнең егерменче гасырның ахыргы, яңа гасырның беренче елларында иҗат ителгән күп санлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Имәнем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш» (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Алар гамьле укучыны да битараф калдырмадылар. Бу елларда А. Хәлим сәнгатьле проза өлкәсендә дә мәгълүм иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992) повесте, «Казыктагы итальян» (1999) новелласы һәм бигрәк тә «Татар вакыты» (1998) исемле кечкенә роман бүгенге татар прозасының яңа казанышы итеп бәяләнде.

Айдар Хәлим үткән гасырның 90 нчы елларында мәйданга чыккан милли-иҗтимагый оешмалар эшендә башлап йөри. Ул 1992 елдан татар халкының Милли Мәҗлесе депутаты, 1997—2001 елларда Мәҗлеснең рәисе. 1992 һәм 1997 елларда җыелган Беренче һәм Икенче Бөтендөнья татар конгрессында делегат булып катнашты. Айдар Хәлим — 1976 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2003).

Айдар Хәлимнең әдәби иҗаты турында башка язучыларның фикерләрен дә карап үтик:

Хәлимовның шигырьләре җир сулышы белән сугарылганнар. Мондый шигырьләр

хезмәтнең, мәхәббәтнең, тормышның кадерен белгән кеше йөрәгендә генә туарга мөмкин. Яшь шагыйрьнең әсәрләре шигырь сөючеләргә, ягъни матурлык сөючеләргә ләззәтле минутлар китерер дип ышанам.
Мостай Кәрим, Башкортстанның халык шагыйре. 1966.

...Аның биографиясе шактый бай. Ул язу характеры белән аерыла. Аның шигырьләре давыллы, өермәле, вулкан дияр идем мин... Кайсы вакыт барысы да бергә бутала, шигъри юллар, детальләр, образлар сүз өермәсе эчендә югала. Бәлки, бу вакытлы хәлдер, үтәр!
Сибгат Хәким, Татарстанның халык шагыйре. 1968.

Айдар Хәлим җир һәм күкләр масштабында фикер йөртә. Аларда фикерләүгә караганда сиземләү көчлерәк.
Саҗидә Сөләйманова, шагыйрә. 1970.

Юк, Айдар Хәлимнең Вильнюста басылып чыккан «Хәсрәт китабы», ул китап кына түгел, ул татар милләтенең гасырлар буена яңгыраган аһ-зары, ачу-ләгънәтнең бер йомгакка тупланган шартламасы — бомбасы. Менә ни өчен сатлык җаннар бу бомбадан ераграк торырга тырыша. Мөгаен, нәкъ менә шуның өчен бу китап әле һаман үз телендә сөйли алмый тилмерә. Кем аны бу газаптан коткарыр икән — Казанмы, Өфеме? Кайда ул фидакарь җан?!
Ибраһим Салахов, язучы. 1992.

Әдип укучының мәрткә китә башлаган иманын уятып, аны битарафлыктан сөйрәп чыгара алырлык кайнар тәэсирле сүз тылсымы тудыра алуы белән үзенең вазифасын раслый булса кирәк. Ләкин бусы -- аерым бер тема. Бу мәсьәләгә кагылуымның сәбәбе исә «Татар вакыты »нда шушы эшнең моңа кадәр татар әдәбиятында күрелмәгән дәрәҗәдә башкарылуын әйтер өчен генә. Чыннан да, Айдар Хәлимнең уңышы татар әдәбиятының уңышы бит. Без әдипләр бу әсәр белән горурланырга хаклы.
Миргазиян Юныс, язучы. 2000.

Айдар Хәлим — үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феноменаль күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмешкә-белмәмешкә салынамы — анысы мөһим дә түгел, — әмма вакыт галиҗәнаплары бу шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә инде...
Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары кимәлдәге профессионал булып була икән ул? Айдар Хәлим ике телдә — рус һәм татар телләрендә (теләгәндә саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь (әле яңа гына чыккан «Милли шигырьләр» китабын укып карагыз!). Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын, — максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Пьесалар язуы да мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте — ул проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә генә булса кирәк. Шулай да «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Казыктагы итальян» әсәрләре «Казан утлары»нда үз вакытында басылып чыктылар. Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия-бүләкләргә лаеклы әсәрләр.

Равил Фэйзуллин, Татарстанның халык шагыйре. 2001.

«Өч аяклы ат» повестеның кыйммәте, бик сирәк үзенчәлеге тагы шунда — монда кеше булмаганҗан иясе, бу очракта ат малкае әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әйткәнебезчә, дөнья әдәбиятында бу сирәк очрый торган, язучыдан гаять дәрәҗәдә осталык, нечкәлек һәм талант таләп итә торган күренеш. Әле кеше хәтле кешене образ дәрәҗәсенә күтәрү — гаять авыр һәм катлаулы эш, ә монда телсез җан иясе турында җан тетрәндерерлек, җан җылатырлык образ тудырырга кирәк! Бу эшне бары тик зур талант иясе генә булдыра ала...

Фәүзия Бэйрәмова, язучы, җәмәгать эшлеклесе. 2001.

Сирәк очрый торган энҗеләрнең берсен 2000 елда Айдар Хәлим бүләк итте. Сүз аның «Казыктагы итальян» исемле новелласы турында бара. Моннан алдарак та бу автор проблемаларының үткенлеге, сюжетының бөтенлеге, эшләнешенең камиллеге белән

аерылып торган «Татар вакыты» исемле кечкенә романы белән шатландырган иде... Айдар Хәлим — олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия. Димәк, хикмәт, кайберәүләр инанганча, жанр зурлыгында яисә вакыйгалар чиксезлегендә түгел, ә кыска, тыгыз, динамикалы сюжет кысаларында сурәтләнгән конкрет тормыш күренешенә күңелгә нык тәэсир итәрдәй тирән мәгънә сала белүдә икән...
Рифат Сверигин, әдәбият галиме, тәнкыйтьче. 2002.

Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек. Утрау... Ачылмаган утрау...Шагыйрь, прозаик, публицист, драматург, җәмәгать эшлеклесе...

Каләмдәше Рәдиф Гаташча әйтсәк, «тынгысыз җанлы, күпьяклы талант, гаҗәеп уңган шагыйрь». Шагыйрьләр, әлбәттә, «уңмыйлар», алар я булалар, я булмыйлар гына. Бу сүздә замандаш шагыйрьләрнең үз каләмдәшләрен ничек тану юлларының авырлыгы чагыла түгелме? Әйе, шагыйрь. Нинди генә жанрда иҗат итсә дә шагыйрь булып кала ул. Тукай кебек туры сүзле, кыю, Такташ кебек моңлы шагыйрь.

**Әдәбият**


1. Айдар Хәлим. Биобиблиографик күрсәткеч.- Казан: «Милли китап» нәшр., 2001.- 476 б.
2. Фәүзия Бәйрәмова . Ак һәм кара көрәше.-Казан утлары.- 2001.- № 12.- 119-128 б.
3. М.  Юныс. Бәхетле мескенлек.- Казан утлары.- 2000.- №2.- 167-172 б.
4. М. Әхмәтҗанов . Милләт каһарманы.- Мирас.- 2000.- № 10, 11, 12



**Смирнова Г.Р., Садыкова А.Н.**
**Татарстан Республикасы,**
**Менделеевск шәһәренең**
**1 нче гомуми белем бирү мәктәбе**


## Татарстанда һәм Башкортстанда милли матбугат: “Ватаным Татарстан” һәм “Кызыл таң” гәзитләрендәге мәкаләләрне чагыштырма аспектта өйрәнү тәҗрибәсеннән

*Теманың актуальлеге*. Мәгълүматлы җәмгыять шартларында яшәүнең төп шартларының берсе булып, дәүләт күләмендәге әһәмиятле вакыйгалардан киң катлам халыкның хәбәрдар булуы һәм ул вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен белдерә алуы тора. Мондый шартларда вакытлы матбугат чаралары халык һәм дәүләт арасында арадашчы вазыйфасын башкара. Алдынгы татар вакытлы матбугаты үзенең барлыкка килү чорларыннан алып халыкның юлдашчысы, таянычы, хак юл күрсәтүчесе, юатучысы буларак эш алып бара. Дөрес, бу чор гәзитләрен трибуна итеп Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал каләм осталары файдаланалар.

Галимнәр мондый басмаларның әһәмиятен югары бәялиләр. В.Гарифуллин мәкаләсендә “татар телле матбугат чаралары милли мәдәният үсешенә һәм татар халкының идентификациясен саклауда зур өлеш кертteләр һәм кертәләр, милли үзаңны үстерүдә мөһим фактор булып торалар” дигән сүзләр бик урынлы яңгырый [Гарифуллин, Сабирова, интернет-ресурс]. Моннан кала басмаларда бөтенрәсәй, бөтендөнья күләмендә актуаль проблемалар да яктыртыла. Бу җәһәттән дә галимнәр публицистика, вакытлы матбугатның роле зур, дип бәялиләр. Мәсәлән, Н.Казакова бу хакта: “активлаштыручы фактор буларак, кризислы ситуациягә оператив рәвештә бәя бирергә, аны төбәк һәм локаль дәрәҗәдә хәл итү буенча конкрет чараларны күрсәтә”, – дип яза [Казакова, 1999: 4]. Татар вакытлы матбугаты әлеге вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә башкара аламы? Бүгенге көндәге кайсы аеруча актуаль мәсьәләләрне яктыртуга зур игътибар бирә? – Без әлеге сорауларга җавап эзләүне әһәмиятле, дип уйлыйбыз, чөнки аларга җавап табу татар басмаларының “дүртенче хакимият” вазыйфасын башкару дәрәҗәсен күрергә ярдәм итә. Эшебездәге тагын бер үзенчәлекле якка тукталасы килә. Ул – Башкортстандагы татар телле матбугат материалларын файдалану. Билгеле, татар-башкорт мөнәсәбәтләре соңгы

елларда киеренке халәттә тора, моңа ясалма факторлар да аз йогынты ясамый. Әмма шунысын да инкарь итеп булмый: 2010 елгы җанисәп буенча, Башкортстанның 25% ын татар халкы тәшкил итә. Димәк, дәүләт сәясәте, хакимият тоткан кыйбла турында сөйләгәндә, халыкның дүрттән бер өлешенә татар телендә мөрәҗәгать итү кирәк. Әлеге вазыйфаны башкалада берничә басма башкарса да, без эшебездә республика татарларының төп рәсми газеты “Кызыл таң” материалларына мөрәҗәгать иттек.

Фәнни эшнең максаты – милли вакытлы матбугатының татар халкы тормышындагы ролен ачыклау. Максатка ирешү мондый бурычларны чишүне таләп итә:

– татар вакытлы матбугаты тарихына кыскача күзәтү ясау;

– Татарстанда һәм Башкортстанда төп рәсми татар басмаларыннан саналган “Ватаным Татарстан” һәм “Кызыл таң” гәзитләрендә сәяси һәм икътисадый мәсьәләләрнең яктыртылыш үзенчәлекләрен чагыштырып өйрәнү;

– “Ватаным Татарстан” һәм “Кызыл таң” гәзитләрендә милли теманың яктыртылыш үзенчәлекләрен чагыштырып өйрәнү.

Эшнең объекты – хәзерге татар матбугаты, ә предметы – татар вакытлы матбугатында басылган мәкаләләрнең тема һәм проблемалары.

Эш дәвамында түбәндәге метод һәм алымнар кулланылды: тасвирлама, тарихи, гомумиләштерү.

Фәнни эшнең структур төзелеше: кереш, ике бүлектән торган төп өлеш, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлеге.

*Беренче бүлек. “Ватаным Татарстан” һәм “Кызыл таң” гәзитләрендә сәяси һәм икътисадый мәсьәләләрнең яктыртылыш үзенчәлекләре*

Вакытлы матбугатның сәяси, икътисадый вакыйгаларны бәян итүдә, вазгыятьне халыкка аңлатуда роле бик зур. Тикшерелә торган ике басманың да үзләрен иҗтимагый-сәяси гәзит итеп танытуы аларда илкүләм әһәмиятле вакыйгаларның объектив яктыртылышы тәэмин ителгән, дип уйларга җирлек бирә. Чынлыкта исә гәзит материалларын өйрәнү каршылыклы хисләр уята.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, ике басмада да авыл хуҗалыгы торышы белән бәйле язмалар шактый күләмдә урнаштырыла. Авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә кагылышлы язмаларның урын алуының да зур мәгънәсе бар, дип уйлыйбыз, чөнки татар халкы элек-электән җир кешесе булган, тамыры белән авылга, авыл туфрагына барып тоташкан. Авыл бетүен милләт бетүе белән тиңләштерүчеләр дә күп. Язмаларның күбесе үрнәк эшчәнләрнең язмышы турында сөйләүне күздә тота. Мисал рәвешендә “Ватаным Татарстан” газетасы журналисты З.Сәмигуллинаның Саба районында маллар табибы буларак танылган Якуп Габделбарый улына багышлаган “Аек табиб булачакмын” дигән язманы китерергә була (“Ватаным Татарстан, 10 апрель). Охшаш күренеш “Кызыл таң” гәзетендә дә күзәтелә. Мәсәлән, журналист А.Юлъякшина “Җирне бала кебек карый” язмасында яшь фермер Вадим Кинҗәбузов эшчәнлеген яктырта (“Кызыл таң”, 2017, 16 ноябрь).

Дөрес, “Ватаным Татарстан” гәзитендә авыл хуҗалыгы һәм икътисад, шулай ук сәламәтлек белән бәйле мәсьәләләрдә кискен, катгый фикер йөртүче журналистлар да бар. Шулар рәтендә без Рәшит Фәтхрахмановны атар идек. Гәзитнең агымдагы елның 6 нчы апрель санында ул сөт һәм сөт продуктлары җитештерү өлкәсендәге фальсификаторлар белән көрәшү проблемасының дәүләт күләмендә хәл ителә башлавын бәян итә. Журналист язмасының уңышлы ягы: ул дөньяны алсу күзлек киеп карауда ерак тора, хәтта бу очракта да дәүләтме, “алдар яки алыпсатар бизнес” җиңәрме дигән сорауга берьяклы җавап бирү мөмкин түгеллеген аңлата, чөнки ялган сөт авыл хуҗалыгын бөлдерүгә, ил икътисадына зыян китерүгә, кеше сәламәтлеге өчен куркыныч булуга карамастан, шул хисапка баючылар да күп. “Ткачев әфәнденең чыгышы ихлас булса, без инде мылтыклардан залп бирелгәнен: фальсификатны кибетләрдән алып чүплеккә ташыганнарын, аның өстендә трактор тәгәрмәчләре әйләнгәнен, намуссыз сату¬чы¬лар¬ның тикшерү изоляторларына ябылуын, закон чыгару¬чы¬ларның ашыгыч рәвештә азык-төлек базарын яклый торган кискен кануннар кабул ителүен, антимонополь оешмаларның сөт бизнесы

арадашчыларына кү¬тәрә алмаслык штрафлар салуын, табигый сөтнең иң түбән сатып алу бәясе 30 сумнан да ким була алмый дигән катгый норма кертелүен, ә пальма маена га¬дәт¬т¬ән тыш югары пошлина салынуын күзәтер идек", дигән нәтиҗә ясый журналист "Ватаным Татарстан", 2018, 6 апрель.

"Кызыл таң" басмасында беренче биттә даими рәвештә кыска күләмле хәбәрләр тәкъдим итеп килենә. Мәсәлән, газетаның 2018 елның 6 март санында кыска хәбәрләрдән "Медиафорумда – көнүзәк мәсьәләләр", "Тагын да нәтиҗәлерәк файдаланыйк!", "Безнекеләр булдыра!" һ.б. теркәлә. Күзәтүем күрсәткәнчә, хәбәрләрне укыган кешедә хакимияткә ышаныч формалаша: хакимият вәкилләре форумнарда, киңәшмәләрдә мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр, халыкны җиңүләргә рухландыралар, ә инде тискәре семантикага ия булган, тамашачыда борчу тудыра алырдай хәбәрләр, безнең күзәтүләребез буенча, газетада күзәтелми.

"Ватаным Татарстан" газетасында аналитикка тартымлык өстенлек итә, дигән нәтиҗәгә килдек. Мәсәлән, И.Хөснуллин мәкаләсендә Олимпия уеннарында җиңгән татар кызы Алинә Заһитованың казанышына илдә каршылыклы караш яшәве, мәсәлән, җиңүчене котлау урынына икенче урынга калган көндәшне юату тенденциясе күзәтелү җиткерелә. И.Хөснуллин үз фикерен дә ярымирония белән хәбәр итә: "Медведевага әле берничә ел элек үк Пхенчхан алтыны вәгъдә иттеләр. Аннан быелгы шау-шулы ярышта милли каһар¬ман ясарга теләделәр, Халыкара Олимпия комитеты тү¬рәләре алдына чыгардылар. Алинә исә балалыгы белән әнә шуларны аңлама¬ган, кү¬рәсең. Медведева рекорд куя, Заһитова исә аның күр¬сәткечен тагын да яхшырта. Ә бездә алай ярамый. Барысы да алдан әйтелгәнчә булырга тиеш" ("Ватаным Татарстан", 2018, 27 февраль).

Аналитиклыкка дәгъва иткән икенче язмага да тукталыйк. Ул "Кызыл таң" газетасының 2018 елның 27 февраль санында урын ала. И.Фазлетдинов В.Путинның үзгәртеп кору елларындагы башбаштаклыктан соң хакимияткә килү белән, Русия Армиясен тернәкләндерү, аякка бастыру, ныгыту, яңа куәтләргә чыгаруны дәүләт сәясәтендә мөһим өстенлек итеп билгеләвен ассызыклый. Алга таба автор Сирия, Украина вакыйгаларына туктала һәм мондый нәтиҗәгә килә: "күренүенчә, ил иминлеге, оборона нәтиҗәлелеге, дөньякүләм тынычлыкны саклау мәсьәләләре Русия җитәкчелегенең һәрдаим җитди игътибар үзәгендә кала. Нәкъ шуңа күрә дә бүгенге яшәешебез тыныч, имин, бернинди хәвефләр дә янамый, киләчәккә исә ныклы ышаныч белән багабыз. Бу җәһәттән алга таба да шулай дәвам итүен телисе генә кала (Кызыл таң, 2018, 27 февраль). Журналистның гомуми сүзләрдән торган, ватанпәрвәрлекне хәрби аспектта гына аңлаткан купшы телле мәкаләсендә аналитиклыкның өлеше аз, дип бәялибез, чөнки ул күтәргән катлаулы мәсьәләдә берьяклы караш кына була алмый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: "Ватаным Татарстан" да, "Кызыл таң" гәзитләре дә үзләрен иҗтимагый-сәяси басма позициясендә торуларына дәгъва итәләр. "Дүртенче хакимият" буларак, вакытлы матбугат илдәге сәяси-иҗтимагый вазгыятьне дәүләткә бәйсез рәвештә яктыртырга, ахыр чиктә, халыкта илдәге тормыш, вазгыять турында тотрыклы бер караш формалаштырырга тиешләр. Өлешчә әлеге вазыйфа "Ватаным Татарстан" басмасында башкарыла. Журналистларның теманы төрле яклап яктырту нәтиҗәсендә объектив картина хасил була. "Кызыл таң" гәзите, Башкортстанда чыга торган милли басма буларак, татарлар тормышында шулай ук зур роль уйный. Әмма әлеге басмада бары хакимият позициясен яктырту, оппозицион фикер йөртүгә урын калдырмау кебек кимчелекләр дә шактый сизелә.

*Икенче бүлек. "Ватаным Татарстан" һәм "Кызыл таң" гәзитләрендә милли мәсьәләнең яктыртылыш үзенчәлекләре*

Хәзерге вакытта көнүзәк мәсьәләләрнең иң әһәмиятлесе тел проблемасы белән бәйле булганга, гәзитләрдә милли теманың ктыртылыш дәрәҗәсен шушы аспектта карыйк. 2017 елның көзендә татар милләте алдында галимнәр (Р.Әмиров, И.Таһиров һ.б.) инде гасыр башыннан диярлек кисәтеп килгән мөһим мәсьәлә – тел проблемасы бөтен кискенлеге белән куела. Кыска гына вакыт аралыгында мәктәпләргә килгән тикшерүләр, башка сәяси чаралар нәтиҗәсендә татар телен ихтыяри укытуга калдыру мәсьәләсе уңай

якка хәл ителә. Әлеге вакыйгаларга бәйле рәвештә, татар телен гаиләдә генә дә үстереп саклап кула, дигән фикер дә, Республика җитәкчеләрен татар теленә ихтыяҗ тудыра алмауда гаепләүләр дә ишетелде, дәүләткә бәйсез оешмалар, төркемнәр Интернет киңлекләрендә татар теленә каршы һәм татар телен яклап эшчәнлекләрен киң җәелдереп җибәрәләр. Татарның төп басмасы, дәүләт карамагындагы "Ватаным Татарстан" газетасы да әлеге проблемага битарафлык күрсәтми, язмаларның бик күп өлеше шушы проблема белән бәйләнешле булуы күзәтелә. Гәзитнең агымдагы елның 10 нчы апрель санында Г.Гыймадованың "Безнең елар чак түгел" дигән мәкаләсе басыла. Ул Мәскәүдә старт алган "Дуслык күпере" фестивале эшчәнлеген яктырта. Журналист фестиваль гимны сүзләрен, чарада катнашкан атаклы кешеләрнең фикерләреннән өземтәләр китереп, тел проблемасына бәя бирә. Мәкаләдә фикерләр плюрализмы белән очрашабыз. Җырчы А.Галимов: "туган телнең ихтыярига калуы яхшы гамәл булмады. Туган телне оныту ул – аска тәгәрәү. Алга таба ничек барырга, ниш¬ләргә? Минем конкрет җава¬бым юк", дигән фикерне җиткерсә, Ә.Нургалиев телне саклап калу гаиләдән килә, дигән позициядә торуын әйтеп үтә; А.Сәгынбаева җыр, сәнгать аша телне саклау идеясен җиткерә. Г.Гыймадованың шәхси фикере, безнең фикеребезчә, язма башында бирелгән "ил белән күтәрелгән мәсьәлә тиз чишелә" дигән җөмләдә чагылыш таба. Шул рәвешле журналист алып барылган сәясәтнең астыртын эчтәлеген ачуга бирелмичә, халыкны битараф булмаска, халык фикеренең вазгыятькә йогынты ясый алуына ишарә итә.

Аңа кадәр, бигрәк тә мәсьәлә кискенләшкән 2017 елның көзендә "Ватаным Татарстан" гәзите әлеге темага игътибарын юнәлтә бирде. Басылган язмалардан Н.Шәрифуллинның "Юрист кызы ярдәм итәрме?" ("Ватаным Татарстан", 2017, 28 октябрь), "Янкилар тотса якаң..." ("Ватаным Татарстан", 2017, 1 ноябрь), "Татар көнен көткәндә" ("Ватаным Татарстан", 2018, 20 гыйнвар), Р.Бикмөхәммәтованың "Әни, елама, татарча сөйләшәбез" ("Ватаным Татарстан", 2017, 24 ноябрь), С.Мифтахованың "Павел, әле ярый син бар" ("Ватаным Татарстан", 2017, 24 ноябрь) һ.б. "Кызыл таң" гәзитенең 2017-2018 еллар тупланмасын өйрәнү басмада әлеге теманың читкә этәрелүен күрсәтте. Шулай да М.Вафинның "Журналистның куен дәфтәреннән" рубрикасында бирелгән "Әйдәгез халыкка хезмәткә! (Милли журналистика язмышы хакында уйланулар)" язмасы игътибарга лаек. М.Вафин Башкортостандагы татар матбугатында аз яктыртылган тема – милли журналистика, халыкта милли үзаң тәрбияләүне күтәреп чыга: "Без, татар журналистлары, үзебез ул милли үзаңны күтәрү өчен нәрсә эшлибез икән? Милли матбага шул телдә чыкканы өчен генә милли түгел. Ул, беренче нәүбәттә, халыкның милли ихтыяҗларына хезмәт иткәне өчен милли дип атала. Соңгы чорларда Русиядә тел, милли мәгариф мәсьәләләре кызу тикшерелде. Шул ук вакытта татар басмаларында эшләүчеләр, шул исәптән үзем дә, милли мәгариф, тел проблемаларын күтәрмәдек" ("Кызыл таң", 2018, 14 декабрь).

Кыскача әйткәндә, гәзитләрне милли тема яктыртылышы аспектында өйрәнүебез шуны күрсәтте: "Ватаным Татарстан" журналистлары мәсьәлә кискенләшкәндә, проблеманы укучы белән уртага салып сөйләшү ягында торалар, милләт алгарышы, үзаң үсеше, телне саклап калу мәсьәләләренә актив мөрәҗәгать итәләр, шактый кыю фикерләрен җиткерәләр. "Кызыл таң"да милли проблема бөтенләй диярлек күтәрелми, һәм әлеге факт журналистларның үзләре тарафыннан да кимчелек буларак кабул ителә.

*Йомгак*

Элек-электән вакытлы матбугат "дүртенче хакимият" дип саналган, әмма журналистлар үзләре дә татар басмаларының бу яктан көч-куәте зур булмавын ассызыклыйлар. Шулай да бүгенге көндә, хәтта татарча басмалар да ашарга пешерергә өйрәтү, эстрада йолдызларының тормышын тасвирлау ягына авышканда, иҗтимагый-сәяси басмалар арасында ил вазгыятен объектив яктыртучы гәзитләр бар. Без эшебездә ике иҗтимагый-сәяси басма материалларын чагыштырдык. Берсе – "Ватаным Татарстан" (җөмһүриятебездә чыга торган, әйдәп баручы басмаларның берсе), икенчесе – "Кызыл таң" (Башкортсан татарларының төп рәсми басмасы). Чагыштыру объектларының шул рәвешчә сайланышы татар телле басмаларның башкорт һәм татарлар өчен уртак булуы, Уфада чыга

торган басмаларның бар татар дөньясына аталып чыгуының бай тарихы булуы, шулай ук хәзерге вакытта “Башкортстан татарлары” мәсьәләсенең аерым игътибарга алынуы белән аңлатыла.

Ике басманы чагыштыру мондый нәтиҗәләргә китерде: бер үк позициядә торучы басмаларның эчтәлегендә ныклы аерма бар. “Ватаным Татарстан” сәяси, икътисадый, милли проблемаларны объектив яктыртса, “Кызыл таң” милли проблемаларга бөтенләй урын бирми, сәясәт, икътисад өлкәләрен ал күзлек аша гына тасвирлый. Дөрес, басмада Ш.Мәрҗани, Г.Исхакый иҗатлары турындагы язмаларга урын бирелә, алар милли үзаң формалаштыруда катнаша, әмма иҗтимагый-сәяси басма буларак, ул сәяси һ.б. өлкәләргә караган язмаларда дискуссияләргә урын калдырырга тиеш дип уйлыйбыз. Әлегә исә газета битләре укучыны иң якты, иң бәхетле, иң гадел илдә яшәвенә ышандыруны максат итеп куйган шикелле тоела.

Сүзне йомгаклап, шуны әйтер идек: татар телле басмалар электән еракларга таралып яшәгән татарларны берләштергә, туган проблемалар турында бергә уйлану мөмкинлеге биргән. Әлеге гадәт югалмасын иде.


*Кулланылган әдәбият*

1. Ватаным Татарстан. – 2017-2018 еллар саннары тупланмасы.
2. Кызыл таң. – 2017-2018 еллар саннары тупланмасы.
3. Гарифуллин В.З., Сабирова Л.Р. Татарская журналистика: исторический опыт и перспективы развития. – URL: https://cyberleninka.ru/article/v/tatarskaya-zhurnalistika-istoricheskiy-opyt-i-perspektivy-razvitiya; (дата обращения: 16.04.2018).
4. Казакова Н.В. Русская публицистика в социально-философском осмыслении приоритетных глобальных проблем: дис. ... канд. философ. наук. – Саранск, 1999. – 170 б.



**Ушакова Г.Г.**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## Айдар Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. (А.Хәлим иҗаты турында башка язучыларның фикерләре)

Фәнни - тикшеренү эшемнең темасы " Айдар Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге" дип атала.

Максатым - Айдар Хәлимнең иҗади мирасы белән танышу, аның татар публицистикасын үстерүгә керткән өлешен ачыклау. Аның иҗатын өйрәнгән әдипләрнең мәкаләләре белән танышу.

Татар публицистикасында Айдар Хәлим зур урын тота. Ул тормышны өйрәнә, кешенең психологиясенең иң катлаулы, иң тирән катламнарына үтеп керә.

Әле алтмышынчы елларның икенче яртысында төрле газеталарда чыккан дистәләрчә чәчмә һәм фото – репортажлары, әңгәмәләре, очерклары, язган әйберен бик өйрәнеп, тирәннән белеп язуы күзгә ташлана.

Айдар Халимнең публицистикасының үзенчәлеге – аның сюжетлы булуында. Ул укучыны үзе белән бергә йөртә, аны үзе белән бергәләп таулар “шартлаттыра”, Чернобыльнең буш авылларыннан уздыра, урыс-чечен сугышы фронтлары буйлап йөртә. Әдипнең иҗат гомерендә публицистика, ил-дөнья вакыйгаларына карата кайнар сүзне батырып әйтә белү маһирлыгы — үзенә аерым бер урын алып тора.

Җитмешенче елларда “Шартлау”, “Туган җирем – гөл арасы”, “Каһарманлыкка юл” “Язмышлар ярында” һәм башка дистәләгән очерклары, кечкенә повесть, кечкенә романнар яза.

Әдипнең егерменче гасырның ахыргы, яңа гасырның беренче елларында иҗат ителгән күп санлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Иманем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш» (2002) кебек китаплары да көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар.

Туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китаплары: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книгапечали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997).

Бу әсәрләрдә Айдар Хәлим татар һәм чәчән халыклары, аларның намуслы шәхесләре алып барган катлаулы, каршылыклы сәяси көрәшнең документаль елъязмасы, аның иң тәэсирле сәхифәләре белән таныштыра.

Публицистика өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен А.Хәлим 2003 елда Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый, Бөгелмә җәмәгатьчелегенең мәгариф буенча Һ.Атласи исемендәге әдәби бүләгенә (1995) лаек була.

**Хаертдинова Л. А.**
**югары квалификацион категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**“41 нче гомуми белем бирү мәктәбе”**

## Сирень Якупова иҗатында туган як мотивлары

Сирень Мөхиббулла кызы Якупова 1961 елның 26 августында Татарстан Республикасының Әлмәт районы Түбән Абдул авылында туа. 1978 нче елда Елховой урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Әлмәт төзелеш техникумында белем ала. Нәкъ шул елларда районның «Хезмәт байрагы» газетасында аның беренче шигырьләре дөнья күрә. Хезмәт юлын Әлмәт шәһәрендә башлап җибәрә.

1982 елда Сирень Якупова Чаллы шәһәренә килә һәм, башта КамАЗның агрегат, аннан соң кече литражлы автомобильләр җыю заводларында эшли. Шушы елларда аның шигырьләре, язмалары КамАЗның «Нур» газетасында даими басылып килә.

Туксанынчы еллар азагында Сирень Якупова «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри башлый. 2003 нче елда «Йолдызлы уйлар»исемле тәүге китабы чыга. 2006нчы елда шагыйрә «Шәһри Чаллы» газетасы редакциясенә эшкә килә һәм 2013 нче елга кадәр шунда хезмәт куя. Шул чорда шәһәр һәм республика матбугатында аның бик күп кенә шигырьләре, хикәяләре, язмалары дөнья күрә, китаплары чыга. «Җирдәге җан ияләре берсен-берсе кабатламый. Уникаль дисәләр дә, мин үзем бик иртә дөньядан киткән әти-әниемнең турыдан-туры дәвамы, кабатланмышыдыр, ахрысы. Мәрхүм әтием бик оста рәсем ясаган булса, әнием җор телле, нечкә күңелле, шигъри җанлы иде. Сурәт белән язу осталыгына ия булуым белән мин тулысынча аларга бурычлы» - дип искә ала шагыйрә.

Сирень Якупова - 2011 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Хәзерге көндә Чаллы язучылар оешмасында эшли.

Шагыйрә Сирень Якупова зәвыклы, затлы шигъриятне үз итүчеләргә ят исем түгел. «Йолдызлы уйлар», «Ике гасыр баласы мин», «Яшәү сере», «Өстәгеләрдән дә өстә» китаплары, матбугатта даими дөнья күреп килгән шигырь-хикәяләре һәм үз фәлсәфәсе, гаҗәеп табышлары белән укучылар күңелен күптән яулады. 2014нче елда, укучыларын сөендереп, «Кар юлы» шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. 2015нче елда «Кар юлы»шигырьләр җыентыгы өчен Сирень Якупова бик зур мәртәбәле бүләккә Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә лаек булды.

«Йолдызлы уйлар» - беренче җыентык. Китап 2003нче елда Яр Чаллы нәшриятында басыла. Китапта авторның дөньяга, тормышка карашы, кешеләргә һәм туган җиргә мәхәббәте чагыла.

« Туган җиргә – үз җиремә кайттым.

Рәхәтлеге шушы кайтуның!
Арган йөк атыдай, тугарылып,
Болын түшәгендә ятуның!
Җанны ярып үлән исе керә,
Чәчәк төсе тула күзләргә.
Җилфер-җилфер күбәләкләр куна
Чыктан юешләнгән тезләргә » . *«Кайту»*

Һәр шагыйрь үз иҗатында үткәнне, бүгенгене, киләчәкне чагылдырырга омтыла, чын шигърият шулай гына яши ала, шуның белән генә кадерледер ул. Сирень Якупова шигърияткә зур җаваплылык белән килә, укучы кабул итәрлек әсәрләр генә иҗат итәргә тиешлеген аңлап эш итә. Ул туры фикерле, гадел шагыйрә, ул күңеле кушканча яза, иҗат итә.

«Уйламыйча әйткән чагым бардыр,
Уйламыйча язган чагым юк.
Әйткәннәрне кире ала алсам,
Язганнарны кире алу юк! » -дип яза ул үзенең шигырендә.

Сирень Якупова - үзенчәлекле шагыйрә. Сәясәт, сугыш, гомумән, заманның караңгы яклары турында язарга яратмый ул. Шагыйрә шигырьләрендәге ихласлык, тормышка, туган якка мәхәббәт хисләре тирәннән тибеп чыккан, шуңадырмы, алар һәр йөрәккә барып җитәрдәй көч-кодрәткә ия. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар:

«Язгы иртә, ә мин гүя сабый,
Таң җиленнән үргән бишектә
Имеп ятам сөтле яшеллекне,
Кош сайравын гына ишетеп ».

Шагыйрә һәр сүзнең тәмен, ямен тоеп, ихлас яза. Бүгенге кырыс заманнан яктылыкка, сафлыкка омтыла.

Гасыр чиген атлап 21 гасырга аяк басканда, Сирень Якупованың «Ике гасыр баласы мин» дип аталган яңа китабы аваз сала. Әлеге исем астында чыккан китабы язучы һәм шагыйрь, Абдулла Алиш исемендәге бүләк иясе Рәшит Бәшәрнең сүз башы белән дөнья күрде. «Сирень Якупова шигырьләре ирләрчә кырыс. Яшь түгү, уфтанулар юк аларда. Ул шигырьгә охшаш такмаклар түгел, шигъри мәрҗәннәр тезә. Җанны җылыта торган, сулышны иркенәйтә торган чын шигъри мәрҗәннәр... Ул, минемчә, рухы белән урыс шагыйрәсе Анна Ахматовага якын... » *Рәшит Бәшәр*

«Яшәү сере» - шагыйрә Сирень Якупованың Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән беренче китабы. Язмыш җилкәне ак шикәрдән аклы, хыяллары таулардан да биек шагыйрә укучыга бер-бер артлы яшәү серен ачарга керешә.

« Сандыгымда өч күлмәк,
Өчесе дә ап-актан.
Ак биләвем, туй күлмәгем,
Ак кәфенлек... азактан. » *« Сандыгымда өч күлмәк»*

«Сандыгымда өч күлмәк» шигыре кешенең туганнан алып соңгы мизгеленә кадәр яшәгән гомере өч күлмәккә сыеп беткәнен аңлап язылган. Шигырьне укыгач гомер көзенә кергән һәр кеше туу, яшәү, үлем, аклык, караңгылык төшенчәләре турында тирәнтен уйлана башлый.

Хисләрнең төзек хәрәкәттә, эзлекле булуы шигырьне җегәрле итә. Беренче шигырьдән башлап, китап ахырына кадәр укучыны шушы төзеклек, хисләрнең чынлыгы озата. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар.

Яшәүнең сере нидә? Яшәү сере шигырьдән шигырьгә ачыла бара. Сирень Якупова исә кабаланмый, каударланмый һәм иң мөһиме -кабатланмый сер чишә дә чишә. Татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге, туган тел, ил язмышы турында уйланганда шагыйрә үзенең гүзәл холыклы, бу мәсьәләдә үз үлчәме, үз фикере булган, милләтне чын күңелдән кайгыртучы шәхес икәнен күрсәтә.

Язучы, шагыйрь,  Гаяз Исхакый  исемендәге әдәби бүләк иясе Факил Сафин китапка бәяләмәсендә мондый сүзләр яза... «Сирень Якупова тормышка, уйлап тапкан шигъри дөньясына кечкенә итеп уйган тәрәзә аша түгел, кайнап торган тормышка зур тәрәзә - үзе күргән, үзе кичергәннәр аша карый белә. Дөнья кеше алдына нинди генә сынаулар китереп куйса да, ул кеше биеклегендә кала алырга тиеш... ». «Әйе, дөнья кырыс. Безнең пәрдәсез күңелләргә, ялангач җаннарга замананың күзе дә тия, сүзе дә тия. Йөрәкләр тоташ яра дисәк тә ялгыш булмас. Ләкин, шулай да, мин үземне тормыш сынауларын сынмый-сыгылмый үтәрлек көчле шәхес дип саныйм. Ни дисән дә, мишәр кызы бит..»

«Гөрләп торган Биләр ягыннан мин,
Җырлап торган мишәр ягыннан.
Булыр микән миндәй шушы якны
Янып сөйгән,өзелеп сагынган.
Булыр микән миндәй горурланган,
Мишәрчә сүз укып шигырьдә.
Кандалыйлар,Туфаннарга якташ
Мишәр кызы бит дип үзем дә»,- дип яза С.Якупова «Ана телем» шигырендә. Шагыйрә йөрәгендә кайнарлыгы сүрелмәс газиз, тылсымлы бер урын бар. Ул әти-әнигә, туган якка, туган нигезгә булган изге хисләрдән кабынган мәңге сүрелмәс учакны хәтерләтә.

« Кычыткан өзәм даруга,
Кулым түзә чагуга.
Бармаклар ни, йөрәгемнең
Уттай янган чагы ла...
Туган авылым кычытканы,
Пешер җанымны, пешер
Ялантәпи балачакны
Елатып искә төшер».  *« Кычыткан»*

Язмышын шәһәр белән бәйләгән авыл кызы, балачагын, яшьлеген, туган авылын сагынып, юксынып шигырьләр иҗат итә.

«Авылыма алып кайтыр юл –
Юлларның юлыдыр ул.
Һәр чокыры мөлдерәмә
Сагыну тулыдыр ул ».  *« Авылыма алып кайтыр юл»*

Шәһәрдә торса да, җаны белән авылда ул. «Таш пулат бар, корыч ат бар, ә күңел - ярлы, ятим», дип моңланган авыл агайлары, авыл апалары янында аның күңеле.

«Шәһәр урамнары төз дә соң,
Күңел урамнары сагышлы», - дип җырлаган шагыйрә өстәгеләрдән дә өстәге Ходайга таяна, шул аңа яшәргә көч, язарга илһам бирә.

Туган як, туган җир дигәндә ни өчендер шәһәр түгел, ә авыл һәм аның бер өлеше булып торган табигать күз алдына килә. Һәрберебезнең дә тамырлары барыбер авылга барып тоташа. Авылның иң күркәм сыйфаты булып аның табигатьтә урнашуы тора. Һәр кешенең үз ягын, аның матур табигатен, суларын, күлләрен мактарлык җирләре күп.

«...Туган йортым...
Менсәм аның түбәсенә,
Бер шигем юк, түбәм күккә тиясенә.. »

*«И түбәннән агылалар бу болытлар»*

«Туган йортым» дигән шигырендә дә шагыйрә туган авылының матурлыгына мәдхия җырлый.

«Бу кадәрле якын булыр икән
Гади генә авыл ызбасы!
Туган йортым,
Син — Мәккәсе җанның,
Күңелемнең изге кыйбласы....
Бар хисләрем, бар рәхмәтем сиңа,

Туып үскән нәни бер оям.
Киң дөньялар кысан, тар чагында
Сиңа әле һаман мин сыям». *«Туган йортым »*

«Ике меңгә якын йортлы авылыбызны урталай бүлеп аккан тирән сулы, тиз агышлы Шушма елгасы, шомыртлы әрәмәләр, болыннар, Хөббәт бабам юлын ачкан Олы болын чишмәсе – бар да күңелгә якын, кадерле»,- дип яза Сирень Якупова.

«Туган җирнең төтене дә татлы...
Минем өчен
Бу сүзләрдә булгандыр ла хаклык...
Учаклар сүнмәгән,
Мичләр сүтелмәгән,
Самавыр гөрләгән чакны...» *« Туган җирнең төтене дә татлы... »*

2011нче елда С.Якупованың «Өстәгеләрдән дә өстә» дигән китабы басылып чыкты. Китапка шигырьләр, хикәяләр, эсселар тупланган. Шагыйрә бу китабында үзенең күңеленә якын булган бер теманы да читләтеп үтми. Шәһәрдәге күптөрле проблемалар турында язамы шагыйрә, бүгенге яшәешебез хакында уйланамы, каләмдәшләре иҗатын бәяләп сүз әйтәме –һәр сүзе, һәр гамәле халык язмышына килеп бәйләнә. Уйландыра, битараф булмаска чакыра.

***Шагыйрә турында иҗатташ дуслары:***

«Сирень Якупованың шигырьләрендә мин шактый микъдарда серле табышларга тап булдым дип әйтә алам. Нинди куаныч! Ниндидер бер шәһәр-төбәкнең шагыйрьле булуы- ул серле булу, бәхетле булуга тиң. Андый каләм ияләре белән аерым йорт, аерым гаилә тәрәзәсе генә түгел, барлык шәһәр, хәтта милләт яктыра. Милләт җылына». *Айдар Хәлим*

«Сирень Якупова - шигърияттә үз урынын тапкан талант иясе. Аның иҗатында күтәрелгән төп мәсьәлә - ил һәм халык язмышы. Ул шигырьләрендә - авылга, кешеләргә, дөньяга һәм туган җиребезгә булган мәхәббәтен чагылдыра, язмышка, җәмгыятькә үз карашын белдерә, шуны тормышчан дөреслек белән, кырыс һәм төгәл детальләр аша табигый итеп сурәтләргә омтыла ». *Әлфия Ситдыйкова*

«Сирень Якупова шигырьләрендә никадәрле фәлсәфи фикер, һәр күңелне тырнап ала торган темалар! Шагыйрә иҗатының киңлегенә, аның күңел диңгезенең тирәнлегенә сокланмый мөмкин түгел. Ул һәр яңа көнгә, мәхәббәткә мәдхия җырлый, туган якны, әниләрне сагынып елый, туган теле өчен кайгырып уфтана, вакыт-гомернең кыскалыгына аһ ора, милли гореф-гадәтләребезнең юкка чыгуына сызлана, яшьлеген уйлап газаплана. Җиребезне кадерсезләгәнгә борчыла*...». З.Хәлимов*

**Файдаланылган әдәбият**


1. Әхмәтгалиева, А. Сирень Якупова: «Серле тормыш бары җирдә генә» [С.Якупованың иҗаты турында]//А. Әхмәтгалиева.- Шәһри Чаллы – 2014. – 24 октябрь. -Б.5.
2. Бәшәр, Р. Сүз бәясе: [С.Якупованың «Өстәгеләрдән дә өстә» китабы турында] // Р.Бәшәр. - Шәһри Чаллы – 2011. – 18 май.- Б.4.
3. Гасыймова, Р. «Яңа гына ачтым күземне...» : [С.Якупованың гаиләсе, иҗаты турында]//Р.Гасыймова.- Шәһри Чаллы – 2000. – 13 май.
4. Журналның Сирень Якупова иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2014. – № 9.
5. Сафин,Ф. Ак җилкәнле шигырьләр: [С.Якупованың «Яшәү сере» китабы хакында уйланулар] // Ф.Сафин. - Шәһри Чаллы – 2009. -4 март.- Б.5.
6. Ситдыйкова, Ә. Шигырьләрендә җан авазы: [С.Якупованың иҗаты турында] //Ә. Ситдыйкова.- Шәһри Чаллы – 2006. – 20 декабрь.- Б.3.
7. Хәлим,А. Шигърият сере: [С.Якупованың «Яшәү сере»китабы турында] //А.Хәлим.-Шәһри Чаллы.-2010.-15 декабрь.-Б.5.
8. Якупова,С. Яшәү сере: шигырьләр / С.Якупова. –Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. – 127 бит.
9. Якупова, С. Өстәгеләрдән дә өстә: шигырьләр, хикәяләр, эсселар // С.Якупова .-

Яр Чаллы, 2011.-168 бит.
10. Якупова,С. Кар юлы: шигырьләр / С.Якупова. –Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 223 бит.

**Хаҗиева Р. Х.,югары квалификацион категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Яр Чаллы шәһәренең “30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

## Татар әдәбияты һәм кино сәнгате
## (Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте һәм фильмы мисалында)

**Кереш**

Татар әдәбиятын, ФДББС таләпләре кушканча, универсаль уку гамәлләре формалаштыру, бигрәк тә, метапредмет нәтиҗәләренә ирешү максатыннан укыту турыдан-туры укучыларның шәхесен һәм дөньяга карашын формалаштыру белән бәйләнгән. «Әдәбият» сүзенең нигезендә «әхлак» төшенчәсе ята. Әдәбият укучыларны тормышка, яшәргә өйрәтә. Дәрестә яңача ачышлар туа, экспериментлар үткәрелә, проблемалар чишелә, хаталар ачыклана, иҗади эзләнүләр алып барыла, уңышлы нәтиҗәләр ясала.

Дәрес ул - укучы өчен үсеш вакыты: кызыклы һәм мавыктыргыч “Белем дөньясына” сәяхәт итү, фән баскычларыннан биеклекләргә менү, аның серле һәм таныш булмаган сукмакларыннан бару. Укытучы һәр дәресенә зур әзерлек белән керә, кечкенә шәхесләрнең интеллектуаль, социаль, психик, физик һәм рухи сфераларын үстерүгә зур көч куя һәм махсус шартлар булдыра. Замана укучысы өчен үзеңдә нинди кыйммәтләрне булдыру, кемгә ышану кебек сорауларга җавап табу бик катлаулы. Бу очракта аларга гомумкешелек кыйммәтләренә өстенлек биргән татар әдәбияты һәм кино сәнгате ярдәм итә ала.

Ленин бабайның: ”Укырга, укырга һәм укырга!” (Учиться, учиться и учиться!) - дигән шигарәсен һәркем белә. Тик юлбашчының: «Безнең өчен сәнгатьнең иң мөһим юнәлеше – кино», -дигәнен күпләрнең ишеткәне дә юктыр, бәлки. Бу сүзләр бүген дә актуаль. Укытучының заманча шартларга нигезләнеп эшләнгән нәтиҗәле алымнарын дөрес куллана белүе, укучыларда фәнгә карата уңай мотивация тудыра алуы – шундый таләпләрнең берсе. Шул рәвешле, иҗади эшемнең ***актуальлеге*** укытучының әдәбият дәресләрендә нәтиҗәле алымнарны тиешле дәрәҗәдә куллануы укучыларның татар әдәбиятын, кино сәнгатен өйрәнүгә ихтыяҗ һәм теләге (мотивация) тууы, укучыларның әлеге предметтан өлгерешләре артуы, хәзерге җәмгыять шартларында үзләрен туган телебездә дөрес һәм иркен аралаша алучы, әхлакый яктан өлгергән шәхес һәм һөнәр ияләре буларак реализацияләргә сәләтле булып җитлегүе белән бәйлелектә торуыннан гыйбарәт. Хезмәтне язганда үземнең эш тәҗрибәмә таянуымны да ассызыклап китү зарур.

***Иҗади-эзләнү эшенең максаты*** – укучыларның белем һәм күнекмәләрен, зиһенгә алу дәрәҗәсен арттыру, әзер мәгълүматны кулланучы позициясеннән уку-укыту процессының актив катнашучысы позициясенә басарга этәрү максатын күздә тотып, дәресләремдә куллану нәтиҗәле дип табылган алымнарны барлау һәм гамәлдә куллануга кертү.

***Бурычлар:***

- Әдәбият дәресләрендә аеруча нәтиҗәле дип танылган алымнарны өйрәнү;
- дәресләрдә нәтиҗәле дип табылган алымнарны кулланып, укучыларның гамәли күнекмәләрен (күзәтү, ситуацияне анализлау һ.б.) һәм сәләтләрен (инициативалылык, коммуникативлык) үстерү юлларын барлау.
- Әдәбият дәресләрендә кино сәнгатенең тоткан урынын ачыклау.

***Иҗади-эзләнү эшенең предметы*** – татар әдәбияты дәресләрендә фильмнар буенча эшләгәндә кулланыла торган алымнар.

***Иҗади-эзләнү эшенең гамәли әһәмияте*** хезмәттә китерелгән материалның әдәбият дәресләрен алып баручы мөгаллимнәр өчен чыганак булып тора алуы белән аңлатыла.

***Иҗади-эзләнү эшенең*** структурасы кереш, ике бүлектән торган төп өлеш, йомгаклау, кулланылган әдәбият исемлегеннән, кушымталардан гыйбарәт.

**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. КИНО СӘНГАТЕНЕҢ ТАРИХЫ**

Кино сәнгатенең тарихы турынданиләр беләбез? Татар әдәбияты һәм кино сәнгате тыгыз бәйләнештә тора. Беренче карашка татар әдәбиятын кино сәнгате белән янәшә куеп карау һәм алар арасында ниндидер бәйләнешләр эзләү сәер һәм ясалма шикелле тоела. Шулай да кино сәнгате татар әдәбиятына төрле юллар белән, төрле юнәлештә тәэсир итеп тора. Кинематографиянең үсүе әдәбият белән киноны тагын да ныграк туганлаштыра. Кино сәнгатен татар халкының җиңел кабул птүе нәрсә белән аңлатыла? Бу күренеш, бәлки, татар халкының сурәтле фикерләве кинематографик фикерләүгә бик якын булуы турында сөйлидер. Чыннан да, халык җырларына гына мөрәҗәгать итеп карыйк. Аларда табигать күренешләре белән лирик геройның рухи халәтен янәшә кую, символлар, метафоралар белән эш итү, яки сөйгәненең портретын «эре планда» сурәтләү аз очрыймыни?

Бакча артларында салкын чишмә,
Тирә-ягын тал алган ла,
Яфраклары саргайган.
Син җан кисәгем хәсрәтендин
Ике күземне кан алган ла,
Йөз генәем саргайган.
Су янына баралмадым,
Басма өстенә баса алмадым;
Теләсәм дә, соралсам да,
Сөйгәнемә баралмадым.
(«Сөйгәнемә баралмадым»)

Шушындый поэтик принципка корылган җырлар татар кешесе өчен һич тә чыгарма яки гадәттән тыш күренеш түгел.

С. Вельтман «Көнчыгыш киносының бурычлары» исемле китабында Н. Наримановның түбәндәге сүзләрен китерә: «Логик фикерләүләргә караганда образларга күнеккән Көнчыгыш халыкларында кино халыкны алдан дәвамлы төстә хәзерләүне сорамый торган пропаганда чарасы булып тора. Көнчыгыш крестьяны экранда сурәтләнгән күренешләрне реаль чынбарлык итеп кабул итә» (С. Вельтман. Көнчыгыш киносының бурычлары (рус телендә) М, 1927, 5 бит.)

Әлбәттә, кино — катлаулы сәнгать. Аны бөтен тирәнлеге белән аңлау өчен билгеле бер хәзерлек тә, кинематографик культурага ия булу да кирәк. Иҗат процессында язучыга бу хәлне искә алмыйча ярамый хәзер. Халыкның әдәби зәвыклары кино тарафыннан да тәрбияләнүе, оптик күрү культурасының нык үсүе язучылар алдына да искергән традицияләрдән кыюрак котылуны, укучыга тәэсир итәрдәй поэтик алымнарны кыюрак эзләүне сорый. Кино сәнгатенең үсеше, шул рәвешчә, татар әдәбияты һәм язучылары алдына яңа бурычлар, яңа эстетик таләпләр куя. Татар әдәбиятында да сценарийлар иҗат итү буенча аерым омтылышларга 20—30нчы елларда ук беренче буразналар салынган. Сценарий — фильмның нигезе. Безнең илдә һәр картинаның титрын сценарист исем-фамилиясе белән башлап җибәрү гадәте юкка гына түгел. Ул фильмның әдәбиятка нигезләнеп тууы турында да сөйли. Сценарий режиссер өчен материал гына түгел, ул, барыннан да элек, тулы кыйммәткә ия. Хәзерге вакытта исә язучыларыбызның дистәләгән әсәрләре буенча фильмнар төшерелде. Г.Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр”, А.Хәлимнең “Өч аяклы ат”, Х.Ширмәннең “Ерактагы йолдызым” һәм башка китаплар буенча фильмнар.

Иң беренче татарча кино 1927нче елда төшерелгән. Татар крестьяннарының Пугачев хәрәкәтендә катнашулары турындагы бу фильм “Булат-Батыр” дип атала. Фильмны 30дан артык илдә күрсәткәннәр.

Әдәбият дәресләрендә куелган максатлардан чыгып, нәфис фильмнарны тулысынча яки берәр фрагмент өлешен карарга була. Бу укытучының әдәби әсәр өстендә эш системасын ничек күзаллавына һәм эш алымнарына бәйле:

1. Бирелгән әсәрдәге һәм фильмдагы проблеманы формалаштыру;

2. Фильмда күтәрелгән проблемага карата режиссёр һәм язучы позициясенең чагылышы;
3. Фильмда күтәрелгән проблемаларны тормыш тәҗрибәсеннән яки карап белгәннәреннән дәлилләр китереп аңлату;
4. Фильмның мәгънә ягыннан бөтенлеге, эзлеклелеге.
5. Фикер төгәллеге һәм тел байлыгы;

Фильмда нәрсә турында, нинди проблема күтәрелә? Язучы күтәргән проблеманы режиссер да күреп һәм аңлап, кайсы эпизодлар аша халыкка җиткерә ала? Күтәрелгән проблема буенча укып белгәннәрдән дәрестә әдәби әсәрне анализлау барышында түбәндәге бурычлар куела:

-укучыларның танып-белү һәм текст белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен активлаштыру;

-әдәбият теориясеннән һәм әдәбият тарихыннан булган белем һәм күнекмәләрне үстерү.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ «ӨЧ АЯКЛЫ АТ» ПОВЕСТЕ ҺӘМ ФИЛЬМЫ.

### 2.1. АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ «ӨЧ АЯКЛЫ АТ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА ФИЛЬМ ТАРИХЫ.

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» автобиографик повесте буенча шушы ук исемдә режиссер Нурания Җамалиева тарафыннан нәфис фильм төшерелде. Фильмның сценарий авторы Айдар Хәлим, операторы Эдуард Ситдыйков Фильм татар телендә булып, русча субтитрлар белән бара. Инде еракта калган 1948 нче ел вакыйгалары хакында сөйли торган әлеге фильм Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә «Иң яхшы операторлык эше» номинациясендә җиңү яулаган иде. Фильм 1948 нче ел вакыйгаларын тасвирлый. “Өч аяклы ат” – колхозлашу чорында кешене генә түгел, аның малын да (бу очракта биясен), сыйнфый дошман итеп, тумаган колыны-ние белән бергә, күмәк казанга салу. Куелганы бар идеме бу проблеманың дөнья әдәбиятында болай итеп? Юк иде!

### 2.2. АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ «ӨЧ АЯКЛЫ АТ» ПОВЕСТЕ БУЕНЧА ФИЛЬМНЫ ДӘРЕСЛӘРДӘ КУЛЛАНУ.

Фильмнан фрагмент караганнан соң, танып белү эшчәнлеге Ә.З.Рәхимовның Иҗади үсеш технологиясе нигезендә оештырыла. ИҮТ нең (иҗади үсеш технологиясе) үзенчәлекләре түбәндәгеләр:

- Уку эшчәнлеге төркемнәрдә оештырыла.
- Уку мәсьәләсен укучылар үзләре куя һәм адымлап, биремнәр чишү аша башкаралар.
- Нәтиҗәләр модельләштерелә.
- Өй эше өч дәрәҗәдә бирелә ( мәҗбүри, ярымиҗади, иҗади)
- Һәр бирем саен үзбәя куела.

Гадәттә, әдәби әсәр өстендә эшли башлаганчы, зур булмаган фрагментны укучыларда эмоциональ хисләр булдыру, кызыксындыру максатыннан чыгып күрсәтергә мөмкин. Бу алым тарихи мохит һәм көнкүреш нечкәлекләрен төгәл җиткерүче фильмнар өчен нәтиҗәле. Фильмның аерым эпизодлары әдәби әсәрләргә иллюстрация кебек күрсәтелергә мөмкин һәм алар анализлау элементы булып та хезмәт итә. Бигрәк тә язучы әйтәсе килгән фикерне кино теленә күчергәндә ярдәм иткән детальләргә игътибар итәргә кирәк. Болар: актерларның гримнары, костюмнары, жестлары һәм мимикалары, интерьер һәм пейзаж. Мөһим момент булып язучы әсәрендәге детальләргә кинода режиссёрның яңаларын өстәве яки алып ташлануы турында әңгәмә кору тора. Әдәби әсәрнең идеясе һәм эчтәлегенә зыян килмәгәнме? Шушы һәм башка сорауларга җавап табу өчен укучылар төркемнәрдә эшлиләр. Һәр төркем үзенә куелган бурычларны башкара. Әсәр өстендә эш фәнни-тикшеренү эше юнәлешендә бара. Бер төркем – символларны, икенчесе – саннарның әсәрдәге вазифасын, өченчесе – образлар бирелешен, һ.б. тикшерәләр. —

Укучылар, әйтегез әле, вакыйгалар кайда, кайсы чорда бара?

— Игътибар итегез: язучы малай кунакка килгән Муса бабайларның йортларын ничек сурәтли? Шул юлларны табып укыгыз. (Күлләр акбуры белән агартылган өйдә, шактый оста, хәстәрлекле кул белән бөтәйтелгән абзар-курада, мунчада — барысында да төзеклек һәм чагыштырмача муллык сизелә. Лапас астында кышкылыкка бөгеп куелган чана

табаннарын, тәгәрмәчләрне күреп, малай бабасының тракторчыдан бигрәк балта остасы икәнлегенә үз күзләре белән ышанды. Димәк, Зөлхиҗә әби белән Муса бабай мулрак тормышта яшиләр.) Фильмда режиссёр ничек күрсәтә? Фильмны караганнан соң сорау куела: ни өчен ат өч аяклы?

- Ат Кәбир тормышында нинди роль уйный?
    - Әсәрдә атның аягы авыртуның сәбәпләре ничек аңлатыла? (Бүре белән якалашкан чакта, ат аягын утлыкка тыгып сындыр-ган, я булмаса буын сеңерен өздергән булырга тиеш. Икенчеләр фараз итүенчә, ат — кешедән һәм эттән кала иң акыллы һәм иң сизгер җан иясе: ул абзарда малларны пыран-заран китергән җанварның чынлап та бүре икәнлеген исеннән сизгән һәм, үз-үзенә урын таба алмый, аранны җимереп, мал-туарны коткары-шырга чыккан, имеш.).

Әлеге вакыйганы Кәбирнең әнисе бик авыр кичерә. Малай атның исән калуына бер яктан шатланса, икенче яктан атның аягы авыртуына бик борчыла.

- Кәбирнең күңел халәтен сурәтләгән өзекне әсәрдән табып укыгыз. Фильм белән чагыштырыгыз.(Кәбирнең миендә нәрсәдер ялт итеп яктырды, анда гүя яңа кояш кабынды. Бу яктыда бар дөнья ап-ачык күренгәндәй итте. Җир белән күк, тау белән үзән, ут белән су арасында гына түгел, хәтта үзенең йөрәгендә дә ниндидер төп — гомерне күтәреп торган авырлык җебе өзелгәндәй итте, һәм ул җеп тиз генә ял-ганмаячак иде.) Кәбирнең әнисенә карата мөнәсәбәте нинди? Укучылар фикерләр әйтәләр. Нәтиҗәләрне модельләштереп күрсәтәләр. Проблемалы ситуацияне чишкәндә, төрле вариант җаваплар тыңлана, ләкин укытучыларга балаларны сабыр итеп тыңлап бетерү, идеяләрне хуплый белү, мактап үстереп тору сыйфатлары җитеп бетми. Һәр идеяне хупларга, дусларча бәяләргә, отышлы вариантларны укучыларның үзләренә сайларга ирек бирергә кирәк. Бу алым безне үзебезне дә яңача эшләргә өйрәтә, дип саныйм мин.

**ЙОМГАКЛАУ.**

Фильмнарны системалы файдалану тәҗрибәсе түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә: бу алымнар әдәби әсәрләрне анализлау күнекмәләре үсешенә этәргеч ясый, тәнкыйди фикер йөртергә, кино һәм видеофильмнарны бәяләп кабул иттертә, шулай ук китап укучыларның кызыксынуларын активлаштыра, укучыларның игътибарын язучының шәхесенә һәм иҗатына җәлеп итә. Хәзерге заман укытучысы шәхес үсеше өчен шартлар тудырырга һәм бу процесс белән идарә итә дә белергә тиеш. Шул очракта гына мәктәп тәмамлаучылар фикер йөртергә сәләтле, төрле хәлләрдә югалып калмый торган кешеләр булып, мөстәкыйль тормышка юл алалар.

Дәреснең һәр этабын кызыклы итү, укучыларны җәлеп итәрлек итеп оештыру - укытучының бурычы. Дәресләрдә әлеге алымнарны куллану түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирде:

- укучыларның сөйләм теле яхшырды, сүзлек запасы баеды;
- татар мәдәнияте, кино сәнгате, әдәбияты турында күзаллаулары үсте;
- укучыларның иҗади эшчәнлеге артты;
-иң мөһиме - укучы дәрескә теләп йөри башлады.

Ә теләк булган җирдә мөмкинлек арта, нәтиҗә дә яхшыра. Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур.

Иҗади эшләүче укытучы беркайчан да дәреслектәге күнегүләр белән генә чикләнми, ул үз укучыларының сәләтенә һәм мөмкинлекләренә туры килә торган биремнәрне, методик алымнарны башка дәреслек һәм кулланмалардан да сайлап ала. Шуның өчен, минем уйлавымча, укыту эш тәҗрибәсендә бу алымнарны һәр укытучы үзенчә яңарта ала. Әлеге хезмәттә бу алымнарның иң уңышлылары дип табылганнары мисал итеп китерелде.

Йомгак итеп шуны әйтер идем: әгәр дә укытучы дәрестә күргәзмәлелекне җитәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле татар фильмнарыннан фрагментлар күрсәтсә, уен ситуацияләре,

сөйләм күнегүләре, инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез, эшендә зур уңышларга ирешәчәк.
Бөек шәхесебез Р. Фәхретдин әйткәнчә, "Һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнгать өлкәләрендә милләтенең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш."

**ФАЙДАЛАНГАН ӘДӘБИЯТ**


1. Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык. – Казан: ТР "Хәтер" нәшрияты, 2003 – 500 б.
2. Шунда ук, 556 б.
3. Хәлим Айдар. http://tt.wikipedia.org/
4. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 6. – 52-101б.3.
5. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат. // Казан утлары. – 1992. – № 7. – 88-129 б.
6. Таҗетдинов Ә. Татарстанда культура революциясе, «Казан утлары», 1967, № 9.72 б.
7. Юзиев Н. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.



**Хамаева Г.Ә., Рәхмәтуллина Ч.Х.–**
**Татарстан Республикасы**
**Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучылары**


## Кино һәм Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат" әсәрен өйрәнүгә методик киңәшләр

Кино сәнгате дистә еллар буе кешенең, аеруча яшьләрнең иң кызыксынган өлкәсе булып тора. Яңа чыккан фильмнарны карамый торган кешеләр бик сирәк очрый. Кинотеатрларга атна саен йөрү — яшьләр арасында гадәти күренеш. Тик бу фильмнарны халык урыс телендә карарга мәҗбүр була. Татар телендә заманча чит ил фильмнарын, үзебезнең татар киноларын карау мөмкинлеге әлегә юк диярлек.

Дөрес, соңгы вакытта тәрҗемә кинолары күп. Бу мәсьәләне танылган режиссер, Татарстан кинемотографистлар берлеге җитәкчесе Илдар Ягъфәров чит ил кинофильмнарын татарчага тәрҗемә итү мөмкинлеген саташу дип бәяли. "Татар телен көлке хәленә калдырасыгыз килә икән, "Форест Гамп" яки "Титаник"ны татарчага тәрҗемә итегез", - ди.- Ни, әмма Татарстан режиссерлары мактауга лаек кино төшерә. Берничә режиссерның иҗат җимешләрен карадым. Татарча кино бар, менә дигән алар! "Айсылу" фильмы да ошады. Аларны халыкка җиткерергә кирәк. Чит ил киноларын тәрҗемә итүгә караганда, үзебезнекен җитештерергә кирәк. Аның өчен акчасы да булуы мөһим. Үзебезнең иҗатчылар бар, алар төшерергә атлыгып тора. Нинди көнбатыш киносы турында сүз булырга мөмкин?!"

Бу урында без аның фикере белән тулысынча килешәбез, чөнки нигә безгә гел урыска йөз тотарга, нигә сүзен сүзгә тәрҗемә итәргә? Безнең үзебезнең татар сүзләре, үзебезнең татар киносын оештыручыларыбыз юкмыни?! Нигә аны дәүләт дәрәҗәсенә күтәрмәскә?!

Ә Мансур Гыйләҗев кино сәнгатенә карашын болай белдерә: "Кинoны барлыкка китерү, аны көчәйтү - безнең милләтебез өчен актуаль проблема. Мәсәлән, татар дөньясы - без операсыз, балетсыз күп еллар яшәгәнбез, киләчәктә дә яшәрбез (минем һич тә операны кимсетәсем килми). Ә киносыз берничек тә яшәп булмый. Бүген милләт үзен кино аша күрсәтә ала. Аны барлыкка китермәсәк, безнең киләчәгебез дә бәхәсле. Билгеле, театрыбыз бик көчле, әдәбиятыбыз көчле. Ләкин заман таләпләре буенча, бүген безгә көчле кино кирәк...".

Ә безгә, татар теле укытучыларына, бары тик бер юл кала: булган киноларны туплап, дәресләрдә, сыйныфтан тыш чараларда укучыларны татар кинолары белән таныштырырга, күрсәтергә.

Хезмәтебезне язганда, без программага һәм татар киноларына күзәтү ясадык һәм

шундый нәтиҗәгә килдек: татар киносының , юк дигәндә дә, үз тарихы бар; төшерелмәгән дисәк тә, күпмедер дәрәҗәдә төшерелгән.

Татар киноларының якынча исемлеген бирик:

1. “Булат - батыр” (1928 нче ел); – татар тарихына нигезләнгән беренче нәфис фильм буларак билгеле. Премьерасы 1928 елның 22 февралендә Казанның «Электра» кинотеатрында узган. Фильмда 1770 елларда Русиядә Пугачев күтәрелеше чорындагы вакыйгалар сурәтләнә.
2. “Хәзинә” (1977 нче ел), Свердловск (Екатиринбур) киностудиясе;
3. “Бәхеткәй” (2000 нче ел), режиссер - Илдар Ягафаров;
4. “Күктау” (2004 нче ел), режиссер - Илдар Ягафаров;
5. “Яңа елда бергә булыйк” (2004 нче ел), режиссер - Нурания Җамали;
6. “Зөләйха” (2005 нче ел), режиссер - Рамил Төхвәтуллин. Гаяз Исхакыйның "Зөләйха" пьесасы;
7. “Яланаяклы кыз” (2006 нчы ел), режиссер - Нурания Җамали;
8. “Өч аяклы ат” (2008 нче ел), режиссер - Нурания Җамали;
9. “Язмыш шуклыгы” (2009 нчы ел), режиссер - Әхтәм Зарипов;
10. “Бибинур” (2009 нчы ел), режиссер - Юрий Фетинг. Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”, “Өч аршын җир”, “Яра” әсәрләре;
11. “Бичаракай” (2009 нчы ел), режиссер - Фәрит Дәүләтшин;
12. “Ерактагы йолдызым” (2011 нче ел), режиссер - Нурания Җамали;
13. “Күк капусы ачылганда” (2012 нче ел), режиссер - **Фәрит Дәүләтшин;**
14. “Бабай” (2013 нче ел ), режиссер - Альберт Шакиров;
15. “Уеннан уймак” (2014 нче ел), режиссер - Нурания Җамали;
16. “Айсылу” (2017 нче ел), режиссерлар - Солтан Сөнгатуллин, Рөстәм Рәшитов;
17. “Ак чәчәкләр” (1970 нче ел, 2015 нче ел), режиссер - Ренат Әюпов. Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы;
18. “Тапшырылмаган хатлар” (2016 нчы ел), режиссер – Рөстәм Рәшитов. Гадел Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повесте;
19. “Мәдинә. Мәхәббәт сынаулары” ( 2018 нче ел), режиссер - Фәрит Дәүләтшин.

Бу исемлектән күренгәнчә, күп кенә кинолар әдәби әсәргә нигезләнгән, ә кайсылары махсус сценарий буенча язылып төшерелгән. Димәк, мәктәп укытучысы киноларны әсәрне өйрәнү, тәрбия бирү максатыннан чыгып файдаланырга тиеш була.

*“Булат-батыр”* – татар тарихына нигезләнгән беренче нәфис фильм буларак билгеле. Премьерасы 1928 елның 22 февралендә Казанның «Электра» кинотеатрында узган. Фильмда 1770 елларда Русиядә Пугачев күтәрелеше чорындагы вакыйгалар сурәтләнә. Бу фильмны “телсез” дияргә була. Моны татар әдәбияты тарихын, Шиһабетдин Мәрҗани, Габдрахман Ильяси хезмәтләрен, Казан тарихын өйрәнгәндә карап үтәргә мөмкин. Киноның бизәлеше дә, геройларның киемнәре, актерларның уйнаулары да укучыларда кызыксыну уятачак.

Гариф Ахуновның “Хәзинә” киносын, әсәрне өйрәнү барышында, геройларга характеристика биргәндә, “портрет”, “пейзаж” төшенчәләренә аңлатма биргәндә карарга мөмкин.

“Казан ханлыгы чоры”, 17 нче йөз әдәбиятын өйрәнгәндә, Гаяз Исхакыйның "Зөләйха" пьесасына анализ бирер алдыннан, шул исемдәге фильмны карау отышлы булачак. Укучылар, тарихи вакыйгалар агышына, геройлар сөйләменә, киемнәренә игътибар итеп, шул чор үзенчәлеген, фаҗигасен ачыкларга тиеш булалар.

“Бибинур” киносы Аяз Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән”, “Өч аршын җир”, “Яра” әсәрләренә нигезләнеп төшерелгән. Фильмның төп идеясе - татар авылындагы әбинең, татар халкының, һәркемнең яшәү мәгънәсе хакында уйлануы.

Картинада Татарстанның төрле театр актерлары һәм гади авыл кешеләре дә уйнаган. Эпизодлар Мамадыш районының Албай авылында төшерелгән.

Татарлар тормышы турында кино төшерергә ниятләгәч, Мәскәү режиссеры Юрий Фетинг Аяз Гыйләҗевнең бөтен әсәрләрен укып чыккан. Андагы язмышларны күңеле аша уздыра алган. Югыйсә, татарның асылы, бәгыре турында, Бибинур кебек олы җанлы, пакъ әбиләр хакында җан тенрәндергеч фильм эшли алмас иде кебек. Режиссер үзе дә кино төшерү процессында күпме малайны татарча сөйләшергә, төп геройларның берсе Мансурны уйнаган малайны азан әйтергә өйрәткәннәре хакында горурланып сөйли.

Киноның уңышына андагы вакыйгаларның чынбарлыктан алынганы да сәбәпче булгандыр. Сценарий авторы Мансур Гыйләҗев: "Бибинур тормыштан алынган образ. Бу үзенчәлекле кыйссаны әтигә сөйләгәннәр. Бер яктан кабатланмас вакыйга, ә икенче яктан татар рухына туры килгән вакыйга турында әти төне буе уйланып чыккан. Ә инде икенче көнне повесть яза башлаган һәм аны "Җомга көн кич белән" дип атаган". Биредә татарның ачы язмышы да, шатлыгы да күренә.

Фильм Мансур исемле малайның азан әйтүе белән тәмамлана. Тик аны ишетүче юк. Бәндәләр радио-телевизор, компьютер белән мәшгуль, тик азан тавышы замана кызыктыргычларын басып китә. Режиссер Юрий Фетинг бу күренеш белән татар авылларының киләчәгенә кечкенә генә булса да өмет барлыгы хакындагы фикерен җиткерергә теләгән дип аңлашыла.

Күренә: бу киноны мәктәптә шул әсәрләрне өйрәнгәндә дә, төрле тәрбия максатыннан чыгып та карау нәтиҗәле булачак.

"Ак чәчәкләр" - ун серияле татарча телевизион фильм. Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы (1965) буенча 2015 нче елда Казанда төшерелгән. Фильм «Татарстан Республикасы телләрен саклау дәүләт программасы (2020 елга кадәр)» кысаларында Татарстанның фән һәм мәгариф министрлыгы ярдәме белән «Татарстан - Яңа Гасыр» студиясендә төшерелә.

1970 нче елда роман буенча фильм төшерелгән, ләкин ул сакланмаган, архивтан югалган.

Фильм «Ак чәчәкләр» романы язылуга 50 ел тулуга багышланган. Мәхәббәт, намус, профессиональлек, җәмгыять алдындагы бурыч кебек сыйфатларга багышланган әсәр төрле телләргә тәрҗемә ителеп, үз укучыларын таба, вакытында бик популяр була.

Фильмда да сугыштан соңгы чор кешеләренең күңел яктылыгы, моннан 50 ел элек яшәгән табибларның эш принциплары, авыруларга мөнәсәбәте, профессионализмга карашы турында бәян ителә. Күпчелек кадрлар Казанның тимерьюлчылар хастаханәсенең ремонтланмаган өлешендә төшерелә.

"Бу фильмның максаты – бүгенге җәмгыятьтә табиб һөнәренең дәрәҗәсен күтәрү. Әбүзәр Таһиров образы аша чын табибның нинди булырга тиешлеген күрсәтергә теләдек",- ди Миләүшә Айтуганова.

"Сценарий авторы буларак, ике төп юнәлешкә игътибар бирдек: Әбүзәр Таһиров образында табиб намусы һәм, әлбәттә инде, Гөлшаһидә-Мансур мәхәббәте. Шәхсән үзем әлеге ике юнәлешне дә бертигез бирергә тырыштым", - дип яза Айгөл Әхмәтгалиева.

«Тапшырылмаган хатлар» — Гадел Кутуйның 1935 нче елда язылган популяр «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча 2016 нчы елда төшерелгән татарча тулы метражлы нәфис фильм. «2014-2020 нче елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында төшерелгән.

Әсәрдә 1920 еллардагы вакыйгалар сурәтләнә. Фильмны исә бүгенге көнгә яраклаштырып төшергәннәр.

Ә хәзер **Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат"** әсәрен өйрәнүгә һәм шул әсәр буенча төшерелгән кинога ныклап тукталыйк.

Әсәрне өйрәнүгә 3 дәрес бирергә мөмкин. Укытучы дәрес темаларын үзенчә билгели ала. Мәсәлән,

1 нче дәрес темасы – "Батыр малай Кәбир".
2 нче дәрес темасы – "Бамбук – фронт аты".
3 нче дәрес – "Өч аяклы ат".

Укытучы дәресләргә түбәндәгеләрне максат итеп куя:

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет**— әсәрдә тасвирланган чор турында балаларга мәгълүмат бирү; тарихка, халкыбыз язмышына хөрмәт хисләре тәрбияләү; «шәҗәрә» төшенчәсенә аңлатма бирү; шәҗәрәне белү зарурлыгының сәбәпләрен ачыклау; Авыл тормышы, атлар турында мәгълүмат бирү; укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү.

**Предмет** — укучыларның Айдар Хәлим иҗаты турындагы белемнәрен ныгыту; «Өч аяклы ат» повестеның төп фикерен ачыклый һәм аңлата белергә өйрәтү, повесть турында төшенчәне ныгыту.

**Шәхескә кагылышлы** — укучыларда кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү; туганлык мөнәсәбәтләренең нык булырга тиешлеген күзаллау; хайваннарга карата мәхәббәт, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

Түбәндә кайбер методик киңәшләр бирелә.

Әсәрне өйрәнер алдыннан, укытучы **кереш әңгәмә** үткәрә:

1) “кулак” сүзен ничек аңлыйсыз? (***кулак*** – утызынчы еллардагы хәллерәк кешеләр);

2) Сез атлар турында ниләр беләсез? (Ат - гаҗәеп камил җан иясе. Ул-

көчле, җитез, чыдам, бик сизгер һәм сак. Текә ярга якын килмәс, куркыныч җиргә керер алдыннан туктап калыр, колакларын боргалап, шомрайтып, башын сузып, зур дымлы күзләрен алга төбәп, бөтен гәүдәсе белән калтыранып, билгесезлектән хәбәр алырга омтылыр. Үзенең колынын ул иснәп таба, үз йөгәнен таный, пычрак суны, бозылган ризыкны капмас. Әгәр солы белән ясмыкны кушып, алдына салсаң, ат аларны аера - солы бетә, ясмык кала. Атның тәне бик сизгер. Ат сүзләрне аңлый, кешенең халәтен тоя, мактаганга, ачуланганга битараф түгел, ул гаделлекне ярата. «Ат юлга бер көнеп алса, йоклаган килеш тә йөри», — дигән сынамыш яши.

3) Кешенең күңел халәтен сурәтләүне әдәбиятта ничек атыйлар?

(Психологизм.)

Укытучы “Өч аяклы ат” әсәре нигезендә фильм төшерелүен әйтә, аның тарихы белән таныштыра: «Өч аяклы ат» фильмы, «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, йөздән артык әсәр арасында җиңеп, унлыкка керә. Аның дөньяга танылу көнен татар киносы туу көне буларак билгеләп куйдылар. Аның режиссеры - Нурания Җамали...

Аннан соң киноның бик матур өлешен күрсәтә. (Урман, табигать һ.б.)

Эчтәлекне ачу өчен, түбәндәге **сораулар** тәкъдим ителә:

- Вакыйгалар кайда, кайсы чорда бара?
- Муса бабайларның йортлары ничек сурәтләнә?
- Әсәрдә ат ничек тасвирлана?
- Кәбир атны ничек тәрбияли?
- Муса бабайның йорты ничек сурәтләнә?
- Повесть нинди күңелсез вакыйга белән башланып китә?
- Кәбир көтелмәгән вакыйгада үзен ничек тота?
- Муса бабай ветеринарга әлеге фаҗигане ничек аңлата?
- Әсәр башында булган фаҗига Кәбиргә, аның әнисенә, Муса бабайга, Зөлхиҗә әбигә ничек тәэсир итә?
- Бамбук бүре белән ничек көрәшә?

Шул рәвешле әсәрнең эчтәлегенә күзәтү барышында **кинодан өзекләр карау** да үзен аклаячак.

Әлбәттә, әсәрнең теленә дә игътибар итәргә кирәк. Ул – анализ бирүнең иң төп чарасы.

Мәсәлән, әсәрдә түбәндәге юллар бар:

*«Катымын! Каты булачакмын! Мин- влач! Дәүләтнең алтын баганасы. Мин бар, димәк, човет влачы бар, мин юк – човет влачы да юк!»*

*«Үзегезнең раскулачивать ителгән ат нәселеннән икәнен белеп зыянлаттыгызмы?*

*Җизнәгезгә сугымга калдырдыгызмы? Җизнәгезнең абзарына бернинди дә бүре төшмәгән. Совет властеның борынгы дошманы аның аягын махсус сындырган. Соң булса да уң булсын, дип, киткән малын кире кайтарырга уйлаган. Бик беләсегез килсә, ул аны суеп та ашаган. Бу сезнең алдан уйлап эшләгән җинаятегез. Менә җизнәгезнең атны суеп, базарга чыгарып сатуы турында жалоба».*

Бу юлларны укыгач та, киноның шушы өлешен карап үтү отышлы булачак.

Укучыларга **төрле иҗади биремнәр** дә бирергә мөмкин:

- Муса бабай белән Андрей (ветеринар) диалогын рольләргә бүлеп укыгыз. Муса бабай сөйләменә бәя бирегез. Төзәтеп укыгыз.

Бу биремне укыгач, укучыларга шушы өзек күрсәтелә.

Дәрес ахырында укучыларга түбәндәге сораулар бирелә:

- Әсәр нәрсәгә багышланган?
- «Өч аяклы ат» әсәре авыл тормышына багышланган.
- Әсәрнең исеме ни өчен шулай атала? Әсәрдә тасвирланган чор турында нәрсә әйтә аласыз?
- Әсәрнең исеме «Өч аяклы ат». Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый - өч аяклы: менә-менә егылам дип тора.

**Өй эшләре** дә иҗади бирелә. Мәсәлән, түбәндәгеләрне бирергә мөмкин:

1) Илдә утызынчы елларда булган вакыйгалар турында әсәрдә нәрсәләр сөйләнелә?
2) Репрессияләнгән кешеләр язмышы турында тарихтанниләр беләсез? Шул турыда фикер алышырга әзерләнеп килергә.
3) Ат җигү һәм тугару тәртибе турында мәгълүмат тупларга һәм сөйләргә әзерләнергә.
4) Кәбирнең халәте сурәтләнгән өзекне сәнгатьле итеп укырга.

Шул рәвешле әсәргә анализ ясагач, дәрестән тыш уку кысаларында бу фильмны тулысынча карау әсәрнең идеясен билгеләргә, истә калырга ярдәм итәчәк.

Хезмәтебезне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: татар телендә әдәби әсәрләр язылып торсын, талантлы татар режиссерларыбыз татар кешесен милли рухта тәрбияләрлек фильмнар төшерсеннәр. Ә без, үз чиратыбызда, аларны укучыларыбызга җиткереп барырбыз.

**Кулланылган әдәбият**


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф”, 2000.– 335б.
2. Исламов Ф.Ф. Татар әдәбиятын укытканда сәнгатьнең башка төрләреннән файдалану методикасы. – Казан: “Мастер Лайн”, 1997.– 108 б.
3. *Юзиев Н. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.*
4. Мөхәммәтова Рузилә. Татар киносы турында уйланулар. - Сәхнә.- № 9, 2010.



**Ханова А.И.–**
**Татарстан Республикасы**
**Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**


## Вакытлы матбугат – рухи азык чыганагы
## (“Мәгариф” журналы тарихына күзәтү)

“Мәгариф” журналы татар мәктәпләре, гимназияләре, лицейлары өчен алдынгы тәҗрибә уртаклашу өчен мөнбәр ролен үти. Ул — укытучыларның, мәгариф системасында эшләүчеләрнең өстәл китабы”.

Яңа методикаларны һәм технологияләрне, мәдәният һәм әдәбият казанышларын тарату, мәгарифне мәгълүматлаштыру, алдынгы технологияләрне куллану, мәгариф системасына яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертү, укучыларның һәм укытучыларның сәламәтлеге турында кайгырту, әхлакый, рухи һәм хезмәт тәрбиясе, сәләтле балалар белән эшләү мәсьәләләре, Россиянең һәм Татарстанның мәгарифкә, тел сәясәтенә кагылышлы законнарын гамәлгә ашыру басманың игътибар үзәгендә тора.

"Мәктәп" журналының беренче саны иске стиль белән 1913 елның 21 нче февралендә дөнья күрә. Казан губернаторы канцеляриясе «Сабах» нәшриятында Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәровның җаваплы редакторлыгында «Мәктәп» дигән педагогик журнал чыгарырга рөхсәт бирә.

Беренче Бө¬тендөнья сугышы башлангач, 1914 нче елның октябрендә, жур¬нал чыгудан туктый, аның ни¬бары 25 саны гына чыгып ка¬ла. Әмма ул үзенең шул сан¬нары белән дә татар мәгариф системасын тамырдан үзгәр¬теп кору юнәлешләрен күр¬сәтергә, алдынгы карашлы мөгаллимнәрнең, педагогларның, әдипләрнең фикерен киң катлам халыкка җитке¬рергә өлгерә.

1918 нче елның 7 ноябрендә Казанда "Мәгариф" исемле журнал чыга башлый. "Мәк¬тәп" журналының беренче саннарында ук үзенең мәкаләләре белән актив катнашкан Галимҗан Ибраһимов «Мәга¬риф"не оештыручы, аның бе¬ренче мөхәррире була. «Мәк¬тәп» журналының актив авторлары да аның дәвамчысы булган «Мәгариф»не чыга¬ру эшенә бик теләп кушыла¬лар.

Журнал 1936 нчы елның октяб¬реннән — «Башлангыч мәк¬тәп», 1938 нче елдан 1990 нчы елның августына кадәр — «Совет мәктәбе» исеме белән чыгып килә. Бу чор 25 ел вакытны эченә ала. 1941 – 1948 нче елларда журнал чыгудан туктап тора.

Еллар уза, заманалар үзгәрә... Замана белән мәктәпкә, мәгарифкә булган таләпләр дә үзгәрә; рубрикалар саны артканнан – арта бара: "Башлангыч мәктәп", "Татар теле һәм әдәбияты", ... "Мәктәп һәм семья"...

1990 нчы еллар башын¬да, Татарстан Республикасы суверенлыгы турында Декла¬рация кабул ителгәч, мәктәп¬ләребез, һөнәри һәм югары уку йортлары тормышында, укыту-тәрбия эшен оештыру¬да, Татарстан Республикасы халыклары телләре турында¬гы Законны гамәлгә ашыру барышында бик күп яңалык¬лар барлыкка килде. «Совет мәктәбе» журналы 1990 нчы елда "Мәгариф" дип үзгәртелә.

"Мәгариф" педагогик журналы – республиканың барлык укытучыларына да хезмәт итә торган басма. Ул мәгариф системасында эшләүче һәркем өчен дә кызыклы. Бүгенге көндә журналда гомуми педагогик характердагы мәсьәләләргә зур урын бирелә.

"Мәгариф. Татар теле" журналы татар теле укытучыларына тәкъдим ителә. Журнал хезмәткәрләре бу турыда болай ди: "Безнең татар теле укытучыларына да күбрәк игътибар бирәсебез килә, чөнки башка төрле фән укытучылары өчен федераль күләмдә махсус басмалар шактый чыгып килә, ә туган тел укытучылары нигездә безнең журналга йөз тота. Әлеге фикердән чыгып, без "Мәгариф. Татар теле" басмасын булдырдык".

"Мәгърифәт" журналы инде 105 ел дәвамында халкыбызга мәгърифәт эстәү белән шөгыльләнә, алдынгы фәнни – педагогик фикер чыганагы буларак, яшь фәнни кадрлар җәрбияләү, мөгаллимнәрнең белемен һәм осталыгын арттыру, халыкка педагогик белем бирү юнәлешендә гаять зур эш башкара.

**Харисова Г. С.**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган**
**31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»**

**А.Хәлимнең публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. А.Хәлим иҗаты турында башка язучыларның фикерләре.**

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында Словакия өчен барган сугышларда һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә. Бәләкәй Кәркәленең башлангыч, күрше Олы Кәркәле авылында җидееллык һәм район үзәге Кыргыз-Миякәдә татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1959—1960 елларда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә техник училищеда укый. Аннан бер ел чамасы калмык далаларында нефть ятмаларын эзләү экспедицияләрендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшләп йөри. 1961—1964 елларда — Совет Армиясендә, полк мәктәбен тәмамлап, кече сержант званиесендә урта авырлыктагы танк йөртүче булып хезмәт итә. 1968 елда Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлагач, А. Хәлим Татарстанның Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында инженер, шәһәр радиотапшырулар редакциясе җитәкчесе булып эшли. Түбән Камада яшьләрнең хакимият җитәкчелегенә буйсынмаган беренче «неформаль» (формаль булмаган) иҗади-сәяси оешмасын — «Кама таңнары» исемле берләшмәне җанландырып җибәрә һәм шундагы эшчәнлеге өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, 1971 елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була. 1971—1975 елларда А. Хәлим Уфада «Совет Башкортстаны» газетасы редакциясенең мәгълүмат, мәдәният һәм сәнәгать бүлекләрендә әдәби хезмәткәр-журналист булып эшли һәм газетаның иң актив публицист авторларыннан берсе булып таныла. Аннары ул алты ел дәвамында Себер-Урал магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә өлкән инженер вазифасында Түбән Варта — Курган — Әлмәт һәм Түбән Варта — Курган -Самара нефтьүткәргечләре салуда катнаша. 1981 елда аны Уфадагы М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрына әдәби бүлек мөдире итеп чакыралар. Анда елдан артык эшләгәннән соң, 1983—1985 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда драматургия буенча югары белем ала. 1985—1991 елларда А. Хәлим — язучы-профес-сионал, ә 1991 елдан 1996 елга кадәр Татарстанның Чаллы шәһәрендә үзе оештырышкан татарча-русча яңа матбугаи басма — «Аргамак» дигән әдәби-сәяси журналның баш мөхәррире булып эшли.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган.

А.Хәлим — драматургиядә дә иҗади көчен сынап караган каләм остасы. Пьесаларыннан «Җан-чишмә» (1983), «Пәри туе» (1990) әсәрләре заманында Башкорт дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш казаналар, ә балалар өчен язган «Биктырыш» исемле поэмасының сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела.

Шулай да Айдар Хәлимнең исемен киң таныткан, бер каләмдәше әйтмешли, «кислород бомбасы»дай шартлау ясаган әсәрләре — туксанынчы еллар дәвамында дөнья күргән публицистик китапларыдыр: «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книгапечали, или Записки аборигена», 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» (1996), «Җиңелмәс ул чечен» («Этот непобедимый чеченец», 1996) һәм «Империяне үтерергә!» («Убить империю!», 1997). Боларның беренчесендә Башкортстандагы миллион ярым татарның тоталитар режим чорында милли хокукларыннан мәхрүм ителүе, мәктәпләре, матбугат органнары ябылуы, Мәскәү хакимияте һәм җирле түрәләр алып барган сәясәт нәтиҗәсендә ике тугандаш халыкны — татар белән башкортны үзара ызгыштырырга маташуы документлар һәм гыйбрәтле вакыйгалар мисалында бәян

ителә. Әлеге китапның дәвамы рәвешендә язылган «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять эзеннән» әсәрендә автор, татар халкының хокукларын даулап, фикердәшләре белән бергә Уфа каласының үзәк мәйданында ун көнлек ачлык вахтасына басуы, шундагы кичерешләре турында сөйли һәм, шул вакыйгаларга бәйләп, сиксәненче-туксанынчы елларда татар халкы, аның намуслы шәхесләре алып барган катлаулы, каршылыклы сәяси көрәшнең документаль елъязмасы, аның иң тәэсирле сәхифәләре белән таныштыра.

«Җиңелмәс ул чечен» китабы, шулай ук мул документаль материаллар нигезендә, чечен халкының үз мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә күтәрелүен, аны сугышта җиңеп чыгуын бөтен фаҗигале күренешләре белән күз алдына китереп бастыра. «Империяне үтерергә!» китабында да язучы-публицист каләменә хас җете буяулар белән чечен халкының йөз илле елга сузылган азатлык көрәшенең күп кенә аспектлары яктыртыла, әмма монда төп игътибар Кырым татарларының тарихи фаҗигале язмышын һәм хәзерге иҗтимагый-сәяси тормышын тасвирлауга юнәл телгән. Гомумән, әдипнең бу дүрт публицистик китабы мәгълүм сәбәпләр аркасында милләт буларак югалган яки әкренләп югала барган, ватаныннан аерылган, җиреннән-суыннан сөрелгән, аракыга батырылган, динсезләндерелгән, шулар аркасында биологик, физиологик һәм рухи сырхауларга дучар ителгән, шул ук вакытта зур тарихлы, мәдәниятле һәм горур табигатьле халыкларның йөрәк авазы булып яңгырый.

Әдипнең егерменче гасырның ахыргы, яңа гасырның беренче елларында иҗат ителгән күп санлы публицистик әсәрләре, мәкаләләре, эсселары, юлъязмалары, туган төбәгенә һәм якташларына багышланган «Минем Түгәрәк Имәнем» (1999), халык санын алу уңае белән язылган «Яңа сагыш» (2002) кебек китаплары да шул ук көрәш рухы, гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләре белән сугарылганнар. Алар гамьле укучыны да битараф калдырмадылар.  Бу елларда А. Хәлим сәнгатьле проза өлкәсендә дә мәгълүм иҗади уңышларга ирешә. Аның «Өч аяклы ат» (1992) повесте, «Казыктагы итальян» (1999) новелласы һәм бигрәк тә «Татар вакыты» (1998) исемле кечкенә роман бүгенге татар прозасының яңа казанышы итеп бәяләнде.

Айдар Хәлим үткән гасырның 90 нчы елларында мәйданга чыккан милли-иҗтимагый оешмалар эшендә башлап йөри. Ул 1992 елдан татар халкының Милли Мәҗлесе депутаты, 1997—2001 елларда Мәҗлеснең рәисе. 1992 һәм 1997 елларда җыелган Беренче һәм Икенче Бөтендөнья татар конгрессында делегат булып катнашты. Айдар Хәлим — 1976 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2003).

Айдар Хәлимнең әдәби иҗаты турыңда башка язучыларның фикерләрен дә карап үтик:

Хәлимовның шигырьләре җир сулышы белән сугарылганнар. Мондый шигырьләр хезмәтнең, мәхәббәтнең, тормышның кадерен белгән кеше йөрәгендә генә туарга мөмкин. Яшь шагыйрьнең әсәрләре шигырь сөючеләргә, ягъни матурлык сөючеләргә ләззәтле минутлар китерер дип ышанам.

Мостай Кәрим, Башкортстанның халык шагыйре. 1966.

...Аның биографиясе шактый бай. Ул язу характеры белән аерыла. Аның шигырьләре давыллы, өермәле, вулкан дияр идем мин... Кайсы вакыт барысы да бергә бутала, шигъри юллар, детальләр, образлар сүз өермәсе эчендә югала. Бәлки, бу вакытлы хәлдер, үтәр!

Сибгат Хәким, Татарстанның халык шагыйре. 1968.

Айдар Хәлим җир һәм күкләр масштабында фикер йөртә. Аларда фикерләүгә караганда сиземләү көчлерәк.

Саҗидә Сөләйманова, шагыйрә. 1970.

Юк, Айдар Хәлимнең Вильнюста басылып чыккан «Хәсрәт китабы», ул китап кына түгел, ул татар милләтенең гасырлар буена яңгыраган аһ-зары, ачу-ләгънәтнең бер йомгакка тупланган шартламасы — бомбасы. Менә ни өчен сатлык җаннар бу бомбадан ераграк торырга тырыша. Мөгаен, нәкъ менә шуның өчен бу китап әле һаман үз телендә сөйли алмый тилмерә. Кем аны бу газаптан коткарыр икән — Казанмы, Өфеме? Кайда ул фидакарь җан?!

Ибраһим Салахов, язучы. 1992.

Әдип укучының мәрткә китә башлаган иманын уятып, аны битарафлыктан сөйрәп чыгара алырлык кайнар тәэсирле сүз тылсымы тудыра алуы белән үзенең вазифасын раслый булса кирәк. Ләкин бусы -- аерым бер тема. Бу мәсьәләгә кагылуымның сәбәбе исә «Татар вакыты »нда шушы эшнең моңа кадәр татар әдәбиятында күрелмәгән дәрәҗәдә башкарылуын әйтер өчен генә. Чыннан да, Айдар Хәлимнең уңышы татар әдәбиятының уңышы бит. Без әдипләр бу әсәр белән горурланырга хаклы.
Миргазиян Юныс, язучы. 2000.

Айдар Хәлим — үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феноменаль күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмешкә-белмәмешкә салынамы — анысы мөһим дә түгел, — әмма вакыт галиҗәнаплары бу шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә инде...
Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары кимәлдәге профессионал булып була икән ул? Айдар Хәлим ике телдә — рус һәм татар телләрендә (теләгәндә саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь (әле яңа гына чыккан «Милли шигырьләр» китабын укып карагыз!). Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын, — максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Пьесалар язуы да мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте — ул проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә генә булса кирәк. Шулай да «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Казыктагы итальян» әсәрләре «Казан утлары»нда үз вакытында басылып чыктылар. Кемгә ничектер, бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия-бүләкләргә лаеклы әсәрләр.

Равил Фэйзуллин, Татарстанның халык шагыйре. 2001.

«Өч аяклы ат» повестеның кыйммәте, бик сирәк үзенчәлеге тагы шунда — монда кеше булмаганҗан иясе, бу очракта ат малкае әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әйткәнебезчә, дөнья әдәбиятында бу сирәк очрый торган, язучыдан гаять дәрәҗәдә осталык, нечкәлек һәм талант таләп итә торган күренеш. Әле кеше хәтле кешене образ дәрәҗәсенә күтәрү — гаять авыр һәм катлаулы эш, ә монда телсез җан иясе турында җан тетрәндерерлек, җан җылатырлык образ тудырырга кирәк! Бу эшне бары тик зур талант иясе генә булдыра ала...

Фәүзия Бэйрәмова, язучы, җәмәгать эшлеклесе. 2001.

Сирәк очрый торган энҗеләрнең берсен 2000 елда Айдар Хәлим бүләк итте. Сүз аның «Казыктагы итальян» исемле новелласы турында бара. Моннан алдарак та бу автор проблемаларының үткенлеге, сюжетының бөтенлеге, эшләнешенең камиллеге белән аерылып торган «Татар вакыты» исемле кечкенә романы белән шатландырган иде... Айдар Хәлим — олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия. Димәк, хикмәт, кайберәүләр инанганча, жанр зурлыгында яисә вакыйгалар чиксезлегендә түгел, ә кыска, тыгыз, динамикалы сюжет кысаларында сурәтләнгән конкрет тормыш күренешенә күңелгә нык тәэсир итәрдәй тирән мәгънә сала белүдә икән...
Рифат Сверигин, әдәбият галиме, тәнкыйтьче. 2002.

Айдар Хәлим татар әдәбиятында үзе бер утрау кебек. Утрау... Ачылмаган утрау...Шагыйрь, прозаик, публицист, драматург, җәмәгать эшлеклесе...

Каләмдәше Рәдиф Гаташча әйтсәк, «тынгысыз җанлы, күпьяклы талант, гаҗәеп уңган шагыйрь». Шагыйрьләр, әлбәттә, «уңмыйлар», алар я булалар, я булмыйлар гына. Бу сүздә замандаш шагыйрьләрнең үз каләмдәшләрен ничек тану юлларының авырлыгы чагыла түгелме? Әйе, шагыйрь. Нинди генә жанрда иҗат итсә дә шагыйрь булып кала ул. Тукай кебек туры сүзле, кыю, Такташ кебек моңлы шагыйрь.

Әдәбият

1. Айдар Хәлим. Биобиблиографик күрсәткеч.- Казан: «Милли китап» нәшр., 2001.- 476 б.
2. Фәүзия Бәйрәмова . Ак һәм кара көрәше.-Казан утлары.- 2001.- № 12.- 119-128 б.
3. М.  Юныс. Бәхетле мескенлек.- Казан утлары.- 2000.- №2.- 167-172 б.
4. М. Әхмәтҗанов . Милләт каһарманы.- Мирас.- 2000.- № 10, 11, 12

**Хуҗәхмәтова К. Н.**
**«Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**“Аерым фәннәр тирәнтен**
**өйрәнелә торган 24нче гомуми**
**урта белем бирү мәктәбе**

## Йолдызларга үрелеп яшә
## (Кадрия Наил кызы Хәлилова иҗаты буенча)
### Кереш өлеш

Соңгы елларда шигъриятькә хатын-кызларның күбрәк килүе, әлбәттә, шатлыклы күренеш. Күпчелек шагыйрьләребез акыл һәм тәҗрибә туплагач, 40-50 яшьләр арасында яза башлый.Тормышның билгеле бер этабы үтелгән, балалар үсеп җиткән бервакытта, күңелдә калганнар шигырь булып формалаша. Хатын-кыз лирикасы ирләрнекеннән үзенең хисләргә бай булуы, эчкерсезлеге, нечкәлеге, сафлыгы, нәзакатьлеге белән аерылып тора. Дистәләгән хатын-кыз автоларыбыз иҗатына мөкиббән киткән, аларның уй-хисләрен, әйткән сүзләрен үз иткән китап укучыларыбызга мин бүген яңа бер исемне әйтер идем. Ул безнең күпләребезгә таныш булган Кадрия Наил.

Кеше күңеле бик-бик тирәндә сулкылдап ятучы моңлы чишмәгә тиң. Ә чишмә, белгәнебезчә, кайчан да булса бер бәреп чыгу һәм бар тирә-якны шаккаттырып, җырлый-җырлый агып китү сәләтенә ия. Ул хисләр, уйлар, назлар, моңнар белән мөлдерәмә тулгач кына, илһам дигән илаһи көч тәэсирендә матур-матур шигырьләргә әйләнеп, дөньягаси белә.

Кадрия Наилнең дә моңнар чишмәсе, сулкылдап ята-ята да, тулып, ургылып, тышка бәреп чыга.. Нинди генә темаларга язылган шигырьләре юк аның: әниләргә мәдхия, сөю-сәгадәт, туган нигез, туган якның матурлыгы, ел фасылларының үзенчәлеге, балаларга багышлап язылганнары да шактый. Чыннан да, Кадрия ханымның йөрәк җырлары саф су тамчыларын, кояш нурларында җиде төс белән балкучы бөртекләрне хәтерләтә. Сусаган җаннарга - дәва, сагыну-сагышлардан моңсуланган күңелләргә шифа булырлык алар. Ә инде Сөю дигән бөек тойгы-кичерешләрне бөтен әрнү-газаплары, бәхет-шатлыклары, хыянәт-нәфрәтләре белән сүзгә төреп бирү – чын бәхеттер ул. Иҗат бәхете, шагыйрь бәхете...

Бәхетлегә санап мин үземне
Дөньяларда яшим бүген.
Кара болыт кире капламасын
Аязып килгән тормышым күген, - дип яза Кадрия ханым.3

### Туган як җырчысы

Кадрия Наил кызы Хәлилова тумышы белән Актаныш районы Зөбәер авылыннан. 1951 елның 1 августында гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә, балачак һәм үсмер

еллары Мөслим районының Симәк авылында үтә. Симәк авылы мәктәбенең сигезенче сыйныфын тәмамлый. Бөгелмә медицина училищесына укырга һәм гомерен шәфкать туташы булып хезмәт итүгә багышлый.

Ә иҗатка килгәндә, ул яшьтән үк серле, моңлы бала була. Аның шигырь юллары туугa сәбәпчеләре байтак. Табигатьнең яшәргән мизгеле дә, зифа буйлы каеннары да, үләндәге энҗе чыклар да, ялгызлыктан йөрәге елаган мизгелләр дә. Яратуы, хөрмәте, рәхмәте дә шигырь юлларына салынган.

Читтә гомер кичерсә дә, ул гел туган нигез, туган авылы, аның кешеләре белән горурланып яши. Туган якларга булган хисләрен, хөрмәтен, сагынуын шигъри юллар белән аңлатырга ашыга:

**Ярый әле, авылым бар –**
**Саклаучы нигез ташын.**
**Арган чакларымда кайтып.**
**Куярга газиз башым.**
*(«Тормышым бизәүчеләр»)*

Иҗатында төп юнәлешләренең берсе булып, әти-әни, туганлык юлларының тыгыз, мәхәббәт җепләре белән бер-берсенә бәйләнеп баруы ярылып ята. Туганнар, балалар, оныклар белән горурланып, алар өчен сөенеп яши автор.

**Оныкларым гөлләр кебек**
**Бизи минем тормышны.**
*(« Тормышым бизәүчеләр»)*

Туган нигез белән янәшәдә кадерле кешеләре, әти-әнидән калган һәрбер әйбер өчен җан атып яши: гөл, шәл, дисбе, чулпылар аның өчен бәһале, ул аларны бик хөрмәт итеп саклый:

**Әнкәм рухы булган шәлне саклыйм**
**Бик кадерләп төреп сандыкта.**
*(«Мамык шәлдә әнкәй исләре»)*

Мамык шәлдә ул ана йөрәгенең назын тойса, гөлләр аңа яшәр өчен көч бирә. Ә ул аларга яшәү, чәчәк атар өчен көч бирергә теләп, сулар сибәргә онытмый:

**Газиз әнкәмнең гөлләрен**
**Назлап кына үстерәм.**
**Алар миңа, мин аларга**
**Яшәр өчен коч бирәм.**
*(«Серем гөлләргә сөйлим»)*

Яшәү өчен көчне ул гөл, чәчәкләрдән шигырьләр тудырып ала. Әти- әнисенә дөньялыкта әйтергә өлгермәгән сүзләрен, аларның матур тормыш юллары кичүенә сөенеп шигырь юлларын тудыра. Инде вакытлар үтсә дә, һәрдаим маяк булып яшәүләренә чиксез рәхмәтле, аларның рухына, шигъри юлларга салып, дога кылырга да җаен таба:

**Фани дөньялардан киткәннәргә**
**Дога кылыйк иң чын күңелдән.**
*(«Киткәннәргә дога кылыйк»)*

Шуларга өстәп, ике бала әнисе, өч онык әбисе ул. Үзен өлкән буын вәкиле итеп санап, шигырь юллары белән үз киңәшләрен дә ишеттерергә тели:

**Балаларның балалары хәтта**
**Онытмасын изге тамырын.**
**Бездән соң да өзми сакласыннар**
**Буыннарның нәсел чылбырын.**
*(«Нәсел чылбыры»)*

Ул бер шигырьдән икенчесенә күчеп, әти- әнисен искә алып, хәтерендә яңартып, яши, иҗат итә.

**Әле дә җитми миңа карашлары,**
**Күңел белән һаман сабыймын.**
*(«Күңел һаман сабый»)*

диеп яза ул, әтиле-әниле елларын кире кайтарасы килеп. Ләкин юк... Булмый! Әтисе Бөек Ватан сугышы ветераны, Ленин ордены кавалеры, күп еллар колхоз рәисе булып эшли. Әтисенә, аның кылган эшләренә горурланып, авылдашлары, якташлары исеменнән дә рәхмәт сүзләрен җиткерә Кадрия. Алар «Җәй көнендә җиләккә дип баргач», «Әткәм белән әнкәм куллары» һәм башка бик күп шигырьләрдә урын алганнар. Әнисе Зәнфирә апа өчен язылган шигырьләр дә шактый: «Әнкәм дисбесе», «Ана күңеле», «Кичер, әнкәй», «Ник ашыктың, әнкәй...», «Серем сөйлим гөлләргә», «Мамык шәл», «Иң татлы сүз», «Әниләргә гомер телик».

«Бәхет нуры» җыентыгы башыннан ахырына кадәр яшьлек, тәүге хисләр, мәхәббәт мизгелләренә багышланган шигырьләр белән тулы. Тормышта авторның өмет чыганагы булып яраткан кешесе тора. Ул һәркемгә, сөю хисендә янып, мәхәббәт белән гомер итүләрен, яратып, яратылып яшәргә өнди, алай гына да түгел, һәрбарчабызны шуңа этәрә кебек.

**Биек тауны буйсындыру-аның төп максаты**

Кадрия Наил - шигырьләре тупланган 10 китап авторы. Ә шигырьләре җиңел укыла, теләп укыла. Үз күңеле җырлап торгангадыр, аларның һәркайсы көй сорап тора. Шуңадыр ахры, соңгы вакытта җирле композиторлар аның шигырьләренә шактый күп көй язды. Хәер, моңа кадәр дә аның байтак шигырьләренә үзешчән композитор Рубис Зарипов, Альберт Шәрипов көйләр язып өлгергән иде. Һөнәре буенча әдәбият-сәнгатьтән ерак торган Кадриянең таланты ачылу серләрен ерактан эзләп йөрисе юк. Тау никадәр биек булса, аның түбәсенә тизрәк менеп җитү теләге зуррак була бугай. Шигырьләр язуы да, көй чыгаруы да аңа ходай биргән сәләт. Ул аны фидакарь хезмәте белән туктаусыз үстерә, камилләштерә бара. Әйткәнемчә, биек тауны буйсындыру – аның төп максаты. Бу халәт иҗат кешеләренә хас нәрсә. Җирле композиторлар – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре Илдус Сәлахов, Валерий Әхмәтшин, концертмейстер-баянчы Владимир Мироваев, эстрада ансамбле җитәкчесе Альберт Шәрипов белән тыгыз эшләп, ул үзенең юбилеена олуг бүләк әзерләде: Алабуга типографиясендә аның 16 җыры тупланган“Өч, күңелем” җыентыгы дөнья күрде.

Кадрия Наил шигырьләре әле һаман тау елгасы кебек ургып-кайнап чыга, димәк, алда әле тагын яңалары китап булып чыгарга үз чиратын көтә. Чират җитмәгәннәре – яңа табадан төшкәннәре - "Алабуга нуры" газетасы битләрендә һәрдаим басылып килә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Кадрия Халилова. Бәхет нуры. / К.Н.Халилова.- Чаллы-2016.
2. Татарская электронная библиотека.
3. Кадрия Наил. Миләшләр балланганда: Шигырьләр җырлар ./ Кадрия Наил – Яр Чаллы: “Формула цвета”, 2015.



**Чанышова Р. К.**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәренең**
**53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**


## Кино сәнгатенең укыту-тәрбия эшендәге роле

I.**Татар теле дәресләрен яңа педагогик технологияләр кулланып укытуның бер алымы буларак кино сәнгате.**

Бүгенге җиһан катлаулы, тиз үзгәрүчән. Шуның белән бәйле рәвештә мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара. Хәзер безнең илдә дөнья мәгариф тирәлегенә керүгә юнәлтелгән яңа мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш педагогик фәнгә һәм укыту-тәрбия процессына сизелерлек үзгәрешләр кертә.

Мондый шартларда укытучыга хәзерге заманның күптөрле инновацион технологияләренә, идеяләргә юнәлеш тотарга кирәк.

Яңа педагогик технологияләрне кулланунның төп максаты - белемле, тәрбияле,тормышта үз юлын табарга әзерлекле, яхшыны яманнан аера, тиешле карар кабул итә белгән шәхес тәрбияләү. Инновацион технологияләр белән укыту - уку процессын яңача оештыру дигән сүз.

Татар теле дәресләрен яңа педагогик технологияләр кулланып укытуның бер алымы буларак – татар киносын һәм спектакльләрен карау, минем фикеремчә, балаларда тел өйрәнүгә кызыксыну уяту чарасы .

Бүгенге көндә татар киносы нинди хәлдә соң? Тел өйрәнүгә кызыксыну уяту чарасы буларак кулланып буламы? Татарстан мәдәният министрлыгының коллегия утырышында татар киносының бүгенге хәле шәптән түгел дип бәяләнде. Чит ил фильмнарын татарчага тәрҗемә итеп мәсьәлә хәл ителәме? Аларга ихтыяҗ бармы?

Бүгенге көн татар кино сәнгатенең укыту-тәрбия эшендәге ролен ачыклау – элеге хезмәтнең **максатын** тәшкил итә. Максатка ирешү юлында түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- Татар кино сәнгатенең бүгенге көндәге торышын билгеләү;
- Татар киносының укыту-тәрбия эшендәге ролен ачыклау (Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәре буенча төшерелгән кино үрнәгендә).
- Татар кино сәнгатенең киләчәген күзаллау.

Кино соңгы дистә елларда күпчелек кешенең, аеруча яшь буынның иң кызыксынган өлкәсе булып тора. Кинотеатрларда атна саен дистәгә якын яңа фильм чыга. Татар яшьләре дә, урта буын вәкилләре дә, балалар да карамыйча калмый. Тик бу фильмнарны урыс телендә карарга мәҗбүр була. Татар телендә заманча фильмнар карау мөмкинлеге әлеге юк.

Татар театрлы, газеталы булыр өчен патша хөкүмәте белән үз вакытында ничек тартышса, кино сәнгатен булдыру өчен дә соңрак шулай ук көрәшә, шулай гына җиңүгә ирешә. Беренче нәфис фильм — “Булат батыр” рус кино сәнгатеннән берничә дистә елга гына калышып, 1927 елда “Советкино”, икенчесе — “Койрыклы йолдыз" — 1929 елда “Востоккино” студиясендә төшерелә. Татар тормышына нигезләнеп язылган тәүге фильмнар шул чор тамашачыларында зур кызыксыну уята.

Татар кино сәнгатенең бүгенге көндәге торышына күзәтү ясауны үз эшемнең бер бурычы итеп алган идем. Берничә татар киносына тукталып китәсем килә.

## II. 1. Татар киноларына күзәтү.

### Татарстаннан бәйгедә катнашкан нәфис фильмнар:

**2005 ел. “Күктау”** – ятим калган ике кешенең авыр тормыш шартларында бер-берсенә ярдәм итүе турындагы дулкынландыргыч драма. Америкага дәваланырга китәргә һәм анда яңа гаиләгә эләгергә тиешле кечкенә Булат һәм автоһаләкәттә гаиләсен югалтып, 6 ел төрмәдә утырган Кәрим хакындагы фильм 2005 елда төшерелгән. Ул − Татарстанда җитештерелгән тулы метражлы беренче нәфис фильм. Картинаның режиссеры — Илдар Ягафаров. Бу фильм 2005 елда Кинотаврда төп бүләккә лаек булды.

**2005 ел.** Г. Камал театрында “Рамай” студиясе төшергән борынгы һәм өр-яңа “Зөләйха”ны тәкъдир итү кичәсе булды. Фильмның сценарий авторы — драматург, актер Юныс Сафиуллин. Ул аны Гаяз Исхакый “Зөләйха"сына нигезләнеп, әмма шул чорны яктырткан төрле чыганакларга киң таянып, шактый нык үзгәртеп, хәтта ки кайбер күренешләрне өстәп, 2002 елның мартында яза башлый. Әйтергә кирәк, үз заманында К. Тинчурин театрында баш режиссер булып эшләгән Дамир Сираҗиев та бу әсәрне сәхнәләштерү уе белән ялкынланып, Юныс Сафиуллинга сценарий язарга тәкъдим иткән була.

Нәфис фильмның идея авторы һәм режиссер-куючысы Татарстанның атказанган артисты, “Упкын” нәфис фильмы төшереп, режиссер буларак та үзен расларга өлгергән тынгысыз һәм талантлы сәнгаткяр Рамил Төхвәтуллин.

**2008 ел.** А. Хәлим повесте буенча төшерелгән **«Өч аяклы ат»** фильмы узган «Алтын мөнбәр» (халыкара) мөселман кинофестивалендә иң яхшы 10 фильм исемлегенә керә.

**2009 ел. «Бөркетләр»** фильмы «Иң яхшы ир-ат роле» өчен бүләккә лаек булды. Мактаулы исемне Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Ринат Таҗетдинов һәм Равил

Шәрәфи алды.

**2010 ел. “Бибинур” нәфис фильмы** Казанда узучы VI Халыкара мөселман киносы фестиваленең ике номинациясендә җиңү яулап, Бибинур ролен башкарган Татарстанның халык артисты Фирдәвес Әхтәмова “Иң яхшы хатын-кыз роле”н башкаручы дип табылуы да нур өстенә нур булды.

**2011 ел.** Илдар Ягъфәровның «**Югалту»** картинасын «Милли гореф-гадәтләрне һәм татар телен саклап калуга керткән өлеше өчен» дигән махсус бүләк белән билгеләп уздылар.

**2014 ел.** Илдар Юзиевның яшь татар язучысы Илдар Әбүзәров әсәре буенча төшергән «**Корбан-роман. Корбан белән бәйле тарих»** фильмы тирәсендә күтәрелгән гауга белән истә калды. Фильм берьюлы ике приз алды: Даниил Шигапов «Иң яхшы ир-ат роле» өчен бүләкләнсә, фильм авторларына Казан шәһәре башлыгының махсус бүләге тапшырылды.

**2015 ел.** Салават Юзиевның «**Ишекне шапылдатым яптым да киттем»** дигән фильмы кыска метражлы нәфис фильмнар арасында иң яхшысы дип табылды, ә баш рольне уйнаган Ильдус Габдрахманов иң яхшы ир-ат роле өчен призга лаек булды.

**2015 ел**. 1970 елда **«**Ак чәчәкләр» романы буенча фильм төшерелгән, ләкин ул сакланмаган, архивтан югалган. Яңача төшерелгән Фильм «Ак чәчәкләр» романы язылуга 50 ел тулуга багышланган. Мәхәббәт, намус, профессиональлек, җәмгыять алдындагы бурыч кебек сыйфатларга багышланган әсәр төрле телләргә тәрҗемә ителеп, үз укучыларын таба, вакытында бик популяр була. Фильмда да сугыштан соңгы чор кешеләренең күңел яктылыгы, моннан 50 ел элек яшәгән табибларның эш принциплары, авыруларга мөнәсәбәте, профессионализмга карашы турында бәян ителә. 2015 елның 5-11 сентябрендә узган XI Казан мөселман киносы фестивалендә күрсәтелә.

**2017 ел. «Тапшырылмаган хатлар»** — Гадел Кутуйның 1935 елда язылган популяр «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча 2016 елда төшерелгән татарча тулы метражлы нәфис фильм. Режиссёры — Рөстәм Рәшитов

Режиссер Нурания Җамали төшергән татар фильмнарын «Яңа Гасыр» каналы тамашачылары Яңа ел алдыннан карарга иялəнгəн. Кемнәрдер аны хәтта, шаяртып, «татар Гайдае» дип тә атый. Бугенгесе көндә аның «Тузган торактан күчкәндә» , «Яңа елда бергә булыйк», «Кешечә яшик», «Китәм димә», «Яланаяклы кыз», «Ерактагы йолдызым», «Сөю көтә йөрәк», «Ышанасы килә», «Бәхетлеме син?», Язышлардан узмыш юк”, «Кияү балакай», «Сөюләрем сине хак минем», «Уеннан уймак», «Нәгыймә» кебек фильмнарын олы яшьтәгеләрне җәлеп итсә, А. Хәлим повесте буенча төшерелгән «Өч аяклы ат» фильмы мәктәп баласының яраткан фильмына әйләнде.

**2. Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәре буенча төшерелгән кино үрнәгендә, татар киносының укыту-тәрбия эшендәге роле.**

«Өч аяклы ат» фильмының «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә катнашып, йөздән артык әсәр арасында җиңеп, унлыкка керүе билгеле булды. Бу вакыйга татар киносын сөючеләр өчен аеруча зур куаныч китерде. Хәзерге яшьләрдә битарафлык, күңел бушлыгы, гамьсезлек, ваемсызлык хөкем сөргән заманда бу фильмның дөньяга тууы күңелләргә сары май булып ятты. Алайса, телевизор экраннарында күрсәтелә торган мәгънәсез тапшырулар, үтереш - суеш, көчләү - талауны күрсәткән кинолар безне тәмам бозып бетерде. Мәгънәле, һәркемнең күңел кылларын тибрәтә торган шушындый фильмнар күбрәк булсын иде диясем килә минем.

Айдар Хәлимнең иҗаты күп кырлы һәм мул уңдырышлы. Беренче әсәрләреннән үк сиземләнгән язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Кайсы чор турында һәм нинди генә темага язса да, кеше шәхесенең катлаулы рухи дөньясын, эш−гамәлләрен гуманистик идея - эстетик карашлар югарылыгыннан торып анализларга тырыша. Аларны чынбарлыктагы милли, тарихи − иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы һәм каршылыклы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерергә омтыла.

«Өч аяклы ат» әсәре буенча төшерелгән нәфис фильм авыл тормышына багышланган. Вакыйгалар үткәннәрне искә төшерү белән үрелеп бара. Бу фильмда халык язмышының

аеруча катлаулы һәм фаҗигале дәвере – крестьяннарны көчләп күмәкләштерүгә мөнәсәбәте дә чагылыш тапкан. Бу чорда акыллы һәм таза тормышлы игенчеләрнең үрнәк хуҗалыкларын туздырып, аларның хәләл көч белән тупланган мал – мөлкәтләрен ирексездән тартып алып, ил икътисадына һәм аның абруена, рухи байлыгына иксез – чиксез зыян китерелә. Сугыштан соңгы елларда авыл халкы җәбер – җәфаны, интегүләрне байтак күргән шул. Хезмәт көненә берни бирмиләр диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфалыйлар! Еллар буе берни бирмиләр, еллар буе барын халыктан гына сорыйлар. Кесәңнән бер башак табылса, бер ел төрмә, ике башак табылса, ике ел төрмә каралган. Ә бер кесә ашлык белән тотылсаң, башыңны ун елга төрмәгә тыгалар. Ә шушы чорда ат хәтле атны сафтан чыгарсаң, бу колхозны сафтан чыгару дигән сүз. Димәк, башың гомерең буе төрмәдә чериячәк.

Сугыш арты еллары бик авыр чор. Әтисез калган ятимнәргә тагын да авыр. Үз көннәрен үзләре күрергә өйрәнеп, авырлыкларны җиңә - җиңә яшәгән чак. Бөтен тормыш авырлыгы хатын – кыз һәм балалар җилкәсендә. Ирләр юк дәрәҗәсендә. Кечкенә малай Кәбир һәм аның әнисе Сания апа шул чор корбаннары. Колхоз бик авырлык белән генә сөйрәлә. Техника юк, барлык авыр эшкә атлар җигелә. Әле аның анысы да санаулы гына. Күп атлар сугышка җибәрелеп, шунда башларын салганнар. Лобогрейкага, сукага һәм башка колхоз эшләренә җигү өчен Кәреш авылында нибары ике ат исәпләнә. Ашарга да такы-токы гына. Җизнәсе һәм апасы Зөлхиҗәләрдән хат килеп төшкәч, алар янына барырга булалар. Бер-ике капчык бәрәңге, азрак он, атланмай алып китәрсез дигәннәр бит… Алар тормышындагы кара көннәр шушы төннән башлана да инде.

Әсәрнең исеме - «Өч аяклы ат» . Шулай аталса да, атның бер аягы бүре тешләреннән чәрдәкләнсә дә, хикмәт башкада. Аның заманасы шундый - өч аяклы: менә - менә егылам дип тора. Бер эшкә яраксыз Галләметдин ишеләр влсть белән идарә иткәндә шулай булмый нишләсен! Ул үзе дә болай ди бит: «Катымын! Каты булачакмын! Мин- влач! Дәүләтнең алтын баганасы. Мин бар, димәк, човет влачы бар, мин юк – човет влачы да юк!»

Ана кеше бердәнбер юанычы - малае Кәбиргә зур өметләр баглап, сабырлыгын җыеп, бөтен көчен эшкә бирә. Сания апа ниләр генә күрми, нинди авырлыкларга гына түзми! Аның чыдамлыгына, түземлегенә сокланмау мөмкин түгел. Сугышта батырларча үлеп калган иренә булган мәхәббәтне олы бер хис итеп саклый. Мәхәббәтенә хыянәт итүне ул уйлап та карый алмый. Күпме газап- михнәтләр чиксә чигәр, башкайлары төрмәләргә керсә керер, ләкин ул намусына тап төшермәс!

Фильмда төп герой - Кәбир исемле үсмер малай. Ул үзенең ихласлыгы һәм авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухлы үсмер булып безнең күңелләрне яулый. Ул ат җанлы. Андыйлар турында «хайван җене кагылган» дип әйтәләр. Бамбук малай өчен бик якын җан иясе. Атны суйганда өзгәләнеп кычкырулары әле дә колагымда яңгырый. Дусты белән ат йөрәген кадерләп күмүләрен генә искә төшерик… Ике дус җирне тырмый – тырмый кабер казый. Бамбук каберенә киләчәктә һәйкәл кую, ай һәм йолдыз сурәте төшерү уйларында. Әйе, Кәбир нечкә күңелле. Аның атка булган мөнәсәбәте дә сокландыргыч. Атны иң олы ярату белән ярата белә шул ул.

Нинди генә кыенлыклар, кимсетелү- җәберләүләр , михнәт – газаплар күрергә туры килми аларга?!Әнисен хаксызга мыскыл иткән колхоз бригадирының ямьсез гамәлләренә ул түзеп тора алмый. Явызлык, намуссызлык, шәфкатьсезлек хакимлек итмәскә тиеш! Алар тиешле җәзаларын алырга тиешләр!

Кәбирнең күңелендә әлеге хаксыз рәнҗетүләр, мыскыллауларга карата көчле протест уяна. Аның җаны ярсый, бәргәләнә. Галәметдин кебек властьтан файдаланып, итәк астыннан эш йөртүчеләрнең мыскыллы карарларын нигезсез, законсыз дип саный. Аның әнисенә тагылган нахак гаепләүләргә җаны җәрәхәтләнә, күңеле сыкрана. «Үсеп кенә җитим, кирәкләрен бирермен мин аларның»,- дип күңеленә салып куя. Шулай да ул җебеп-сыгылып төшми, үзендә алга таба барырга тагы да зуррак көч туплый бара. Тормыш рәхимсезлеге белән көрәшергә үзендә бетмәс-төкәнмәс көч таба. Әнисен, Сания апаны, бары бер генә нәрсә коткара ала – Бамбукны алып кайтып, аның исән икәнлеген раслау.

Бәрелеп - сугылып, төрле кыенлыкларга очрап, сазлыкларда бата – бата, чегәннәргә юлыгып, аның эзенә төшәргә теләгән бригадир һәм участковыйлардан яшеренеп, ул, исән-имин килеш, атны үз авылларына - Кәрешкә алып кайтып җиткерә. Аңа ана мәхәббәте, җитезлеге, уңганлыгы бу бәладән чын егетләрчә чыгарга мөмкинлек бирә. Ананың балага, баланың анага карата булган мәхәббәте таш – кыяларны да җимерергә, явызлыкларны җиңәргә сәләтле шул! Режиссер Кәбир кебек геройлар булуына ышандыра. Бала күңелендә «Моны мин дә шулай эшләр идем" дигән фикер уяна. Ул вакытта илебез көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек, курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналары бар. Кәбиргә дә бәхет төшенчәсе туганда ук, ана сөте белән кергән, әнә шуны чын мәгънәсендә аңлау аңа бетмәс – төкәнмәс көч, әнисенә карата мәхәббәт биргәндер. Ләкин Галләметдин кебек власть дип җикеренгән, ятимнәрнең бәхетсез язмышлары бәрабәренә яулап алган байлык, муллыкка кызыгучыларны бөтенләй күралмый укучы. Кәбирнең әнисе – Сания Садриеваның нәселенә үк кереп китеп яла ягучыларны да хупламый. "Минем нәселемне хурласалар, мин дә түзеп тормас идем" дигән батырлык эшләү теләге уяна балада.

Гомумән, Кәбирнең әнисе батыр, уңган, чиста, пөхтә, сабыр булып кала белгән. Кәбир – Сания. Әни – ул. Сания Садриева ролен артистка Зөлфия Вәлиева шулкадәр дөрес, чын итеп башкара. Ә бит атны да кинога төшерү җиңел булмагандыр. Бу кинофильмны карагач, ат дуслыгы бөтен явыз көчләрдән дә өстен икәне аңлашыла. Фильмны тамаша кылганда йөрәк телгәләнә, күзгә яшьләр килә. Геройларның тиешсезгә рәнҗетелгән урыннарында ярсулар, ачу кабарулар тынны кыса, бугазны буа. Кәбирнең җан ачысы белән өзгәләнгән, ачыргаланган минутларында бөтен тәнгә кырмыскалар йөгергәндәй була, кайгы- хәсрәт ялкынында янасың.

Ана… Бу сүз баланы шундый дулкынландыра. Әни - баланың иң якын, иң яраткан кешесе, сердәшчесе, эштә үрнәге. Аннан башка дөнья буш. Һәр бала да газиз әнисен Кәбир әнисен яраткан кебек яратсын иде. Безгә Кәбир кебек ятимлекне күрергә язмасын иде. Җир йөзендә Сания Садриева кебек намуслы аналар, Кәбир кебек әнисе өчен үлеп торучы балалар күбрәк булса иде. Бу кинофильмны кабат – кабат күрсәтсәләр дә артыгы булмас шикелле!

Моннан берничә ел режиссер Рәмис Нәҗмиев: «Татарстан киносында әдәбият, гореф-гадәтләр юк. Милли күзаллау һәм аның нигезе юк, шуңа әлегә киносы да юк», дигән иде. "Өч аяклы ат" нәфис фильмында кайсы гына эпизодка тукталсак та, тәрбиянең өлгесе булып тора. Авыл халкының бер-берсенә мөнәсәбәте – фильмда иң якты урыннар. Татар халкы гомергә ярдәмчел һәм шәфкатьле булган, башка милләт вәкилләрен хөрмәт иткән, алар белән дус, тату яшәгән. Без моны Кәбир – Степан, Муса – Андрей мөнәсәбәтләрендә ачык күрәбез.

Фильм бик гыйбрәтле, безгә бик көчле тәэсир итә. Кәбир белән Сания апа арасындагы мөнәсәбәтләр сокландыра. Кәбир гел яхшылыкка омтылып, яхшылыкка ышанып яши. Шуңа күрә дөнья аңа яхшылык белән җавап бирә. Фильм авырлыкларга бирешмәскә өйрәтә, аны карагач, шундый нәтиҗәгә киләсең: дөньяда яхшы кешеләр күбрәк һәм авыр вакытта алар ярдәм итәргә әзер икән.

## III. Кино сәнгатенең киләчәге.

Күренекле шагыйрь, Разил Вәлиев, ике эшне дә берьюлы алып барырга кирәк, дигән фикердә. Хөкүмәтнең Татарстанны спорт аша гына танытуга басым ясавы дөрес түгел, кино аша да дөньяга татарның барлыгын белгертү мөһим, ди ул. Популяр чит ил кинофильмнары татарча яңгыраса да, тамашачыны татарча кинога якынайтыр, ана телебезгә хөрмәтне арттырыр, татар теленең даирәсен киңәйтер иде. Татар теленең мәйданы кысыла баруын күзәтәбез: мәктәптә, бакчаларда кими, дәүләт учреждениеләрендә шундый ук хәл, Татарстаннан тыш гомумән татар теле сүнүгә таба бара. Шуңа күрә мин бу юнәлештә дә эш барырга тиеш дип уйлыйм. Хыял – татар милли киносәнгатен аякка бастыру. Советлар берлегендә булган чакта урыс булмаган милләтләр арасында иң беренчеләрдән булып татарлар телсез кино иҗат иткән. Әле дә төшеп калганнардан түгелбез. Нәрсә кирәк? Акча, кадрлар юк дип зарланабыз, әйе, анысы да

мөһим. Әмма беренче чиратта теләк кирәк. Анысы да дәүләт дәрәҗәсендә булырга тиеш. Җитәкчелектә тәләк булса, хәл итмәслек мәсьәлә юк. Бу кинога да кагыла. Татарны милләт итеп танытыр өчен, иң кулайы әдәбият, кино сәнгате. Әмма әдәбиятның даирәсе кинога караганда таррак. Киносәнгать – ул иң йөремсәк, барысына да аңлашыла торган популяр сәнгать төре.

**Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була:** Рухи-әхлакый тәрбия бирү татар теле дәресләрендә татар киноларын, спектакльләрен крсәтү аша уңышлы тормышка ашырыла. Кино балаларны дулкынландыра, мавыктыра, көлдерә, елата. Һәрхалыкның үз киносы бар, алар барысы да буыннан буынга әхлакый кыйммәтләрне тапшыралар.

Аларда юмор да бар, ямансулык та, бер-береңә, иптәшләреңә, үз туганнарыңа һәм ниһаять иң мөһиме төрле милләт халкына тирән мәхәббәт ята. Дәресләрдә “Өч аяклы ат”, “Ак чәчәкләр”, “Тапшырылмаган хатлар”, “Бибинур” һәм башка татар киноларын күрсәтсәк, алар өчен кызыклы да ,файдалы да була дип уйлыйм.

Шул уңайдан Мансур Гыйләҗевның сүзләрен искә төшерәсе килә. “Киноны барлыкка китерү, аны көчәйтү - безнең милләтебез өчен актуаль проблема. Мәсәлән, татар дөньясы - без операсыз, балетсыз күп еллар яшәгәнбез, киләчәктә дә яшәрбез (минем һич тә операны кимсетәсем килми). Ә киносыз берничек тә яшәп булмый. Бүген милләт үзен кино аша күрсәтә ала. Аны барлыкка китермәсәк, безнең киләчәгебез дә бәхәсле. Билгеле, театрыбыз бик көчле, әдәбиятыбыз көчле. Ләкин заман таләпләре буенча, бүген безгә көчле кино кирәк

**IV. Файдаланылган әдәбият.**


1. Разил Вәлиев. Татар киносы хыялда гына кала. Мәкалә, 2016 ел.
2. Татар киносы туып килә. Мөршидә Кыямова, intertat.ru Татарстан Республикасы электрон газетасыннан.
3. “Өч аяклы ат” нәфис фильмы. “Татарстан яшьләре” газетасы, №46, 14.10.2008 ел.
4. Вәлиев Р. Информационное обеспечение процессов образования // Мәгариф.–2005.–№



**Шаева В. М.**
**«Татарстан Республикасы**
**Мөслим районы Тат.Шуран**
**төп гомуми белем бирү мәктәбе**


## АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ “ӨЧ АЯКЛЫ АТ” ӘСӘРЕНДӘ МИЛЛӘТ ФАҖИГАСЕ

Яңа татар әдәбиятында башка өлкәләр белән бер рәттән балалар әдәбиятына бик зур урын бирелде. Өч аяклы ат” әсәрендә төп проблема, халык арасындагы каршылыклар, ләкин әсәр төбендә милләт фаҗигасе ята. Әсәрдә Кәбир, Сания, Чтапан дәдәй кебек яхшы күңелле геройлар белән беррәттән үзләренең әшәкелеге, үчле булулары белән кешеләрнең канын эчүче Бөкебаш Галләметдин, депутат Саҗидәләр кебек тискәре образлар бар.

Фәнни эшне язу барышында Газинур Морат, Ибраһим Сәләхов һ.б. язучыларның хезмәтләре файдаланылды.

Эшнең темасы бик актуаль. Айдар Хәлим 2017 елда үзенең юбилеен билгеләп үтә, аның татар милләте, татар кешесе, татар аңы яктыртылган әсәрләре “Өч аяклы ат” белән генә бетми. “Татар вакыты” романында, “Авылдаш”, “Кыйбла”, “Эңгер” кебек күпсанлы хикәяләрендә дә татарның асылы булган һәм “иман”га нигезләнгән татар моңын эзләү, татар җанын “ терелтү ачык чагыла”. Алай гына да түгел хәзерге чорда әлеге теманы яктырткан Ф.Бәйрамованың “Болын”, Әхсән Баяновның “Урланган ай” һ.б. әсәрләрдә безгә яшы таныш.

Эшнең максаты: “Өч аяклы ат” әсәрендә татар милләте фаҗигасе мәсьәләсен өйрәнү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

– темага нисбәтле нәзари- тәнкыйди материал белән танышу;
– язучы иҗатына гомуми күзәтү ясау;

– “Өч аяклы ат” әсәренең образлар системасын барлау;
– Әсәргә структур һәм проблемалы- тематик анализ ясау.

Эш керештән, төп өлештән, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Айдар Хәлим татар халкы, татар милләте өчен янып- көеп йөргән шәхес. Авторның бик күп шигырьләрендә әлеге проблема күренеп үк ята.

Өч аяклы ат- ул безнен гарипләнгән, имгәтелгән, сугымга салынган милләтебез дигән фикер туа әлеге әсәрне укыгач. Чөнки, өч аяклы ат кебек үк безнең милләтебез имгәтелгән, имгәтелүенә карамастан, ничә гасырлар яшәп килә, милли йөзен югалтмый. Милләтне бары тик бердәм булганда гына саклап калап була. Бары тик хыянәтләр булмаганда гына яхшылыкка ирешеп була, татар милләтен саклап калып була.

Бу әсәр укучыны яхшылык белән явызлыкны, аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, өмет һәм иман белән яшәргә өйрәтә. Бу әсәр безне көрәшергә һәм җиңәргә өйрәтә.

**Шакирова Р. С.,**
**Гали Акыш исемендәге**
**84 нче лицей-интернатның**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## АЙДАР ХӘЛИМ ҺӘМ БАЛАЛАР ТӘРБИЯСЕ

Мин - танылган журналист, җәмәгать эшлеклесе, бөек йөз татар исемлегенә кергән шәхес Гали Акыш исемен йөрткән 84 нче лицей-интернат укытучысы. Әдипнең безгә васыять булырдай шундый сүзләре бар:

“Без телебезне, мәдәниятебезне саклап, кыямәт көненә кадәр иректә булып яшәрдәй шәхесләр үстерергә тиеш. Алар милләт өчен хезмәт итсен, динне хөрмәтләсен, тарихны белсен, дөнья белән дус яшәсен” .

Әгәр бу сүзләрнең авторын белмәсәм, һичшиксез, Айдар абый Хәлим сүзләре дип әйтер идем мин. Чөнки Айдар абый да бөтен барлыгы белән шуны тели дип чын күңелемнән әйтә алам. “Үзем турында” шигырендә:

Мин акыллы диеп,
Милли хисләремнең
Гөлбакчасын таптар хәлем юк,”- дип яза шагыйрь.

Ул - җәмәгать эшлеклесе дә, милләт өчен янып-көеп яшәүче сәясәтче дә, язучы-әдип тә ул, чит җирләрдә яшәүче, үз җиребездә гомер итүче милләттәшләребез тормышын, тарихын бәян итүче публицист та, шагыйрь дә һәм башкалар. Аның турында бик күп итеп, әсәрләрен анализлап язып булыр иде. Бу эшне коллегаларыбыз эшләр, ә мин Айдар абыйны, үзеннән ризалык алып, башка яктан ачарга тырышып карармын.

Минем **хезмәтемнең темасы: “Айдар Хәлим һәм балалар тәрбиясе”.**

**Максатым:** Айдар Хәлимнең яшь буынны тәрбияләүгә керткән өлешен, күпкырлы хезмәтен күрсәтү.

Алдыма куелган **бурычлар**:

- әдипнең тормыш юлын өйрәнү, искә төшерү;
- балалар өчен язылган шигырьләренә күзәтү-анализ ясап, тиешле нәтиҗәләр чыгару;
- каләмдәшләренең фикерләрен өйрәнү;
- аның катнашында лицейда узган чараларны, фотосурәтләрне барлау;
- үз балаларына мөнәсәбәтне ачыклау.
- презентация ясап, әзер мәгълүматны тәкъдим итү.

**II.Әдип һәм милли тәрбия.**

**1. Айдар Хәлим һәм аның балалар шигърияте.**

Аның туган ягы – Башкортостан. Бала чагы Кәркәле таулары кочагында, Өязе инешендә коенып, табигать кочагында, дүрт баланың берсе булып, эш белән уза. Миякә урта мәктәбен тәмамлаганнан соң бораулаучы һөнәрен үзләштереп, Каспий диңгезе буенда нефть эзләүдә катнаша. Армиядә хезмәт итә. Казан университетының журналистика бүлеген, соңрак СССР Язучылар Берлегенең Мәскәүдәге Югары Әдәби

курсларын тәмамлый. Түбән Камада, Уфада, Чаллыда журналист, техник белем буенча инженер, бораулаучы ярдәмчесе, Башкорт Академия театрының әдәбият бүлеге мөдире, "Аргамак" журналының баш мөхәррире булып эшли.

Аның әсәрләренә классикларыбыз Мостай Кәрим, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Ибраһим Сәлахов, Саҗидә Сөләйманова, Аяз Гыйләҗев, Миргазиян Юныслар югары бәя биргән. Ул төрле жанрларда язылган алтмышка якын китап, шул исәптән "Өч аяклы ат" повесте, "Хунвейбин" трилогиясе һәм "Кыйбла", "Кылганнар чәчкә атканда" кебек киң билгеле хикәяләр, “Татар солдаты” тарихи-фәлсәфи роман авторы. Гаяз Исхакый, Һади Атласи исемендәге әдәби премияләр иясе.

А. Хәлим беренче шигырьләрен хәреф таный башлагач язгалый, беренче шигыре район газетасында уналты яшендә басылып чыга. Шагыйрь язучы булырга хыялланмый. "Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты", — ди ул.

“Әтинең барлык иҗаты минем күз алдымда үтә диярлек. Кайчандыр ул илһамлы җиңеллек белән "җырлап", кайчакта тирә-ягында беркемне дә күрмичә, үз-үзенә бикләнеп, "җылап" яза. Шунысы кызык: аның иҗатының байтак өлешен шигърият алып торса да, мин аның шигырь язып утырганын күргәнем булмады. Гүя шигырь аның күңелендә төйнәлеп төймәләнә дә, ул аны кәгазьгә күчереп кенә ала. Аннан безгә укый. Әгәр өйдә беркем дә булмаса, берәр якын дустына, каләмдәшенә, алар булмаса, берәр танышына шалтырата. Укымыйча калмый, чөнки ул яңа әсәренең дөньяга тууын шулай итеп күңелендә ныгыта”. [Айдар Хәлимнең кызы Кадрия Хәлимованың иҗади эшеннән]

Айдар Хәлим шигъриятендә, жанр ягыннан чыгып караганда, балалар өчен язылган шигырьләр күп түгел, берничә генә. Алар арасында балалар һәм олылар тарафыннан да яратып укылган, аеруча автор башкаруында сәхнәдән яратып тыңланган "Кыяр караклары" бар. Әдипнең балаларга багышланган башка шигъри әсәрләре барысы да поэма жанрына карый: "Биктырыш", "Казлар көткәндә", "Казанбаш". Аның “Тал баласы Талхаветдин”, “Татар балалар шигърияте һәм “орчык-малай” Биктырыш” китаплары үзләре генә дә бик зур бәягә ия. Ул шагыйрьләребезнең иҗат үрнәкләрен этик-эстетик, әхлакый-әдәп һәм башка яклардан чыгып карый, уйлана, үз фикерен әйтә. Балаларга гамәлләре өчен җавап бирергә өйрәтә, яшь буынның киләчәккә булган иманы, ышанычы, гомерлеккә тапкан тормыш мәгънәсен ачып бирергә тырыша.

Аның балалар шигырьләрен дистәләрчә тапкыр укыганым бар. Әмма ул туйдырмый, һәрвакыт яңача ачылып, елмайттыра. Уйландыра, тәрбияли.

Балалар өчен язган һәрбер әсәрендә дә диярлек А.Хәлимнең үзен, сугыш ятимен, шулай да хыялларга, вакыйгаларга бай балачагын күрергә була. “Өч аяклы ат” әсәрендәге төп каһарман Кәбирнең башыннан үткән җан тетрәндергеч вакыйгалар – язучының үз язмышы. “Биктырыш” тагы “борчак малай, ут малай” – Айдар Хәлим үзе.

“...Айдар Хәлимнең балалар өчен иҗат итүе миңа бик сәер тоелды. Әле генә президентлар, ил башлыклары белән үз әсәре мөнбәреннән катлаулы бәхәсләр алып барган әдипнең, кинәт кенә сабый балага әверелеп, 6-7 яшьлек малай хакында поэма иҗат итүе шаккатырлык нәрсә бит!.. Күңелемә бик тә хуш килде, ошады миңа ул шук та, зирәк тә һәм бик тырыш та малай! Тырышлык, булганлык, чисталык-пөхтәлекнең татар халкындагы иң гүзәл сыйфатлар булып саклану-сакланмавы киләчәктә шушы бүгенге “Биктырыш” лардан торуы барыбызга да мәгълүмдер...” – дип яза Р. Вәлиев яңа басмага өстәп язылган “Балачакны сагыну” дигән сүз башында.

**2. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык, йөз аклыгы китерер.**

Милли тәрбия, милли үзаң, милли рухны тәрбияләү, минемчә, гаиләдән башланырга тиеш. Айдар абый Хәлим дә милли тәрбияне үз гаиләсеннән - кызларыннан башлаган. Кызларының барысы да туган телләренең, моң-көенең кадерен белә һәм аны саклауга үз өлешләрен кертә. Кызларының берсе – Зөлфиясе – Уфада яши. Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Илсөяре Казанда яши. Һөнәре буенча режиссер. Кече кызы Кадрия дә музыка мәктәбен уңышлы тәмамлады, бик матур итеп җырлый. Кызлары да, әтиләре кебек үк, милләтебезгә хезмәт итәләр.

Әтиләренең кызларына багышланган “Зөлфия дөньяга чыга”, “Илсөяр кызым

белән сөйләшү” шигырьләре, Кадриягә багышлап, “Беренче адымнар”, “Төнге поезд” шигырьләре иҗат ителгән. Алардагы балага мәхәббәт, беренче адымнарыннан ук, табигать, тормышны аңлату, аңлау белән тыгыз үрелеп бара.

Мин күбрәк шагыйрьнең кече кызы – иң яратканы, иң кадерлесе - Кадриясе турында сөйләрмен, чөнки ул минем иң яраткан укучыларымның берсе. Гали Акыш лицеен тәмамлаганнан соң, КФУ да белем ала. Киләчәктә журналист булу хыялын да тормышка ашырыр дип ышанасы килә. Чөнки ул лицейда укыганда шуңа әзерләнде: шәһәр газеталарында, лицейның “Илһам” газетасында мәкаләләре басылып чыкты, төрле бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулады. Аның бу һөнәрнең остасы булырлык сәләте бар. Гомумән алганда, Кадрия - бик тырыш һәм үз дигәненә ирешүче максатчан татар кызы. Фәнни-гамәли конференцияләрдә дә, иҗади эшләр бәйгеләрендә дә катнашты. Аның эшләре һәрвакыт үзенчәлекле, башкалардан аерылып тора. Ә бит Кадрия шундый актив, кешеләр белән аралашучан булсын өчен, әтисе нинди генә адымнарга бармады, хәтта Кадрия 5 нче сыйныфта укыганда ярты еллап интернатта яшәде. Ә Айдар абый аны көнаралаш лицейдан каршылап, музыка мәктәбенә йөртте. Менә бит ул ата мәхәббәте, ата җаваплылыгы!

“Татарга тылмач кирәк” дип аталган республикакүләм олимпиадада да, ике ел рәттән призлы урын яулады Кадрия. Димәк, бу - аның гаиләдә, лицейда, гомумән, һәркайда телнең тәмен белеп, сүзләрне урынлы кулланып сөйләшүе нәтиҗәсе. Укыган чорында да, сагынып укытучылары янына килгәндә дә, Кадрия һәрвакыт туган телендә сөйләшә, туган телен олылый.

7 нче сыйныфтан башлап, 11 нче сыйныфны тәмамлап киткәнче, Кадрия һәр елда, яңа тема алып, фәнни-эзләнү эшләре язды һәм республикакүләм “Яшьләр фәнни эзләнүдә”, шәһәркүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә, “Ломоносов укулары” нда чыгыш ясап, призлы урыннар яулады. Менә аларның кайберләре: “Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасы үзенчәлекләре”, “Айдар Хәлимнең балалар шигъриятендә бәхет мәсьәләсе”, “Айдар Хәлимнең балалар өчен "Тал баласы Талхаветдин" дигән китабыннан бер хикәятнең язылу тарихы турында”. Бу фәнни эшләрдә фикерләр, нәтиҗәләр бик үзенчәлекле ясала. Мәсәлән, Габдулла Тукайның “Шүрәле” поэмасын өйрәнгәннән соң, Кадрия шундый нәтиҗәләр ясый:

“Беренчедән, Тукай тере һәм тере булмаган табигатьне күз алмасы кебек сакларга, аларның матурлыгының кадерен белергә, акыл белән яшәргә, вак нәрсәләргә алданмаска, халыкның тирән тел-авыз иҗатын өйрәнергә куша. Икенчедән, кешелек табигатенә дә, кыргый табигатькә дә Тукай бер үк тигез мәхәббәт белән килергә куша. Һәм безгә дә табигать, кешеләр белән эш иткәндә ашыкмаска куша. Өченчедән, Тукай җанлы һәм җансыз табигатьне бер үк сөю белән сөюне шарт итеп ала, безгә шуны васыять итә. Тукай карурманда шүрәлеләр дә булырга тиеш дип, исән калдыра. Дүртенчедән, һәр кеше үзенең тарихын белергә, аның белән Тукай шикелле горурланырга, аянычлы хәлләрен күреп борчылырга, аннан чыгу юлларын эзләргә тиеш. Татар милләтенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында барыбыз да уйлану мөһим”.

Кадриянең “Айдар Хәлимнең балалар өчен "Тал баласы Талхаветдин" дигән китабыннан бер хикәятнең язылу тарихы турында”дип аталган эшенең нәтиҗәсе мондый: “... Шулай итеп, базар мәйданында Тал Баласы Талхаветдин тарафыннан табылган бер тәңкәлек көмеш яшь буынның киләчәккә булган иманы, ышанычы, гомерлеккә тапкан тормыш мәгънәсе буларак сурәтләнә язучы тарафыннан.

Китаптагы һәр хикәят шундый тирән мәгънәгә ия. Мин барлык балаларның бу җыентыктагы рухи-рухани хәзинәләрне укып куанырга, дөрес юлга, хак юлга басарга ашыкмауларына борчылам. Шулай да өметемне өзмим, кем белә, килер шундый көннәр, китап дигән бөек байлык тагын да халкыбызның акыл һәм әдәп чыганагына әверелер. Шулай була күрсен иде!..”

Мондый тирән фикерләр әйтә алган баласы булу һәр ата өчен горурлык булыр иде. Айдар абый Хәлим өчен бигрәк тә. Минемчә, кызында ул үз чалымнарын күрә, фикердәшен табадыр. Кызы да милләт язмышы, аның рухи-рухани хәзинәләре өчен борчыла, татар милләтенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында барыбызны да уйланырга чакыра.

Кадрия лицей тормышында актив катнашты. Әтисенең “Өч аяклы ат” әсәре буенча куелган фильмын да, әле башкалар күргәнче, лицейга Кадрия алып килеп күрсәтте. Үзенең иҗади эшләре белән төрле бәйгеләрдә катнашты. Мәсәлән, “Габдулла Тукай – публицист” дип аталган республикакүләм иҗади бәйгесендә “Тукай әкиятләре яхшылыкка, матурлыкка өнди” номинациясендә җиңүче булып, дипломга лаек булды. Бу җиңүләрдә, үзе һәм укытучысы белән беррәттән, әтисенең дә өлеше зур дип саныйм мин.

**3. Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернатта Айдар Хәлим тәрбиясе.**

Айдар Хәлимнең 84 нче лицей-интернаттагы эшчәнлеге күпләрне сокландырырлык. Безнең коллектив, шул исәптән укучылар да, Айдар абыйны “лицейның атасы”, Гали Акыш дәвамчысы дип атыйлар, чөнки ул үзенең эшчәнлеген лицей ачылган көннәрдән үк башлаган һәм дуслыгыбыз бүгенге көннәргә кадәр дәвам итә. Бик еш мөрәҗәгать итәбез без аңа. Ул безне һәрвакыт игътибар белән тыңлый һәм үзенең киңәшләрен бирә. Лицейның 20 еллык тарихында Айдар абый Хәлим - балаларны, ата-аналарны милли юнәлештә тәрбияләүдә төп терәк булган шәхес. Хәзер бераз сирәгәйсә дә, безнең очрашуларда Айдар абый Хәлим һәрчак көтеп алынган кадерле кунак. Шагыйрь һәрвакыт: ул “Әтиләр конференциясе” ме, “Мин татарча сөйләшәм” акциясеме, “Белем бәйрәме” яки “Соңгы кыңгырау” мы, әллә тагын “Сәләтлеләр парады” мы үзенең сүзен укучыларның күңеленә үтәрлек итеп әйтә белә, тирән эчтәлекле шигырьләрен укый, шунда шаяртып, көлдереп тә ала. Аның саллы сүзе һәрчак әзер. Очрашуларга ул һәрвакыт теләп, китап-күчтәнәчләре белән килә. Ә инде шагыйрьнең үз куллары белән теләкләр язылган култамгалы китаплар алу балалар өчен зур дәрәҗә. Сүз уңаеннан, безнең китапханәбез дә Айдар Хәлимнең бүләк иткән китапларына бай. Без аңа бик рәхмәтле.

Айдар Хәлимнең “Өч аяклы ат” әсәре буенча төшерелгән фильмы Мөселман кинолары фестивалендә дәрәҗәле урынын алгач, фильмны, әле башкалар күргәнче, лицейга Кадрия алып килеп күрсәтте. Ул балалар күңелен тетрәтте, хисләр өермәсен кузгатты, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәде. Фильмны караганнан соң, балалар иншалар яздылар. Аларның иншалары газеталарда басылып чыкты. “Өч аяклы ат” әсәрендәге төп каһарман Кәбирнең башыннан үткән җан тетрәндергеч вакыйгалар – язучының үз язмышы булуын да белгәч, тәэсир итү көче бермәбер артты Иншалардан юллар...

“...Айдар Хәлим Бамбукны безнең Татар милләте белән чагыштыра. Аның белән ул безгә Татар милләтенең ат шикелле аксаганын күрсәтә. Ләкин, безнең милләтне Кәбир кебек алга тарткан кешеләр дә бар. Әгәр дә безнең илдә милләтне алга тарткан кешеләр артмаса, безнең милләт Бамбук урынында калачак!..” [Азат Нәҗмиев, 8Б сыйныфы]

“ ...Минем фикеремчә, сүз монда җәмгыятьтәге таркаулык, кешеләрнең бер-берсен кыерсытуы, рәнҗетүе турында гына бармый. Бу фильмда милләт һәм аның язмышы сурәтләнә. Өч аяклы атка яшәве авыр, яки бөтенләй мөмкин булмаган төсле, милләткә дә, үз халкы арасында дуслык, бердәмлек булмаса, тормыш итүе катлаулы. Алай гына да түгел, мондый милләтнең киләчәге булмаска мөмкин. Шуңа күрә дә бер милләт кешеләре үзара дус яшәргә тиеш. “Бердәмлектә-көч” дип юкка гына әйтмиләр бит. Мин бөтен татар халкына шуны әйтер идем: әйдәгез, тату һәм бердәм булыйк, бер-беребезнең уңышларыннан көнләшмик, ә киресенчә, аңа шатланыйк. Бер-беребезгә һәрвакыт ярдәм итик, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклыйк, хөрмәт итик! Шулай яшәгәндә генә милләтебезнең киләчәге матур булыр. [Шәйхлисламова Айгөл. 10 В сыйныфы укучысы]

Язучы-шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерен укучылар үзләре әйткән: бердәмлек булмагач, җәмгыять таркала башлый, аның билгеле юлы булмый, ул алга бара алмый. Ул үзе дә шул өч аяклы ат хәлендә калган кебек. Ат та бит бер генә аягы аксаса да, нинди фаҗигага дучар була... Димәк, милләтебез алга китсен, аны хөрмәтләсеннәр өчен бердәмлек кирәк.

Айдар Хәлим бик еш була лицейда. Әле директорыбыз Ш.Р.Закиров янында ул, әле укучылар белән сөйләшә. Ул да булмый, Айдар абый дәресләргә кереп, шигырьне аңлау, аны ишетү, күрү серләренә өйрәтә, балаларның күңел кыңгыравына кагыла, аларны да иҗат итәргә этәрә. Шундый дәресләреннән соң, балалар күңелендә дә шигырь туа. Мәсәлән, 8Б сыйныфы укучысы Салахова Ландыш язган

“Шигырь сере” шигыре. [1нче кушымта]

Шагыйрь Айдар Хәлим һәм язучы-милләтпәрвәр Фәүзия  Бәйрәмова белән очрашу да тирән эчтәлекле булды. Кичә мәҗлесләр залында укытучылар, укучылар белән очрашудан башланып, сыйныфларда дәрес-әңгәмәләр белән дәвам итте. Әдипләрнең һәрберсе милләтне әйдәп баручы зыялыларның нинди булырга тиешлеге, милли үзаң, милли горурлык турында әңгәмә корды

Шагыйрь үзенең дусты Рубис Зарипов белән килә очрашуларга.  Айдар абый шигырьләрен укып җанны тетрәндерсә, Рубис абый тальян моңнары һәм җырлары белән күңелләргә керә, уйландыра, хәтта мәҗбүр итә иде. Аннан парлашып уйнап җырлыйлар. Балачакларын искә алалар. Укучылар бу очрашулардан канәгатьләнү хисләре алалар. Бу – буыннар очрашуы, буыннарның бер-берсенә әйтер сүзе, милли моң тәэсире, милли тәрбиянең иң көчле, иң тәэсирле чарасы. Шундый шәхескә ничек рәхмәтле булмыйсың да, ничек аны хөрмәт итмисең. Ирексездән күңелдә шигырь туа. “Юбилей уңаеннан Айдар абый Хәлимгә” шигыреннән өзек. [2 нче кушымта]

**III. Шагыйрьнең иҗаты һәм эшчәнлегенең  әһәмияте.**

Укучысына татар теленең чиксез мөмкинлекләрен күрсәтү белән бергә, әдипнең бигрәк тә балалар өчен язылган әсәрләре зур тәрбияви дәрес бирә. Аны матурлык тәрбиясе, тарих тәрбиясе, табигать тәрбиясе, иман тәрбиясе дип тә атарга мөмкин. Бу тәрбия һәр вакыйгадан, геройларының һәр гамәленнән, үз-үзләрен тотышларыннан, сүзләреннән-күзләреннән саркып тора. Иң мөһиме: Айдар Хәлим балаларга Аллаһ яраткан матурлыкны, дөньяны таный, саклый белергә өйрәтә [Ф.Бәйрәмова. Кылган күзен ачкан әдип. “Мәйдан” журналы, №3, 2012 ел].

Айдар Хәлим - милләтебез киләчәген уйлап иҗат итүче шагыйрь. Балалар өчен язылган  шигырьләре дә, гамәлләре дә фәлсәфәгә этәрә. Аларны уйланырга мәҗбүр итә, гыйбрәт алырга куша. Ул сабыйларның күңел дөньясына килеп кагыла да алары реаль тормыш белән очраштыра, олыларча фикер йөртергә  өйрәтә (“Казлар көткәндә ” шигыре, лицейдагы чаралар).

Әйе, бүгенге көндә көне-төне компьютер каршында, интернетта утырган балалар өчен бу бик мөһим, чөнки бүгенге балаларның күбесе табигатьтән ерак. Шул сәбәпле алар табигатьнең матурлыгын күрүдән, аны таный, бәяли белүдән мәхрүм. Шундый чакта аларга Айдар Хәлимнең геройлары кебек табигать телен аңлаучылар кирәк. Ул шигырьләрендә балаларны җитәкләп болыннарга-кырларга алып чыга, чикерткәләр симфониясен тыңлата, кош булып, күкләрдән җыр яңгырата.

Айдар Хәлимнең балалар шигъриятендә шундый фикер  кызыл җеп булып сузылып китә:  җир йөзендәге һәр баланың, милләтенә, тән төсенә карамастан, бәхетле булырга хакы бар.  Гүя аның балаларга шундый шартларны  бүләк итәсе килә. Мондый гармониядә яшәгән  хәлдә  кешеләр  генә түгел, Өязе ярларында Биктырышка охшатып китап укыган "кырык кырмыскалар" да бәхетле була,  дип ышандыра   безне автор. Аның шигырьләре уен аша гыйбрәт алырга чакыра, белемлелеккә өнди, тәрбияли. Мин моңа чынлап та ышанам һәм чын күңелемнән куанам.  Әгәр без Айдар Хәлим әсәрләрен  укысак  һәм алардагы  уңай  геройлар  кебек яшәсәк, бәлки күпкә  бәхетле  булган булыр идек.

“Тормышның мин ике даһиен беләм:

Берсе – ут, икенчесе- бала.

Икесе дә мәңгелек,  икесе дә кешелекне җылыта,”- ди әдип. Кешелекне  җылытырлык милләт балалары үстерерлек шагыйрьләребез булганда, милләт яши, үсешкә ирешә. Әдипнең шигърияте дә, барлык кылган гамәлләре дә милләтнең бәхетле киләчәгенә җирлек. Бары тик тырышлык кына милләтебезнең яшәү рәвеше, яшәү гамәле булып кала.

**IV. Кулланылган әдәбият.**

1. Айдар Хәлим. Биктырыш: Поэма. - Казан.  1994.
2. Айдар Хәлим. Казанбаш: Поэма. Татарча -русча басма. - Казан, "Идел-Пресс" нәшрияты, 2004.
3. Айдар Хәлим. Кыяр караклары: Шигырьләр. –Казан: "Раннур" нәшрияты, 2002.
4. Айдар Хәлим. Татар балалар шигърияте һәм “орчык-малай” Биктырыш китабы,

АРП “Диамант”, 2011
5. Айдар Хәлим. Печән чапканда: Поэмалар. -Казан. " Идел-Пресс " нәшрияты, 2004.
6. Айдар Хәлим. Тилергән сирень: Поэмалар һәмм шигырьләр –Казан, Рухият" нәшрияты, 2003.
7. “Мәйдан” журналы, №3, 2012.
8. Гали Акыш исемендәге 84 лицей-интернатның архивы

**Шигырь сере**

„Айдар Хәлим –кем?” – дисәгез,
Аңлатам читкә китми...
Шагыйрь дә ул, прозаик т а.
Тәнкыйтьне дә чит итми

Айдар абый - булган бит ул!
Өлгерә ул һәр эшкә.
Шигырь серен аңлатты ул
Шулай безгә дәрестә...

Шигырь ямен, гүзәллеген
Күрегез күзләр белән,
Сүзләренең тәмен татып,
Аңлагыз йөрәк белән.

Күңелеңнең кыңгыравын
Чыңлатса әгәр шигырь...
Ишет син аны: аһәңен,
Моңын той, аның көен.

Хәзер инде шигырьләрне күрәбез, ишетәбез,
Йөгереп эченә керәбез, тоярга сүзләр тәмен.
Ишетәбез җан авазын, абайлап дөнья ямен.

Шигырьләре - сихри сандык сыман,
Һәрбер юлы серле, хикмәтле.
Сүзләрендә тирән мәгънә аның
Энҗе бөртегедәй кыйммәтле.

**Юбилей уңаеннан Айдар абый Хәлимгә.**

Һәрбер чорның үз әдибе, үз галиме...
Кешеләргә бәя бирә гамәлләре.
Һәр заманның инсанына үз таләбе,
Шагыйрьләрнең төп коралы - каләмнәре!

Үз эшенең галиҗәнап профессоры,
Язганнары йөрәкләргә үтә туры.
Зыялы да, сабыр да ул,
Кирәк чакта арсландай батыр да ул -
Курку белмәс ватанпәрвәр татар улы.

Хөрмәт итә зыялылар, мөгаллимнәр,
Киңәш ала олылар да, балалар да.
Лицейның Сез аксакалы, кунагы да,

Кирәк чакта, ярдәм итәр атасы да.

Янып-көеп: “Татар!”- диеп,
Сизелмичә айлар ага, еллар ага...
Милләтемнең каһарманы, яклаучысы,
Телебезнең сакчысы Сез, Айдар ага!

Раббем Сезгә сәламәтлек, гомер бирсен.
Хезмәтегез тиешенчә бәяләнсен.
Каләмегез тутыкмасын, ялтырасын,
Җан авазы Ода булып яңгырасын!

**Шәйхуллина З.Н.**
**I кв. категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**“Татарстан Республикасы Мөслим районы**
**Мари Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе”**

### Шагыйрь Рифат Сәлах шигырьләрендә әхлак тәрбиясенең чагылышы

**Кереш.**

Кешенең нинди икәнен беләсең килсә, аның туган ягына барып кара ,диләр. Шагыйрьнең нинди уйлар белән януын, нәрсә өчен борчылуын һәм шатлануын беләсең килсә, аның иҗаты белән таныш! Мин үземнең фәнни эшемне Рифат Сәлах шигырьләрендә чагылган –әхлак темасына багышладым.

**Теманың актуальлеге.**Бүгенге көндә татар рухи дөньясында әһәмиятле роль уйнаган яшь шагыйрьләр шактый, аларның берсе- Рифат Сәлах . Иҗатын төрле юнәлешләрдә башлап, ул җәмгыятебезне борчыган проблемаларны колачлый алды. Нәкъ шушы сыйфаты белән ул укучыларның үзенә җәлеп иттермәде микән?

Һәр әдип үз заманыныннан, үз чорыннан аерылгысыз. Рифат Сәлах иҗаты теленең матурлыгы, фикерләренең фәлсәфилеге, темаларының киңлеге белән үзенә тартып тора.Һәрбер шигыренең асылында туган як, туган тел, әхлаклылык ята. Бу яктан аның иҗатын өйрәнү аерым әһәмияткә ия. Боларны ачыклау өчен аның әсәрләрен тикшерергә, аларга бәяләмәләр бирергә кирәк.

**Хезмәтнең максаты** – Рифат Сәлах шигъриятен тикшереп, аларда әхлак темасының бирелешен ачыклау. Бу максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне күтәрдем:

- әдипнең язган әсәрләрен, китапларын барлау, аларны өйрәнү;

-аларга бәяләмә бирү, үз мөнәсәбәтемне ачыклау;

**Өйрәнү объекты һәм предметы**- Рифат Сәлах әсәрләре.

**Тикшерү методы** итеп әдәби анализ һәм бәяләмә алымнарын файдаландым.

**Эшемнең фәнни-практик әһәмияте-** татар әдәбиятында укучыларга әхлак тәрбиясе бирүне яшь шагыйрь Рифат Сәлах иҗатын тикшерү аша ачыклау.

**Кереш.**

Кешенең нинди икәнен беләсең килсә, аның туган ягына барып кара ,диләр. Шагыйрьнең нинди уйлар белән януын, нәрсә өчен борчылуын һәм шатлануын беләсең килсә, аның иҗаты белән таныш! Мин үземнең фәнни эшемне Рифат Сәлах шигырьләрендә чагылган әхлак темасына багышладым.

**I бүлек Әхлак төшенчәсе.**

Татар халкында борын-борыннан ата-анага,туган ил,туган җиргә,туган телгә мәхәббәт,якыннарга ,туган-тумачаларга кадер-хөрмәт хисләре яшәп килгән. Бу хисләр әби- бабаларыбыз тарафыннан югары бәя алган. Бу сыйфатларны без “әхлак”, тәрбияле кешене әхлаклы дибез.

Татарларда “фарыз[14]” дигән сүз йөри, бу гарәп теленнән кергән. Ул “бурыч”, ”үтәлүе

---

[14]Ганиев Ф.Ә., Миннибаев К.С., Газизова Ф.М.,Саберова Г.Г., Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 816 нчы

мәҗбүри бурыч ( эш)” дигән мәгънәне белдерә. Безнең барыбыз өчен дә әти- әнине, үзебездән өлкәннәрне олылау; икмәкне кадерләү; туган-тумача, нәселеңне хөрмәт итү - фарыз гамәлләр.Шушы фарыз гамәлләрне үтәү , әхлаклылык дигән билгеләмәгә нигез булып торадыр да инде.

“Әхлак- кешеләрнең җәмгыятькә һәм бүтән кешеләргә карата мөнәсәбәтләре[15]” Шушында ук әхлаклы сүзенә “әхлак ягыннан тотанаклы: тәрбияле; әдәпле” аңлатмалары бирелә. Димәк, әхлакның үзәгендә - кеше.

Кеше – табигать баласы гына түгел, җәмгыять җимеше дә. Һәм әйтергә кирәк, монысының урыны хәтта зуррак та. Җәмгыятьнең ниндилеге , иҗтимагый һәм тарихи шартлар инсанга, аның үз-үзен тотышына гаять зур йогынты ясый.

Билгеле булганча, һәр чорның үз кануннары, әхлакый нормалары бар. Шушы чорда яшәгән һәр кеше бу кануннарга буйсынырга һәм әхлакый нормаларны үтәргә тиеш.

**II.Әхлак тәрбиясенең нигезләре.**

Минемчә, әхлак тәрбиясенең нигезендә гаилә ята. Гаиләдә алган тәрбия балалар бакчасында, мәктәптә бары тик ныгытыла гына. Тәрбия ике якның бердәм, бер максат куеп тырышлыгы нәтиҗәсендә генә уңышлы була ала.

Балалар бакчасында алган тәрбия, мәктәп бусагасын атлап кергәч, тагын да баетыла һәм ныгый.

Татар халкы өчен кадерле һәм хөрмәткә лаек күңел байлыкларын без балага бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә җиткерәбез. Халык авыз иҗаты әсәрләреннән алып, бөек язучыларыбызның тиңдәшсез иҗат җимешләре,аларның төпле фикерле әсәрләре аша укучы үзендә тормыш тәҗрибәсе туплый, тиешле тәрбияне ала.

Танылган язучыларыбыз иҗаты аша укучы үзендә булган яхшы һәм начар якларны күреп ала, аны яхшы якка үзгәртергә тели, начар адымнары өчен кызара. Әхлаклы булу[16]( тәртипле,тәүфыйклы,инсафлы, әхлак кагыйдәләренә ярашлы рәвештә яшәүче) яхшы кешеләр, аларда уңай сыйфатлар күрергә теләү, әсәрләре аша тәрбияләү һәрбер язучының изге бурычы.

**III.Шагыйрь Рифат Сәлах шигырьләрендә әхлак тәрбиясенең чагылышы.**

Мин дә бу зур төшенчәнең кечкенә генә бер өлешенә ачыклык кертү теләге белән, яшь шагыйрь Рифат Сәлах иҗатына мөрәҗәгать иттем.

Фәнни эшемне Рифат Сәлах иҗатына, аның шигырьләренә нигезләнеп башкардым. Фәнни эзләнү эшемнең ахырына кадәр шагыйрь иҗатында әхлак тәрбиясе чагылышын тикшердем.

Шагыйрь– Рифат Сәлах авыл малае.Ул саф һавалы, эш сөючән күркәм холыклы, уен-көлкегә, җыр – моңга гашыйк авыл агайлары, апалары тәрбиясен күреп үскән егет.

Рифат Гали улы Сәлахов (Рифат Сәлах) 1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында дөньяга килә. Ул тел-әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлый. Беренче шигырен бишенче сыйныфта яза. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша. 2004 елда туган авылындагы урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. Шигырьләре матбугатта даими басыла, «Безнең гәҗит», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында мәкаләләре дөнья күрә.Рифат Сәлах бүгенге көндә алты китап авторы. "Күңел бөртекләре" (2007), "Яшел ай" (2009), "Ташта үскән гөлләр" (2012) шигырь китаплары һәм автор-төзүче буларак Муса Җәлил иҗатына багышланган балалар өчен "Җәлил варисларына" (2016) китаплары Татарстан китап нәшриятында басыла. Сүрәя Гайнуллина тәрҗемәләре белән татарча-русча "Кызыл юл - Алый путь" (2015) китабы "Ак бүре" нәшриятында, Азәрбайҗан шагыйрәсе Сона Вәлиеваның татарчага тәрҗемә итеп, "Аразбары" китабы "Илһам" нәшриятында дөнья күрә. Шагыйрь Рифат Сәлахның чираттагы

---

бит Казан:”Матбугат йорты” нәшрияты,2005.-848 б.

[15] Ганиев Ф.Ә. , Миннибаев К.С., Газизова Ф.М., Саберова Г.Г., Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге ,751 нче бит Казан:”Матбугат йорты” нәшрияты,2005.-848 б

[16] Ганиев Ф.Ә. , Миннибаев К.С., Газизова Ф.М., Саберова Г.Г., Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге ,751 нче бит Казан:”Матбугат йорты” нәшрияты,2005.-848 б

китабында аның өр-яңа шигырьләре туплап бирелә. Алар укучыны уйландыра, гаҗәпләндерә, сискәндерә, күңелдә хисләр өермәсе уята. “Җәлил варисларына” исемле яңа китап дөнья күрде. Советлар Союзы Герое, шагыйрь, көрәшче Муса Җәлилгә багышланган китапның автор-төзүчесе – шагыйрь Рифат Сәлах.

2015 һәм 2017 елларда ТР Язучылар берлеге аны Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә тәкъдим итә.

Әби – бабайлы тулы гаиләдә үскән баланың күңеле бай, тормышка карашы да уңай. Башкалардан үзенең тәрбиясе, сакчыллыгы бер сүз белән әйткәндә, әхлаклылык белән дә аерылып тора. Моның сәбәбе нәрсәдә соң?

Әхлак туган телне, туган илне яратудан башлана дидек.Балада бу хисләргә нигез салу гаиләдән башлана. Чыннан да, һәр кеше үз туган телен хөрмәт итәргә, яратырга ,аның белән горурланырга тиеш. Туган телнең язмышы, киләчәге яшь буынны шагыйрьл дә битараф калдырмый. Алар тел язмышы өчен борчылалар, туган телне саклап калуга үзләреннән өлеш кертергә тырышалар. Рамил Сәлах тел өчен борчуларын “Имансыз татарларга” шигырендә түбәндәгечә җиткерә:

Бу дөньяда изге сүзләр:
Туган тел бар, Ватан бар!
Сезгә бу сүзләр танышмы,
Әй, имансыз татарлар!
Ана теле кирәкмидер
Маңкорт булыр буынга.
Нигә кирәк булды сезгә
Татар булып туарга?

Туган телен яраткан хөрмәт иткән кеше аңа беркайчан да хыянәт итмәс.

Нинди генә биек үрләр яуласак та, безне хөрмәтле кеше иткән ул безнең газиз туган илебез. Димәк, туган телен хөрмәт итмәгән кеше үзендә, ата-анасын да хөрмәт итми дигән сүз.

Туган тел белән янәшә туган җир, туган туфрак төшенчәсе. Туган җирен ярату, анда хезмәт кую әхлаклы кеше өчен иң мөһим сыйфатларның берсе. Яшьлегендә бәхет эзләп ерак җирләргә, калаларга киткән кешеләр дә бер көн килеп, туган җирләрен туган туфракларын сагыналар. Үзләре өчен туган җирдән дә кадерлерәк җир булмавына кабат инаналар. Туып үскән газиз җирләргә кабат кайтырга чакыралар. Рифат Сәлах та бу хисләрен үзенең “Син кайт әле” дигән шигырендә ачык чагылдыра.

Син кайт әле дустым, ерак китмә,
Кайт әле син Идел буена.
Анда сине көтеп балыклар да
Яр буенда гына коена.
Анда сине көткән су кызлары
Озын чәчен тарый басмада.
Бөтен гөнаһларың коелырлар
Туган җиргә аяк басканда.
Сагынуга түзеп яшәгәнче,
Бер кайтуың илгә – мең шифа.
Үләннәрдә борынгыдан калган
Җанны эретерлек моң шыта.
Син кайт әле дустым, читтә йөрмә,
Сагынуга башка чара юк.
Анда озын толымнарын үреп,
Су кызлары көтә саргаеп.

Татар халкында борын – борыннан килгән матур гадәт-гаиләдә ата- аналарга хөрмәт, аларны зурлау. Үз ата- анасын үз гомереннәндә артык яраткан баланы ничек әхлаксыз дип әйтергә була! Балага тормыш бүләк иткән ,туган телгә һәи илгә мәхәббәт тәрбияләүче кадерле кешеләребез – әниләр. Әниләр сызган туры юл бары тик яхшылыкка һәм

башкаларның сине хөрмәт итүләренә генә илтә. Шагыйрь газиз әниләргә булган рәхмәт һәм хөрмәт хисләрен "Әни" шигырендә түбәндәге юллар белән белән белдерә:
Бу дөньяның фани гүзәллеге
Беркайчан да күммәс бәгыреңне.
Яз кояшы җанда мәңге балкыр
Гел кадерләп торсаң әниеңне.
Бу дөньядан кемдер җылы эзләр,
Кояш йә ай бирмәс андый назны.
Бар җылылык әни йөзләрендә,
Әни күңле һәрчак сандугачлы.
Бу дөньяда саф мәхәббәт эзләп,
Ялгышадыр күпләр әле бездә.
Безнең өчен бөтен күңлен биргән,
Иң сөекле сөю әниебездә!

Дине, иманы булган кеше генә башкаларга карата мәрхәмәтле һәм хөрмәтле була ала. Иманлы кешенең генә үз кыйбласы бар. Бу мәсьәләдә Рифат Сәлахның фикерен белү өчен "Изге Коръән" шигыренә мөрәҗәгать итик:
Изге Коръән —
Күңелләрдә балкый бер нур,
Изге Коръән —
Бер Аллаһтан безгә иңгән!
Изге Коръән —
Яшәр өчен бердәнбер юл,
Изге Коръән!
Могҗиза да, рәхмәт тә ул!

Ә менә "Игътикаф" шигыре белән автор үзенең иманлы һәм инсафлы икәнен исбатлап күрсәтә:
Җәйге җомга җылы була диләр,
Әллә кая киткән бөркүлек…
Ә күңелләр безнең туңмас бүген
Иман нуры торса бөркелеп.
Табигать тә, әнә, су коена,
Ул тәһарәт алып өлгергән.
Урамнарда канәферләр балкый,
Урманнарда пешә бөрлегән.
Тузан сулап җир дә өшәнгәндер,
Саф һавага дөнья сусаган…
Гыйбадәткә генә качып була,
Тормыш дигән кысан кысадан.
Дөнья хәятенә буйсын әйдә,
Табигатьне тиргәп ваксынма.
Бер әйләнеп килсәң иман йортын,
Мәшәкатьнең бетәр барсы да!

Җомга бәйрәме котлы булсын!

Тормыш йөген тартыр өчен, дуслар да кирәк бит әле. Минемчә, чын дус берәү генә буладыр.Авыр чакта ярдәм кулын сузардай, кайгың булганда синең белән кайгыручы, уңышларыңа чын күңелдән сөенүче- менә кем ул чын дус. Иң мөһиме – эшләгән яхшылыклары өчен бернинди хак та, бәя дә сорамаучы кеше. Моннан да мактауга лаек булырлык сыйфатлар бармы соң?! Ничек инде бу кеше тәрбиясез була алсын ди.

## Йомгаклау.

Рифат Сәлах иҗаты белән якыннан танышканнан соң, шундый фикергә килдем: үзеңнең яхшы һәм начар сыйфатларыңны күрер, яхшы якка үзгәрер өчен татар әдәбиятында матур, эчтәлекле әсәрләре белән бай мирас калдырган язучылар һәм

шагыйрьләрнең иҗатын тирәнтен өйрәнү дә бик мөһим. Бу тормыш тәҗрибәсе туплаган, тормышның

Кеше тормышындагы туган телне хөрмәтләү, туган җирне саклау, ата- ана хакын хаклау кебек иң олы кыйммәтләрне үзебездә тәрбияли алсак, без дә иманлы кешеләр, алдагы көндә татар милләтенең сагында торучылар булыр идек.

Уйлап карасак, бу бер дә авыр эш түгел бит!

**Библиография**


Кулланылган әдәбият

1.Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият 10 сыйныф өчен дәреслек. – “Мәгариф”нәшрияты.- Казан. 2002

2. Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009 ел.

3. Батулла Р. Сихрилек //Мәдәни җомга. — 2006. — 9 июнь.

4.Ганиев Ф.Ә. , Миннибаев К.С., Газизова Ф.М., Саберова Г.Г., Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге ,751 нче бит Казан:”Матбугат йорты” нәшрияты,2005.-848 б

5.Гыймадиева Н. Дәресләрдә әхлак мәсьәләләре. // -Мәгариф.-2003. -№3

6. Зарипова А. Эзләнүчән укучыларыгыз булсын // Мәдәни җомга. — 2009. — 5 июнь.

7. Зәйдулла Р. Шигырьләргә кереш сүз // Идел. — 2005. — № 10.

8. Зәйдулла Р. Яңгыравык балчык // Идел. — 2008. — № 2. — 36-37 б.

Интернет ресурслар

1.tt.wikipedia.org›Рифат Сәлах

2. azatliq.org



**Шиһапова А.Р..**
**Татарстан Республикасы**
**Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**
**4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”**


## АЙДАР ХӘЛИМ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРИ ЛЕКСИКАНЫҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ .

Гомумән татар сүзләре кебек үк, татар һөнәри лексикасы да чыгышы белән берничә чыгынакны үз эченә ала. Әби-бабаларыбыз арасында һөнәрчелекнең борынгыдан чәчәк атуын искә алганда, борынгы чордан ук барлыкка килгән һөнәри лексиканың күп булуына алшарт булып тора. “Археологик казылмалар Идел Болгары шәһәрләрендә кара металлургия, тимерчелек, зәркән, бронза кою, чүлмәк ясау, күн, агач эшкәртү кебек җитештерү өлкәләре һәм һөнәрләренең булуын раслый”, – дип яза И.Ә. Гафаров. – Археология мәгълүматларына караганда, болгар осталары аркылы балта ярдәмендә эшкәртелгән тактаны киң файдаланганнар, пычкыны да белгәннәр. Алар бүрәнәләрне чөй белән һәм терсәкле тоташтыру алымын да файдаланганнар һәм моны бик оста башкарганнар. А.Хәлим әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, әдип кулланган профессионализмнарның чыганакларын билгелик. Татарның борынгыдан, гомумтөрки телдә үк формалашкан, берегеп калган сүзләрдән түбәндәгеләр теркәлде:

Яктыдан яктырakka өндә!
Ян!
Соңлама, төнгә көн **сипләә!**
Ян!

Икенче мисал:

Халык телендә “тастымаллык” дип аталган шадра тукымадан, **кулдан, эре атлатып тегелгән** һәм әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл киҗеле кыска киндер ыштан белән өстен-башын бөтәйтеп алган һәм шул ыштаны белән бодырдан торып барлык ихатаны кызыл әләм кебек кызарткан Канәгать, тәкате бетеп, ачык ишеккә кычкырды.

Тагын бер мисал:

Ул **сызымга** билгесен сала да,
Бөкләштереп тыга куенга.

Телебезнең сүзлек составында урын алган һөнәри лексиканың бер өлеше тарихыбызның төрле чорларында килеп кергән һәм телдә берегеп калган алынма сүзләр пластын тәшкил итә. Мондый лексемаларны өч төркемгә бүләргә була: гарәп-фарсы атамалары, рус атамалары, көнбатыш европа телләреннән кергән атамалар. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

Орлык киптерү өчен **зерноскладларым, хранилищеларым** минем болай да җитәрлек.Күпләр сөрән салган иде, имеш**, горюче-смазочные** да җитәрлек булды.Бүген авылда кулак булу өчен **посевной площадь**, **удобрение, механизация** гына җитми.

Күренгәнчә, һөнәри лексиканың күпчелек өлеше я татарның үз җирлегендә, үз сүз байлыгы хисабына ясалган, я рус һәм көнбатыш европа телләреннән кергәннәр. Гарәп-фарсы телләреннән кергән һөнәри лексика юк диярлек. Без моны шуның белән аңлатабыз: гарәп-фарсы сүзләре телебезгә Шәрекъ илләре белән багланышлар нәтиҗәсендә кергәннәр. Бу мөнәсәбәтләрнең күбесе әдәбият, мәдәният, сәнгать, дин белән бәйле. Шуңа күрә мондый сүзләр дини, мәдәни тематикага караган әсәрләрдә, мәкаләләрдә еш очрый. Әйтергә кирәк, А.Хәлим әсәрләрендә дин әһелләре лексикасы шактый еш очрый. Мәсәлән:

Аңа, **мәзин** баласына, **ислам кануннары** ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән**, Иман шарты, Коръән Кәрим сүрәләре, догалыкларны** да яхшы хәтерли, Аллага шөкер, тел дә тидертми. Карчык, без кыйбланы дөрес сайлаган булганбыз микән? – диде Гарифулла, **калушлары**н киеп, каз тәпиле намазлыгын җыештырып маташкан Өммегөлсемгә.

Мәдәният, сәнгать өлкәсендә дә гарәп-фарсы алынмалары кулланыла. Боларны язучы, музыкант, журналист профессияләре белән бәйләнештә карарга мөмкин. Мәсәлән:

Хөрмәтле **баш мөхәррир**! Күптән түгел генә архивымны актарганда, бер кулъязмага тап булдым:

Күңелләргә хуш киләсең, **Маэстро**.
Күгең – кояш, баш өсләрең
Аяз тора.

Кайбер профессионализмнар алынма сүз + татар сүзе моделе буенча ясалганнар. Мәсәлән:

Гомере буе **процент исәбенә** колхозны сауган Процент Галләм, авыл батракларыннан бердәнбер азамат, моңа алданып, “Минем үз фикерем бар!” – диеп колхоздан аерылып чыккан иде, малай.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: А.Хәлим әсәрләрендә кулланылган һөнәри лексика чыганагы буенча берничә типка карый. Күп кенә сүзләр татарның үз сүзлек хисабына барлыкка килгән, алар арасында кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр, тезмә сүзләр өстенлек итә. Гарәп-фарсы алынмалары исә бары дини лексика һәм мәдәният белән бәйле сүзләр арасында гына очрыйлар. Һөнәри лексикага караган сүзләр арасында рус алынмалары күп очрый. Алар да кушымчалау я тамырлар кушылу юлы белән ясалганнар. Кайбер сүзләр алынма көнбатыш европа сүзе + татар сүзе (кайбер вакытта – мөстәкыйль алынма сүз + ярдәмче фигыль) калыбында оешканнар.

**Әдәбият:**

Гафаров И.Ә. Болгар-Казан тарих көзгесендә. – Казан: Мәгариф, 2005. – 54 б.
Хәлим А. Колмак җыя кызлар: шигырьләр, балладалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – Б. 42 - 44.
Хәлим А. Кыйбла: Хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 278 б.
Хәлим А. Беренчеләр. Индустриаль эскизлар. – Казан: Матбугат йорты нәшр., 1998. – 35б.
Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 65.
Хәлим А. Яшисебез киләӏ: сайланма публицистика (1957 – 2008) // кереш сүз авт.Р.Бәшәр. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 596.
Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 30.

**Фатыйхова Ә. Ф.**
**Югары категорияле татар теле укытучысы**
**“49 нчы кадет мәктәбе” муниципаль автономияле**
**гомуми белем бирү учреждениесе**

## Бүгенге көн яшь шагыйрьләр иҗаты

### Кереш

**Фәнни эшнең актуальлеге**. Яшьләр иҗаты дигәндә, без яңа гасырда – XXI гасырда әдәбиятыбыз мәйданына килгән яшь каләм «ияләрен күз алдында тотабыз. Инде без яшьләр турында сөйләшәбез икән, чын дөресендә әдәбиятебезне киләчәккә тапшыручыларны барларга тиешбездер. Без яшьләргә әдәбиятыбызны нindидер биеклеккә күтәрүләренә, ана телебезне саклап калуларына өметләр баглыйбыз. Бөтен дөньяда глобальләштерү хөкем сөргәндә безнең яшьләрнең фикере, карашы нindирәк, милли хисләр, милли төсмерләр сакланамы аларның иҗатында – менә шушы сораулар безне борчый һәм кызыксындыра.

Бүгенге шигърият мәйданына килеп кергән яшь шагыйрьләр исемлегендә Рифат Сәлах, Ленар Шәйхи, Луиза Янсуар, Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһимов, Йолдыз Миннуллина, Лилия Гыйбәдуллина,Резеда Гобәева Эльвира Һадиева, Айгөл Закировалар бар. Алар барысы да бер чорда туып үсеп бүгенге көн кадагында торган мәсьәләләрне һәрберсе үзенчә хәл итәләр, тормыш чынбарлыгын үзенчә тоеп, үзенчә аңлап иҗат итәләр. Димәк, һәммәсенең үз юлы, үз карашы, үз нәтиҗәсе бар, дигән сүз.

**Максат**: Хәзерге татар шигъриятендә яшьләр иҗатын өйрәнү

Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычларны** үтәү күздә тотылды:

- фәнни эшне башкарып чыгу өчен материал туплау, анализлау, өйрәнү;
- бүгенге яшь иҗади буын тәрбияләнеп үскән чорга күзәтү ясау;
- бүгенге көндә татар шигъриятендә яшьләр тоткан иҗади урынны анализлау;
- Ленар Шәйхи иҗатына күзәтү ясау;

### Бүлек 1
### Хәзерге татар шигъриятендә яшьләр иҗаты

#### 1.1 Бүгенге яшь иҗади буын тәрбияләнеп үскән чорга күзәтү

Бүген шигърияткә төркем булып килүче яшьләрне узган гасырның 60 нчы елларында әдәбиятка килгән шагыйрьләр белән тиңләү күзәтелә. Мәсәлән, Илсөя Иксанова үзенең “Яшьләр иҗатын барлыйбыз” исемле мәкаләсендә бүгенге яшь иҗади буын вәкилләре Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһимов, Йолдыз Миннуллина, Лилия Гыйбәдуллина, Резеда Гобәева, Эльвира Һадиева, Айгөл Закировалар иҗатын анализлаганда башта “Хрущев җепшеклеге” дип тарихка кергән хәбәрдарлык, демократия нәтиҗәсендә, 60 нчы еллар да шигърият аерым бер күтәренкелек кичерүен; әдәбият мәйданына килгән бер төркем талантлы яшь шагыйрьләр - Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Мингалимнәрнең шигърияткә яңа төс биреп, аны яңа юлга алып керүе турында мәгълүмат бирә. Традицион калыплардан китеп, яңа формалар эзләү, сүз уйнату, яңа сүз әйтү омтылышы белән янып һәрберсе шигърияттә үзенең үзенчәлекле юлын тапкан татар поэзиясен яңа биеклеккә күтәргән буын бу. 70 нче елларда исә Рәшит Әхмәтҗан, Зөлфәт, М. Әгъләм, Ф. Яруллиннар буыны инде башка вәзгыятьтә - илдә партия диктатурасы, торгынлык чоры хөкем сөргән бер вакытта әдәбиятка килде.

Бүгенге яшь иҗади буын тәрбияләнеп үскән чор 80-90 нчы елларга туры килә.

Бүген шигърияткә яңа дулкын булып килеп кергән яшьләребез 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш шартларында тәрбияләнгән буын, дидек. Шуңа да аларда гражданлык позициясе һәм хөрлеккә омтылыш көчле. Илсөя Иксанова фикеренчә, милләт һәм тел язмышы турында уйланулар татар тарихында казыну – үткәннәргә кайтып, тамырларны барлау, бүгенгебез өчен җан әрнү, киләчәккә өмет-өметсезлек кебек мотив лар бөтенесенә дә диярлек яшьләребез иҗатына хас.

#### 1.2 Бүгенге татар шигъриятендә яшьләр тоткан иҗади урын

Татар поэзиясенең тема ягыннан төп үзенчәлеге шунда – милли азатлыкка омтылу,

дәүләтчелек идеясе аны беркайчан да читләтеп үтми. Хәтта шагыйрьләрнең рухи өлгергәнлеген билгеләүче бер критерий буларак та кабул ителә мондый шигырьләр. Чөнки, татар шагыйре, Тукайчарак әйтсәк, беркайчан да коеп куйган шагыйрь генә була алмый, ул публицист та, җәмәгать эшлеклесе дә. Яшь шагыйрьләребезнең иҗатында бу тема бик киң яктыртыла, хәтта кайберләрендә доминант буларак бара. Мәсәлән, Рифат Сәлах, Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһимов, Ленар Шәйхи безне, беренче чиратта, шундый шигырьләре белән җәлеп итте.

Яшьләр иҗатында яшәү һәм үлем фәлсәфәсе − экзистенциаль фәлсәфә (ялгызлык, кешенең башкалар тарафыннан тулысынча аңлана алмау проблемасы; аллегорик, символик, мифологик алымнарга мөрәҗәгать итү, тормыштагы ялгыш һәм ялганга эчке каршылык...) шактый еш очрый. Ул һәрберсендә үзенчә, яңача бирелә.

Дингә кайту, гореф-гадәт, милли традицияләрне саклау проблемаларын күтәргән, аеруча бу өлкәдәге югалтуларыбызга әрнеп язылган шигырьләрне дә яшьләр шигъриятендә уртак тема дип аерып карарга мөмкин:

Һәм, әлбәттә, яшьлеккә хас мәхәббәт, тәүге хис-тойгылар, шуңа бәйле күңел конфликтлары табигый. Бу шигырьләр хисләр ихласлыгы, көтелмәгән сурәт-тойгылар белән сокландыра.

Мәңгелек темалар −туган як, туган җир, әти-әни турында шигырьләрдә күзгә бәрелеп торган яңалык булмаса да, эчкерсез хисләр, сурәтләү чаралары хисабына алар күңелне җәлеп итә.

- Образлар системасы ягыннан караганда, күбесе өчен уртак булган образларның үзенчәлекле, үзләре тойганча үстерелеше бар. Ләкин, нигездә, болар традицион образлар. Бигрәк тә ил-халык язмышы, милли сәясәт, дин, гореф гадәт белен бәйле образлар бу: ай, ярымай, төн, җил...

Яңа образлар сирәк очрый. Бу яктан Йолдыз Миңнуллина, Лилия Гыйбадуллина, Эльвира Һадиеваларның иҗатлары аерылып тора.

- Иҗат юнәлеше, ягыннан караганда, аларның барысына да диярлек модернизм һәм постмодернизм элементлары хас. Бу аңлашыла да. Дөньяга карашлары формалашкан чор - 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш һәм аннан соң позицияләрне бирү, милли төшенкелек - әлбәттә, яшләр иҗатында киң чагылыш таба.

- Юмор-сатирага мөрәҗәгать итүчеләр яшьлар арасында да сирәк. Гамил Афзалның якташы Ленар Шәехтә генә аның беркадәр үрнәкләрен очрый. Ленарның мәхәббәт шигырьләрендә дә нечкә юмор бар:

Күзләр тонган, тамаклар ач –
Мәхшәр инде!..
Ярты көндә ярты еллык белем килде.
Хәзер дискәтүкләр белән ерак ара –
Ә син менә имтиханда биеп кара! [15;135]

Илсөя Иксанова яшь иҗатчыларга карата мондый фикерләр әйтә:

- "яшь иҗатчылар арасыннан әдәбиятта инде үзенең юлын тәгаенләгән дип Ленар Шәехне һәм Рифат Сәлахны гына санарга мөмкиндер", ди - Икесе дә традицион калыпка өстенлек бирә. Шигырьдә жанр таләпләренә буйсынып рифма-ритм кагыйдәләрен саклап иҗат итә. Аларның киләчәктә поэма жанрында үсү перспективасы да бар. Төрки-татар әдәбиятенә хас (шигъри кыйсса, дастаннар....) бу жанр шагыйренең өлгергәнлеген билгеләүче бер мисал буларак та кабул ителә. Ленар да, Рифат та әлеге жанрга мөрәҗәгать итеп карый. Ләкин Ленарның "Нәрсә әйтим?" дип аталган поэмасы жанр таләпләренә җавап бирми, аны поэма дип кабул итеп булмый. Рүзәл Мөхәммәтшинның да иҗат юлын анык күзалларга мөмкин. Аның Такташча сөйләмгә корылган шигырьләре беренче карашка, бик гади кебек. Ләкин ул укучыны мавыктырып, үзе артыннан алып китә, көтелмәгән детальләре, көтелмәгән образлары, метафоралары белән сискәндереп куя, уйландыра. Миңа аның поэтик мине тормыш тәҗрибәсе туплаган зирәк, җор телле авыл агаен хәтерләтә.

Димәк, беренче бүлекне йомгаклап, нәтиҗә ясыйбыз. Яшь шагыйрьләребез

иҗатынахас сыйфатлар:

- милли азатлыкка омтылу, дәүләтчелек идеясе;
- ялгызлык, кешенең башкалар тарафыннан тулысынча аңлана алмау проблемасы;
- дини темаларда аллаһны олылау, аннан ярдәм сорау, аңа мохтаҗлык;
- сөю хисләрен йөрәктән бигрәк акыл аша кичерү;
- туган якны ярату хисләре;
- юмор-сатирага мөрәҗәгать итүчеләр яшьләр арасында сирәк.

## Бүлек 2

## Хәзерге татар шигъриятендә иҗат итүче Ленар Шәйхи иҗаты

Ленар Шәехнең 2011 нче елда гына чыккан «Җылытасы килә дөньяны!..» исемле шигырь китабы хакында **шагыйрь, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*Зөлфәтшундый фикерләр әйтә: “*** Кулъязмасын укыйм. Китапның исеме үк минем уйларымны куәтли: Әйе, изге теләк бу, шагыйрь туганкай! Яшәгән дөньябыз җылытуга күрәләтә мохтаҗ... Язган шигырьләребез бөтен дөньяны ук бер селтәнүдә җылыта алмас, әлбәттә. Әмма ул күңелләрне җылытсын, ә күңеле җылы кешеләр дөньяны җылыта лабаса” [15;5-6]

Ленар Шәех сүзләрне ягымлы, ипле, моңлы бер шигъри тәртипкә китерә белә. Бу — чын шагыйрьлек галәмәте. Зөлфәт шулай ук, замандашларыңның (һич югы, бер замандашыңның!) җанын җылыта алгансың икән, бу гражданлык бурычыңны үтәү, дигән фикердә. Шуның өчен шигырьгә, шагыйрь иҗатына сәер таләпләр куярга ярамый, ди. Янәсе, шигырь көрәшергә тиеш! һаман: «Көрәшчеләр кирәк!» — дип кабатладык. Янәсе, шул була инде ул чын гражданлык хисе!, дип каршы чыга.[15;5]

1. Ленар Шәехка хас үзенчәлек итеп Зөлфәт моны атый: шагыйрьне борчулы, фаҗигале хәлләр дә, тарихның шомлы мәлләре дә тетрәндерә. Ләкин ул бу хакта язганда истерикага бирелми, сукранмый-сүгенми, теш шыгырдатмый. Шагыйрьнең кичерешләре ипле, алар, галибанә сүзләр булып, синең күңелеңә күчә. Һәм син шагыйрьнең тойгысын аңлавыңа куанасың:

2.Ленар Шәех затлы сөйләм серләрен белә. Көндәлек тормыш ыгы-зыгысыннан тинтерәгән күңелне затлы сөйләм сафландыра, терелтә. Чын шигырьнең бөек көче әнә шунда:

Алда еллар.. Алда озын юллар..
Ак кәгазьгә сеңгән караң күк.
Шигырь яздым сине юатырга,
Йөрәктәге тирән яраң күк.[15;99]

3. Шигырьләрендә – кеше күңеле. Монда милләт язмышы да, гашыйкның сагыш¬тан көрсенүе дә бер үк дәрәҗәдә мөһим:

4. Ленар шигырьләреннән һәркем үзенә кирәкле җан җылысын табачак. Укучының ничә яшьтә бу¬луы, аның тормыш тәҗрибәсе мөһим түгел:

Мәсәлән, һәммә кеше кичерә торган изге хисләр шигъри юллар булып тезелгән:

Кочагыма бөтен дөнья сыйган,
Күңелемә сыйган Җир шары.
Биек күге шундый зәңгәр аның,
Ә кояшы аның сап-сары.
Гаҗәп матур, шундый изге дөнья,
Керле җаның белән үрелмә!
Һәрбер сере, һәрбер могҗизасы,
Һәр бөҗәге якын күңелгә.[15;94]

5. Шигъри остазларына багышланган шигырьләре байтак (Афзал, Гәрәй, Зөлфәт, Мөдәррис Ә., Кол Гали, Мәрҗәни, Ф. Яруллин, Г.Тукай, Р.Миннуллин һ.б.); һәм күренекле шәхесләргә багышланган шигырьләре бар (Минтимер Шәймиев, Галина Казанцева,Нәҗип Газизов һ.б.)

6. Шигъри үлчәмнәргә бай: берьюллыклар, икеюллыклар, дүртюллыклар

бишьюллыклар, цикллар, халәтләр, триптихлар – бар да бар. Мәсәлән, мәхәббәт хисләрендә янган яшь шагыйрь уйлары болайрак яңгырый:

Күктән чык булып төшкән болыт “Мин” [15;63]
Бер-берсенә үралып үскән ике гөл. “Без” [15;63]

Яки:

Йөрәгем түзалмый ут өрә,
Җавапсыз мәхәббәт үтерә... [15;14]

Яки:

Син чиргә сабыштырасың,
Син терелтә аласың.
Син – Сөю фәрештәседер,
Син – Гүзәллек Алласы.[15;11]

Яки:“Җылытасы килә дөньяны» триптихын карап китик. Ул өч өлештән тора. Беренче өлеше кешенең җылы эзләп йөрүенә, бәргәләнүенә, өшүенә багышлана:

Бу дөньяга җылы эзләп килдем,
Бир син, Җиһан, җылың жәлләмә!
Болай да бит салкын.
Ялкын юктан
Гаҗизләнгән башым әйләнә.

Икенче өлештә Лирик герой барлык кешеләргә үзе җылы бирә алырга әзерлеге турында хәбәр итә һәмяфрак кадәр гомердә кеше җылы эзләп вакыт уздырмасын иде дигән фикер сызыла:

Мин үзем дә җылы бирә алам,
Тилмермәсен кеше, көтмәсен.
Яфрак хәтле гомер җылы эзләп.
Ялкын эзләп кенә үтмәсен!..

Өченче өлештә тилмереп җылы көтүчеләргә җылылык бүтән мәңге суынмаслык итеп килүенә ышанып, яшь шагыйрь теләге “Җылытасы килә дөньяны» дип яңгырый:

Яфрак кадәр гомер юкка чыкмас...
Мин ышанам ... Тоям мин аны...
Бүтән мәңге суынмаслык итеп
Җылытасы килә дөньяны![15;84]

Димәк, йомгаклап, Л.Шәехкә хас үзенчәлекләрне барлыйк:

- шагыйрьне борчулы, фаҗигале хәлләр дә, тарихның шомлы мәлләре дә тетрәндерә. Ләкин ул бу хакта язганда истерикага бирелми, сукранмый-сүгенми, теш шыгырдатмый. Шагыйрьнең кичерешләре ипле, алар, галибанә сүзләр булып, синең күңелеңә күчә, һәм син шагыйрьнең тойгысын аңлыйсың;
- сөйләме затлы;
- шигырьләрендә – кеше күңеле; монда милләт язмышы да, гашыйкның сагыш¬тан көрсенүе дә бер үк дәрәҗәдә мөһим;
- шигырьләрендә һәркем үзенә кирәкле җан җылысын таба;
-төсләрне күп куллана;
- шигъри остазларына багышланган шигырьләре байтак;
- шигъри үлчәмнәргә бай: берьюллыклар, икеюллыклар, дүртюллыклар бишьюллыклар, цикллар, халәтләр, триптихлар – бар да бар.

**Йомгак**

Гомумән, татар шигъриятенә үтә кызыклы яшь буын килә. Иҗатларына карап, киләчәктә гатар поэзиясе, традицион калыпны да аклаган хәлдә, яңа формалар белән баетыр дип гөманлап була. Ләкин нинди генә форма яңалыклары туса да, татар шигъриятенең төп үзенчәлеге сакланыр, милли үзаңны үстерүдә эстетик нигез булыр дип ышанабыз.

Л.Шәехкә хас үзенчәлекләрне барлыйк:

- шагыйрьне борчулы, фаҗигале хәлләр дә, тарихның шомлы мәлләре дә тетрәндерә.

Ләкин ул бу хакта язганда истерикага бирелми, сукранмый-сүгенми, теш шыгырдатмый. Шагыйрьнең кичерешләре ипле, алар, галибанә сүзләр булып, синең күңелеңә күчә, һәм син шагыйрьнең тойгысын аңлыйсың;

- сөйләме затлы;
- шигырьләрендә – кеше күңеле; монда милләт язмышы да, гашыйкның сагыш¬тан көрсенүе дә бер үк дәрәҗәдә мөһим;
- шигырьләрендә һәркем үзенә кирәкле җан җылысын таба;
- төсләрне күп куллана;
- шигъри остазларына багышланган шигырьләре байтак;
- шигъри үлчәмнәргә бай: берьюллыклар, икеюллыклар, дүртюллыклар бишьюллыклар, цикллар, халәтләр, триптихлар – бар да бар.

## Кулланылган әдәбият


1. Вәлиулла И. Һәр шагыйрь бер дәрья. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 207 б.
2. Зәкиев М, Сафиуллина Ф. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 225с.
3. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод.кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. –335 б.
4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман: татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.
5. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.
6. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
7. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / соавт. Т.Гыйлаҗев, Ә.Закирҗанов. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.
8. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / соавт. Т.Гыйлаҗев, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.
9. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / соавт. Т.Гыйлаҗев, Ә.Закирҗанов. – Тулыл. 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.
10. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз / соавт. М.Ибраһимов, В.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 б. – 1000 д.
11. Иксанова И. Яшьләр иҗатын барлыйбыз // Мәдәни җомга / 2010, 14 май. – Б.8.
12. Ибраһим Б.Х. Балык теле. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 160 б.
13. Мөхәммәтшин Р. Бүре мин: шигырьләр, поэмалар / Рүзәл Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 159б.
14. Шәех Л. Җылытасы килә дөньяны: шигырьләр, поэмалар / Ленар Шәех; кереш сүз авт. Зөлфәт. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2011. – 255б.